www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА. Үлмәс. *Бәян.* ....3
Рифә РАХМАН. Шигырь аша телне өйрәттем. *Шигырьләр.* ....101
Алмаз ХӘМЗИН. ...дисәң дә була. *Шаян әңгәмә.* ....105
Данис ХӘЙРУЛЛИН. Күккә бага, кулларына дога алып. *Шигырьләр.* ....119
Асия ЮНЫСОВА. Моң агыла нурлы Казаннан. *Шигырьләр.* ....128
Рәүфҗан ЗАКИРОВ. Җилкәнсез диңгезче. *Бәян-хатирә.* ....132
Әлфия СИТДЫЙКОВА. Вакыт – җитез болан. *Сонетлар.* ....149

100нче БИТ

Рәмзия ЛАТЫЙПОВА. Ана теле «Әлифба»дан башлана. ....100

«ИҢ ШӘП ХИКӘЯ» КОНКУРСЫНА

Сирень ЯКУПОВА. Уран. *Хикәя.* ....123

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Роберт МИҢНУЛЛИН. Казакъларның йөз аклыгы. ....153
Мукагали МАКАТАЕВ. Шифа эзлим җаныма, телгә – терәк. *Шигырьләр.* ....155

КӘРИМ ТИНЧУРИННЫҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

Мөхәммәтгали АРСЛАНОВ. Фидакарьлек. ....160

ЮБИЛЕЙЛАР

Зөфәр МӨХӘММӘТШИН. Рифә Рахман прозасының иҗади үзенчәлекләре. ....164

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Моң шагыйре... (*Рәмис Аймәт иҗаты турында уйланулар).* ....172

ТАРИХ

Лирон ХӘМИДУЛЛИН. Беренче мөфтиләрне биргән төбәк. ....179

«Казан утлары» архивыннан. ....158
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Данил Салихов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (баш бухгалтер)**.**

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266).*
: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*

: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.08.2017, график буенча 29.08.2017.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-2119. Тираж 4150.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2017 ел



Нәбирә
Гыйматдинова

# ҮЛМӘС

БӘЯН

**1**

...Ул тәгаен генә үзе дә белми: бусагасыннан уздырырмы, әллә ләгънәт яудыра-яудыра, куып җибәрерме? Белми, берни дә белми... Ә барыбер кайта. Ничәмә-ничә чакрымнар үтеп, каргыш ишетергә кайта. Баш аска иелгән саен иелә: мәгәр күтәрелеп караса, ир бәндәсенең ачудан чатнаган пыяла күзе бәгыренә кадала. Йә, монысына ничек тә түзәр, чөнки кире борылырга ярамый! Өмет алга әйди. Алга, алга!

Юл буе уфылдаган ир, ниһаять, «шартлады»: теленнән зәһәр агуын тамызып:

– Син такый безне адаштырдың, май чүлмәге! – дип акырды. – Кайда монда авыл?! Кругом урман! Кругом саз! Батсак – хана! Үләксәңне дә тапмаслар!

Гәрчә, дәшмәскә дип тешен кысса да, хатын әйтеп калырга ашыкты:

– Батмабыз, җир таш төсле каты...

– Синең авырлыктан тимер дә сыгыла, ништу таш! Ваня, тәгәрмәчләр чүт сытылмый!

Шофёр хуҗасыннан акыллырак иде:

– Сазлыкта черки мыжлар иде, Сәйфи Бариевич, монда аяк асты шыгырдап кипкән, – диде.

– Мужыт әле сез, бу урман да тегел, кыр диярсез, акыш-макышлар!

– Куактан азган урман анысы, Сәйфи Бариевич.

– Тормозга бас!

– Ник, Сәйфи Бариевич?

– Тирә-якны караштырыйк, миңгерәү! Без точно адаштык! Караңгыга тиклем моннан үкчә җалтыратырга кирәк. Черки жук тек, бүре до черта!

Кара джип корыган агач ботакларын изә-сыта туктагач, ирләр җиргә сикерде. Аңа да әзрәк кымшанасы иде. Утыра-утыра аяклар шар кебек өрелеп шеште. Әмма хатын сынын кузгата алмады. Аннары ул машина ишегенә яны белән генә сыя, тыштан берәрсе булышмаса, кысылып калачак иде. Урман һавасы белән борынга әллә нинди таныш ис бәрелде... Көлдә бәрәңге күмеп пешергәндә генә

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА – *прозаик. «Мәхәббәттә гөнаһ бар», «Икебезгә дә авыр», «Үзем генә беләм», «Сөйлим, тыңла» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

шундый татлы көйгән ис тарала лабаса! Димәк, ул беркемне дә адаштырмады: әнә теге куерып тыгызланган агач-куак артында тереклек бар! Бәлки, анда аның туган авылыдыр, ә? Ике араны шушы яшеллек дәрьясы гына бүләдер?

Ир бәндәсе киресенә катып сәфәрне өзгән тәкъдирдә, шул якка үрмәләргә әзер булып, хатын ишеккә табан янтайды. Тик фәрман белән дәрман икесе ике нәрсә иде: ул таш белән бастырган төсле, ярты сүәмгә дә урыныннан купмады. Ирләр, әйтерсең, аяк белән таптап юл сала, озакладылар. Авылдан чакрым ераклыктагы урман элек мондый ук караңгы чытырман түгел, каены, имәне, усагы тәртип белән генә үсә иде. Әзме качышлы уйнады бала-чага шунда, әзме бөрлегән чемләде. Ә тирә-юнь яп-якты: гүя кояшның алтынсу нурлары җәлпәк яфраклардан гына коела иде.

Хатын чәчелгән уйларын бер төенгә төйнәп, «уф!» дигәндә генә, машина «мөгезе» белән «сөзгән» чикләвек куагы селкенеп, ботакларын сарган колмак үләненең алкалары биешә башлады. Кемдер куак артына поскан иде. Әнә, аның гыж-гыж сулаганына кадәр ишетелә! Җиңел-җилпе Минап шаяра! Куркыта, янәсе.

Ләкин шофёр белән Сәйфи бөтенләй башка җирдән – уң яктан килеп чыккач, хатын өнсез калды. Ә анда кем соң алайса, кем?

– Әнә тегендә... Чикләвек куагы артында нииндидер кеше! – дип, ул тавышын калтыратып кычкырган иде, Минап, гәүдәсен урталай сындырып көлде:

– Һи, һи, сеңел, саташма! Мондый чытыр-мытырда нинди җүләр йөрсен!

– Без җөрибез, ватый! Безнең иркә бикәбез маҗара тансыклаган! – Ир, йөзендәге канәгать елмаю битлеген салып, сырт йонын кабарткан иде, шофёр аны тиз генә уңайга сыпырды:

– Алай бик ватылмадык инде үзе, Сәйфи Бариевич. Сезнеке кебек шәп машинага җиде йөз чакрым пүчтәк ул! Рульне ничек боргалаганымны тоймадым да мин!

– Җумалама, карт хөрәсән! Артка чиген давай. Анау теге уң җакта бер морҗадан төтен ургый. Аучылар җортыдыр. Тавык тәпиле ызбада җәшәгән убырлы карчык турында нидер әйтерләр мужытсы. Җанган үкчә, сызлаган буыннар өчен түләү итеп поши да атарбыз, ха-ха!

– Әй, юк белән мәшәкатьләнмик, Сәйфи Бариевич! Ризык хайванымыни поши. Пешерсәң – шулпасы әче, ди. Ите дә чәер кебек, ди.

– Ыспурлашма, надан! Поши ите кыздырырга якшы. Серкә, тоз, төрле тәмләткечләр белән җебетеп өч-дүрт сәгать тотсаң – авызда эри!

Кайнар мичкә тыктылармыни, хатынның тәне бөршәйде. Ишегалдындагы канлы эзләрне әле дә яңгыр юмагандыр, әле дә... Әй балачак, балачак! Күпме гомер хәтер дәфтәрендәге тапларны сөрттермисең бит син. Инде тагын берәүсе хайван рәнҗетмәкче... Ул «тимә!» дип, алгы утыргычка ишелгән иренең чәчен умырмакчы иде, машина кисәк кенә артка чигенде дә, терсәге ишек тоткасына бәрелде. Күзен яшь элпәсе каплады. Сөяге чатнап авыртканнан түгел, чарасызлык елата иде. Аның хәзер бу дөньяда бернәрсәне дә үзгәртерлек көче юк микәнни?! Ул бары тик кол кебек буйсынырга гына тиешме?! Кайда хатынның гайрәтле чаклары?! Әгәр дә мәгәр пыскып кына янган соңгы чырагы да сүнсә – яшәүнең ни кызыгы!

Чынлап та, тереклек бар дип искәрткәндәй, уң якта ат юлы сызылган, тик ул яшь үлән белән капланып беткән иде. Хатын инде кай тарафтан сыек кына төтен бөркелгәнен дә күрде. Шәт, юл туп-туры шунда табан илтер. Шәт, агач-куакка «төренгән» туган авылы да шушы тирәдәдер...

Баядан бирле кыбырсыган ир бәндәсе шофёрның кулына сукты:

– Ачтан үләм, туктале, Минап. Син берәр нәстә тыктыңмы?

– Казылык, әпәй һәрчак тартмада минем, Сәйфи Бариевич.

– Арытты, черки сытарлык та хәл җук, ниушто поши гөпелдәтергә.

– Соң, капкалыйк, әйдәме, Сәйфи Бариевич. Ач кешенең ачуы яман, дигән борынгылар.

– Синең карының ачтымы суң, майбикә? – Ир бәндәсе борылып хатынны үчекләде.

Әй, тамактан валчык та үтмәс иде. Аның йөрәге дөп-дөп типте, сулышы эчтә кайнарланып, иренен көйдерде. Авыл якын! Бөтен вөҗүде белән тоя, якы-ы-ын!

Ә Сәйфи, мәрхәмәте уянып:

– Ашамасаң – ашама, чеметем генә һава сула, атусә җан тәслим кылырсың, – дигәч, хатын киреләнмәде. Ирләр аны утыргычтан суырып алып җиргә бастырганда, тез буыны йомшарып, ул аска сыгылды.

– Әйдәме, сеңелне каенга терәтәбез, Сәйфи Бариевич, – диде Минап.

– Каенны аудара бит ул!

Айгыр төсле кешнәгән ирнең үртәвеннән гарьләнмәде хатын. Эш үртәлүләрдән узган иде шул... Икәү капот өстендә табын корганда, ул дүртаякланып торып басты, чайкала-чайкала нәзек каенга килеп сөялде. Кайчандыр хатын да шушы агач кебек зифа иде, сылу иде. Биш былтыр гынамы, ун былтыр элек. Ул хәзер һәр яшәлгән елларын өчкә тапкырлый, чөнки аның һәрберсе газап белән тамгалана. Һай, бу көн белән төннең озынлыгы! Тәүлек, күн төсле, тартылган саен тартыла. Ахырзаманда вакыт су кебек ага, имеш. Күрәсең, мәхшәр кубасы көннәр ерак, бик ерак әле.

– Сеңел, әз-мәз чәйнәштер. – Минап абзый аңа ипи кисәге сузды.

– Рәхмәт, мин тук, – диде хатын, аңарда ашау хәсрәте юк иде. Йөрәк һаман дөп-дөп бәреп колагын шаулатты. Кул сузымында гына аның авылы... Кайчандыр үзе үк каһәрләгән аймагына дәва эзләп кайтырмын дип, ул уена да китермәгән иде. Авылдашлары аларның нигезен көл иткәч, һәм дә этисе шунда...

– Нәстә мәлҗерәдең? – Аяк өсте генә казылык белән ипи умырган ир бәндәсе аның йөзенә шешәдән су бөркеде. – Үлмә тагы, җәфа!

Бу каен сихәтләндерә микән әллә, хатын үзендә нәни генә үзгәреш сизгәндәй булды. Сәйфи белән ярты кәлимә дә алышмаска дип юлга кузгалганда ук теленә йозак салган иде ул, ә хәзер үзалдына шуның биге ачылды:

– Мин сиңа Минап абзый белән генә барам, дидем, Сәйфи! Чакрым саен битәрләгәч, нишләп безгә тагылдың?!

– Һо-һо! Сиңа кем ышанган ди, кадерле катынкаем! Мужытсы син, мине җәтим ясап, чит илгә кыякларсың. Махсус очкыч җаллап. Упшый самолётка утыртмаслар сине, күктән мәтәлербез дип шикләнерләр. Биш филдән дә авыррак син, катынкаем. Валлаһ, дим! – Ир бәндәсе, кул арты белән авызын сөрткәч, гыр-гыр кикерде дә, үпкәләгән тавыш белән: – Ит җакшылык, көт җаманлык, – диде. – Кайгыртуың өчен рәхмәт, Сәйфи, димисең, ватый. Машинада бөкләнеп бара-бара бил катты, муен кәкрәйде, ә син, ватый, нервыны кытыклыйсың. Минап, давай, май чүлмәген урынына шудырыйк! Кил, катынкаем!

– Сабыр, Сәйфи Бариевич, безнең арт көпчәк тишелгән бит!

– Мин куян куган арада тиз генә рәтлә, едрит-кудрит, – дип, ир бәндәсе сүгенә-сүгенә куаклыкка таба атлады.

Минап ах-вах килеп тәгәрмәч алыштырганда:

– Әшәке җан син, Сәйфи, ватый, – диде. – Утырган җирендә артыңны елан чаксын! Пинсәгә тагы ике ел, шуннан соң төкерәм мин сиңа, Сәйфи, ватый. Без

аның белән авылдашлар, сеңел. Аның атасы Сергач якларыннан өйләнеп кайткан. Анасы Айшәттәйнең сөйләме үзгә иде. Мин дә мишәр дип мактана Сәйфи, ике сүз ятлаган да. Өчне ятлар иде, башында чүбек. Ямаулы ыштан кигән хәерче малае сиңа өйләнеп баеды, сеңел, иеме? Ялкау ятыр, бәхете артыр, диләр картлар.

Куаклыктан ялтырап ир бәндәсе чыккач, шофёрның «җыры» үзгәрде:

– Син, әйдәме, сеңел, мондый кайгыртучың барына сөен! Катын-кыз өчен Сәйфи Бариевич төсле борчылган ирләр сирәк, сеңел. Зифа апагызны шулай иркәләсәмме? Аягымны юып, суын эчә, билләһи! Маладис кеше безнең Сәйфи Бариевич!

– Көн кичкә авышты, давай җәтрәк эшлә, Минап! – дип әмер бирде ир бәндәсе. – Мине ни мактагыз, ни җаманлагыз – мыек очым да селкенми.

...Әйе, әле үзе дә юньләп тамыр ныгытмаган каен баласы ниндидер тылсымга ия кебек иде. «Көч-дәртеңне миңа да күчер», – дигәндәй, хатын тагын да җайлабрак аңа сыенмакчы иде, Сәйфи җиңеннән йолкыды:

– Син дә кымшан! Иту ыргытырмын да китәрмен бүреләргә азык итеп. Нужартып җәһәннәм читенә җөртәсең! Минап, давай, тауарны күтәреш!

Эткәли-төрткәли хатынны машинага керттеләр. Ул бәләкәй сумкасын итәгенә куймакчы иде, ир бәндәсе бавыннан эләктерде:

– Җул буе букчаңны кочакладың, ватый! Нәстә җәшердең? Шик уянды миндә, ватый. Нукы, бир! – Йонлач кул сумканы бутый башлады. – Мин сиңа алтын-көмеш әрбирләреңне алма, җугалтырсың, хәсрәт, дидем. Ызначит, тыңламадың, катынкаем. Нәстә бу, нәстә? – Ир бармагына ураган муенсаны әйләндерә-тулгандыра тикшерде. – Карале, Минап, сихыр-михыр кулланмасы тегелме?

– Аллам, ник шаккаттың? Муенса инде, Сәйфи Бариевич. Яшь чакта безнең әниләр ат каштаны чикләвеген энә белән тишеп җепкә тезәләр иде.

– Синең анаң – авыл катыны, кәҗә бугын киптереп асса да шаккатмам! Ә минем бичәгә моның ни хаҗәте? Үдә тартма-тартма берлиант, муеныңа катлап-катлап так!

– Бир, бир! – диде хатын, өзгәләнеп, ләкин ир тыңламады, җирәнгән кыяфәт ясап, муенсаны куаклар арасына болгап атты.

**2**

– Чоланны җыештыр, кем кыз. Ару мендәр-юрган хәстәрлә!

– Бәй, без ике бөртек җан, кайсыбыз ызбага сыймый, җиңги?

– Аңа аерым урын-җир кирәк!

– Бәй, кунак-мазар мәллә? Ызба иркен, өч ятак, җиңги. Бер кичкә – кер мичкә, ди.

– Кушканны үтә, Миңсылу!

Карчык тәрәзә пәрдәсен кырыйга этәрде. Ничек кенә чекерәйсәң дә, күзең белән дөньяны иңләрлек түгел, офыкка кадәр агач-куак томалаган иде. Бу – Аллаһ кодрәте. Бары тик аныкы... Бөек зат түшәгән язмыш сукмагыннан берәү дә читкә тайпыла алмый. Ат ярышларында дала җиле белән узышкан кыз бала ят туфракка орлык булып күмелермен дип бер уйласа икән! Гыйшкы тилертте, гыйшкы... Мөгаллим җегеткә шул ияртте. Беренче мәлләрдә иренең аймагы шыксыз тоелды. Мондагы тарлыктан җан кысылды. Югыйсә ике чакрымдагы урман белән Айтуган авылын ул чакта әле кыр-басулар аерып тора, әмма яшь киленгә барыбер кысан иде. Ул иркен даласын сагынып көн-төн сыктады. Һай, вакыт барысын да көйли икән: яши-яши туып-үскән илләр хәтердән сөртелде, җан әкрен генә шушы җиргә беректе. Еллар гына рәхимсез иде, хәләленең болай да бәләкәй авылын картайтып, зиратын зурайтты. Балта-пычкы кайрардай ир заты азайгач, чакрымдагы әрсез урман, тамыр җәя-җәя, киңәеп, агач-куак явы йортларга табан шуышты һәм тирә-якны яшел дәрья күмде.

– Без кемнәрне көтәбез соң? Кеше түгел, безгә каргалар да сәлам бирми ләса. Пләмәштән гайре. Оныттылар сине, җиңги.

– Күп тәтелдәмә, телеңә тилчә чыгар!

– Чыкмагае ни! Нәрсә тәтелдәдем әле шулхәтле? Сорадым нибарысы. Өч көн инде сәер генә йөренәсең. Уеңнан уелган сымак син, җиңги? Кем инде ул кунак дигәнең?

– Япма, ызба караңгылана, – дип, карчык тәрәзә пәрдәсен бөтәрләп бау белән бәйләде.

– Моңарчы гел дә ябык иде ләса, Ходаем! И, хәбәремне әйтми торам икән. Бистәдә йорт саталар. Нарат бүрәнәдән. Җүн генә бәягә. Хикмәт инде: гүпчим дә заманча, ди. Газ белән ягыла, ди. Суына тиклем ызбада, ди. Җәннәт почмагы ди, җиңги.

Түрдә сиртмәле караватка барып утыргач, беренче тапкыр күргәндәй, каенсеңлесенә текәлде ул. Эшсез аптырый... Шуңа күңеле уйный... Дару үләннәре җыярга иртәрәк. Әлегә сүрән май кояшы кайнар нуры белән кыр тычканнарының бәвелен киптергәч кенә, табигать дәвасын өзәргә була... Быел арырак китәрләр. Бу тирәләрдә алан-болыннар сирәгәйде. Ачкүз урман ачык урыннарга гаскәр кеби әрсез усак малайлары бастыра...

Карчык үзалдына елмайды да:

– Алай яңа ызба дип дәртләнсәң, күчсәнә, кем кыз, – диде.

– Икәү күченәбез, сине ялгызың гына калдырмыйм, җиңги.

– Мин ялгыз түгел, мин Кодрәтле Зат карамагында!

– Анысы шулайдыр да. Карилегең турында уйла. Туксан казык кактың ласа, җиңги. Әзмени, Ходаем!

Каенсеңелнең эчендә терекөмеш «йөгерә», ул юк эшен бар итеп өстәл сөртә, артсыз урындыкларның җәймәсен төзәтә иде.

– Сора! – диде карчык. – И азапланасың да, бахыр.

– Җиңги, минем исәнлек тә чамалы инде. Үлсәм – үкенечкә калыр. – Миңсылу бармагын угалады. Йөзе кызарып, күзе яшьләнде. – Рәхмәт, әгәр син шифасын тапмасаң, аягым чери иде инде. Чатан-патан инде мин. Хуҗалыкта нәрсәдер майтарырга ярыйм инде алай да. Менә син Алланың һәр бирмеш атнасы диярлек утарга барасың. Мәрхүм малаең Рәшит исән чакта да, хәзер оныгың Фәрит янына да. Анда бер-бер якының бар мәллә, җиңги, ә? Япь-яшь ир синең төенчеккә төйнәгән ризыгыңа мохтаҗмыни инде! Үзе безгә әйбер ташый әнә. Эчемне күптермә, зинһар, әйт, кем ул, җиңги?

Каенсеңелнең баш түбәсенә баса-баса төпченүе ачуын китерсә дә, карчык күтәрелеп бәрелмәде. Һе, кара син моны, кара! Җитмеш җиде кадак суккан сандык капкачын җиңел генә каерып ачтырмакчы! Ни белсәң, шуңа разый бул!

– Син, кем кыз, биләмәдәге Сәмүшне хәтерлисеңдер, шәт? – Ул караватында тирбәлеп алды. Тимер сиртмә «җырлый-җырлый» шыгырдады.

– Теге чырае ямьшек кап-кара абзыйнымы? Үз гүмеремдә бер күрдем, анда да шәүләсен генә. Син аны карендәшем, безнең яклардан, Рәшит җәйлеккә яллады, дигән идең. Моңа байтак ел ласа. Бәй, нишләп ул үзенә кайтып китмәде соң, җиңги?

– Минем сымак шушы илкәйләрне яратты. Аңа минем дәвам килеште, күзе хәйран яхшырды, Аллаһның рәхмәте. Күрә карау иде Сәмүш.

– Һи, илкәйләрне яраткан, имеш. Знамы, ярата! Ашау байдан, үлем Ходайдан! Нишләп син картаймыш көнеңдә дә аны тәрбиялисең? – диде Миңсылу, тавышына битәр өстәп. – Аңа ашарга илтәсең син! Вәт тәмле тамак! Җитәр, җиңги, утар юлыннан өзел!

Монысы инде артык, монысы инде чамасыз узыну иде. Карчыкның чырае җимерелде.

– Мине өйрәтмә, кем кыз! – дип, ул катырак «тирбәлгән» иде, караватның сиртмәсе идәнгә кадәр чумды.

– Йа, пыр тузмасана, җиңги! Йөри күр соң! – Каенсеңел аның мизгел эчендә бишкә төрләнгәнен белә иде, шуңа күрә тиз генә чыгып тайды. Карчык берара күзен йомып оеп утырды. Ул тары бөртеге сыман чәчелгән, аңа җыелырга кирәк иде. Күңеленнән генә кортка оныгына эндәште:

– Бәбкәчем, син хәзергесендә урман буйлыйсың. Биләмәңне барлавыңдыр. Читләтеп үт, бәбкәчем, Зур әнкәңә сугылма хәзергесендә.

Аннан соң уй утарга «очты»:

– Син дә, Сәмүш, тыпырчынма. Үткәнеңдә казынасың да казынасың. Аяк-кулыңны бәйләмәсәм дә – ирегеңне чикләдем. Үзең шуңа канәгать идең, Сәмүш. Монаусы өчен Аллаһ кичерер мине, ялганым хәтәр ялган, бусы кичерелмәс, сөякләремә тиклем тетелеп тәмуг утында янар. Вәләкин хаклыкны ирештермәм барыбер! Җәза иде ул сиңа! Шул-лай, Сәмүш, җанымның бер нүешендәге ак савытта – изгелегем, икенче нүешендәге кара савытта – явызлыгым тум-тулы. Кем кайсына лаек, аңа шунсын сиптем. Мин генә сөйлим, син дәшмә, Сәмүш атына ия Аллаһ колы! Миңа мырлама, ата мәче! Сез – адәмнәр кылган золым җир-күкләрне иңрәтә. Шул җөмләдән синеке дә, Сәмүш. Минме? Мин дә гөнаһлы. Шул ки, Ахырзаманда сиңа да, миңа да Ләүхел Мәхфүз кыйтабын сул җилкәдән бирерләр.

Карчык, урыныннан төшеп, озынча өстәлгә иелде. Тышы саргайган китап битләрен актарып, авыз эченнән мытыр-мытыр укыгач:

– Сигез ишек булыр, шуның җидесе ачылыр да ябылыр, соңгысы кыямәт көненә тиклем ябылмас, ачык торыр, улсы тәүбә ишеге, аң булыгыз, – диде. – Миңсылу!

Чалыш аягын чыш-чыш идәнгә ышкып, каенсеңел керде.

– Чоланны әрчедем, җиңги. Шуны әйтмәкче идем дә, кычкырып-кычкырып кемнедер тиргәдең, анык кына ишетелми калын имән ишек аша, эһем, – дип елмайган хатын алдында карчык, өс-башын каккалап:

– Ак киндер күлмәгемне киям, монсын юмакка куй, – диде.

– Иртән генә алмаштырдың, чип-чиста бит, җиңги! Әнәгенәк, сары җирлеккә сибелгән чәпәк-чәпәк кызыл чәчәкләре ут яна! Әй, акаймасана миңа, җиңги. Киндере бәләкләнгән килеш сандыкта ята. Сорысы да шунда. Анысын байтактан кимисең тагы.

– Җәтрәк йөр, Миңсылу. Көттермә! Пичтә тәгәрәткән бәрәңгеләрең күмерләнмәсен! Онытма!

Ак төстәгесен кисен әле, агын... Күңел шулай тели. Тик аң төпкеленә яшеренгән бер сөаль генә сискәндереп-сискәндереп җибәрә.

«Йа, савытыңдагы кара буяуны кайчан тамчысына кадәр түгәсең дә, шуңа изгелек кенә салып, «мәңгелек йорт»ыңа китәсең, кортка? Гомернең туксан казыгы әзер... Туксан беренчесен кагып та җитешмәссең, бәлки».

Юу-ук, савытны бушатмыйм! Әз дә түгел, күп тә түгел, адәмнең эшәкелеге кадәр генә аның карасы...

Карчык киндер күлмәгенә яраклаштырып ак яулык бөркәнде. Ул капка төбенә чыкканда, зур гына борынлы машина, юлга авышкан агач ботакларын үгез кебек «сөзә-сөзә», аларга табан якынлаша иде.

Хуҗабикә, киртә коргандай, кулын алга сузып, бармакларын тырпайтты.

– Ары китеш жук!

Ике ир-ат, машинадан төшеп, аның янына килде.

– Сәлам, әбекәй, – диде тәбәнәк буйлысы. – Адаштык без, әйеме, Сәйфи Бариевич? Урман да урман. Шушы якларда, имештер, бер өшкерүче-төчкерүче карчык бар, ди. Кулы белән сыпырса, чирең бетә, ди. Аны эзлибез. Авылы моннан ерак микән, әбекәй?

– Якын. Синнән ике адым гына. Ни йомыш, адәм балалары?

«Ни йомыш? Моңа җавап кирәк идемени? Зарыгып көтмәсә дә, кайтты... Ул нәсел утта янмый, суда батмый...»

– Син үзең мәллә, әбекәй? – дип гаҗәпләнгән «тәбәнәк буй»га тәкәббер кыяфәтле ир-ат:

– Багажниктан әйберләрне ал, Минап! – диде.

– Туктале, Сәйфи Бариевич, кая соң монда авыл?

– Чуртымамы сиңа ул? Ватый ни йомыш, дир, әби. Тучны үзе, тучны. Ваня, май чүлмәге баш селки, таныды, ызначыт. Давай, башта аны ызбага кертеп ыргытыйк!

Карчык тагын уң кулының бармагын тырпайтты:

– Аяксыз шуышыр, аяклы атлар!

Аның бу «тапкырлыгы»ннан ирләр шаркылдап көлгән иде, карчык карашы белән икесен дә өтеп алды. Тәбәнәк буйлысы, авызы пешкәндәй, өф-өф өргәләп:

– И әбекәй, сеңел бик симерде шул. Аягына гүпчим дә басалмый, – дисә дә, хуҗабикә катгый иде:

– Әйткәнне тыңлагыз!

– Әй, син! – Тәкәббер кыяфәтлесе йодрыгы белән машинаның борынына сукты. – Ишеттеңме, катын? Хәзер без түшкәңне тышка сөйрибез, шуннан соң син үзең тәпилисең, дир, ваня, бөкре җен!

Борын астыннан гына мыгырданган ирнең сүзләрен урман җиле һәр хәрефенә кадәр колагына ирештерсә дә, «бөкре җен» кушаматына илтифат итмәде. Һәр җирдә борынын тыккан Миңсылу, күзе кояш нурында чагыламыни, кулын каш өстенә «кадаклап», саескан төсле чыркылдый иде:

– Бәй, җиңги, йортка көтүе белән ышпана кертәсеңмени?! Ку, җиңги, ку бу нәмәстәләрне! Атышып бер-берсен яралаганнар икән, бүлнистә дәвалансыннар!

Җиңги кеше каенсеңлесенең белгеннән йомшак кына чемется:

– Шыпырт, кем кыз!

Ирләр ахылдый-ухылдый машинадан бөтенләй чит-ят хатынны сөйрәгәндә, карчыкның гәүдәсе кечерәеп җиргә сеңә язды. «Ничәмә-ничә көннәр аңа ялварган зифа буйлы, нечкә билле, озын толымлы кыз бала түгел лә бу. Чәчен кыркыган нинидер марҗа! Йа күкләр, җир-сулар падишаһы! Син, ахры, күңелемдәге тою-тоемлауларымны киметтең. Адәмне сихәтләндерү сәләте синең бүләгең иде, җитәр, азынма, дисеңдер. Туксан тугыз исемең белән җанымны нурландырган газиз Аллаһым, сиңа гына буйсынган мин колың, кул-аягымны богаулап газап зинданына яптыртсаң да карышмам. И Әхәдем, и Сәмәдем!»

– Күземнән югалыгыз, югал! Мин сезне көтмәдем! Сез миңа ялгыш юл саптыгыз! – дип, ул, тавык сыман пырхылдап, капкага чигенгәндә генә зәгыйфь тавыш:

– Үлмәс әби-и, – диде. – Үлмәс әби...

Карчык егылмас өчен каенсеңлесенә таянды. Йа Аллаһым, кем аның атын ятларга ирештергән?! Үлмәс ул, хак, Үлмәс... Тик бу исем хәләле белән ияреп кайтмады, бу исем кылганнарга сарылып мәңгегә далада калды...

– Кем ди теге калын хатын сиңа, җиңги? Кем ди? – Миңсылуның күзе шарланган иде.

– Сорама, кем кыз! – диде карчык, дерелдәгән ияген сыпырып. – Төшләнә, бахыр.

– Бәй, тиле-миле микәнни? Фу, нинди генә зәхмәтләр ташымыйлар үзеңә, җиңги!

Җебеп торса, гайрәт сүнә иде, шуңа күрә ул тиз-тиз генә:

– Гөлҗиһан, кунагым бул, ызбага кер, – диде. – Сез икәвегез китегез, кит! – диде.

Тәкәббер кыяфәтле ир, хатынны ычкындырып, аңа ташланды:

– Ник безне куасың, бөкре җен?! Приказ бирмә монда! Давай, әфсенләтөфсенлә и живо терелт минем катынны! Сиңа өч сәгәт вакыт, иту... – Ул түш кесәсен капшады. – ...корал, ватый үзебездә!

**3**

Үкчәсен меңәрләгән энә чәнчеде, һәм авырту, кан тамырларын куырып, йөрәккә сикерде. Басып булмый! Карчык аны юри үрти, югыйсә гарип икәнен күрә. Бая гына: «Корал, ватый үзебездә», – дип этәчләнгән ир бәндәсе буш капчык төсле карчыкның алдына «ишелде». Атларга кирәк! Бер сүәм, ике сүәм, өч сүәм... Әнә күк йөзе дә аның белән бергә чайкала... Әнә урман зыр-зыр әйләнә... Агачлар тамырыннан кубып, аңа табан егыла... Нәрсә дип мескенләнә инде Сәйфи?!

– Әбиҗан, катынкаемны терелтмәсәң – хана миңа! Хана, әбиҗан. Аңардан башка җәшәүемнең кызыгы җук, ватый. Катыныма мәхәббәтем көчле минем, әбиҗан. Акчасын түлим, күпме сорасаң да – итәгеңә салам, тучны, әбиҗан!

Авыртудан сыкранган хатынны йомшак каз каурые белән сыйпадылармыни, ул сөенеп куйды. Ир дигәнең аның турында чынлап кайгырта икән лә! Тупаслыгы тышкы кабык кына, күңелендә исә ярату белән мөлдерәмә тулы сөю касәсе икән! Кайчакта чайпалып әзрәк түгелә дә икән ул... Бәлки, Сәйфинең каты бәгырьле кешегә әйләнүендә Гөлҗиһан үзе дә гаепледер? Бәлки, көннәрдән бер көнне мәхәббәт йөрәк капкасын шакыр да иде, зур күзле хәтер ирек бирмәде. Чая-шук үсмер кыз белән яшәмәс борын яшәп арган күңелсез хатын арасында тамчы да уртаклык юк иде. Ләкин хәтер күзе бәгырьләрне телде: ул еллар аша үрелеп караган саен, үзәк өзелә иде. Карчык:

– Әбиҗан, ишегалдыңа тау итеп алтын үәм, тулкы катынымны терелт, – дип сайраган ирнең баш түбәсенә аркылы-торкылы сызыклар сызгандай хәрәкәт ясап:

– Миңа юмаланма, бәндәм! Вакыты да, шифасы да Ходайдан, әүвәлендә маңгаеңны орып син аңарга инәл, – диде. – Урман саргаер, үлән-яфрак саргаер, шунда катыныңны алмакка кил! Хәзергә хушың, хуш!

– Әттәгенәсе! Ярты елдан соң гына апкитәбезме сеңелне, Сәйфи Бариевич! – дип, Минап та сүз кыстырды.

– Шулай дир, да, тучны! Ватый бөкре җен!

Хатынның исә үз мәшәкате: белекче гүя ике арага үтә күренмәле җеп сузган да, ул, шуңа тотына-тотына, җил капкага табан теркелди иде. Яна үкчәсе, яна! Аның ялкыны май кояшында изрәгән чирәмне көйдерә төсле. Егылмаска иде, ничек тә егылмаска!

Бернинди ярдәмчесез генә селкенгән хатынны күзәткән ирләрнең күзе маңгаена тәгәрәде:

– Сыйраклары хутланды, ватый! – Ир бәндәсе әллә шатлана, әллә мыскыллап көлә иде, хатын аңламады, үрдәк сыман уңга-сулга чайкалып ишегалдына керде. Бу иске генә йорт аңа бик-бик таныш иде. Авыл кырыендагы иң соңгы хуҗалык... Ул ниндидер бер моңсулык белән буявының төсе уңган тәрәзә йөзлегенә, ярымай сурәте уелган өй кыегына карады. Киң такталы баскыч кына шүрләтә иде. Менә иң хәтәр киртә кайда икән! Ничек шуннан камыр төсле йомшарган гәүдәңне күтәреп менмәк кирәк! Хатын, булышыгыз, дигәндәй артына борылмакчы иде, карчыкның тавышы, әйтерсең, үткен пычак, аркасын «кисте»:

– Кешегә салынма, үзең хәрәкәтлән! Кем кыз, кунакка урынын күрсәт!

Тыз-быз йөгергән Миңсылу ишекне ачты да:

– Әйдә, әйдә, тутый кош! – дип куәтләде. – Моның тиклем симермәсәң! Зур коштабактан ашагансыңдыр, зур кашык белән кабып! И шушы шәһәр хатыннары! Бүксәләрендә катлам-катлам май гына!

Баскычның һәр бүлемтегә текә тауга тиң иде. Гөбедәй өрелеп шешкән тезләр бөгелмәгәч, аяклар әз генә кыек бассаң да, аска мәтәлдерә иде. Менә хатын соңгы үрне «яулады».

– Ну төлке! Ну хәйләкәр бичә! Җүри-марый бездән ташытты! Ваня, җилдертте, ваня! – дип, тышта ир бәндәсе пырылдаганда, ул инде чоландагы сәкегә ауган иде. Бермәлгә кояш сүндемени, күз аллары караңгыланды, тын алуы авырлашты, сулышы кысылды. Үлә, ахрысы, үлә... Гомере чикләнгәндә, адәм баласын кендек каны тамган туфрагы тартыр, ди. Тартты... Авылы монда, аны урман гына чолмаган...

Ишегалдындагы мәхшәр иске мәетне дә терелтер иде: чылбырга бәйләнгән этмени, ир бәндәсе һау-һау «өрә» дә «өрә» иде. Хатын такта диварны шакылдатмакчы иде, оеган кулы язылмады.

– Давай, срокны кыскарт, бөкре җен! Ничә көндә катынкаемның маен эретәсең? «Япрак саргайгач», дир, кара син! Биш ай бичәсез җәшәргә дурак тегел без!

– Сәйфи Бариевич, чү, син алай ярсыма, – дип, Минап хуҗасын җайларга кереште. – Моның ише әби-чәби белән иплəп кенә сөйләшергә инде, Сәйфи Бариевич! Корал, дисең, атам, дисең, ни пычагыма батыраясыңдыр. Әфсенләп тараканга әйләндерсә – бетте баш, Сәйфи Бариевич! Ярыкка чумабыз бит!

– Син дә канымны кыздырма, бүкән!

– Кызма, Сәйфи Бариевич. Азагын уйла. Безнең бит әле киредән карурманнар ерасы була. Әгәр әбиең дүрт тәгәрмәчне дә тиштертсә, ә? Куак саен берәр җен бастырса, ә? Адаш та үл, Сәйфи Бариевич!

– Җә, җә, җылак! Бөкре карчыктан шөлләп ыштан төбеңне җүешләт, ваня! – дисә дә, ир бәндәсе басылды. Аның кеше белән аралашу алымы ике төрле: ул үзеннән көчсезләргә яный, ә җиңәрлек көче бетсә – ялагайлана иде. Урамда исә әлеге тамаша икенче формада дәвам итте.

– Әбиҗан, ачуланма миңа, җәме? Дуслашыйк без синең белән, әбиҗан. Улың төслек күр син мине. Тәмле чәйләр китерермен үзеңә, тартмасына фил рәсеме чәпәгәнен, – дип юмаласа да, карчык эремәде. Ул каткан таш кебек иде. Йә инде, йә, әз генә йомшар, кортка! Сәйфи хатыным дип өзгәләнә ләбаса! Аны тынычландырып, көйләп-чөйләп озат! Сабыр ит, бичәң терелер дип өметләндер!

– Син катыныңа йөрәк белән якынаймаган! – Карчык гүя ачу куыгы, сүз саен шартлый иде. – Җиде ят син аңа!

– Ха-ха! – Ир бәндәсе башын артка чөеп шаркылдады. – Ха-ха! Ватый, Хуҗа Насретдин мәзәге! Көл, Минап, торма монда чинап!

– Берни дә төшенмим әле, Сәйфи Бариевич.

– Төшенмә, син печкән үгезгә ни салам, ни печән! Күшәргә генә булсын! Әбиең, ваня, Джиганга мин җиде җат, дир.

– Китик без, Сәйфи Бариевич. Күктә болытлар куера. Яңгыр яуса, урман юлы лычма балчык дип сана.

– Метелдәмә, Минабетдин-бетдин! Түшең белән саз җырырсың, җаңгыр җауса! – Сәйфи бугазын гырылдатып каһ-каһ йөткерде, усаллык исәпләгәндә шулай кисәк кенә буыла иде ул. – Җиде җат, дир, ваня! Катынның тучны шөрепләре бушаган. Җәһәннәм тишегендәге авылдан имче эзләттерде. Кемне

диген, Минап! Бер бөкре җенне! Син нәстә кыбырсыйсың, кишер борын? Хуҗаңны хурлыйлар, ваня! Җаклап сүз әйт!

– Китик, әйдәме, Сәйфи Бариевич.

Такта дивар аша барысын да ишетеп яткан хатын уңайсызланып яндыпеште. Бу ирдән яманның да яманын көтәргә мөмкин, чөнки кемдер аны җиңсә, ул салмак кына искән җилне дә давылга әйләндерә иде. Әллә карчыкның дәшмәве сагайтты («бөкре җен»нең шаукымы тисә!), әллә Минап абзыйның әйдәкләп торуы ярады. Сәйфи:

– Май чүлмәген тапшырдык, бурыч үтәлде, – диде. – Моторны кабыз, шылыйк моннан!

– Сеңел белән саубуллашыйк алайса, Сәйфи Бариевич.

– Нәмәстәгә мин аның белән саубуллашыйм, тукмак борын?! Убыр оясына чумды, ваня.

– Хатының вчүтеки, Сәйфи Бариевич.

– Акылдан сапкан бичә, диген! Аның ише чәчбиләр миңа чиратка тезелә! Акча гына күрсәт! Давай, әйберләрен кертеп бәр дә кайтыйк! Живо, тукмак борын!

Хатын, терсәгенә таянып, баш кына сыярлык тәрәзәчектән урамга карады. Ир бәндәсе ярышка ыргылган чабышкы аты сыман ике аягында сикеренә иде. Әй, йодрыгы белән сугып күк йөзен чатнатыр иде! Каты бәгырьле Сәйфинең кыланмышы җанны тетрәтте. Янәсе, хушлашмый. Янәсе, аңа кызлар чиратка тезелә!

Менә, мышный-мышный, баскычтан Минап абзый менде:

– Сеңел, син кайда әле?

– Уң якта, чоланда, – диде хатын.

Озын баулы сумканы иңенә аскан шофёр сукыр төсле бусагага төртелде:

– Куышың сәпсим бәләкәй икән, сеңел. Авыл ызбасы шул.

– Миңа җитә, Минап абзый. Коттедж зур иде, ләкин анда миңа кысан иде.

– Атна-ун көн тиз узар, сеңел.

– Мин озакка, Минап абзый. Яфраклар биш-алты айдан гына саргая.

– Үзең үрсәләнден бит, сеңел. Юкса сездәге байлык белән чит илләрдә нечкә билле курчак әвәләрләр иде. Надан авыл карчыгыннан могҗиза көтмәскә иде дә...

– Чит илләрдә акча гына суыралар, Минап абзый. Монда мин бушка дәваланам, – дип елмайды ул.

– Ай-яй, әбиең елгыр! Тәккә генә синең белән вакыт үткәрмәс, может доллар белән түләттерер, сеңел. Яшелләрне алдыңмы соң?

– Алдым, алдым, Минап абзый. – Хатын, якынрак кил дигәндәй, кулы белән ишарәләде һәм пышылдап кына: – Сәйфи ыргыткан муенсаны табып бир, зинһар, – диде.

Минапның йөзе үзгәрде.

– Ничек «табып?»

– Урынын хәтерлисеңдер, абзый. Минем өчен мең алтыннан да кыйммәтрәк ядкарь ул!

– Ай сеңел, вай сеңел! Миңа мондый хәтәр йомыш кушма син. Әнә, Сәйфиең котырган эттән дә хужы. Итең-сөягең белән чәйни, каһәр. Мин аңа нәрсә диим? Көт, Бари малае, муенса эзлим диимме? Атып үтерсенме, дәҗҗал. Карурманда агачка тәрәп! Ата да, имансыз. Чөнки миңа аның күп кенә кыңгыр эшләре мәгълүм. Сиңа карата да нидер маташтыра ахры. Беркөнне телефоннан әшнәсе белән чүкердәште. Безнең әрекмән колак кайчан Әмирикәдәге радио дулкыннарын тота, сеңел. Ниндидер кыягазлар әзер түгел, ди. Шунда кадәр симезбикә аягын гына сузмасын, кул куйдыртып җитешәсе иде, ди. Әлегә син Сәйфигә исән килеш кирәк, сеңел.

Урамда ир бәндәсе үкерде:

– Мина-а-ап! Эттән туган!

– Әнә, ватый абзаң дулый. Хуш, сеңел!

Менә тышта тавышлар тынды. Бая гына ыгы-зыгыдан кайнаган йорт үзе дә тирән йокыга талган кебек тоелды. Кайда карчык? Кайда Миңсылу? Нишләп алар югалды икән? Хатын шомланып ишеккә караган иде, әйтерсең, идән астыннан калыкты, ятагы кырыена хуҗабикә килеп басты. Төймә хәтле генә коңгырт күздән нур сирпелә иде. Шул көлтә нурның берсе ыргак төсле бөгелеп үзенә тарттымыни, хатын җиңел генә урыныннан купты.

– Элгәреге атым-чатымны ничек белдең, Гөлҗиһан? – Карчыкның күзендә сагаю да бар иде.

– Ун яшемдә мин шомырт агачыннан егылган идем. Хәтерлисеңме, әни күтәреп сезгә кертте. Баланы калдыр, дидең аңа. Мине озын кабык тагаракка яткырдың. – Гөлҗиһан китаптан укыган кебек тиз-тиз сөйләде. – Өч мәртәбә беләгемнән сыпырганда: «Тәңрем, Үлмәс атлы колың шушы оланны имләгәндә, учыма кояш җылысы сал», – дидең. Мин үз аңымда идем, Гамбәр әби!

– Саташма, минем андыен исмем җук!

– Соң, Гамбәр әби...

– Шайтан телегезгә лач-лоч әллә нәмәләр төкерә. Ризык дип ... чәйнәтә! Ниткән Тәңре, димсең! Им-том – догада, кодрәт – бер Аллаһта! – Карчыкның тавышы дәһшәтле иде, йөрәге каккан хатын:

– Ярар соң, чәйнәмәм, – диде. – Үләм бит инде мин...

– Адәм чирдән үлми, гомере беткәнгә үлә! Әй син, кем кыз!

– Әү, җиңги!

Ишек артында гына сакта торган ахрысы, Миңсылу пәйда булды.

– Кем кыз, моңа җан асрарлык кына ашат!

Көнозын ач йөреп, хәлсезләнгән хатын, әлбәттә, ризыктан баш тартмас иде. Әнә, эче быгырдый. Өстәлгә ни генә куйсалар да, ачкүз кабып йотарга әзер. Әмма калай тәлинкәдә аппетитыңны аздырырлык тәгам юк, нибарысы ике кабыклы бәрәңге дә ярты стакан су гына иде шул. Хатын балалар кебек үпкәләп, авызын турсайтты.

– Ай, бигрәк аз!

– Җиңги җан асрарлык кына дип әйтте лә. Миңа дисә, ун бәрәңге аша, гөлкәем.

– Минем җаным бәрәңге белән генә канәгатьләнмәс, апакай. Хәер, нишләп сез мине туендырырга тиеш ди әле. – Хатын сумкасын ачты. – Менә, биш мең сум. Кибетегез еракмы? Иренмәгез инде, ипи, кызыл уылдык, балык алып кайтыгыз! Өчәү бергә сыйланырбыз.

– Ниткән кибет ул?!

– Абау, бүген адым саен супермаркетлар эшли. Авыллар да шәһәрдән калышмый, апакай.

– Атакай, анакай, апакай! – дип үртәлде Миңсылу. – Чиркәүдә диярсең! Гап-гади генә иттереп сөйләш. Апа, дисәң, матуррак ла.

– Хуш, апа. Йә инде, киреләнмә, кибеткә чап!

– Юу-ук бездә кибет, гөлкәем, юу-ук! Кызыл кәгазеңне яшер! Җиңги, әгәр әмерен үтәмәсәң, кызган табада биетә мине. Сине дә ызбадан очыра. Үтүт аннары ташкалагызга! Чемчен, әйдә! Җан кош йомыркасы кадәр генә, ди җиңги, ә бәрәңге аңардан зуррак. Туяр җаның.

Нәрсә сатулашып утыра икән ул? Карчык йортына тамак түгел, чир китерде ләбаса! Хатын бәрәңге кабыгын әрчеде.

– Тәмле микән? – диде. – Без бала чакта, кырда учак ягып, көленә бәрәңге күмә идек. И исе иде, исе! Чакрымнарга таралыр иде.

– Без дә без, дисең. Син кайсы як кавеменнән соң, калын катын? Танып та танымыйм үзеңне. Шәһәрнеке анысы, авылныкылар болай иләмсез симерми.

– Ә син кем, апа?

– Койрыклы җен! Әбиеңнең каенсеңлесе мин, гөлкәем.

– Син дә миңа таныш түгел, апа.

– Икәү иренгә бал сылап чәй эчмәдек шул, калын катын. Элекке заманнарда синдәй чирләшкәләр бу йортта хәтсез сихәтләнгән. Дөнья читеннән килгәннәр җиңгине юллап. И-и, ул хикмәтләрне сөйләсәңме? Капка төбендә чирәм үстермәгәннәр, көтү-көтү халык чиратка тезелгән. Хәзер сирәк кеше җилкапкага орына, сирәк кеше. Инде кирәкләре дә юк, җиңги картайды. Сине мунчада пакьлибез, әйдә, аяклан, гөлкәем.

– Мин шушы килеш кенә үләм! – дип ыңгырашты хатын. Бәрәңге аңа чеметем генә дә көч өстәмәде, киресенчә, котыртты гына. Әнә, ризык дип алданган ашказанын «усал эт» үтереп-үтереп талый. Кырлы стакандагы су да аңкауны гына чылатты. Коттеджагы утыз кеше сыярлык түгәрәк өстәлдәге сый-нигъмәтләрдән соң коры авыз чапылдату көлке хәл иде. Әкияттәге тылсымлы ашъяулыкны җәегез, җәй! Туйганчы ашап үлсен ичмасам!

Акыл дәрьясыннан саркыган бер аваз кисәк кенә айнытып җибәрде: «Яшә-ә!»

Ул арты белән идәнгә шуышып төшеп, ишеккә табан үрмәләде. Үзеңне күпме кызганырга була! «Адәм чирдән үлми... Чирдән үлми...» Карчык та үзгәргән: бөтәшкән... Аны кабыкка салып буыннарын уган куллар йомшак иде, ә хәзер каты, бик каты... «Адәм гомере беткәч үлә...»

Ишегалдын гүя томан сарган иде. Кара мунча якканнар... Бүрәнә ярыгыннан ургылган төтен күзне әчеттерә иде.

**4**

«Һы, юл буе икеләнде. Янәмәсе, ләгънәт яудыра-яудыра куып җибәрәм! Явасылар яуды инде, балакай. Нәселегез корыды. Вәләкин минем каргыш түгел, Аллаһ җәзасы. Мин кодрәтемә ялваручы гына. Без – дөнҗа хуҗасы, ат итеп аның сыртына атландык, дип кәперәймәгез, хисап көне һәркаюсыгызга тәгаенләнгән. Ни чәчсәгез, шуны урырсыз! Күңелегез басуындагы агулы орлыктан шыткан явызлыктан үзегез үк авыз итәрсез».

Мунча өлгереп килә иде. Карчык, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, былтыргы имән себеркесен тозлы суда җебетте. Бөрешеп кипкән яфраклар яңа гына бөредән ачылган төсле җете яшел төскә «буялды». Аны кызган таш өстендә җилләткәч, агач ләгәнгә батырып куйды. Мич алдына тарттырылган күмер өемендә калай чәйнек бығыр-бығыр кайный иде, тоткасыннан эләктереп ләүкәгә күчергәч, киндер капчыктан бер уч үлән салды, төнәтмәне чырагач белән бутады. Бармакларының ибе юк шул. Былтыр гына җилдән җитез иде лә. Келәт диварындагы куакларга күч-күч аскан җитмеш җиде төрле дару үләнен ул берүзе җыеп киптерде. Каенсеңел ерак алан-болыннарга кадәр йөри алмады, шушы тирәләрдә генә кайнашты. Аның үлән тануы да чамалы гына иде. Чамалы, билгеле! Гамбәр бу авылга килен булып төшкәндә, унбиш яшьлек кыз калага – киҗе-мамык фабрикасына эшкә җыенган иде. Тулай торакта ирсез картаеп, өстәвенә аяк бармагын черетеп кайтуына да биш ел чамасы кана.

Барысын да хасиятләп әзерләгәч, карчык сарайдан кочагы белән салам алып килеп идәнгә ташлады. Аннары аркылы тактага элгән шадра сөлге белән

тирләгән бит-муенын корыткач, һавага чыкты. Аңа корымлы татлы ис тә иярде. Баскычка ауган хатынга ул:

– Тор, Гөлҗиһан бала, – диде. – Тор! Тәнеңдә гүр салкыны. Сөягеңдә җелегең туңса – харап. Сине җылыту кирәк.

– Нишләтәсез мине, Үлмәс... әй, Гамбәр әби?

– Шулай дөрес, шулай, мин – Гамбәр атлы. Такмагыз миңа ят исем! Такмагыз! Кемне ачуланам, димсеңме? Дөнҗасын ачуланам. Син шуның шаһиты гына. Кузгал! Нишләтсәм дә – карышма. Җелек катса – җан бимазалана, гәүдәңне тарсына.

Мәрхүм ире Заретдин белән ызба төзегәндә, урманнан аркан бәйләп икәү агач тарттыралар иде. Җиңел иде ул, күрәсең, кулларның җегәре булган. Яшь чаклар, куәтле чаклар! Ә бүген бу хатынны беләгеннән тотып мунчага илтерлек тә рәте юк.

– Миңсылу, ярдәм ит!

Каенсеңел, шелтәләп:

– Никләр моның эше имгәкләр белән җәфаланасың икән, җиңги?! Бүлнистә брачлар дәваласын, – диде, һәм сукранып кына, хатынны култыклады. – Һай, авырлыгы!

– Шым бул, мөрәвәтсез! – Карчык Миңсылуга акайды. – Аллаһ мохтаҗ бәндәсен безгә турылаган икән, шуңа чиксез шөкрана кыл! Шифасын бирер өчен Ул без фәкыйрьнең кулын сайлаган кана. Ничекләр Бөек Затыма карышмак кирәк! Тәүбә, тәүбә!

– Әстәгым, сине җәллим мин, җиңги! Яшәрү ягындамыни син?! Үз көеңне үзең көйләсәң дә – рәхмәт кенә.

– Лыгырдап көемне бозасың, кем кыз. Җәтрәк атлат! Мунча суына.

– Суынмый ни! Һәйбәтләп тимер мичле сабриминный мунча төзеттер оныгыңнан дигәч, карасы сихәтлерәк, дидең. Корым оясы, шул гына инде.

– Йа Аллаһым, озын да телең, Миңсылу! Эчкә кермә, кал!

– Мәйлең, җиңги. Калын катынны юындырганда хәлдән тайсаң, миңа кычкыр. Моның бит аркасы да куна тактасы тиклем, хи-хи!

Карчык, авыруны чишендереп саламга утырткач, чүмеч белән ташка су бөркеде. Түшәмгә ургылган көл катыш пар мизгел эчендә аска төште.

– Ник мине газаплыйсыз? Мин чип-чиста, мин керләнмәдем, – диде парга тончыккан хатын. – Хезмәтчеләрем көн саен саунада юындырды, Үл... Әй, Гамбәр әби!

Үч иткәндәй карчык тагын чуерташларны чыжлатты. Яңгыр коендырдымыни, Гөлҗиһанның тәненнән шыбыр-шыбыр тир акты.

– Ясалма мунчаларыгыз белән мактанмагыз! Чир оясы алар, чир оясы. Шакшы кортлар мыжлый анда. – Ул пыяла савыттагы суган төнәтмәсен учлап-учлап мичкә сипте. – Авызыңны ачып, борын тишегеңне киереп, тирән сула. Суган суы эчтәге былчыракларны чистарта, дияр иде Сабирҗан мулла. Адәмнең тәне берлә рухы да хасталанган. – Карчык сүз белән дөньясын уңлы-суллы «яңакларга» тотынды. – Пычранасыз да духтырларга зарланасыз, чиремә дару килешмәде, дисез. Җан сырхавына тарган адәм баласы икеләтә бәхетсез. Мин андыйларны илләп күп күрдем үз гомеремдә. Үзе бисмилла, дия, үзе хәмер лыкына, үзе дога кыла, үзе шайтан гамәле – гөнаһ эшли. Мондайлар ике битле, мондайлар аерата куркыныч. Алар да какты ишегемне, вәләкин бусагадан узалмады. Рәхим-шәфкать булмады безләрдән.

Тел сөйләде, ә имән себерке яфраклары тетелгәнче шап та шоп хатынның аркасын «кыйнады». Каян инде аңа көч-гайрәт? Бетерештем дигәндә генә, йа?

Актыккы чырагы кабындымы? Шуның яктысында ул соңгы шифа-дәвасын башкарамы?

Кортка чәйнектән үлән суы агызды:

– Мә, йотымлап кына эч. Шешең кәмер, иншә Аллаһ.

– Гамбәр әби, – дип пышылдады хатын. – Үлмәс кол кем иде соң ул? Син аңардан куркасың шикелле.

Камыт энәсе белән тез астына чәнечтеләрмени, карчык әздән генә идәнгә чүгәләмәде. Нинди бетмәс шом бу, йа Аллам?! Ул аны тамчысына кадәр кан тамырларыннан сыкты кана. Шомнан яралган курку, гүя каракош, очып китә дә, канаты белән бәрә-суга кабат йөрәккә оялый иде. Югыйсә дала күкрәгендә чыбыркы шартлата-шартлата артыннан кумыйлар, югыйсә еллар кан дошманы белән ике арага җил дә үтмәслек вакыт кыясы бастырды. Сабирҗан мулла: «Исмең онытылу берлә – курку куыгы да шиләр», – дигән иде. «Җир астына яшеренсәләр дә, табып муенын чабабыз», – дигән янаулардан соң әлләниләр уйлата шул. Үзен кайгыртамыни, Аллам?! Баламның баласына үч камчысы белән сыдырмасыннар.

Карчык идәндәге буш чиләкне тибеп аударды: аның эсседән комач төсле кызарган хатынга җавабы шул иде. Миңсылу кунакны җитәкләп өйгә илткәннән соң, ул юеш саламны кулы белән тырмалап чокырга түкте.

Өйлә вакыты җиткән иде. Сарай артыннан урманга сузылган тар гына сукмак җәйге айларда җомга саен аны иске мәчеткә илтте. Әллә гадәтләнде, әллә күңел шулай теләде, карчыкка үзе кебек үк бөрешеп картайган «иман йорты» кырыенда намаз укуы рәхәт иде. Нигез туфрагы догалы иде шул. Аяк үзеннән-үзе шунда тартылды. Килгән саен әүвәл мәчет тирәсен чүп үләннән әрчи иде, бу юлысы ашыкты, намазлыгын яшь кычытканнар өстенә үк җәйде. Ашыгуының сәбәбе: Аллаһка сыенып, куркудан качу иде. Намазын тәмамлагач та карчык агач-куак арасыннан кулъяулык хәтле генә күренгән күк йөзенә төбәлде:

– И Раббымыз, – диде. – Үзең ярлыкагыл! Үзең җаныма тынычлык иңдер! Артыгын сорамыйм. Гөнаһым зур: курку күлмәге киеп җәфаланам. Шуны бер киям дә салам, салам да киям. Синең әмереңнән башка яфрак та селкенми ансы. Ерак бит инде ул хәлләр, ерак, никләр онытылмый икән, Раббымыз. Бүген дә исмен әйтеп йөрәкне кузгаттылар.

* * *

...Иртән үк ата йортында тыз-быз чабыштылар.

– Бүген безгә яучылар килмәктә, Котлыбәк агай угланын үләндермәк кели, – диде анасы. – Сине капкасы алтын тоткалы җыртка урнаштырсак, атаң көтүлектән ун бияне бирнәгә аерыр, Үлмәс кызкаем.

Яшь үлән сыман әле генә җирдән калыккан унҗиде яшьлек кыз урталай «сынды». Бу иң яман хәбәр иде. Кем-кем, Котлыбәк углы Мукай аңа тиң идемени, Олуг Тәңрем?! Акылга таман егеттән көтүче халкы тәмам гарык, ул йә аларның чатырын яндыра, йә ат белән таптатып сарыкларын имгәтә иде.

Үлмәс бик тиз сынын төзәтте.

– Мәйлең, Анам, үләндерсеннәр, – диде. – Чү, чү, иртә шатланма! Мин риза, димәдем, Анам. Котлыбәк малаена эчем-тышым карыша. Җан җылымсыз ул!

– Вай-вай, аузың ни сүли, Үлмәс! Җил хуҗасы ишетеп далага чәчмәсен, Ходаем. Синең бәхетең – безнең бәхет, кызкаем. Син – сыңар олан – Тәңребез бүләге. Тәүге балаларыбыз туды да үлде, туды да үлде. Ызба иясенең шаукымы тиде. Имче Сайрәби саттык йоласын үтәмәсә – сине дә бишегеңдә буар иде ызба иясе. Ушлы Сайрәби, ушлы. Оланыгызны биләүсәгә төрегез дә тәрәзәдән

генә миңа сатыгыз, дип үрәтте. Анарда өч көн, өч төн кундың, кызкаем. Үлмәс атын да әбкәч үзе кушты.

– Ызба иясен алдадыгыз әлсә? – дип көлде кыз. – Чур, мине алдый алмассыз, Анам. Котлыбәк йорты – тирес, улы – корт. Без алар белән туганлашмыйбыз!

– Вай-вай, безнеңчә сүләшмисең, кызкаем. Мөгаллим генә бозды телеңне, каһәр суккыры!

– Бозмады, сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтте, Анам. Ул миңа: «Син – татар кызы», – ди, татарча дөрес сөйләш, ди.

– Ни пычагыма сиңа дөрес тел! – дип чәпчегән анасына ул серле генә елмайды.

– Кыз бала, буй тартса, киләчәген уйлар, Үлмәс!

– Уйламаган кая! Мин урман күрәм. Тоташ урман, Анам.

Хыялыннан әсәренгән Үлмәс кисәк кенә ишеккә ташланды. Тояк тавышыннан дала яңгырый кебек иде. Киләләр! Олуг Тәңрем, ияләрең җыйнаулашып миңа ярдәм итсен! Җил, каршы ис, давыл, кылганнарны төбе-тамыры белән куптарып, Мукайның йөзенә сыла! Сукырайт аны, сукырайт!

Кунаклар озаклады, көтә-көтә көтек булган Хөсәен йорты кич белән кеше аркылы белеште: пар атлар тиянадан гына дулап, Котлыбәк угланны тарантастан мәтәлдергән, имеш. Кыз ярәшү иртәгә кадәр кичектерелә, имеш. Үлмәс шат иде. Иртәгәсен өйдәгеләр әүвәлгесеннән дә мулрак ризык хәстәрләде, әмма сәкедә аяк бөкләп утырып, майлы куй ите кимерәсе агай-эне тагын бәлагә тарган: ат өстеннән егылып, кул-аягын каймыктырган, имеш. Үлмәснең ничек сөенгәннәре бер Тәңрегә генә мәгълүм иде.

Гәрчә, исем анасы дәрәҗәсе күтәрсә дә, имче тора-бара кызны күралмый башлады. Йа Күкләр хуҗасы, Сайрәбинең тирә-юньдә оста белекче дигән даны таралгач кына, ник ул баланың сизем-тоемын да, кул шифасын да артыграк итәсең?! Яшь көндәштән котылу юлын ап-ачык сызды имче: Котлыбәк оланына ярәшергә! Ул ерткыч нәселдә кыз-катынга сан юк! Анда эт тормышы! Камчы белән сыдырган саен, Үлмәснең дәвалау сәләте югалыр!

Сайрәби имче, киң ыштан балакларын җилфердәтеп, Котлыбәкләргә чапты. Камзул кесәсендәге чүпрәген Мукайның учына сонып:

– Шушы нәстә белән авыз-борынын томала, тыны буылгач, ат сыртына салып апкайт! – диде. – Урла! – диде.

Шадра йөзле, әрекмән колаклы килбәтсез егет төенчекне чишеп иснәде.

– Фу, сасы!

– Уылган тилебәрән үләне, җегет! Сиңа ярдәмем тисен. Узгынчы юлчыдан апкалган ыем им-томга, – диде ялагай карчык, кеткелдәп.

– Синең ярдәмеңә кем мохтаҗ ди, кәкре сыйрак! Мин, дала күкрәген изгән баһадир Мукай, бер чәчбине генә үзем дә буйсындырам! Шыл моннан! – дип, егет үлән онын карчыкның битенә сипте. Имченең авызы чалшайды, ул кулы белән йөзен җилләтеп мыгырданды:

– Һы, буйсындыра ди! Ике трит юлыгыздан борды. Өстегезгә болыт иштерде, чаптарларыгызга каршы җил истерде. Өченче трит муеныгызны сындыртыр!

Көнләшүеннән кара көйгән карчык аларга да сугылды. Аңа ничек тә уй-ниятен тормышка ашырырга кирәк, югыйсә җаны тынычланмаячак иде.

– Син, тамырларыңда татар каны аккан Хөсәен, безнең аймакта төпләндең, безнең гореф-гадәтләргә күндең, абзар, дала, җил ияләрен санладың, су бабасын, су анасын хөрмәтләдең, дөнҗалыктан арынып, күк-җир падишаһы Тәңребез катына ашасыңны белдең, хәзер мине тыңлап бак, – диде ул, куактагы тәтелдек кош сыман тиз-тиз сөйләп. – Йә гайрәтле нәсел белән туганлашып,

дәүләтеңне арттырасың, йә алардан зыян-зәүрәт күрәсең. Соңгысы яхшыга илтмәс, Хөсәен. Кызыңны төнгелеккә келәткә яп, иртән таң зәрәсендә Котлыбәк угланы апкитәр үзен. Баш бирмәс Үлмәсеңне шулай гына җиңәрсең, Хөсәен.

Имченең өздереп-өздереп сайраганын кыз ишетте, ләкин ачуын тыйды: монда бары тик хәйлә белән генә котылырга мөмкин иде. Келәткә бикләгәндә ул карышмады, ә караңгылаткач, түбә тактасын куптарып, ireккә чыкты. Күк гөмбәзен бизәгән йолдызлар үрелеп алырлык буйда гына якын иде, Үлмәс Илаһи зат камил итеп төзегән җиһанның матурлыгыннан хушланып берара онытылып торды. Аннары җитез генә аска сикерде. Җил тынган, төнге һава тыгызланган иде, качкын кыз дала иңләп очты. Мөгаллимнең атлары әзер иде, егет килә-килешкә үк аны күтәреп ияргә утыртты.

– Ашыгуың хәерле, – диде егет. – Куып тотсалар, икебезне дә ат койрыгына тагып сөйрәп йөртәчәкләр. Сездә халык кыргый гадәтләрдән арынмаган. Артта калма!

Таң атканда алар шактый чакрым үткән, әмма атлар арган, әгәр малкайларны ял иттерсәң – Котлыбәк углы, куштаннары белән эзгә төшәчәк иде. Шуңа күрә мөгаллим, акча биреп, чаптарларны яңалары белән алыштырды. Тагын кичкә хәтле җил белән куыштылар. Төн күзендә качкыннар җәяү генә тимер юл кырыеннан атлый иде инде. Агач төягән тауар поездының койрыгына ябышып менеп, бүрәнә арасына поскач кына иркенләп сүз алышты алар.

– Үлмәс, бу гамәлеңә ахырдан үкенмәссең микән?

– Үкенмәм, Заретдин.

– Мин сине үз илемә дәшәм. Мәңгегә. Сиңа далага юл ябыла, Үлмәс.

– Мәңгелек тормыш Тәңре катында гына, Заретдин. Син дә, мин дә җирдә кунак кына.

– Бездә үзгәрәк дөнья, Үлмәс. Йолалар да бүтән. Үзеңнекеләрне юксынсаң, нишләрсең?

– Түзәрмен, Заретдин.

Мөгаллим егеткә үлеп-бетеп гашыйк иде кыз, мәхәббәт аның бөтен барлыгын биләгән иде.

Яшьләр бәләкәй генә стансада поезддан төшеп калды. Өч тәүлек авыллар аша уза-уза, ниһаять, соңгы ноктага җитәбез дигәндә генә, Заретдин:

– Әнә-ә, теге калкулыктагы бистәдә әтинең туганнан туган абзасы Мифтахетдин бабай яши, без аңа кагылыйк әле, синең өстең дә юка, җиңги әби берәр нәрсә кигезер, – диде.

Качу хәсрәте белән мие сыекланган кыз кием-салым турында кайгыртмаган иде шул. Ярымшәрә иде Үлмәс. Кыска күлмәген күпме генә аска тартса да, тез капкачы май чүлмәге кебек ялтырый иде.

– Минем аяк-кулым да тузан гына, Заретдин.

– Юл хутында күл бар, юынырсың.

Йокыга талган күл өсте көзге сыман шоп-шома иде, су иясеннән ояла-ояла гына, кыз тәнен паклагәч, толымыннан бер бөртек чәчен йолкып күлгә агызды. Арырак Заретдин юына иде, ул аның да сакалыннан төк тартып алды. Егет, сискәнеп:

– Нишлисең? – дип кычкырды.

Кыз:

– Су иясенең күңелен күрергә кирәк, – дип елмайган иде, Заретдин беренче тапкыр аңа:

– Акылдан сапкан! – диде. – Акылдан сапкан! Су – җансыз! Аның хуҗасы юк!

– Бар! – Үлмәс тә бирешмәде. – Тәңре яралткан һәрнәрсә – тере!

– Куй шул Тәңре-мәңреләреңне, кызый! Мин сине кисәттем, бездә үзгә

дөнья! Өч елда чәчемне агарттыгыз әкиятләрегез белән! «Төкермә – җил иясе орыша!» «Сызгырма – йорт иясе ачулана!» имеш. Сезнең якларга хәреф танытырга барган мин – җүләр!

Хәер, кызды-кызды да тиз сүрелде юлдаш. Егетнең абзасы иркен генә йортта яши икән, ул кунакларны берникадәр каушау катыш борчылу белән каршылады.

– Бәдерниса әбиегез чирләде, оланнар. Үләм, дип бәхилләште. Сез инде гаепләмәгез, ни бары белән сыйланыгыз, – диде карт.

Үлмәс мич аралыгындагы кадакка элгән озын халатка уранып сырхау янына – алгы бүлмәгә керде. Аның яныннан ул өч сәгатьтән соң гына чыкты...

Мифтахетдин бабай иртән газиз карчыгының самавыр чыжлатканын күргәч: «Машалла!» – дип сакалын сыпырды.

Хуҗалар озак кына чаршау артында чыш-пыш килде. Яшьләр юлга кузгалганда гына карт:

– Сез, оланнар, бер-берегезгә кемнәр инде? – дип сорады. Заретдин җилкәсен сикертте, ә Үлмәс шунда гына үзенең нинди аяныч хәлдә икәнлеген аңлады. Ул бит беркем дә түгел, бары тик мөгаллимгә тагылган качкын гына иде! Гыйшык уты нибарысы аның йөрәгендә генә кабынган, егет аны залимнәрдән коткарса да, Үлмәс дип өзгәләнми иде. Ләкин Заретдин шаккатырлык сүз әйтте:

– Үлмәс – минем кәләшем!

Мифтахетдин бабай колакка саграк ахрысы:

– Кем, кем? – диде.

– Кәләшем, – диде егет.

– Ансы, хуш, ярый. Кушаматы ямьсез кыз баланың, энем.

– Исем ул, бабай.

– Әстәгъфирулла! Мәҗүсиләр кавеменнәнмени?! Безнеке түгел алайса. Кыз сиңа хәрәм, энем.

– Атасы, кешегә каты бәрелмәле син! Хәләлеңне терелткән баланы рәнҗетү хак мөселманга килешмәс, – дип, Үлмәсне яклаган Бәдерниса әбигә карт йодрыгы белән үк селтәнде:

– Һи, шайтан ырымы белән сихәтләнгән ди берәүсе. Догасыз-нисез өшкерү – гөнаһ! Энем, кире үз оясына илт бу нәмәстәкәйне. Әлхәмделилләһ, бездә ислам динендәге мөселман кызлары күп, сине үзем үләндерәм, боерса!

Туганының кискенлеген өнәмәгән егет, аркасына биштәрен асып:

– Аш-суларыгыз өчен рәхмәт, без туган авылыбызга киттек. Әйдә, Үлмәс, – дигән иде, кыз аның беләгенә ябышты:

– Кабаланма, Заретдин! Минем дә хак диндә буласым килә!

– Акылдан яздың мәллә, кызый! – Егет биштәрен идәнгә бәрде: – Ниткән дин тагы?! Без – замана яшьләре, без – атеистлар! Яңа тормыш корганда, искелек калдыкларын чүплеккә түгәбез! Бездә һәркем ирекле, һәркем үзенчә яши!

Үлмәс исә кирелеге белән үз басуын сукалады:

– Мин Аллаһка иман китерәм! Дога-сүрәләр үрәнәм!

Бая гына тузынган картның йөзе нурланды.

– Карчык, кыз баланың башына яулык бөркә! – диде ул. – Кызым, артымнан кабатла. Лә-иләһә-иллаллаһ, Мөхәммәд Рәсүлүллаһ. Тәрҗемәсе шул, кызым: Аллаһтан башка Илаһ юк, Мөхәммәд галәйһиссәлам аның Рәсүле.

Лә-иләһә... Бу ят кәлимәләр шунда ук аның күңеленә сеңде. Учын кушырганда, бармакларына нур коелды... Әле йола тәмамланмаган иде.

– Кызым, хәрәм исемеңнән арыну кирәк, – диде карт. – Әлеге атыңны онытам дисәң генә, мөселман исеме кушарбыз. Син ризамы?

– Онытам, Мифтахетдин бабай. Ант!

– Антыңа тугры кал, кызым. Моннан ары син... – Карт өч мәртәбә аның колагына пышылдады. – Гамбәр, Гамбәр, Гамбәр...

«Сезнең уеныгызга катнашмыйм» дигән кебек читтән генә күзәткән егеткә дә камчы очы тиде. – Син – җаһилият корбаны, этиес дип ирсәймә, яме? – Бабай Заретдинны җилтерәтеп артсыз урындыкка утыртты. – Аллаһы Раббел-Гыйззәбезне танымаган бәндә – мөртәттер. Дөнҗави укуларың белән дә масайма. Иң бөек гыйлем иясе – Аллаһ! Хәзер туры гына җавап бир: Гамбәрне хатынлыкка аласыңмы?

– Алсам ни?

– Никах беләнме?

Егет авызын йозакка бикләде. Һичшиксез, ул моңа каршы иде. Юл буе комсомолларның «кызыл туйлары» турында сөйләп кайт та, менә сиңа мә, никах укыт, имеш!

Үз ихтыяры белән Гамбәргә әйләнгән кыз өчен хәлиткеч мизгел иде бу. Ул:

– Без риза, бабай, – диде.

Беренче төндә ир белән хатын аеры-чаеры йоклады: Заретдин үпкәләгән иде... Шуннан бирле болай да әллә ни җылынмаган аралар бөтенләй суынды. Бәлки, никахтан соң ук авылга юнәлсәләр, үтә күренмәле гаилә пыяласы чатнамас та иде, Мифтахетдин карт тоткарлады. Аның энесендә гаме юк, йомыш килендә иде. Карт:

– Кызым, Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә олуг китап – Коръән иңдергән. Адәм мин кушканнарны үтәп, тыйганымнан тыелып яшәсен, дигән. Ислам гакыйдәсенең җиде нигезе бар, син шуларга төшенеп, әммәсенә дә иман китерергә тиеш, кызым. Бистәдә Коръән Хафиз Сабирҗан мулла яши. Кизләү мәдрәсәсендә гыйлем эстәгән кари. Аңардан шыпырт кына дин сабаклары үрәнсәң иде, кызым. Бабаебызга блач тими, сукыр диләр дә куялар, – дигәч, яшь хатын тамчы да икеләнмәде:

– Үрәнәм, үрәнәм! Заретдинга нәрсә дияргә соң, бабай? Аның авызында гел кызыл җөмләләр, – диде.

– Ирецә белгертмик, кызым. Зәгыйфь картка йорт эшләрендә булышам, диярсең. Савап өчен, диярсең. Ил-көннән дә яшер, кызым. Аллам сакласын, мәчет манарасын аударып, аятелкөрсиләрне яндырган мөртәтләр башыбызны өтермәндә черетер.

Заретдин йомшак күңелле иде, әйдә, ярдәм ит, әллә кая ашыкмыйбыз бит, әни карчык бераз күтәр, диде. Бәлки, ул ашыктырыр да иде, аны бистә мәктәбенә укытырга чакырдылар. Гамбәр исә хәйлә капчыгын кат-кат кысып бәйләде: көнен-көнгә, аен-айга ваклап ярты ел узды, ул һаман сукыр картны «тәрбияләде». Дога-сүрәләрнең көч-кодрәтеннән тетрәнгән дала кызы, мөгаен, гыйлем коесын тагын да тирәнрәк казыр һәм остазы Сабирҗан мулланы да уздырыр иде, «кыңгыр эш»нең кыңгыравы чылтырады. Мифтахетдин килене дин белән халыкны агулый, дога белән өшкереп сырхауларны дәвалый икән, дип «озын телләр» хакимнәргә әләкләгәч, яшьләр кара төндә бистәдән сыптырды. Әмма «балыкчылар» Гамбәрне кармакка эләктергән иде инде: Заретдин йортына тентү керде. Идән такталарына кадәр куптарып, Коръән китабын эзләделәр, тик файдасыз, ул табылмады. Чөнки яшь хатын аны йөрәгенең иң ерак нүешенә яшергән, кыскасы, һәр хәрефен, һәр иҗеген иман каләме белән күңеленә уя-уя ятлаган иде. Тентү бер хәер, ә менә ире үзәк базарыннан ишетеп кайткан хәбәр бик яман иде. Имеш, кырыктартмачы Сәләхетдингә дала ягындагы таныш-белеше фатирга тукталган. Имеш, шул адәм Үлмәс кыз турында риваять сөйләгән. Имеш, аны дала иясе урлап, урман иленә качырган. Кызның ярәшелгән җегете, сезнең якларга шымчылар җибәртеп, үч алмакчы, имеш.

– Дала иясе – мин инде ул, – диде Заретдин. – Риваятьне әзрәк үзгәрткәннәр. Ул табак битләр иснәнә-иснәнә безнең эзгә басмагае тагы.

Гамбәр ирен бүлдерде:

– Без инде салам кибәнендәге энә төсле, Заретдин.

– Кайчак инә ялтырап күзне чагылдыра. Авылда синең ят җирдән икәнең күрше этенә тиклем мәгълүм!

– Аның каруы элгәреге атымны белми күрше этегез. Мин сезнеке, Заретдин. Төс-кыяфәтем – сезнеке, телем – сезнеке.

– Ансы син безнең буяуга оста гына буялдың, җанкисәк. Безнең шивәне оттың, безнең ризыкны килештердең. – Ире аны үрти иде. – Моннан ары тыныч кына яшәүләр юк инде. Кайчан килеп үтерерләр дип ят! Их, даланнан кузгатмаска иде сине, кыргый!

**5**

...Кич белән аңа бер телем арыш ипие белән су гына бирделәр. Өстәлгә кем ризык куйгандыр, хатын күрмәде: мунча сөякләренә кадәр йомшарткан һәм ул тоташ дүрт сәгать йоклаган иде. Ни гаҗәп, ашыйсы да килмәде, әйтерсең, әле генә табын яныннан кузгалган иде. Алай да сындырып ипи капты, аны су белән көчкә генә тамагыннан юдырды. Тәгам әче иде. Минап абзый: «Яңы теләгән – елан ите ашаган», – ди. Әйе, хатын иң зәһәр еланны да чәйнәмичә йотарга риза иде. Тик ябыксын гына! Монда инде икесенең берсен сайлыйсың: йә өметеңнең күзе сукыраеп, дөм караңгы дөньяда яшисең, йә савыгып кеше арасында кайныйсың. Кеше, кеше... Кем соң алар? Сирәк-мирәк кенә «хәл белешкән» дус-ишме? Андый дуслык чәнти бармакка чорнарга да җитми. Коттедж – цирк, караватт – мәйдан, ә анда «фил» ауный. «Дуслар» шул тамашадан көлеп рәхәт чигә. Чү, терелсен генә, кәмитнең бүтән төрлесен күрсәтер Гөлҗиһан! Башта иң затлы ресторанга җыеп сыйлар. Өстәл саен тукталып, үзе кыстар. Сылу гәүдәле, нечкә билле хатын күбәләк сыман очып кына йөрер. Ир-ат: «Кара, бу хатын нинди чибәр икән», – дисә, ханым-туташлар көнләшүдән кара көяр. Аннары ул «ахирәтләр» белән арасын өзәр: очрасалар – «танымас», шылтыратсалар – «ишетмәс». Әкияттәге тары боткасы кебек, акчаң кесәңнән ташып акса, яңа танышлар бик тиз үрчи! Кодрәтле ялтыравык кәгазь бүре белән сарыкны да туганлаштыра.

Ә хәзер әле Гөлҗиһан мескен бер кемсә генә. Әнә ишегалдында кайчандыр аңа якын булып та, бүген ят һәм шыксыз күренешкә әйләнгән мохит. Кәҗә мәэлдәве дә, тавык кыткылдавы да ямьсез, чын матур тормыш шау-шулы шәһәрдә генә кебек иде. Аның шушы кысан-тар аймакка килеп төртелүе аклана тагын! Җаны теләде, җаны... Кайда соң бу җан?! Ник ул аң хәтле аң белән идарә итә? Ник акыл хәтле акылны буйсындырып, адәмне кол хәленә җиткерә?! Үзе көненә бишкә төрләнә: сыкрый, шатлана, газаплана, үрсәләнә...

Миңсылу ике чиләк күтәреп керде.

– Тез тигентен сыйракларыңны тык! Җиңги әмере! – дип, ул хатынның аякларын караватт кырыена салындырмакчы иде, Җиһан:

– Үзем, үзем, – диде. – Нәрсә соң бу?

– Җиде үлән төнәтмәсе, гөлкәем. Пешермиме?

– Юк, талымса гына. Моннан соң кәҗә бәтие кебек сикереп уйнармын инде, әйеме, Миңсылу апа?

– Хи-хи! Чагыштырдың! Кәҗәдә – тояк, синдә – бүрәнә аяк. Әз-мәз селкенсәң дә, җиңгигә рәхмәт укы, гөлкәем. Син – туксан яшьлек карчыкның авыртмаган башына тимер тарак. Сезнең ише имгәкләр белән интегә, бичарам. Намазлык өстендә генә утырасы юкса. Әнәгенәк, миңа эш кушты да каядыр

кыяклады. Капчыгында пыяла банкалар шылдырый. Мәйтәм, сөлеккә китте микән? И Ходайгынам, җәһәннәм читендә лә күл.

Миңсылуның борчылуы аңа да күчте. Карчык Гөлҗиһанны мунчада юындырганда ук хәлсезләнгән иде. Урманда үле тынлык, әгәр Гамбәр әби егылса – эт белән табарлык та түгел. Хатын шушы тишектә алты ай азапланыр микән? Элемтә юк, кесә телефоны тотмый.

– Миңсылу апа, син ярыйсы гына йөрештерәсең бугай. – Җылы суда аяк туңа башлады. Курку кан тамырларын суыта иде.

– Ташбака сымак әкрен генә кыштырдыйм, – диде тегесе. – Элгәре атна саен бистә кибетен әйләнеп күңелне хушландыра ием, быел әллә ни очындырмас: үкчә сызлый. Бәй, сиңа ниемә минем йөрештерүләрем? Ә-ә, сез шәһәр бичәләре тамаксау шул. Тәм-том кирәкме? Кемгә нәстә, кәҗәгә кәбестә инде. Һай, җиңги исән-сау микән?

Әй, тамак ди сиңа! Алай-болай карчык кайтмаса – акырып кына үләсе лә.

– Суынды төнәтмә. Чиләкне ал, – диде хатын, еламсырап.

Кем кызганыч: синме, белекчеме? – дип сорасалар, әлбәттә, Җиһан кызганыч иде. Кортка яшисен яшәгән, ә менә аның гомер йомгагы шулай бик тиз сүтелер микәнни?!

Миңсылу шадра сөлге белән хатынның аягын корытты. Корытты да дәшмитынмый гына чыгып китте. Шом тулы кара уй, карчыга төсле, йөрәккә һөҗүм итә иде. Ятагыңа кадакланып үлем көтеп ят инде! Ул шыр ялгыз... Гарип Миңсылу санга бар, исәпкә юк... Тураеп идәнгә басмакчы иде, аркан ауды. Башы шык итеп караватт тимеренә бәрелде. Ыңгыраша-ыңгыраша чигәсен уганда гына, Миңсылу тәрәзәгә шыкылдатты:

– Җиңги исә-ә-ән!

Авырту кисәк басылды. Бая гына «тишек» дип хурлаган чоланның диварлары киңәеп, күз аллары яктырды. Бу җанның бүтән халәте иде. Хәзер аңа оят, бик оят иде. Гомер юрганмыни, хатын аны карчыктан тартып алып, үзенә япмакчы иде.

Җиһан терсәге белән этелә-этелә, җайлап кына гәүдәсен ятагына «урнаштырганда», бусагада карчык күренде. Аркасында киндер капчык иде. Ул:

– Уй-мендәрегез сүрүсез, мамыгы дөнҗага оча, – дип битәрли-битәрли, пыяла савытлар бушатты. – Мин тере кана! Әллә нәстәләр юрамагыз! Син, кем кыз! – Кортка ишек төбендә сурайган Миңсылуга акайды: – Нәмәстәгә кеше күңеленә шик саласың?

– Ни-нәстә дидем соң әле ул кадәр, җиңги? Зарландымыни, и симез үрдәк!

Карчык кулындагы чүпрәкне йомарлап каенсеңлесенә ыргытты:

– Аның аузы йомык! Мин әйтәм! Коткы – шайтан гамәле. Түшәгемдә җан бирермен, иншә Аллаһ! Түшәгемдә!

Пыр тузынган кортканың «җиле» Гөлҗиһанны терелтте ахрысы, ул ничек торып утырганын да сизмәде. Сулы савытта кап-кара суалчаннар кыймылдаша иде. Җирәнгеч иде алар, җитмәсә карчык савытны кырынайта да, хәшәрәтләр иреккә чыкмак булып өскә үрмәли иде.

Миңсылу мышкылдаган борынын чүпрәккә сөртте:

– Бәй, синең өчен кайгырдым ич, җиңги! Ник пырылдыйсың инде, җә? Урманда хәтта бүре дә адаша, ди.

Бая гына өермә куптарган Гамбәр карчык аның белән сүз көрәштерерлек хәлдә түгел, ул башын аска иеп йокыга талган иде. Җиһан мондый үзгәрешкә таң калды. Йоклый! Әнә сулышына кадәр тигезләнде! Берничә минуттан хуҗабикә тынычланып, йөзе нурланып уянды.

– Бисмиллаһ, – диде ул, битен сыпырды, аннары назлы тавыш белән каенсеңлесенә: – Хәзер тәһарәтемне яңартып, ике рәкәгать намаз укыгач, башлыйбыз, кем кыз, – диде.

– Әйдә, симез түшкәңне туры суз! – Миңсылу хатынны каз дип уйлады микән, беләгеннән дорфа гына йолыккалады. – Ай Аллам, нәстә бәбәгең шар төсле түгәрәкләнде. Кортканың гел шул инде аның: дулый да тына. Шунысына рәхмәт диген: җен-пәриләре ярыкка поскач кына им-томына керешә. Сабырлангач кына. Иту зәһәреннән чеметеп, тәнеңне яндырыр ие.

– Бүген нишләтә ул, апа җаным? – Савыттагы хәшәрәтләр бизгәк тоткандай бөтен тәнен калтырата иде: – Әнә теге... пычрак суалчаннардан тешләтмәс бит, әйеме, апа?

– Һай, мисез тавык! Ниткән суалчан? Сөлек ул! Шуларны апкайтыр өчен ничәмә-ничә чакрым җәяү теркелдәгән, бичаракаем. Син, гөлкәем, әбигә киреләнмә! Характер күрсәтсәң – артыңа типте дә озатты! Тилмереп чакырган кунагы түгел лә.

Уй агышы ниндидер үтә күренмәле чыбык аша тапшырыламыни, намаздан соң тагын да йомшарган карчык, Җиһанны җиңелчә генә әрләп:

– Сөлекне Аллаһ яралткан, ник аңардан чирканасың, – диде. – Каның куерган, мәгәр сыеклатмасаң – тамырларыңа төер укмашыр.

Миңсылу, белдекле кыяфәт ясап:

– Әй, җиңги, хәзер беләктән дә кан агыза брачлар, бүлнистә мин көнаралаш анализ тапшырдым, – дигән иде, идән ярыгына поскан җен-пәриләр кабат карчыкны «камады»:

– Адәм гелән-гелән ансат эзли. Зарарын тәгаен белеп тә тискәресен хуплый. Йөрәкне сугарган терек суын әнә белән тишеп агыза. Аллаһ аның микъдарына кадәр үлчәгән кана. Иблис эчә ул канны азактан, иблис! Аңа үзе куәт бирә адәм!

Каенсеңел шыпан-шыпан гына чоланнан тайды, карчык исә җиңнәрен сызганды да:

– Бисмиллаһ, – диде. – Бисмиллаһ! – Һәм көйләп-көйләп такмаклады. – И Җир-Күкләрнең кодрәтле хуҗасы! Мин – синең колың, тын сулыклардан җитмеш җиде бөҗәк сөздем. Вәләкин синең рәхмәтеңнән башка аларның һич файдасы тимәс. Телемдә дога, бармак очларымда им-том, яңгылышсам – кичерә күр, Аллаһым! Изгелек җиһанда нурланып балкыса, яманлык карадан кара болыт сыйфатында асылынып тормыштыр. Соңгысы тән-җаныбызны былчыратып өстебезгә яумасын, Газизем! Үзеңә тапшырылдым, Әхәдем... – Ул, иелеп, хатынның әче камыр кебек күпергән корсагына баскалады. – Үзеңә тапшырылдым, үзеңә... Синнән килдем җир йөзләренә, сиңа әйләнеп кайтам, и бер Аллам. Син кем, канәтем... – Монысы Гөлҗиһанга атала иде. – ...бавырың иләмсез зурайган. Ат солы ашаган күек син дә гелән дару чәйнәгәнсең. Агу эчәсез кана!

– Нишләтим инде! Дарусыз үләм бит мин, Гамбәр әби.

– Талагыңда шеш бар. Борчак тиклем.

– Юк, юк, минем эчке әгъзаларым сау-сәламәт!

Карчык өнәмәсә дә, Җиһан үз сүзен кыстырды. Күңел могҗиза көтә дигәч тә, төрле уйдырмаларга ышанмас лабаса! Ике атна элек кенә клиникадан аппаратурасын төяп килеп ике тапкыр тикшергән баш табиб: «Сезнең организмда бик аз гына тайпылышлар күзәтелә, тик зарарсыз. Кыска гына дәвалау курсы үтәрсез», – дигән иде. Әгәр ул шеш-фәлән тапса, ай-ваеңа карамыйча, шунда ук вип-палатасына ябар иде. Ул дарулар гына язып өлгермәде, хатын сәфәргә җыенган иде.

Гаҗәп, белекче аның белән бәхәсләшмәде, өстен юка ситса белән генә бәйләгән савыттан сөлек алды. Җиһан чытырдатып күзен йомды. Карчык «бисмиллаһ»

дигән саен, ул эченнән генә санап барды: бер, ике, өч... сигез... ун... Хәшәрәтләр тәненә кадалгач та, әрнүеннән үрле-кырлы сикерер кебек идең, баксаң, чебен болардан катырак тешли икән. Ләкин барыбер җирәнүдән күңел болганды.

– Чәбәләнмә, – диде кортка. – Начар каныңны суыргач, үзләре кубар. Миңсылу, син нәмә эш кырасың әле? Солы белән кәҗә сөте кайнаттыңмы? Иншә Аллаһ, җылы төнәтмә эчсәң, тыныч йокларсың, канәтем. Сөлектән соң йокы кирәк, тирән йокы.

– Мин сезгә хезмәтегез өчен түләрмен, Гамбәр әби. – Олы башын кече итеп икәүләшеп аны тәрбияләгән җиңги белән каенсеңелне ул йөзе белән бәхилләтәчәк иде.

Белекче сагайды:

– Нәстә белән түләрсең икән?

Хатын гадәти нәрсә әйткән кебек:

– Акча белән, билгеле, – диде. – Мин саран түгел, Гамбәр әби.

– Ярабби, кыягәз кисәге белән түләмәктә исәбе! Баедыгыз инде, хәрәм килешмәде генә!

Шунда гына нинди ялгыш сүз ычкындырганын аңлады Гөлҗиһан. Тик соң иде инде, соң иде. Нишләп ул кемнәр йортының капкасына кунган кош икәнен исеннән чыгарды икән?

Карчыкның ачу белән ялтыраган төймә күзендә рәхим-шәфкать юк кебек иде. Сөлекләр туенып, берәм-берәм коелды, Миңсылу һәр ярага канлы үлән суы сөртте. Төнәтмә дә эчелде, әмма кортка «вәгъдә иткән» тирән йокы гына «сай» иде. Гәрчә башы уйдан авырайса да, хатын иртән ниндидер бер җиңеллек тоеп, ятагыннан торып утырды, хәтта ки бүрәнә аякларын да идәнгә тидерде. Сузып-сузып кычкырган әтәчнең тавышын ишетүе дә күңелле иде. Ятсынган авыл тормышына күнегә микән әллә?

Чәче тузган, тарыйсы иде... Сумкада юеш салфетка бар, шуның белән бит-кулларын «юасы»... «Аһ, кичә ялгыштым!» – дип ут йотудан ни мәгънә? Кәкре барыбер тураймый. Нихәтле генә кузгатмаска тырышсаң да, үткәннәр, бүгенгесе белән тоташып, хәтер капкасын шакый. Унбер яшьлек Гөлҗиһан (әле бала гына!) барысын да бүгенгедәй исендә тота икән, кортка инде, кортка ул чактагы мәхшәрне күңел дәфтәренә үк теркәп баргандыр.

Юл сумкасы карават кырыенда гына иде, Җиһан актарынып салфетка эзләгәндә, кулына медицина кенәгәсе эләкте. Анализларымны юлда укып «ләззәтләнермен», дигән иде ул. Исеме дә «күңелсез дәфтәр». Анда озы-ын чир чираты. Ертып кына ташлыйсы! Нинди генә ысуллар белән дәваласалар да, хатын ябыкмады, киресенчә, авырлыгы арткан саен артты. Менә монысы баш табибның соңгы тикшерү нәтиҗәсе. Ни бу, йә? «Бавыр зурайган... Талакта шеш...» Әйтерсең, карчык белән икәү башта ук сүз берләштергәннәр!

**6**

Акча, акча... Нәселләре белән пот итеп шуңа табыналар. Шушы кыягаз дөнҗаларын болгата, шушы кыягаз акылларыннан яздыра...

Карчык умырып-умырып чирәм йолкыды. Эчендә тәгәрәгән ачу ташын тыярлык түгел иде. Аны да үзләренең былчырагына буямакчылар. Бары тик бер Кодрәтле Аллаһ ризалыгы өчен дәва өләшә Гамбәр. Болар күек малга хирысланса, күптән инде капка-ишек токтасын алтын йөгертеп ясатыр, вәләкин ул вакытта түргә шайтан менеп кунаклар иде.

– Бәй, җиңги! Ишегалдын шәп-шәрә калдырасың ла! – Каенсеңлесе анын

кулыннан тотып туктатты. – Әллә нишләдең әле син, карыябез. Теге калын катын килгәннән бирле пакуйсыз әле син. Элгәре алай пыжламый идең. Йөриләр иде лә моңарчы да халык. Берсен дә болай озак имләми идең. Шул катынга була женләнәсең лә, җиңги. Шуңа була көнеңнең көе бозылды. Кем ул, ә? Ник ул башта сине ят исем белән атады?

Карчык, чирәм чүбен учыннан кагып:

– Безнең туфрак баласы, – диде.

– Бәй, Айтуганнанмыни?! Кем кызы ул, җиңги?

– Син кемне беләсең соң, кыякламыш? Ничә былтыр аулдан эз суыткан идең, җә?

– Суыттым шул, суыттым. Сез Заретдин абзый белән әчелешле идегез. Ул – урманда, син Айтуганда яшәдегез. Мин сине барыбер туганым саныйм, син рәтләмәсәң – аяк черегән иде инде. Оныгың да, минем төсле, ярата үзеңне. Зур әни дә, Зур әни генә, ди. Карале, җиңги, – Миңсылу аның колагына пышылдады. – Карале син. Куып җибәр бу калын катынны, ә! Артык мәшәкать ул сиңа.

Оныгың дигәч, кортканың ирен читенә татлы елмаю җәелгән иде, каенсеңел аны тиз сөрттерде. Кария:

– Өйрәтмә! – дип, мүкәләп торып, сарай нүешендәге себеркегә ябышты. Җир себергәндәй шуның белән уңлы-суллы селтәнгәч, кире урынына сөяде. Аннары төбе ярылган чиләкне беләгенә асып, бакчага юнәлде. Койма кырыен сарган яшь кычытканнарны, яланкул черт-черт өзеп, чиләккә җыйды. Гаебен танып, артында Миңсылу мышный иде, ачуы сүрелгән карчык:

– Табигать анабызда ак белән карадан гайре хәттин төс бар, кем кыз, кечеткән, әнәгенәк, яшел, тузганак чәчәге, әнәгенәк, сары, – диде.

– Һи, җүләрмени! Ансын гына аерам ла!

– Аермыйсыңдыр, кем кыз. Адәм күңеле табигать күек төрле төсләр белән бизәлгән. Сиңа нәбары карасы гына күренә.

– Үлеп яклыйсың бай катынны! Әллә инде акчасына кызыгасың, җиңги? – дип телләшкән каенсеңлесенең ул борылып итәгеннән тартты:

– Көфер сүз сөйләмә, кем кыз! Чиләкне ал!

– Нәмәстәгә бу кечеткән, ә? Тавыкларга тапаргамы?

– Кайнар су белән пешекләп, вак-вак тура да киндер мае куш. Кунакка иртәнге ризык шул.

– Хуп, үлән тамагыннан үтәр микән әле?! Алар бит тамаксау халык, тәмледән-тәмле ашап бозылган.

– Һәркаюсына бозылыр өчен бер сәбәп җиткерелә, кем кыз. Беребез дә фирештә түгел. Әүвәле гөнаһ кыла-кыла кыек юлдан барабыз да соңра, Аллаһка кайтыр алдыннан, турысын эзлибез.

Каенсеңел бакчадан чыккач та, кортка үз-үзе белән «гәпләште»:

– Син соң, Мифтахетдин карт Гамбәр диеп колагыңа кычкырган кария, аклык-пакьлек өлгесеме? Сиңа чәнти бармакка сыланырлык та гөнаһ тузаны кунмаганмы? Һә-һә, мин гаепсез, алар нәселе миңа былчырак чәчрәтте димсеңме? Бүген: «Шакшы кыягазга буямакчылар», – дип тузынуларың давылга йодрык селкүдер, Кария! Холыксыз син, холыксыз! Шушы баш бирмәс холкың аркасында Заретдин җәфаланды, улың ана назы күрмәде. «Моннан ары тыныч кына яшәүләр юк», – дигән ирең никах көнендә үк синнән бизгән иде... Даланыкылар, мөгаен, сез качкыннар артыннан ат чаптырмагандыр. Син: «Без – энә», – дидең, табалмаслар, дидең, ә үзең йөрәгеңә курку уты үрләттең. Озак яндырды ул, озак... Гөнаһ касәсенә беренче тамчы әнә шулай тамды. Югыйсә Аллаһы Тәгалә ихтыярыннан башка адәмне черки дә тешләми! Иренең

туган авылы Айтуганда ул, ниһаять, бөтен шик-шөбһәләреннән арынып, җан тынычлыгы белән гомер күперен азагына кадәр кичәргә тиеш иде. Күпердә әллә ничә кат абынды шул. Заретдин белән татулык бетеп, гаилә ике сыйнфый дошманга таркалды. Мәктәптә укытуын ташлаган мөгаллимне клуб мөдире итеп куйдылар. Беркөнне ул, кызыл кенәгәсен хатынының борын төбендә болгап:

– Мин – коммунист! – диде. – Димәк ки, кем белән түшәк бүлешкәнеңне бел. Кисәтәм: әгәр авылны дин сөреме белән агуласаң – үкчәңә ут ягып, далаңа куам, – диде.

Гамбәргә кабарынган әтәч-ирнең кикриген хәйлә белән генә шиңдерергә иде. Хатын-кызда тимер эретерлек наз-җылы бар, ә Гамбәр – дуамал бичә, киресенчә эшләде:

– Син – мөртәт, син – иблис! – дип, Заретдинны боз итеп катырды. Холык күлмәк түгел, салып кына ыргыта алмыйсың шул.

Сугыш елларында сукага җигелеп җир сөргән Шәмсекамәр каенана авыр эштән өзлеккән иде, килен аны бала кебек тәрбияләде. Өйдә иртә-кич дога тавышы тынмады. Ир ашарга утырганда, ул отыры көчәя һәм Заретдин кашыгын бәреп торып китә, йорт тирәсендә кайнаша, инде хатын көйләп аргандыр дип керсә... авыру әнкәсе дәвам итә. Каенана Гамбәрне яратты, кызым, мин бәхил, диде. Зинһар, ничек тә улымны иманга күндер, шайтан төркемендә буталып дененнән язмасын, диде. Һай бичара ана! Заретдинның niләр кыланганын белсә икән! Беркөнне ир манарасын кисеп, клубка әйләндергән мәчет кыегына кызыл әләм кадаклаган һәм, Айтуган урамын яңгыратып:

– Без искелек калдыкларына каршы көрәш башлыйбыз, яшәсен яңа тормыш! – дип кычкырган. Черек баскыч тактасы сынып, җиргә мәтәлгәч, ул халык алдында катлап-катлап сүгенгән. Йа, шуннан соң аны иман белән әдәпкә өндәп кара! Күрәселәр алда икән әле. Шәмсекамәр каенананың соңгы көннәре якынлашкач, Гамбәр сандыктагы кәфенлекне барламакчы иде, Заретдин үз законын «төзеде»:

– Әни белән клубтагы «кызыл почмак»тан хушлашабыз. Чүпрәк-чапракка чорнамыйбыз, күлмәктән генә җирлибез! Мин – партиягә тугры коммунист, миңа фәлән йола, тегән йола, димәгез! Мулла-мунтагай капкама якын килмәсен!

Монда да телеңдә былбыллар сайратып ирен көйләргә-чөйләргә кирәк, ахыр чиктә Заретдин хатасын аңлар, бит ул татарның гореф-гадәтләрен санлап, Аллаһның берлеген һәм барлыгын танып яшәгән нәсел кыйпылчыгы иде. Әйт идең аңа Гамбәр, сезнең бүгенге ясалма дөньягызның нигезе бисмилласыз корылган. Көннәрдән бер көнне ул уптым ишелер дип, әйт идең! Галәмдә чиксез «блач» хуҗасы Җәнәбел Аллаһ кына, ә сез – «кызыл авызлар» оештырган «тәхет» вакыт узу белән җимерeләчәк дип кисәт идең! Тик син ирeңне иплəп-җайлап кына вәгазь белән сугармадың, кана, ә бәлки, эчеңнән генә: «Мин синнән көчлерәк, мин сине җиңәм!» – дидең.

Юл аягы дип, көтүче Сафиуллага ун йомырка тоттырып, Мифтахетдин абзыйларга җибәрде хатын. Карт җилле иде, «кызыл эне»сен тиз агартты, таягы белән кизәнеп:

– Миңа шайтан указы чыгарма! Әбиләребез ничек җирләнсә – сеңел дә гүргә шул рәвештә иңдерелер, – диде.

Заретдин, билгеле, абзасына кенәгәсе белән мактанмады, әллә оялды, әллә әнисенең үлеме бәхәстән тыйды: мәрхүмәне бөтен шартын китереп, җеназа догасы укып «мәңгелек йорт»ка озаттылар.

Карт яшьләрнең тормышына тыкшынмаса да, саубуллашканда:

– Сез, балалар, ике кылый күз сымак икегез ике якка карыйсыз икән.

Хәерлегә түгел бу, балалар, – диде. Шуннан соң ир әтәчләнеп йөрүләреннән туктады. Күмәк хуҗалык умартачысы Нәкыйп бабай үзенә ярдәмче итеп чакыргач, бишкуллап ризалашты. Гамбәрдән читләшүе, Гамбәрдән ераклашуы иде аның. Әле хатынга чатнаган гаилә пыяласын җилем белән булса да ябыштырып куярга мөмкин, барысы да аның тәмле теленнән тора. Әгәр ул: «Җаным, кичер, мин дә киреләнеп ялгыштым», – дисә, Заретдин кичермәс идемени?! Әмма яшь хатынның «кирелеге» төзәтелмәслек иде инде: ул хак дин юлына баскан иде. Сайла: йә иман, йә ир...

Сайлады... Заретдин артыннан моңсу гына карап калды. Сирәк-мирәк кенә өйдә күренгән хуҗа, малай тугач, канатланып яңа йорт та тергезде. Ул, мөгаен, бала баккан Гамбәр элеккеге гадәтен ташлар да догалар белән өшкермәс дип өметләнгәндер, хатын исә иремә яраклашам дип кенә күңел дөньясын яктырткан нурны кара пәрдә белән капларга теләмәде. Авылда йорт борынча аятелкөрсиләр яндырган мөртәтләр, куштанланып, район үзәгенә жалу сырлагач, күзе – боз, йөзе – калай ике блач кешесе өйгә бәреп кергәндә, Гамбәр намаз укый иде. Алар аны намазлыктан суырып алмакчы иде, куллары «тыңламады», өстенә җикеренмәкчеләр иде, авызлары бөрештe. Күрше Ярулла: «Сез аның белән ник булышасыз, тиленең тилесе бит ул катын, шуңа аңардан иренең дә гайрәте чикте», – дигән. «Тиле» кушаматына төренеп, җил-яңгыр тидертмичә генә яшәве җиңел икән, хатынны бүтән «дин тарата», дип, ачыктан-ачык эзәрлекләмәделәр. Шөкер, Айтуганда халык ул кадәр үк шайтан көтүенә иярмәгән, аның гомер бакый Аллаһны теленнән төшермәгән карт-корысы исән, нәкъ менә алар өчен «блач» бер дә абруй түгел иде. Тик кайчакта изгелек чиксез гаскәр тупласа да, явызлык белән көрәшкәндә, җиңелә. Азан тавышына тилмергән бабайлар җәйге айларда зираттагы тавык кетәклеге хәтле генә такта куышта җомга намазына җыела иде, мөртәтләр шуны да ут төртеп яндырды. Иске нигез «эшкә» яраклы иде әле, Гамбәр аны эчтән сылап, диварын акшар белән аклады, идәненә корамадан теккән келәмнәр җәйде. Йорт җыйнак кына мәчеткә әверелде. Ире белән генә киңәшмәде менә. Заретдин урман каравылчысы дәрәҗәсенә кадәр «үскән» иде, бер кайтуында биш яшьлек улы Рәшитне тезендә биетә-биетә:

– Улым, әзрәк исәйгәч, атаң янына күчәсең. Урманда өй салу безгә малмыни! – диде. – Әнкәңә ышанма, бу йортны да мәчет итмәгәе, – диде.

Җомга иртәсе иде, таң белән мунча яккан хатын иренә чиста күлмәк-ыштан сузды:

– Юын, Заретдин. Бабайлар өйлә намазына килә, син дә аларга кушыл.

Урман хуҗасы бүре төсле авызын күккә төбәп улады:

– У-у-у!

Суксын иде ул шунда, тәгәрәтеп җибәрсен, ләкин болай улый-улый зәһәрен тышка төкмәсен иде. Ир кичкә кадәр Яруллаларда югалып торды. Күршенең Рәшит белән яшьтәш малае Сәмигулла гына балалыгы белән тәтелдәде:

– Әтиләр утлы су эчәләр дә, шәп кыздыра дип, күкрәкләрен кыйныйлар, – диде.

Ауган-егылган коймасын да төзәтмәгән ялкау Ярулла, димәк, җиңел генә акча көрәмәкче иде. Моны йә шайтан кәсебеннән тыярга, йә «көрәге»н сындырырга! Имеш, «утлы су» белән гаиләсен туендыра. Гамбәр беркөнне күршеләренә ярты капчык бәрәңге белән өч түгәрәк мич ипие кертте. Ярулла япмасыз озынча такта өстәлгә терсәге белән таянып көнбагыш чиртә иде.

– Әйдүк, Зартдин катыны, әйдүк!

– Гыйльменисаң өйдәме?

– Әнкәсендә. Идән-сәке юам, дигәние.

– Мин сезне хәләл ризык белән тукландырам, Ярулла. Биш әпәй пешерсәм, өчесе сезгә булыр. Хәрәмнән бизгәнчегә тиклем.

– И рәхмәт яугыры, – дип, ипи сындырырга үрелгән күршесенә ул:

– Башта бисмилланы әйт! – диде.

– Бисмилла инде, бисмилла! Бигрәк син, Гамбәр! Оныгыз күп шул, ник безне дә сыйламаска ди!

– Мин сезне сыйламыйм, Ярулла! Күзегезне ачам. Хәләл белән хәрәмне аерыгыз, дим. Шартым бер генә: көмешкә кайнатып сатуыңны ташла! Ир-атны исертеп, авылдан бөтенләй бәрәкәт качырсаң – тәмугта янарсың!

– Инде дә син, Гамбәр катын! Мин аны чувашларга гына аткарам. Син кушканча, «бисмилла» дип агызам да бирәм фелэгедән. Хи-хи!

– Аллаһтан курык, күрше. Янәшәңдә мәчет.

– Мәсҗед? – Ярулла тыгыла-тыгыла ипи кисәген чәйнәп йотты. – Нинди мәсҗед? Әллә җеннәрең күзеңә күрсәтәме?

– Иске йортыбызда картлар намаз укый.

– Манарасы кайда соң? Шунсыз ул мәсҗед булалмый берничек тә!

«Булалмый, булалмый...» Гамбәрнең җанын шик корты кимерде. Әйе, Ярулла дөрес сукалый, дөрес. Манара кирәк! Хатын чыкканда, өйалдындагы тимер әйбергә бәрелде. Сасы ис аңкыган тоткалы фляга иде ул, Гамбәр аңа җирәнеп бер генә карады, бер генә...

Икенче көнне күрше хатыны ишек дөбердәтте.

– Гамбәр, Гамбәр! Ярулла үлә!

Ишегалдында яртылаш бөгелеп укшыган (әйтерсең, тамагына очлы сөяк кадалган эт!) ирне ул җилкәсенә баскалап турайтты. Күзеннән яшь атылган Ярулла:

– Кара, җиңеләйтте, – диде. – Атакайгынам, үзалдына ютәлләтә. Уф, коткардың, Заретдин катыны. Чуваш Әндриенә ашыгам әле. – Ир баскычтагы көмешкә савытын күтәргән генә иде, тагын буылды. – Фу, әкәмәт сасы!

– Бу ис тончыктырмасын, дисәң – хәрәм кәсебеңнән баш тарт! – Гамбәр сүзен кыска тотты. Ә җәнҗалның буе озын иде, аның ни-нәрсә турында кисәтүе иртән генә күршеләрен «уятты». Башта тавык-чебешләргә җим сипкән Гамбәрне нәҗескә «коендырдылар»: сыер тизәген көрәк белән койма аша гына алдылар – очырдылар, алдылар – очырдылар. Ярулла хатыны ярсый иде. Ул моның белән генә канәгатьләнмәде, теле белән дә «чыбыклады»:

– Иремне әфсенләде, килмешәк! Яхшы гына акча эшләгәндә, җеннәреннән будыртты. Бездән көнләшә, килмешәк!

Гамбәр тавыш-гауганы йөрәгенә кагылдырмыйча тыныч кына уздырды, аның бөтен уе – манара иде. Ул киңәш-табышка дип Мифтахетдин бабайларга китте. Карт әле көч-куәтендә, ат җигеп еш кына Айтугандагы яшьтиләренә кунакка килә, кайчакта Гамбәрләргә дә кагыла иде. Ә бу юлысы аның чырае бик төксе иде. Ул:

– Тәки ирең белән татулашмагансың икән, килен, – дигән иде, хатын коры гына:

– Минем йомышым бүтән, Мифтахетдин абзый, – диде. – Авыл мәчетсез бүгенгесендә. Бездә халык җебегән! Әнәгенәк, Чәтрәннәр көрәк-сәнәк белән иман йортын саклаган.

– Без белмәгәнме бу хәлләрне, килен? Белгән, бик тә белгән! Шушымы йомышың?

– И, үз йомышың белән вакланыр чакмыни, Мифтахетдин абзый?! – Хатын сыкранды. – Әллә, дим, иске йортыбызның түбәсенә манара бастырыйкмы? Адәм буе тикле генә. Блачлардан яшереп, ә? Бакчада бит ул, тирә-ягы агач-куак, дигәндәй.

Карт та ачылды.

– Бәракалла! Заретдин урманчы, дүрт агач егып тактага ярдыртса – ник бастырмаска ди.

– Заретдин, дисең дә син... Энең ярты ел кайтмый әле.

– Ту-ту, килен! Көлдергән дә катын, елаткан да катын. Ирең бизгән икән, гаеп – синдә!

– Миндә, миндә, Мифтахетдин абзый.

– Ту-ту, килен! Чәчегез – озын, акылыгыз – кыска. Заретдин булышмаса – аксакалларга эндәш. Ил төкерсә – күл була.

Гамбәр монысын да яшермәде:

– Бабайлар безнең капкадан йөрми. Иске йортка бакча артыннан сукмак салдылар. Алар мине үги итә, кушаматым да Килмешәк кана.

– Тр-р, килен! Ата-баба ничәмә-ничә чакрымнардан кыз димләгән, вәләкин берсен дә рәнҗетмәгән. Синдә икенче мәсьәлә. Мәрхүм Сабирҗан кари тәртипкә өйрәтмәдемени? Кыз-катынның төп бурычы өй эчендәге җәмәгатен тәрбия кылу, димәдемени? Син бит, килен, урамга ташыдың? Сораштырам мин синең хакта, әмма да ярты кәлимә яхшы хәбәр ишеткәнем юк. Ник Чокыр Талипның битенә туфрак сиптең? Ник Камәрне себерке белән кыйнадың? Күрше хакы – Тәңре хакы, дигән борынгылар. Ник син Ярулла белән әрепләштең? Знамы аул мондый тәртипсез катынны яратмый, знамы картлар, җиле тимәсен, дип аулакта сукмак сала. Бөтен гаеп синдә, килен! Кешеләрне үзеңә каршы куеп бә-әк ялгышасың.

Мифтахетдин абзый санаган гаепләр «Ике күзем чәчрәсен, минем малкай», – дип, урлаган сарык бәрәнен сатарга маташкан Талип, чишмәгә мәче үләксәсе ыргыткан Камәр, ир-атны көмешкә белән тилерткән Яруллалар белән генә чикләнсә икән! Картның бәнахакка тиргәве йөрәген әрнетсә дә, Гамбәр акланмады. Аны барысы да үзгәртергә тырыша, ә ничек үзгәрсен соң ул, ничек?! Караны ак дип тәкрарласынмы? Имансыз адәмнәрне хуплап кул чапсынмы? Әллә битарафлык кабыгына төренергәме? Син – сукыр, син – чукрак, әйеме? Бәлки, бәлки! Яратмыйлар, тиргиләр, яманатын җилгә чәчәләр, ә үзләре, әз генә бәлагә тарсалар, ярдәм ит дип, аның бусагасына егылалар. Хак, яман уй-ният белән капкасына орылсалар, кулына ни эләксә – шуның белән аркаларын да кашый Гамбәр.

Бәдерниса карчык метердәгән картына баядан бирле сүз катмакчы булып өтәләнә иде. Ул:

– Атасы, самавыр кайнады, синең дә, кунакның да тамагы кипкәндер, теге бөртекле әҗмуха чәйне табалмыйм гына, – дигәч, мыжыкның әр-битәреннән туйган Гамбәр:

– Ат арбасындагы печән астында әҗмуха, Бәдернисәттәй, – диде.

Киленен «фаш» итеп гайрәт чәчкән карт кинәт кенә үзгәрде.

– Син нәрсә дисең, кызым? Манара, дисеңме? Азансыз авыл – нурсыз авыл. Минем дә шуңа эчем поша. Эшләрбез, боерса. Син моны безгә – ир-атларга тапшыр, әһе.

– Кайсы җүнсезе әрбир яшереп шаяра икән, – дия-дия, Бәдерниса карчык чәй эзләргә чыккач, хуҗа яңадан «зурайды»:

– Ай-һай, усал син, килен!

– Аръяктагы ялгызак Зәйтүнә әби тәмле кытай чәе эчеп кенә яшәрмәс инде, Мифтахетдин абзый.

– Болгатма инде, килен. Яшь чакта ярлы идем, шул иркә җанга бүләк бирәлмәдем. Чәйне Бәдернисага белгертмә, талап үтерә.

Гамбәр әле усал гына түгел, явыз да иде. Нигә бичара картның бәгырен

чеметергә ди инде, йә? Битәрләр-битәрләр дә, теле арып, туктар иде. Андый бөртекле чәй үзендә бар, ул аны тансыкка дип саклады, тик эчмәде, чөнки киптергән үләннәргә берни җитми иде. Кызулатып өенә кайтты, кызулатып Зәйтүнә карчыкларга барды. Халат кесәсендәге төргәкне әбинең учына салып:

– Мифтахетдин абзыйның күчтәнәче, – диде.

Бит очы алсуланган Зәйтүнәттәй дә, карт кебек сызланып:

– Кавышалмадык без, – диде. – Мине әтиләр әтрәк-әләмгә димләде. Мифтахетдин шуннан соң күрше авылда йорт җиткереп өйләнде. Онытмый үзе, әле дә ат белән турдан үткәли, – диде.

Кортканың яшьлек хатирәләрен тыңларга вакыт тар, вәгъдә – иман, «без – ир-атларга тапшыр» дигәч, Заретдин туганы озакка сузмас, манара хәстәренә керешер, шуңа күрә иске өйнең череп каралган салам түбәсен куптарырга кирәк иде. Биеклектән дөнья тәрәзәсе ачыла икән. Гамбәр тирә-юньгә күз ташлады. Әнә тыкрык буендагы Газизҗан утын яра. Төнлә урлап ике каен кискән... Урман каравылчысы кулына сукмаса, тагын аударыр. Шәкүрләр ишегалдында бала-чага әүмәкләшә. Тугыз тере «керпе»... Ә Гамбәрнең сыңар бала... Анысы да, бүре төсле, муенын гел урман тарафларына каера: өч көн авылда, ун көн атасы утарында. Чү, борын төбендә генә күршеләр ни майтара?! Йа Аллам, Ярулла поши тиресе туный! Яңа кәсебенә керешкән: киек-җанвар ата, кабахәт!

– Кансы-ыз!

Бу дәһшәтле тавыштан пыжымлап, Ярулла сарай нүешенә посты.

– Нәстә бу? Сиңа әйтәм, аңгыра! Болыт акыра!

– Син үзең аңгыра! – Гыйльмениса кулындагы табагы белән иренә кизәнде. – Кара, турыга кара! – Ярулла хатынының күзе очлы, ул Гамбәрне бая ук шәйләгән иде. – Салам түбәгә сары сандугач кунган, аты Гамбәр имди.

Ярулла, пычагы белән һаваны кискәләп:

– Әй син, куркытма! – диде. – Заретдин күрше миңа үзе куша, быел пошилар ишәйде, атып итлек яса, ди. Син бусы ярый, бусы ярамый, дип закун язма! Мин симиямны туйдырырлык кына ит табам, – диде.

Ләкин күршеләр йортында хайван каны елга кебек акты. Атты да сатты Ярулла, атты да сатты. Бәндә түзсә дә, Аллаһы Тәгалә түзми икән: тамагына поши итенең сөяге кадалып, хәсрәт аучы гомер төенен төйнәде, тик ул чәчкән комсызлык орлыгы шытып, яңа җәллад баш калкытты: атасының дәвамчысы булып улы Сәмигулла мылтык күтәрде... Җәза бары Аллаһтан, бары Аллаһтан, ә Ярулла хатыны иренең үлемен Гамбәрдән күрде:

– Син каргадың, килмешәк! – диде.

Билгеле, уллары Сәмигулла боларны ишетеп үсте, эченә үч-нәфрәт җыйды. Бәләкәй генә манара торгызылып, авыл азан белән яктыргач, хатын адәм баласы үзгәрер, хөсетлек, яманлык, көнчелек кебек начар гадәтләреннән арыныр, савaплы гамәлләр генә кылыр дип уйлаган иде. Сизде югыйсә, киләчәктә ни-нәрсә сагалаганын да сизде... Һәр иртә, офыкта кояш керфеген тибрәткәндә, улы Рәшит азан әйтә һәм Гамбәр бу мизгелдә учына коелган алтынсу-зәңгәр нурларны Илаһ сөеп яраткан барча-барча җан иясенә өләшергә әзер иде. Әмма бәхетнең гомере бик тиз кыскарды. Беркөнне Заретдин кайтты. Ир күптән инде өйдә үзен кунак сыман гына тота, хуҗалыкта салам да селкетми иде. Хәл-әхвәл сорашмады, кызган табадагы май кебек чыжлады:

– Урманда яши дигәч тә, без саңгырау мәллә? Гайбәтеңне минуты-секунды белән ирештерәләр! Мифтахетдин абзыйдан иске йортка манара куйдырткансың икән. Ярар, ул әлиф белән таяктан гайре хәреф танымаган

надан карт безелдәп чапсын да ди! Син соң, син, дала чәчбие, әзрәк башыңны эшләтер идең! Партбилетымнан колак кактырасың бит! Ничек аңламыйсың икән, бүген коммунистлар заманы!

– Әкрен, Заретдин, әкрен. Заманның әүвәлгесе дә, алдагысы да сезнеке түгел.

– Әнә, әнә, тиленең гел тилеләрчә! Ярар, минем тормышымны ватсаң – ват, ну малайны дин сазлыгына батырма. Баладан азан кычкырта, имеш, адәм хуры!

– Аңа унике яшь, Заретдин.

– Вәт, вәт! Рәшитнең киләчәге турында да кайгыртырга вакыт, дала чәчбие. Авыл мәктәбендә белем сай. Мин аны үзәктә укытам, аннан урман техникумына илтәм. Икегез дә җыеныгыз!

– Кая?

– Кая, кая! Утарга. Анда сиңа да акчалы эш бар. Хатын-кызлар белән имән чикләвеге җыеп тапшырырсың.

– Мин авылда да эшкә тилмермим, Заретдин. Абзар тулы тояклы. Сыер бозаулады, сарыклар бәрәнләде.

– Терлек-туарыңны Яруллаларга куып кертербез. Кәтүк хәтле генә малай әнкәсе белән ит сата. Кеше баласы уңган, тырмашып көн итә, безнеке сыман манарага үрмәләми!

Хатынның йөрәге сикерде:

– Шул кәтүк урманда поши аулый! Син бит каравылчы, нишләп аның колагын бормыйсың?

– Ауласын! Поши әрсез, тиз үрчи.

Гамбәр, иренең битараф кыяфәтенә рәнҗеп:

– Без беркая да китмибез, – диде.

– Хуш, китмә, син кал! Кирәгең шулкадәр генә. Рәшит белән икәү дә рәхәт миңа.

– Ул әле бала гына, аны миннән аерма, – дип инәлсә дә, Заретдин боз иде, эремәде. Әй, ул чакта иренең диварлар ишеп акыруы!

– Син кем, ә? Кем?! Анасы?! Кит аннан! Менә яңалык! Әни кеше баласына җеп кебек тагыла. Артыннан бер тотам калмый. Нишләп син шушы авылга беректең, дала чәчбие?! Туган илкәйләреңмени!

«Ник мин урманга качыйм ди. Мин монда кешеләргә кирәк. Бәндәнең яхшысын догам белән сыйпармын, яманын каты кулым белән суктырырмын, вәләкин ансын да яратырмын», – дисә, Заретдин аю кебек үкерә-үкерә җир тырмар иде. Бит ул хатынның авыру-сырхауларны өшкерүенә катгый рәвештә каршы иде.

Кешеләр, кешеләр... Кемнәр өчен ире белән улыннан ваз кичте икән ул, йә?

...Гамбәр таң атканда гына аңына килде. Эт чиный-чиный аның битен ялый иде. Нишләп җирдә ята икән ул? Бу төндә яшәүдән киселеп торды микәнни? Әллә соң Бөек Кодрәт иясе, һушыннан яздырып, йөрәге ярылудан сакладымы? Чирәмдә капкага табан ярылган тәгәрмәч эзләре... Улын урлаган чыклы эз... Бигрәк мәрхәмәтсез икән син, Заретдин! Икеләтә хәсрәткә батырдың, тәкәббер ир! Мәчет тә ятим. И Аллаһым минем, авыл шулай азансыз гына уяныр микән инде?

Хатын, вакыт белән узышкандай, сад-бакчага йөгерде. Сиртмәле коеның капкачын каерып атып, чиләген аска чумырды. Салкын су аны тәмам айнытты. Иртәгесен картлар белән киңәшер, бүген үзе азан әйтә, үзе! Их, Заретдин, Заретдин! Кызыл кенәгәң белән Илаһ каршысына басасыларың алда әле!

Ни хикмәт, ашкынган хатын баскычтан менә алмады! Кисәк кенә тезләре сыгылды. Нindидер билгесез көч аның хәлен суыра кебек иде. Идәнгә йөзе белән егылган Гамбәр сытылып-сытылып елады. Ул хатын-кыз иде, манара аны кабул итми иде...

## 7

– Ай, берәвесе үлем йокысы белән исергән! Уян, патша кызы! Бәхетеңне йоклама тагы.

Миңсылу аның өстендәге юрганын тартып төшерде.

Гөлҗиһан аңгы-миңге сыман иде. Аны нишләттеләр икән? Шәһәрдә төннәр буе керфек тә какмый иде, ә монда гүя мәңгелек йокы бишегендә тирбәтәләр.

– Бит-кулларыңны чылатмыйсыңмы? Хәзер ләгән белән комган апкерәм. Чистый хезмәтчең ясадың инде, гөлкәем, – дип сукранган каенсеңелне ул бу «авыр хезмәте»ннән азат итеп:

– Рәхмәт, мәшәкатьләнмә, мин тышта юынам, – диде.

– Синең түшкәңне сөйрәргә бездә Алып батыр юк, гөлкәем.

– Үзем чыгам, апа бәгърем.

– Шулай шул, әзрәк кыймылдасаң – корсагың шиңәр иде. Алай да тамагыңа кап син, гөлкәем. Иту ач ятып җаның күкләргә ашмасын!

Хатын, муенына сөлгесен урап, ишеккә табан китте. Әлеге дә баягы табанын йөзләгән энә чәнчә иде. Әмма бу авыртуның ләззәте дә бар иде. Ул бит җирдән шуышмый, ул атлый! Ходаем, берүк адымнарын чикләмә! Сәгать саен арттыр! Офыкка кадәр йөгерсен Гөлҗиһан!

Ишегалдындагы чирәмгә тавыклар сибелгән иде, алар дәррәү хатынга иярде. Мәхлук тавык, ишектә кем генә күренсә дә, җим теләнә. Әтәч исә алдатмады: читтән генә «бичәләре»н күзәтте, ә инде алар хатынның кызылга буялган аяк тырнакларын шык-шык чукыгач, тамак төбен гыжлатып кычкырды:

– Кикерикүк! Ахмаклар! Җиләк түгел, буяу бит! Кикерикүк!

Җиһан көлде:

– Орышма, әтәч, – диде. Тавыкларың да: «Йөр, йөр», – дип, мине үсендерә, ахры, – диде. Озынча такта өстендә чиләкләр тезелгән иде, изүенә су агыза-агыза юынды «чакырылмаган кунак». Аңа рәхәт иде, гәрчә ул нибарысы мизгел белән генә исәпләнсә дә, рәхәт иде...

Баскычта Миңсылу боерды:

– Озак маташма, тәгамең суына!

Карчык белән исәнләшим дип, хатын як-ягына каранды, әмма хуҗабикә күренмәде. Йоклый, ахрысы. Иртәнең дә иртәсе шул. Әнә иркә кояш та ялкау гына нурын чәчә. Аңа да йокы татлы.

Тәгам дигәнең вакланган кычыткан бәбәнәге белән калай кәндинең төбенә генә сыланган карабодай боткасы иде. Бер генә кап, бүтән үрелмә!

Ишектән башын тыккан Миңсылуның авызы ерылган иде.

– Бәй, моның хәтле ашасам – күбенәм, дисең мәллә? Миңа турсайма, мин җиңги кушканны гына эшлим. Аның каравы, банкада дәрья суы. Эч тә эч, гөлкәем.

– Нишләп ул яшькелт?

– Яшь әрем төнәтмәсе чөнки. Эчеңдәге шакшыларны чистарта, ди әбиең. Әле син бәхетле авыз, җиңги алдыңа кашык очына эләктерерлек ризык куйдырта. Сөйләсәм – ышанмассың, гөлкәем. Өч ел элек аңа олы абзасы бирән энесен китерде. Сыер төсле көн-төн күши, ди. Өйдә ни бар – кырып-себереп ашый, ди. Врачларның даруы отыры апититын кузгата, ди. Катыны аш-суын яшерә башлагач, бирәнкәем күлдән бака сөзеп кыздыра, ди. Ун көн коры үлән суында тотты җиңги. Абзасы аяк-кулын чылбырга бәйләп саклады, иту ачтан үтерәсез дип дөньяны ишә иде.

– Ай-яй, мәрхәмәтсезләр! Кеше бит ул, эт түгел!

– Алла, – диде Миңсылу, – алайса бер тамагыгызга хуҗа булыгыз. Сезне кем монда ялынып-ялварып чакырган ди!

– Мин алай күп ашамадым.

– И алдама сана! Сез – байбикәләр майлы кабып, озак йоклап симерәсез. Йә, кайсы ярлысы мендәр хәтле корсак күпертә?

– Без – эшлибез, безгә акча күктән яумый.

– Ява, ява! Халыктан талаган алтын тәңкәләрне банк дигәннәренә генә аударасыз.

Авызында әвәләгән тозсыз ботканы кире төкерердәй булды Гөлҗиһан. Бу авылга ялгыш кайтты, ялгыш... Ярты кашык ризык өчен аның җанын суыралар. Чит ил клиникасында гына тапаласы-туналасы иде. Ә ул шушы тишеккә ашкынды. Кеше туганына да болай өмет багламас, хатын исә: «Коткарса карчык кына коткара», – дип саташты.

– Җәтрәк селкен, гөлкәем. Сиңа җиңги казык какты.

– Нинди казык?

– Әйдә, башта капка төбенә чык!

– Гамбәр әби уянсын әле.

– Һи, көт! Ул таң зәрәсе белән каядыр олакты инде, гөлкәем! Бик иркенәймә, яме? Әбиең сине миңа беркетте. Миңсылу, ди, теге нәмәстәне кымтырат, бүксәсендә җиде май катламы үстермәсен, ди.

Бер ишәккә ике хуҗа! Мондый дорфа сүзләргә үпкәләсә дә, Гөлҗиһан үз хокукын дауламаска тиеш иде. Аңа бары тик буйсынырга гына кала, чөнки ул хуҗаларның тансык кунагы түгел иде.

Казык дигәнең егерме-утыз адымдагы озын таяк иде. Үгез котырткан төсле аның очына кызыл чүпрәк бәйләгәннәр җитмәсә.

– Агачка тотынма түлке, кулыңны селтәп атла. – Миңсылуның йөзендә тантана иде. – Йәле, йә, ташбака көнләшсен! Кем ул анда мине уздыра, дисен. Йәле, йә!

Хатын бу юлысы аяк табанын яндырган энәләрне санамады, иртән алар бихисап иде. Ә хәзер әллә кимегәннәр, әллә тәне авыртуларга ияләнә башлаган иде. Әле «башлаган» гына иде шул. Әле ни уртасы, ни азагы! Казык гүя җанлы, һаман артка «чигенә» иде.

– Йәле, йә, тизрәк! – дип кул чәбәкләде Миңсылу. Хәер, аның үзенә дә таякның юан башы эләкте. Җиһан тирләп-пешеп чоланга кереп утырганда карчык та кайтты. Ул көянтәсенә капрон чиләкләр элгән иде.

– Уф, җиңги, тагын нәстә күтәрдең инде? – дип, каршысында тыпырдаган каенсеңлесенә:

– Ник мунча якмадың? – диде.

– И җиңги былбылым, хәзер генә калын катын белән әвәрә килдем. Казык кактым да берчәк тәпиләттем үзен!

– Сиңа кем андый вәкаләт бирде?! – Карчык аяз көндә яшен яшьнәтте. – Аны ирексезләргә кем боерды? Ник минем эшемә катышасың? Раббымыз миңа турылаган бәндәмә берегез дә хан-солтан тегел! Бистәдә ызба саталар, дисеңме? Акча сандыкта, шунда көч, кем кыз!

Миңсылу бирешмәде:

– Әзрәк кул-аягын селкетсә – файдага бит инде, җиңги, – диде.

– Нәстә файда, нәстә зарар, бер Аллаһ кына белә, кем кыз!

– Бистә дия-дия тәки канымны эчәсең, җиңги. Әй, тартар теленнән табар, ди. Никләр ызба турысында сиңа белгерттем икән, җүләр.

Бу ызгыш-талашның сәбәпчесе Гөлҗиһан иде. Аңа була ике карчык пыр тузыша.

Әйтерсең, дөнья җимерелгән! Көенеч артында сөенеч тә бар лабаса: хатын үз аягы белән казыкка хәтле теркелдәде. Димәк, авыртуын җиңде! Ул Миңсылуны яклап тәрәзәчектән генә кычкырмакчы иде, кәефе бозылган Гамбәр әби «төзәлеп» өлгерде:

– Син, кем кыз, монау балчыкны такта өстенә җәй. Кояш җылысы сеңсә, дәвасы артыр, иншә Аллаһ.

– Абау, чи балчык! Авырлыгын күр син! Җилкәң уелгандыр, җиңги?

– Барсы да Раббыбыз кодрәтендә. Кирәксә, ул авырын җиңеләйтер, җиңелен авырайтыр. Мунчада Гөлҗиһанның тәненә тозлы балчык сыларбыз, кем кыз.

– Моңарчы сырхаулар белән болай ук кайнашмый идең, җиңги.

– Һәркаюсына үз шифасы, кем кыз.

– И җиңги, кундырыплар ук яткырмый идең инде. Монысы туганыңнан да артык ахрысы.

– Алар нәселе – бәгыремә укмашкан таш, – диде карчык, ләкин каенсеңел аны ишетмәде, ул балчык белән мәшгуль иде. Гөлҗиһанның исә башы шаулады, әйтерсең, кортка бәгырендәге шул таш белән аның маңгаена орды. Тәрәзәчек шар ачык иде лә! Кичер, Гамбәр әби, генә диясе иде лә! Беренче тапкыр күрешкәндә үк аңа гафу сорыйсы иде лә! Ата-баба гөнаһысы җир белән күк арасында асылынып тормый, ул балаларга һәм оныкларга күчә, диләр. Димәк, Гөлҗиһан – гөнаһлар варисы... Нишләп хатын кадаклангандай урыныннан селкенми, нишләп карчыкка үкенеч тулы күңел савытын бушатмый соң әле?

Ул тирән итеп сулыш алды да аягын идәнгә салындырды. Карчык – житез күбәләк, «ташбака» үрмәләп чыкканда, каядыр очкан иде инде. Миңсылу елан төсле аңа ысылдады:

– Жалу капчыгы! Синең аркада җиңги белән чәкәләшеп үләбез бит.

– Без бүген әбиең белән сөйләшмәдек тә әле! Син үзең шаһит, апа! – Мондый яла җанны әрнетә иде. – Мин сезне тәрәзәчектән генә тыңладым, апа!

– Тыңласаң ни! Казыкка тиклем барасың, дигәч, миңа рәнҗегәнсең син. Җиңги шуны сизгән, димәк ки! Тавыш чыганагы син, симезбикә, чын мәгәр. Без әлегә кадәр җиңги белән чүкердәшеп кенә яши идек, араны бутадың менә. Карале, кызый, – Миңсылу балчыклы кулын алъяпкыч итәгенә сөртә-сөртә, аның янәшәсенә – баскычка чүгәләде. – Әйдә, дуслашабыз! – Аның күзендә хәйләкәр төлке койрык болгый иде. – Әүвәл минем белән таныш. Мин Гамбәр әбинең ире Заретдин сеңлесе. Абзый җиңгине ягадан апкайтканның икенче көнне үк калага юл саптым, киже-мамык фабригында өйрәнчек идем башта, аннан тукучы булдым. Айтуганга кайтулар тәтемәде, чөнки Заретдин туганым белән җиңги килешмәделәр, абзыкаем урманда көн итте. Яшәүләрем тулай торакта иде инде. Бистәдәге танышлар берәүгә димләгән иде, карт, дидем. Җиңгигә сыендым ахырдан. Күңеле киң, сыйдырды, рәхмәт яугыры. Йа, сине кем диик, гөлкәем? Туып-үскән җирләрең кайда?

– Табышмакның җавабы гап-гади, апа. Ник яшерим ди, мин сезнең күршегез Ярулла оныгы, ягъни Сәмигулла кызы – Гөлҗиһан идем.

Кушаяклап тай типтемени, Миңсылу баскычтан мәтәлде. «Йөрәге ярылды!» – дип, хатын аңа ярдәмгә ташланмакчы иде, бакчадан карчык аваз салды:

– Күп белмәктә зарар бар!

– И Аллам, – каенсеңелнең йөрәге исән иде, ул җирдә аунап елый-елый такмакларга кереште:

– И Аллаһ, читтә каңгырап йөргәч тә, миңа авыл хәлләрен житкермәделәр дисез мәллә? Ярулла малае Сәмигулла, бәдбәхет, бабам туган, атам туган, әнкәм җан биргән нигезебездән кудырган ласа! Шулай бит, җиңги? Нинди хурлык!

Үләм, җаным бугазыма терәлде! Никләр кан дошманыбызның кызын куеныңа сыендырдың, җиңги!

– Тагын кабатлатасың, кем кыз. Күп белмәктә зарар бар. – Култык астына үлән бәйләме кыстырган карчык, каенсеңлесенең йөзенә иелеп дога укыгач: – Җен өстенә егылып зәхмәт суктырма, өс-башыңны каккала, – диде. – Безнең эшлиселәр байтак, җитешик, кем кыз. Гумер пичтән соскан күмер, әлегесендә кайнар, әлегесендә салкын. Мунчасын үзем булдырырмын, син тоз сибеп балчык из.

Миңсылу тиз генә ипләнмәде, тез капкачын уа-уа зәһәрен чәчте:

– Ниткән эш, җиңги! Калын катынга бил бөгү ич! Ишщу кем кызына, диген. Икәүләшеп чабабыз, кара, ә! Ник аны тик яткырасың, ник ул үз-үзенә хезмәт итми?!

– Кунакның хөрмәте – өч көн, кем кыз.

– Көлдермәсәнә, җиңги. Кунакны тәм-том белән сыйлыйлар, ә моның ашаганы – кычыткан, эчкәне – әче яфрак суы.

Җиһанның тагын күңеле иңрәде: «Кичер, әбекәй, кичер!» Тик бу иңрәү шунда ук тынды. Гүя, кемдер ихтыяр көченең умырткасын сындыра. Сындырмыйдыр, бәлки. Үткәннәрне кузгатуы тау күчерү белән бер иде шул.

Терсәккә хәтле чумып балчык изгән Миңсылуның күзенә арыш кылчыгы кебек кадалмас өчен, хатын урамга чыкты. Урамы да шартлы исем генә, чынлыкта ул тоташ агач-куактан «тегелгән» яшел пәрдә иде. Күз – карады, борын – иснәде. Нәрсә күрде? Нәрсә тойды? – Уң якта тар гына юл, алар машина белән шуннан керде. Сул якта – сукмак. Димәк, Гамбәр әбигә ике яктан да килеп торалар. Мөгаен, сукмакны җәяүлеләр салгандыр, чөнки ул аяк эзеннән тапталып тигезләнгән иде. Бәс, алайса кайдадыр тагын тереклек бар. Хатын титак-титак шунда атлады. Менә хәзер сукмак Җиһанны да өйләренә илтеп куячак... Өй генәме соң, Айтуганда иң зур хан сарае иде ул! Һай, авыштың мәллә, хатын?! Авыл юк, хан сарае да юк... Моңа күптән пошынмыйсың ласа. Синең илең-җирең – ташкала. Шулай дисеңмени? Йә, нигә үзеңне алдыйсың икән, Гөлҗиһан-Җиһан?! Син ап-ак чәчәк идең, ап-ак чәчәк... Атаң гына таҗларыңны каралтты. «Кем кызы? – Җәллад Сәмигулла кызы!» Олылардан күрмәк, яшьтәшләрең дә синнән читләште. Синең белән уйнамады, чана шумады, су коенмады, кыскасы, син – миһербансыз атаның көзгедәге чагылышы кебек идең. Чү, берәү син – кызчыкны читкә тибәрмәде бит! Ул да инде «берәү» тамгасы белән хәтер тузанына күмелде. Истәлеккә дип ат кылына тезгән каштан төймәсен дә, әнә, Сәйфи куаклыкка ташлады. Ничәмә-ничә ел күз карасыдай саклаган ядкарьне нигә сумкасына тыкты икән? Әллә... иясе белән күрешербез дип өметләндеме?

Гөлҗиһан камыр төсле изрәгән гәүдәсен сукмак кырыендагы түмгәккә аударып хәл алдыртмакчы иде, ат пошкырды. Карчыкның турында бер ир-ат арбадан тартмалар бушата иде. Бу юлаучы кем икән, ә? Хатын капка төбендә әз генә таптанса, йөзгә-йөз очрашалар иде дә инде... Йә, кем булса да барыбер түгелмени?! Әбиең әле үз көчендә, димәк, Гөлҗиһан кебек могҗизага өметләнгән сырхаулар белән элемтәсе өзелмәгән. Өзелмәсен, ярар... Хатынның монда үз хәсрәте – хәсрәт... Ләкин йөрәк нишләп җилкенә соң әле? Нинди җүләрлек инде бу, Ходаем? Шул ят ирнең йөзен күреп каласы килә! Әйтерсең, ул ат арбасындагы тартмаларга бәхет төягән дә шуларны йорт саен таратып йөри иде. Аңа башта атасы, аннары бай туганы белән ире, дуслары: «Бәхет – зур акча», – дип тәкрарлады, әмма Гөлҗиһан-Җиһан һаман үзен бәхетле итеп сизмәде. Бәхет ул каядыр йодрык кына сыярлык урында посып ятадыр шикелле иде. Мәсәлән, әнә теге тартмаларда... Хатын тыелып кына көлде. Биш яшьлек сабый да мондый беркатлы уйлар уйламас иде.

Атлы кеше озак юанмады, мөгаен, кибеттән әйбер-фәлән китергән иде.

Җиһан солы капчыгы кебек түмгәккә ишелде. Миңсылуның күзендә чатнаган нәфрәт яшене аның бәгырен көйдерә иде. Сәмигулла – бәдбәхет, ди ул. Ата дигән зат киек-җанвар канын әз коймады, аның кушаматы да җәллад иде. Бәлки, кансыз аучының явызлыгы шуның белән чикләнер дә иде, көннәрдән бер көнне озын буйлы ике әзмәвер Сәмигулланы кара машинага утыртып үзәккә алып китте. Ире атып чалган поши, кабан түшкәләре ташып эче төшкән һәм Гөлҗиһаннан гайре бүтән бала табалмаган әнисе: «Иремне төрмәгә ябалар», – дип улый-улый елыйсы урынга, кинәнеп:

– Шөкер, – диде. – И Ходайгынам, үзең коткардың. Ач тамагым, тыныч җаным, – диде. – Кызым, Гамбәр әбиеңә сәдака керт, – диде.

Атасы катгый торгач, алар аралашмый, хәер, Гамбәр үзе дә Сәмигуллалар ишегенә орынмый, морҗадан ургылган төтен генә күршеләрнең дөньяда барлыгын искәртә иде. Авыл белән дә әлләни бәйләнеше юк, дисәң, авыру-сырхау белекче йортыннан һич өзелми, анда да ул сайлап кына өшкерә, имеш.

Капка ачык, ишегалдында ике хатын кайнаша иде. Әйтсәң кеше ышанмас, Гөлҗиһан күрше апасының йөзен бик үк танымый, чөнки ул маңгаен каплап яулык бәйли иде.

– Әни сәдака бирде. Кайсыгызга икән? – диде кыз, тартынып кына.

Тагаракта кәшемир яулык чайкаганы, керен сыгып селкегәч, янындагы апага сузды:

– Мә, Сәйдә, моннан соң чигәң сызламас. Марҗа күек пумала чәчеңне тузгытып йөрмә! Күк гөмбәзе синең башыңа ябынгыч тегел.

Шуннан соң гына ул, Гөлҗиһанга игътибар итеп:

– Анаң бик иртә шатлана, – диде. – Ул үзе яхшы катын, ерткыч тырнагыннан тырналып кына җәфалана, бахыр.

Тимер акча кызның учын авырттырды. Куркудан ул аны бик каты кыскан иде.

– Сәдакаңа картлар дога кылыр, мәчет тартмасына шудыр. Хәерсез хәбәргә укымыйм, – дигәч, кыз нәрсә дисен, тыңлады билгеле. Аның өчен иске генә агач йорт дөньяның иң җылы почмагы кебек иде. Кайчакта алар шыпырт кына мәчеткә кереп утыралар, кансыз иреннән җик күргән, кыйналган-сугылган әнкәсенең монда ничектер сулышы иркенәеп, йөзендәге җыерчыклары языла иде. Кайчакта хуҗабикәнең үзен дә очраталар, тик ул түрдә оеган хәлдә була, ялгыш та артына борылмый, ә инде кыр казлары кебек тезелеп җомга намазына картлар килгәндә, гомумән, тәрәзә капкачына хәтле томалап, өй тоткынына әйләнә иде. Баксаң, аңа бабайлар күзенә чалынырга ярамый, гәрчә иман йортын юып-җыеп, ауганын-егылганын үз акчасына төзәтсә дә, тегеләр, үзләре әйтмешли, «Заретдин катыны»н өнәми, аның им-томы «шайтаннан» дип тирги иде. Боларны кызга әнисе сөйли иде.

– Аксакаллар бер дә гадел түгел, – дия иде ул. – Сәдака акчасын үзара бүлешәләр. Мәсҗедкә бер файдалары юк, бөтен чыгым Гамбәр әбидән. Дога укып өшкерүен гаепкә бөгәләр бит әле.

...Әнкәсе сандык актара иде.

– Әбиең нәрсә ди, кызым?

– Хәерсез хәбәргә укымыйм, ди, әни.

– Ай Аллам, оекбаш бәйләп саткан хәләл акчамны Сәмикныкы дип шикләнде микән?!

– Анаң бик иртә шатлана, ди.

– Ай Аллам, котылулар юк икән алайса. Яңа күлмәгемне киярмен, дигән идем. Юк икән, юк...

Чынлап та, кич белән ата кеше кайтып та җитте. Аның һич беркайчан кәефе

булмас, ул өйдәгеләргә тиктомалдан акырып-бакырып иде, бу юлысы исә Сәмигулла Җир шарындагы иң соңгы җанварны бугазлаган кебек шат кыяфәттә иде.

– Минсара! – Моңарчы ямьсез итеп «катын» дип кенә эндәшкән иренең авызыннан беренче тапкыр үз исемен ишеткәч, әнкәсе «әстагым», диде. – Минсара! – Әтисенең тавышына кадәр үзгә иде. – Без яңа тормыш башлыйбыз, Минсара, аңгыра сарык! – Кушаматта да катылык сизелмәде, ул җөмлә йомшартыр өчен генә әйтелде. – Син хәтерлисеңме, әти бабайның энесен кулак дип Себергә куганнар, дигән иде.

– Әһе, нәрсәдер хәтерлим, Сәмигулла.

– Пычагым хәтерлисең, аңгыра сарык! Синнән ни йон, ни ит! Җә, бөрешмә, мин сине тукмамыйм. Бүгеннән Сәмигулла Насыйров – примир симия башлыгы! Вәйт! Моны башыңа киртлә, Минсара. Кызым, каяле, син әнкәңнән ушлырак, мәптектә укуың да яхшы. Син дә колак сал. Вәт шул, бабайның энесе Себердә югалмый. Мал туплый, Арчиный улын да акча эшләргә өйрәтә, Арчиный, ызначит, үз чиратында малаен байлыкка чумыра. Акчаның бер тәмен белгәч, улы да капчыкның авызын зур итеп «тегә». Шунсыз Мәскәүгә якын җибәрәләр димени аны! Безнең быраt үткен балта икән башкалада! Кирәк икән, муеннарын чаба да өзә!

– Безгә балта ни, пычкы ни, – дип сүз кыстырган әнкәсенә атасы җикеренде:

– Ахырын тыңлап бетер, аңгыра сарык! Упшым шул: минем туган, ягъни дә бабайның энесенең бердәнбер оныгы Радий бүгенгесендә иң кәттә бизничмин икән. Тау-тау акча икән быратта. Мине үзәккә илткән баһадирлар аның памушниклары икән. Ни ди ул җегетләр, абзый ди, синең энекәш Радий Арчиныч бабасының төп-тамырын барлый, үзәккә запрус ясаткан идек тә, сез күренәсез, ди. Как жы, мәйтәм, тучнысында без аның карендәшләре. Эзләтүенең сәбәбе бар икән, быраt дикутатка сайланмакчы, ди.

Алтынчы сыйныфны тәмамлаган Гөлҗиһан әтисен төзәтте:

– Депутат, әти.

– Авызыңны яп, салам сыйрак! – диде аучы, әмма дуамалланып бәйдән ычкынмады. – Матур гына гәпләшик, без хәзер зур кешенең туганнары, без – примир симия.

Гомерендә беренче мәртәбә әнисе батырайды.

– Безнең кайсы җиребез примир симия икән соң, Сәмик?! Кыйный-кыйный тәнемне күгәрттең, үлгәндә дә агармас, Ходайгынам. Урманда хәтсез киек-җанвар кырдың, ерткычлыгың бөтен авылга мәгълүм. Әүлия булып кыланма, зинһар.

Атасы кулына ни эләксә – шуның белән сукмасын дип, кыз әнисен ышыклап басты. «Примир симия башлыгы» аларның икесен дә ботарлап ташлар иде, ишек дөбердәттеләр. Авыл советы рәисе Мирхәйдәр абзый икән, гадәттә, йомышын капкадан гына әйтеп үткән кеше, кунакмыни, түр башына ук узды.

– Самавырыңны үрләтсәң дә ярый, Минсара сеңел, – дип, чәйгә дә «теләнде».

Баягы ярсуы сүрелмәгән атасы бармак шартлатты:

– Җәтрәк, катын! Минем дә авыз кипте.

– Авыз гынамы, миеңне дә киптерелек мәшәкатьләр куптарасың бит әле син, Сәмигулла энекәш.

– Чыбыркыңны ерактан ук шартлатма, блач абзый! Мин поши атсам, син урлап агач кисәсең. Күрдем мин сине өченче көн, очлы минем күз, – дип һөҗүмгә ташланган хуҗаны кунак басынкы тавышы белән туктатты:

– Кызмале син, Сәмигулла энем, кызмале. Биш усак аудардым инде. Ачкүз Гөлйөзем апагыз, яңа мунча төзе, башка төшкәрәк, ди, искесендә шомландыра, ди. Соң, дим, мунча салырга ниятләп урын билгеләү белән, анда иң әүвәл

искесендәге җен-пәри күченә, дим. Сезне ырым-шырым белән Гамбәр кортка гына бозды, әллә ниткән уйдырмалар белән, дим.

– Изге китапта Аллаһы Тәгалә: «Җеннәрне һәм кешене Мин фәкать үземә гыйбадәт кылсыннар өчен генә яраттым», – дигән лә, Мирхәйдәр абзый. – Әнкәсе, хокуксыз бичара әнкәсе, кунакны «аң-белемле» итмәкче иде дә, этисенең маңгае җыерылып, кашлары тигезләште:

– Ирләр янында бәкелдәмә, аңгыра сарык!

– Үзең дә чәпчемә әле, Сәмигулла энем. Сүз кыстырмаса – кыз-катынның теле шешә. Хәзер сезгә тату гына яшәргә дә яшәргә, балалар. Синең арттан ук мине первай чикритар чакыртты, энем. Карендәшегез бар икән бит!

Хуҗа, ата каз кебек муенын сузып, горур гына:

– Бар, бар! Иң якын туганым ул, – диде.

– Туганнан битәр, дәрәҗәсе зур әле аның, Сәмигулла энем, дәрәҗәсе! Әттәгенәсе, егыл да үл, сәләмә генә аучының карендәшен дипутатка чөяләр. Аннан пәлитбүре әгъзасы итеп күтәрерләр! Уен-муен эшмени!

– Син миңа чүбек чәйнәмә, блач дигәч тә! Кем сәләмәдер монда, – дип кабарынган атасы, кисәк шиңеп: – Чикритар ни ди, җә? – диде.

– Башта сиңа ни диләр теге җегетләр?

– Упшым болай, ике әзмәвер үзәккә апкиткәндә котым очты, малай. Өтермәнгә илтәләр дип, малай. Ну болар сталавайга апкерде, лыкынганчы ашатты. Урысча чамалы бит инде безнең ишенең. Тылмач минекен дә, аларныкын да әйләндерде. Радий Арчиныч нәсел-нәсәбе белән бә-әк кызыксына икән.

– Син артык очынма, Сәмигулла энем. Пәлитбүре әтрәк-әләмне үз бригатына җыйнамас. Кем улы, кем оныгы икән дип, җиде кат җир казып тикшерерләр. Тәртибен дә, әдәбен дә исәпләрләр.

Ата кеше кара коелды.

– Алайга китсә – казыйсы да юк, әммәсе дә өстә генә. Радий энекәш – кулак оныгы, мин шуның туганы! Майт якасын, булмый икән, булмый!

– Һай, Сәмигулла энем, синдә шул поши атарлык кына акыл бар. Ике ат, өч сыер асраган һәр крәстиәнне Себергә куганнар. Миндә бүген ун сарык, бер сыер, ну давай, сөрегез авылдан! Ту-ту, заманы бүтән!

– Минекеләр көтүе белән урманда, – дип ыржайган хуҗаны Мирхәйдәр абзый бүлдереп:

– Моннан соң синекеләр дә сарай-абзарда мөгрәр, – диде. – Чикритар әмере бу, энем. Хуҗалыгыңны яңартасың. Иту адәм ыстырамы, каралты-кураң кыйшайган, мунчаңның түбәсе ишелгән, кетәклек хәтле генә ызбаңа этәч кунса – тавык, тавык кунса – этәч сыймый.

– Блач дигәч тә, кеше хурлама, җәме! Типтек очырдык урындыктан! – Атасының түземлеге төкәнде. – Ни ди чикритар, дим сиңа?!

– Тәки аңламыйсың! Сай ми савыты синдә! Иске-москыдан арынасың, ди район башлыгы. Әгәр дипутат белән тилибизырдан, гәҗит-мәҗиттән кайтсалар, аларга чүп оясын күрсәтеп мактанасыңмы? Карендәшең оятыннан нишләр, ә? Син бит аның аутарититын төшерәсең, сайлаучыларда нәселләре булдыксыз икән дигән фикер уятасың, энем!

Әтисенең исә өмете бик-бик бәләкәй иде.

– Аутаритит кирәк икән, Мәскәвендә генә шауласын! Миңа памушниклары примир симия булыгыз, без бәхилләтербез, диде. Радий Арчиныч хакына татулашырбыз да, иеме, катын Минсара? Түлке безнең бер шартыбызны үтәсен бай туган. Минем мылтык искерде, мылтык. Урыс Сидыр үзенекен сата, ну

кыйбат сорый, кәҗә сакал! Мылтыклык акча тамызса Арчиныч, без канәгать, иеме, катын Минсара?

– Тучны башсыз икән син, Сәмигулла энем! Алтатар гынамы, йөз пулимутка акча бирерлек хәлле бизничмын ди синең карендәшең! Рас памушниклары аша өч көннән ярты арыш капчыгы сәмән китертә! Чикритар шулай ди.

«Ярты арыш капчыгы» дигәч, гаилә башлыгының бәбәге маңгаена тәгәрәп менде.

– Чынмы, Мирхәйдәр абзый? Ике күзем чәчрәп аксын, диген!

– Акмасын әле, энем. Сукырайтма, яме? Чикритар белән минем дә интирис бар монда. Юкка гына синең белән сөйләшеп тел арытам мәллә? Хуҗа бай иптәштән техника сорамакчы, ә безнең авылда күпер сәләмә, шуны яңабаштан төзергә булышыр.

Атасы тилергән төсле, кулын селки-селки, идән уртасында бии иде. Аның «чикритар» белән «блач»та гаме юк, аның үз җыры җыр иде:

– Ярты капчык акча-а! Зу-ур ызба бастырам, зу-ур келәт, зу-ур абзар! Катын! Биш сыер саварсың, аңгыра сарык! Тьфү, примир симия булгач, кушамат ярамас. Минсара бит әле син, тити... баш! Ну Минсара инде, ананңны... Тьфү, әристәкрәтләр ничек сөйләшә икән тәти-тәти сүзләр белән. Хуп, Минсара. Мунчаны өч бүлемтектән төзербез, иеме? Алгысында мич белән ләүкә, уртасында... Чурту, берсе дә җитә безгә, иеме, катын... Минсара?

– Бик җәелә алмассыз шул, энем. Урыныгыз ашъяулык хәтле генә. Атаң, мәрхүм, мокыт, чәчмәде-урмады. Сез – бүреләр төсле әзер-бәзерне генә ботарлый торган халык. Әнә, Заретдин ушлы иде, уңган иде, иске йортын сүтмәде, уң яктан җир өстәттереп, яңасын салдырды. Бүген Гамбәр карчык алпавыт утары кебек йортта япа-ялгызы яши. Синең чамадарак Рәшит исемле улы тәки авылны үз итмәде. Аңа утар җене суккан бугай.

– Рәшит белән саруымны кайнатмале, блач! Миңа аның җеннәре ни пычагыма!

– Һәй, баш тартмаңның эче гүпчим дә куыш икән, энем! Әзрәк шөрепләреңне боргала инде! Карчык ялгыз, диләр сиңа!

Атасының нурсыз күзендә тычкан уты кабынды:

– Син туры ярып әйт! Туры ярып! Әйләнмә әйләнчек сарык төсле минем тирәмдә, әрекмән яфрагы! Нигә аңа бу тиклем җир, диген! Калхуз кыры шае бакчасының яртысын үзеңә кисеп ал, диген! Уф, хәерче бет блачтан да адәм рәтле киңәш-мимәш ишетәсе көннәр бар икән, чурту-матыр, гөбернатор, шатыр-пытыр!

## 8

Күк түбәсенә караган иде, кояш нуры керфегенә бәрелеп сынды. Вакыт! Балчык җитеште. Аның һәр бөртеге кайнар һава белән өретелде. Тоз да кушылгач, сихәте бермә-бер артыр, иншә Аллаһ. Нинди чебен тешләде икән, сукмактан эчкә үк кереп утырган. Йөрүе хәерле, йөрүе...

– Кем кыз, апкайт үзен! Җил-җил атла!

– Таш кебек каткан буыннар белән җилләнерсең, ди.

– Син, ялкау, кем кыз. Үзеңне тәрбияләргә иренәсең. Җиде төрле үлән пешекләгән суда аякларыңны изрәт.

– Минем чир чүп кенә шул сиңа, җиңги. Кан дошманыңның баласы артык кадерле сиңа. Сыла менә балчыкны миңа!

– Азынма, Миңсылу. Син бер дәваландың кана. Сез, Хода бәндәләре, чит кулдан гына терелүгә өметләнәсез, гәрчә сихәт даруы – үзегездә лә. Тән нәстә ул, әүвәле җаныгызны пакьләндерегез.

– И сөйләп тә күрсәтәсең инде, җиңги. Теге калын катынның җаны актан да акмыни? Күптән акча белән былчыранган ул! Ник син аңа: «Чистарынгач кына кил», – димәдең, ник әйдүк дигәндәй кочагыңны җәйдең?

Күкрәк читлеген утлы шар кыздырып, йөрәген пешерде. Капкадан ук бора алмады шул... Дөнья арбасының тәгәрмәче аның теләге белән генә тәгәрәсә, ул өстенә моның кадәр хәсрәт тавы иштерер идемени, Аллаһым!

– Җә, җә, – карчык йөрәген пешергән шарны учында сытып сүндергәндәй хәрәкәт ясады. – Җә, Гамбәр, өтелмә. Аларга да җәза таягы сукты ла.

– Нинди таяк, җиңги? Кемгә сукты?

– Анысы сиңа ниемә кирәк, кем кыз? Кунак әнәгенәк, синең мыштырдаганыңны көтмәде, килә.

– Тач ташбака!

– Көлмә, кем кыз.

– Ябь-яшь башыннан бу хәтле симермәсә!

– Ябыгыр, тиз ябыгыр, ул да минем күек үткәннәр тозагына капты... Капса ни! Кем каршысына кайтканын белде кана.

– Җиңги! Кемгә сөйлисең соң, ә? Кем капкан? Кая капкан?

– Чү, кем кыз. Дәшмә! Хәтерләмәскә ни! Нәселләре белән тукылган кана.

– Син әлләме соң, теге калын катынны ачуланасыңмы, җиңги? Ишетми бит ул, катырак кычкыр!

– Шыпырт, кем кыз! Мунча суына. Читкә каерма, миңа булышырсың.

– Ие инде, без байбичәнең хезмәтчеләре бит. Чиләк төбендә ипи телеменә ягарлык балчык калса, миңа да өлеш чыгарырсың, шәт, җиңги.

– Иясенә аталган әйбергә ымсынма, Алла бәндәсе. Гөлҗиһан, җәтрәк кил!

– Хәзер, хәзер, Гамбәр әби!

– Ай-һай, тавышың гайрәтле, җиңги! Әле генә чыш-пыш иде үзе.

Моңарчы шәүлә кебек кенә арттан йөргән каенсеңелнең соңгы арада теле зәһәр үткенләнде: сүз белән телә дә телә иде, карчык, күзеннән очкын чәчрәтеп:

– Кусам – себерке белән куам! – диде.

– Мәйлең, җиңги. Бая гына оныгың, әйдә, апа, үземә кунакка, дигәндә, нишләп кумадың икән, ә? Монда да урыны шәп, диден бит, ә? Уең да гел миннән котылу, ахрысы.

Карчык аны бүтән әрләмәде, ни дисәң дә, иренең нәселе белән тоташтырган бердәнбер җеп – Миңсылу иде. И-и, урманда да колаклар җитәрлек шул! Авам-авам дигән сыман уңга-сулга чайкалган Гөлҗиһан, әсәренеп:

– Теге атлы ир-егет Фәрит иде мәллә? – диде.

Үзең кичер, Раббым, бытбылдыкның авызын ничек ябарга икән? Җә, исемен мең кат кабатласын, мең кат, тик икәүдән-икәү генә күрешмәсеннәр... Берсен – елганың уң яры, берсен сул яры ит, Раббым! Ялгыш та сер сандыгына кагылдырма!

Хәер, аның йозагы биш былтыр күгәрде. Аны хәтта ки әфсен укып та ачалмаслар. Йа Раббым, монысы нинди шик тагы?! Сиңа – җир-күкләрне төзеп, камил рәвештә саклаган Кодрәт иясенә биктә торган берни дә юк!

Карчык усал гына:

– Ул ир затыннан бихәбәр бул, – диде. – Рас, синдә терелү нияте икән, терел дә кит!

«Тиянадан гына ярсыйсың кана, кортка. Шайтанга азык бирәсең», – дип үз-үзен битәрләп, ул мунча ишеген тартты. Ишек җилем белән ябыштыргандай каткан иде.

– Әй җиңги, җиңги! Син дә картайдың. – Каенсеңел аны кырыйга этәрде. – Кая, мин көчлерәк.

– Картаймадым, ачуым гына басылсын, оланнар. Син, кем кыз, аңа акайма.

Карчык артына борылмаса да күрде: Миңсылу Гөлҗиһанны күзе белән «ашый» иде.

– Карап-карап та туймаслык бит бу гөлкәебез! Авыртмаган башка тимер тарак ул! Кара, кара, җиңги! Сыйраклары рәтләнә бит моның. Бездән калышмый, тьфү!

– Аллаһның кодрәте киң, кем кыз.

Икенче тапкыр тартканда, ишек карышмады.

– Уң аяктан атлап керегез, – диде карчык.

– Абау ла, җиңги. Кунагың мунчаны ишмәс микән? Идән тактасын сындыра, билләһи.

– Әй синдәге әшәке тел, кем кыз! Җиде елан угыннан әвәләнгәндер. Чишен, Гөлҗиһан. Оялма, синең белән безнең арага пәрдә корылыр, күз пәрдәсе. Миңсылу, бакыр кәндигә балчык сос!

– Һай, моның бүрәнә ботына ярты күл сазы кирәк! Хәтерлисеңме, җиңги, бер хатын килде, бөтен тәнен чуан чуарлаган иде. Син аны әллә ниткән үлән сулары белән коендырдың.

– Канлы үлән төнәтмәсен әйтәсеңдер, кем кыз.

– Тагын нәрсәдер эчердең әле, җиңги.

– Әчеткән колмактыр, кем кыз. Балчык берсәк төерле, Миңсылу!

– Ул катын шакшыдан чистарынгач, рәхмәт тә димәде сиңа, җиңги. Соңыннан эт төсле ырылдады, әйеме?

– Балчык берсәк төерле, дим, кем кыз! Иренеп кенә изгәнсең.

– Коймак пешермисең әле, җиңги.

– Төннекнең чүпрәген ал, кызу, – диде карчык, ә каенсеңел һаман аны ирештерде.

– Сине ана керпе дип мыскыллады бит, чәчби. Анысы, кушаматы дөрес инде, энәләрең каты чәнчә.

Беренче уч балчыкны ул, чәчен аралап, хатынның баш түбәсенә чәпәде. Кулы җитез иде, тиз эшләде. Каенанасы яшь киленнән текмәдән корылган тавык сарае сылаткан иде. Иртәгесен балчык ярылып коелды. «Сыер тизәге белән салам кушмагансың икән, – дигән иде мәрхүмә. – Заретдин үтерә, килен!» Бу аңа онытылмаслык сабак иде. Әгәр шушы ят туфракка берегеп калыйм дисәң, мондагы гореф-гадәтләргә төшен, эшнең җаен-тәртибен өйрән икән. Гамбәр өзгән һәр үләннең, һәр яфракның исемен отты, соңра алар китап рәвешендә күңелгә теркәлде... Ач та укы гына!

– Кем кыз, ләгәнне кырынайт әле.

– Бәс, бу катын балчык чүмәләсенә әйләнде ич инде, җиңги!

– Тиресе чемердәп тартылгач, җылымса су белән коендырырбыз, – дип, белекче бусагага чүмәште дә, үзе дә танымаган калтыравык тавыш белән: – Керп-е-еме? – диде. – Аның да энәләрен чүплилә-әр. Көндез сукырая мескенем, төнлә күзе ачыла. Качмаса – корбан, ябалак аулый. Минем дә җаныма ерткыч бәндәләр тырнагын батырды, вәләкин җиңдермәдем. Ярасы гына әле дә каный, ярасы гына... Син кем, Миңсылу! – Зәгыйфь тавыш кисәк кенә тимер кебек чыңлады. – Кырып-чистартып ләгәнне келәткә – ару җиргәрәк куй!

– Хәзер, җиңги, хәзер! Баягы фикеремне очлыймсана инде!

– Синең фикер миңа ниемә, кем кыз!

– Берәр эшкә ярар, җиңги. Бу саз бакасы ипләнгәч, – Миңсылу салам өстендә изрәгән хатынга ымлады, – туже теге чәчби кебек ырылдар, җиңги. Алларыңа тезләнеп рәхмәт яудырыр мәллә?

– Телеңә кайсы чиләкне элим, кем кыз? Зурысынмы, кечтегенме?

– Бәй, миннән әйтү, синнән ишетү, җиңги!

Хәрәкәтсез утырган «балчык өеме»ннән дә өн чыкты:

– Нишләп миңа Ходай җиңелрәк чир бирмәде икән, Гамбәр әби?

Гүя зил-зилә урыныннан куптарып күккә чөйде дә, ул карчыгага әверелде һәм, канаты белән шап та шоп дошманын тәпәләргә җыенгандай, кире аска атылды. «Кемдер нәселегездә хәрәмнән күбенергә тиеш иде!» Ләкин нәфрәт утыннан канат очы көеп, «карчыга» хәлсезләнде. Ярамый, артык явызланырга ярамый! Гомернең хисап дәфтәрендә язылган кайбер битләрне ертсаң, бәлкем, күршеләрнең җәбер-золымы хәтердән җуелыр иде. Битләре кыягаз гына түгел шул, түгел...

Карчык хатынның беләген сыпырды:

– Кибә, – диде һәм тыныч кына: – Һәркемнең үз тәкъдире, – диде. – Бер адәм бөкресеннән зарланмыш, имеш. «Әй Ходайгынам, аркамның ямьсезлеге күземә күренмәсә дә, авырлыгын чамалыйм, аны күтәреп йөри-йөри кабыргам сызлый», – ди, имеш. «Соң, – ди икән Бөек Затым, – менә бер ызбада чүттин чүт бөкре, кер дә, үзеңнекен җиңелрәге белән алыштыр, колым», – ди, имеш. Адәм шатлана-шатлана йөгерә ызбага. Бөкресен идәнгә ыргытып, бүтәнен куйдыра. Җиңел дип куанып ишек төбенә җиткәч: «Аһ, Ходайгынам, монаусы күкрәкне изә икән», – ди, имеш. Аңа тагын икенчесен күтәртәләр, харап, ансы да авыр, имеш. Бәндә каюсын гына сайласа да, аркасына таш капчык аскан кебек, имеш. Азактан ул: «Үземнеке әммәсеннән дә җиңелрәк икән», – дип, газиз бөкресен кире ябыштырткан, имеш.

– Мин дә, шул адәм төсле, синең катыңа килдем, Гамбәр әби. Әйе, минем чир – минеке, ә даруы синдә, Гамбәр әби!

– Кая соң ул дару? Минем учым буш кана.

Хатын, гаҗәпсенеп:

– Көн саен нәрсәдер эчертәсең ләбаса, Гамбәр әби? – диде.

– Көфер сүзләрең белән мине гөнаһлы итмә! Аллаһы Тәгалә ни бирсә – шуны кулланган кемсә мин. Җә, безнең эш тәмам. – Карчык кызган ташка чүмеч белән су томырды. Мунча эче пар белән тулып, диварларга куе томан сарды. – Аллаһым, гамәлләребез синең рәхмәтеңә өметләнеп башкарыла, башын-азагын хәерле ит! Хәзер мин сине коендырам, Гөлҗиһан. Аннары җәймә белән гәүдәңне ура! Миңсылу кайнаткан төнәтмәне эчкәч, сусавың басылыр.

«Балчык чүмәләсе» тезләнеп үзе торды. Аллаһның рәхмәте киң шул, киң... Менә, кортка, сихәт тамчысы әкрен генә тама... Әй, йөрәк! Сикермәсәнә, йөрәк... Онытмады яшен Гамбәр... Унтугызда түгел, әйе. Тик аңа бөтәшергә иртәрәк түгелме әле?

Ул өстендәге чүпрәк япманы чишеп, аркылы тактага элгән күлмәген киде. Хак, бөтәшергә иртә әле, кортка. Әз-мәз хәлсезләнсәң нишләтәсең, дәрман юк та, аның каравы дәрт бар дип юан. Моңарчы дәрт яшәтте ләса. Адәм баласының көч-куәте шуңа бәйле!

Мунчадан карчык аксап кына чыкты һәм, хәлсезлеген сиздермәс өчен, утын түмәренә утырды. Эчен тотып тирән итеп сулагач:

– Бәракалла, – диде, – бәракалла, бигрәк йомшардың бит, кортка. Ялкаулык җилкәңә менеп атланмасын, аңа хуҗа булырга ирек куйма, әйдә, селкен! Әй, Миңсылу!

– Әү! – Каенсеңел аның каршысына килеп басты. – Нәстә, җиңги? Бәй, йөзең агарган! Әллә симезбикәнең җиле тидеме? Хәтерлисеңме, Садикау катынын өшкергәч, өч көн колагың шаулады.

– Кем, кыз, монда чирләргә җыенган кеше юк! Гөлҗиһан кайда?

– И-и, җиңги, син аңа ясалма аяклар беркеткән ахры. Дуфкым ызбага

элдерде. – Каенсеңел шөпшә сыман анып колагына ыжылдады. – Карале, җиңги, зерә шикләндерә. Бу катын җинаятьче-мазар түгел микән? Гуртта берәр яманлык эшләп, чирлим сылтавы белән бездә – аулакта палитсадан качып ятса, ә, җиңги? Хәзер кыз-катын бик азды. Ярулла нәселеннән барысын да көт син.

Карчык:

– Тач шулай, кем кыз. Корсагын һава өрдереп тутырган да шар кебек безнең якка тәгәрәгән, – дип көлгәч, уң аягы белән җиргә типте. – Тайт, кем кыз! Иллә дә борчак шыттырырга оста син. Шик – шайтаннан, бел, кыз. Гөлҗиһанны бирегә чакыр!

Әкрен генә үзенә табан теркелдәгән хатынны ул күз кырые белән генә күзәтте. «Йа Аллаһым, син шушы имгәкне әманәт итеп йортыма иңдердең. Шуңа да мин аны кире бормадым. Йа Аллаһым, көтелмәгән бәла-казалардан саклагыл! Бу нәсел күп җәпле сәнәк күек: кадый да кадый. Монаусы күңелендә яман уй йөртми, ансы – хак, вәләкин анып изгелегендә дә минем каумем өчен куркыныч бар».

– Гөлҗиһан, кунак кадере өч кояш баешы, өч кояш чыгышы, инде дә безнең тиң булып, эшләп аша.

– Эшлим, эшлим, куш кына, Гамбәр әби.

– Сул яктагы сукмактан кер дә, өч нарат төбеннән былтыр коелып төшкән күркәләрне кәрҗингә җыеп кил.

– Хи-хи, калын катынның ашаганы үлән дә үлән, берочтан урманда яфрак белән туклансын, хи-хи, – дип теш җемелдәткән каенсеңелне дә ул тик тотмады:

– Син, кем кыз, җиз самавырның көлен кагып, чишмә суы сал. Нарат күркәсе белән дөбердәп кайнар, иншә Аллаһ!

Миңсылу:

– Әй, мин тиз ул, җиңги! Синең симезбикәң кайчан әйләнеп кайтыр бит, – дигәч, карчык:

– Аны дәрте кызулатыр, – диде.

– Нинди дәрт, җиңги?

– Чирдән арыну дәрте.

Күрәләтә кемне алдыйсың, кортка? Хатын бая гына ташбака иде, урман дигәч, әнәгенәк, чикерткә күек сикерә. Аңарда бүтән уй, бүтән... Син тамгалаган сукмак кыска, бик кыска... Ә югалткан әрбире исә чакрым арты чакрымда... Эзләмә дә, тапма да! Сезнең нәсел белән каберең якын булмасын...

Карчык түмәрдән торып күлмәк итәген какты. Яулыгын чишеп, яңадан бәйләде, кул арты белән дымланган күз тирәсен сөртте. Агач-куактан нур сирпелгәндәй тоелды. Менә хәлләнде... Аллаһ яраткан колының тамырын кисмәсә – яшисе дә яшисе әле. Ә Ярулланыкылар очынды. Алар үзләренең Бөек Кодрәт иясе сипкән тузан бөртеге генә икәнен онытты шул. Күрше хакы – Тәңре хакы, диләр. Ул хак хакландымы соң? Юу-ук, һич юу-ук! Гамбәр дә гаепле иде. Бүген генә хата-ялгышларын танып сыкрана кортка. Яшь чагында артык туры сызык сызды ул: аннан берәү дә читкә тайпылмаска тиеш, янәсе. Әйтерсең, адәм баласы шушы гөнаһлы җир өстенә әүлия сыйфатында тереклек итәр өчен төшерелгән иде. Чү, дала кылганы, чү! Хаталар да төрле-төрле зурлыкта: каюсы учка йомарлана, каюсы җиһанга да сыймый. Син бит инде, болар вак-төяк дип, бәндәнең ничәмә-ничә гөнаһысын гафу кылдың. Ә синең үзеңнеке кичерелер микән? Җиһанга сыймый дигәнең синеке түгелме соң?

...Беркөнне аучы Сәмигулла:

– Эшләрең хуттамы, Гамбәр апа, – дип яңратып сәламләгәч, юаш кына адымнар белән ишегалдына үтте. Сүгенмичә өч сүз әйтмәгән шөкәтсезнең әдәпле генә сөйләшүе сагайтты: шайтан әллә ничә кыяфәткә керә иде. – Ну,

Гамбәр апа, җир астындагы тычкан сыман шыпырт кына кыштыр-мыштыр ятасың, иеме? Качалмыйсың, Гамбәр апа. Күршеләрнең дүрт күзе дүрт нүешне дә күрә. Безгә кыңгыр эшләрең мәгълүм: яшертен генә догалар белән өшкерәсең инде, иеме? Синнән кеше өзелми, ну без жалу белән блачка бармыйбыз, түзәбез, Гамбәр апа.

– Мәгәр сезгә энә очы кадәр зыяным тисә – барыгыз, бар, энем.

– Һи, Гамбәр апа! Какуй бару! Әнә, күрше авылларда мәчет манарасын кистеләр дә яңасын төзеттермәделәр. Ә синеке агачларга томаланып исәнимин яши. Анда җомга саен карт-коры намаз укый. Район блачына җиткерсәң – үзеңне пырылдаталар түлке, ну без жалу белән мәтәшмибез. Син сукыр Гарәфетдинне җитәкләп китереп азан кычкыртканда да колак саңгырау безнең. Гарәфетдиннең бабасы – мулла-мунтагай, ди, Себердә түңкәйгән, ди. Оныгы дин калдыгы дип, моның да бугазын чәйнәмәсен блач бүреләре, дим.

– Куркытма, энем.

– Куркытмыйм, Гамбәр апа. Үз туганым кебек якын син миңа. Әйдәле, бер-беребезгә чәйгә йөрешик...

– Йомышыңны әйт, Сәмигулла.

Ир лычкылдатып борынын сеңгергәч, кулын чалбарына ышкыды.

– Күңел нәзегәя, Гамбәр апа. Күптән синең белән гәпләшкән жук. Йомыш дип... Кыскасы шул: бакчаң зур, яртысын миңа бир! Ялгыз башыңа ниемә сиңа гектар-гектар җир!

– Сезнеке дә минеке чамасы, энем.

– Без өчәү, Гамбәр апа. Ә син бер генә баш! Бәрәңге үстереп саткан акчаңны тозлыйсың, ахры, анаңны... – Сәмигуллага әдәп саклап торуы бик авыр иде. Ул иләмсез итеп күзен алартты, әмма «йомры-йомры» сүзен теш арасында кыстырып калдырды. – Ни, Гамбәр апа, безнең ызба бәләкәй, каралты-куралты иске. Хуҗалыкны рәтләр идем, урын кысан.

Гамбәр дөнья малының ялына ябышып ятамыни, и Ходаем! Бәрәңге саткан акчасына ул кульяулык та алмый, мәчет кирәк-ярагына тота иде. Менә быел түбәсеннән су ага. Аны көзгә шифер белән яптырырга кирәк... Гарәфетдин балакайны кышкы суыкларда ничек азанга йөртер? Бишмәте кырык ямаулы, итегенең олтаны тишек. Аның өс-башын бөтәйтү – Гамбәр намусында.

Тик боларны шушы бәндә кисәгенә берәмтекләп аңлатудан ни мәгънә? Моның күңеле кояш көйдереп яргаланган каты балчык: нихәтле генә су сипсәң дә – җебеми.

– Бакча закунны минеке, энем.

– Знамы синеке, албасты хатын... Тфү, күршекәем, апа җаным. Телемә чебен куна, тфү. Закунный җиреңне якшылык белән сорыйм шуңар, Гамбәр апа. Блач Мирхәйдәр, эт койрыгы, рөхсәтсез генә кис тә ал, ди.

– Киселәсе көннәрегез алда әле.

– Нәмә дисең, күрше апа?

Хатын бүтән кабатламады. Офык читендә ниндидер кара чүпрәк кисәкләре җилферди иде. Көтүе белән каргалар очып килә икән! И Аллаһым, авылда каркылдавык кошлар елдан-ел күбәя. Кешесе кырылса – аймактагы ятим агач-куакка карга оя төпли. Сизенәләр, ахрысы. Ә монда берәүсе җир сорый. И адәм, синнән барысы да өелеп кала!

– Хуп, ярты бакчам синеке, Сәмигулла, – диде хатын, күз карашын иргә күчереп. Ләкин ул тирләгән кызыл йөзгә туры бакмады. Бу йөз, уйларыңны чәчеп җибәрерлек киң офык түгел, үч-мәкердән иртә җыерчыкланган бу йөз бик тар, өстәвенә нурсыз һәм котсыз иде.

Тик күршесенең нәфес тамагы моның белән генә туймаган иде. Икенче көнне Сәмигулла тагын гозер белән керде.

– Күршекәем, апа бәгърем, үлчәгән идем, синең теге өлешеңне, бигрәк кечкенә икән. Шунда сарай да, мунча да төзе, имеш. Упшым, бакчаңны тулаем минем исемгә күчерик!

Гамбәр кое янында кер чайкый иде, тыныч кына:

– Бусына шөкерана ит, – диде.

Сарык тиресе ябынган бүре тешен шыгырдатты:

– Мин синнән яхшылык белән сорыйм, күрше апасы!

– Синең яхшылыгың белән начарлыгың бертигез, энем.

– Миңа сручны киңәергә кирәк, күрше апасы!

– Аллаһ тарлыкка төшерсә, биш бакчаң да җитмәс, энем.

– Ну кара, сихерче калдыгы! Ал дип ялынырсың! Ну кара!

Гамбәрнең ишегалды яланаяк йөрерлек ямь-яшел чирәм, гүя анда мамык җептән тукылган келәм җәелгән иде. Иртәгесен ул аркан ава язды: чирәм-келәмдә кабан дуңгызы башлары ауный иде. Хатын кем кулы уйнаганын чамаласа да, тавыш-гауга куптармады, хәрәм сөякләрне чокырга илтеп күмде. Сәмигулла отыры азды: койма аша гына хайван эчәкләре томырды. Аннары бүре аяклары, поши мөгезләре «яудырды». Гайрәтләнеп күршесенең дөньясын туздырыр иде Гамбәр, әмма ниндидер көч: «Кешеләр тарафыннан кылынган зыяннарга каршы сабыр бул!» – диде. Ул көч ачу-ярсуыннан тыйса да, җанының әрнүеннән тулышкан хатын үзе генә салган сукмактан утарга китте. Мәрхүм Заретдин аның ни терәге, ни җилкә ышыгы була алмады, бәлки, улы Рәшит әнисен усал җилләрдән яклар дип өметләнде. Улының исә үз мәшәкате, утар тирәсендәге усакларны кистерә иде.

– Агач эшкәртү заводы оештырам, әни, – диде ул. – Әтинең хыялы иде.

– Атаң зурдан купкан иде дә... – Гамбәр нокта куймыйча җөмләсен өзде.

– Иртәрәк үлде шул. – Рәшит аның кинаясен аңламады. – Кабердәге чардуганы аумады микән әтинең?

– Соң, бар да карап кил, улым.

– Вакытым юк, әни. Син дә зират кырыеннан үтәсеңдер. Күренмиме?

– Аннан үтмим мин, улым.

– Әти үлгәч тә дошман инде сиңа, әни.

– Атаң бәхетле, алдындагы кәндие буш түгел, улым.

– Уф, үтерәсең, әни! Нинди «кәнди?» Саташасың мәллә? Мәетләр ашамый-эчми.

– Чәршәмбедән җомга шае мәрхүмнәр дога савытын барлар, ди. Кәнди буш икән, кайгырыр, тулы икән – шатланыр, ди. Мин әтиең рухына багышлап намаз артыннан дога укыйм, улым. Комунисларның комачына төренгән Заретдин «мәңгелек йорт»ка ак кәфенгә уранып күченде.

– Авылга – нигеземә үләргә кайтам, дигәч, мин аны шаярта дигән идем.

– Шаяртмады, улым. Атаңа мин риза-бәхил. Аллаһ аның бер гөнаһысын кичерерме икән? Ул сине манара биеклегеннән тузанлы җиргә сөйрәп төшерде.

– Әти миннән кеше ясады, әни! Калада укытты, һөнәргә өйрәтте. Бу утардагы байлык безнеке, әни, безнеке!

– Мал дия-дия йөрәгең мүкләнмәсен, улым. Авылга биш былтыр эз басмыйсың. Сагынмыйсыңмыни, улым?

– Айтуган мине тартмый, әни. Ул минем өчен ябылган капка.

– Анда мин – анаң бар.

– Синең йортың әнә-ә! – Рәшит урманга терәп үк салган ызбага күрсәтте. – Күпме чакырам, кил, рәхәтләнеп яшә.

– Кыстама, минем үз нигеземдә рәхәт. Атаң биздерде сине авылдан, атаң. Катыныңнан аерылсаң да, баладан каерылма.

– Оныгың үсә, әни. Ул шәһәр малае. Кем өчен завод дип чабам соң мин?! Аңа дип дәүләт төзим! Без ярдырган такталар акчага әйләнәчәк, әни. Йә, боекма, өч-дүрт атнадан оныгың белән танышырсың. Малай үзе дә: «Минем Зур әни кайда?» – дип аптырата.

Улы кисәк кенә сүз агымын бүтән якка борды һәм, шелтәләп:

– Әни, син дә гаепле, син әтине коммунист дип санламадың, – диде.

Әни кеше бәхәсләшмәде. Аның кайчандыр азан кычкырып таң аттырган үсмер улы Рәшитне еллар урлаган, монысы Заретдин куагыннан тәгәрәгән алма иде... Ләкин ул барыбер Гамбәрнең бәгырь җимеше иде. Рәшит: «Йомышың юкмы?» – димәде, чөнки анасы көнаралаш диярлек утарга килеп чыга һәм беркайчан да әйбер-фәлән сорамый иде. Күрше-күләннән зарланып ни файда? «Авылда сине кысалар икән, әнә-ә, синең ызбаң, рәхәтләнеп яшә!» – диячәк.

...Уйларына чумган карчыкны Миңсылу җиңеннән тарткалады:

– Җиңги, әй, җиңги! Оедың мәллә, җиңги? Самавыр мәңге кайнамас. Теге симезбикәне эзләп чыкканыем, нарат төбендә сыңар күркә дә кузгалмаган. Качкан калын катын! Кисәттем мин сине, җиңги, шыпиун ул, дидем.

– Чәчрәмә, кем кыз. Энәсе әллә ни җүләмәс, җебе кыска.

## 9

...Кая бара ул, кая? Күркәләр коелган сукмак бу якта түгел лә! Кемдер хатынны үзенә суыра кебек... Аның камыр аякларымы соң болар? Нишләп алар тәгәрмәч төсле тиз-тиз «тәгәри»?! Йөрәк җилкенүе табаннарга ут якты мәллә? Муенсаны табасы иде. Табасы... Гөлҗиһан өчен шундый да тәҗел әйбер микәнни ул? Ни-нәрсә теләгәнен хатын-кыз үзе дә белми, диләр. Ул белә! Энҗе-мәрҗәннәрдән артык күреп, алтын тартмада саклаган икән, димәк, бүләкнең кадере бар. Әллә аның иясенеңме? Чү, бу хакта уйларга да ярамый хәтта! Гөлҗиһан – карчык өчен кан дошманының кызы. Атасы явыз иде шул, күршеләренә бәйләнүдән туктамады: җир өчен көрәш кызган саен кызды. Башбаштак Сәмигулланың кулына сугучы юк, авыл хуҗасы Мирхәйдәр абзый, аның бөтен әшәкелеген хуплагандай, һәр кич көрәшнең нәтиҗәсен белешә иде.

Ирләр очрашканда, энисе, йөрәк өянәгем кузгалмасын дип, келәткә бикләнә, ә олыларның сүзен тыңлар өчен Гөлҗиһанны, иске фуфайкалар белән каплап, мич аралыгына яшерә иде. Кыз исә барысын да киптергеч кәгазе кебек хәтеренә сеңдерде.

– Ни хәлләрдә, Сәмигулла энем? Ярты бакча синекеме?

– Минеке, минеке! Ул гына аз түлке.

– Аягыңа карап юрганыңны суз, дияр идем дә энем... – Авыл хуҗасы кеткелдәп куйды. – ...аягың хәтәр озынайды әле. Нәстә ди Гамбәр?

– Тулаем бир, дим, карыша, сихерче калдыгы! Ишегалдына ниләр генә бәрмәдем, каһәр. Бүген төнлә мин аның йортын нәҗескә буйыйм! Исеннән кырык чакрымга качсын, каһәр.

– Алай ук быкырдатма әле син, Сәмигулла энем. Ирләр эшемени инде ул.

– Соң, син чарасын күр! Син бит блач. Авылны дин белән агулый, дисең бит, тип артына, анаңны...

– Сүгенмә, өшәнгән бүре! Заретдин белән без дус идек. Ул да җиңәлмәде бичәсен. Киресенчә, үзе җиңелде. «Мин – камунис», – дип күкрәк төйгән баһадир җаны чыкканда, Алла, Алла дип ыңгырашкан, ди. Катын кибеттә сөйләделәр, ди.

Атасы йодрыгы белән өстәлгә сукты.

– Син монда катының җырын җырлама, блач! Мөслимә апай Гамбәрләргә ешлады.

– Кыз-катын бер-беренә кунакка йөрешер инде. Син дә тагы!

– Кунакка, дисеңме? Өшкертергә, диген, Мирхәйдәр абзый. Катының сөннәтче Фәхретдин кызы икәнен дүрәк тә белә. Мөәзин бабасы Чистай төрмәсендә черегән Мөслимәнең.

– Туктале, Сәмигулла, аның бабасы бүлнистә үлгән.

– Кая үлсә дә, миңа адин чурт! Дин белән агуланган алар. Төп-тамырыгызны казытсам – урыныңнан маминт очыртырлар, блач!

– Чур, энем, ыштан бөрмәң бушамасын, ату арт чүмечең ялтырар! – Мирхәйдәр абзый да үз чиратында дөрләп кабынды: – Радий Арсинычка вак корт икәнеңне хәбәр итсәк – төкерә сиңа. Бик узынсаң без аңа авылда менә дигән примир туган әтмәлләрбез. Ялган кыягаз эшләтергә мачтыр без!

Ирләр беркавым тынды. Менә атасы, авыр мышнап:

– Ызбулыч, янап утыра бит, ә! – диде. – Блач икәнсең, булыш лутчы. Әзрәк боргычла киребеткән нәмәстәне.

– Өйрәтмә, энем. Гамбәр белән бер сөйләшкән идем мин. Шуннан соң бөтен миргә рисвай итте. Үзең майла-җайла, вчүтки сез – күршеләр. Хуш, Сәмигулла!

Идән сайгагы шыгырдады. Мирхәйдәр абзый артыннан атасы мыгырданып калды:

– Блач тәресе! Җебегән су күсесе!

Төнлә әнисе Гөлҗиһанны уятты:

– Кызым, тор, янабыз!

Тәрәзә пыяласы кып-кызыл, әйтерсең, кызыл буяу сөрткәннәр иде.

– Сәмигулла, Сәмигулла, – диде әнисе. Хуҗа, гадәттә, сөякләрем туңа дип, бик эссе көннәрдә дә мич башында йоклый, тик бүген ул өн-төн чыгармады, аның урыны буш иде.

– Әйдә, әйдә, атаң төнге аудә! – Аналы-кызлы ишеккә ташландылар. – Без янмыйбыз бугай, кызым.

Әйе, күршенең йортын ут чолмаган иде. Йокы белән исергән халык:

– Пожар, пожар! – дип акырышты. Кемдер чиләк, кемдер көрәк күтәреп чапты. Әлеге күренеш еллар узгач төсен җуйды, билгеле, тик менә күбәләкне хәтерләткән ак күлмәкле Гамбәр апаның:

– Мәчетне сакла-а-а-гы-ыз! – дип сөрән салуы әле дә булса адашкан кайтаваз кебек колакта чыңлый. Җан җепселләрен өзеп кычкырган тавыштан җиһан калтыранып, күктәге ай да кителеп төшкән иде кебек.

Әтисе «аудан» иртән генә кайтты. Тустаганнан гына салкын су чөмергәч, куе кашларын җыерып:

– Ызбада ниткән үле тынлык? Кая ашарга? – диде.

– Синдә тамак кайгысы икән, Сәмигулла. – Әнисе тастымалга төргән ярты түгәрәк ипине өстәлгә куйды. – Мә, аша. Казан асмадым. Күрмисеңмени, Гамбәр апа янды.

– Күрәм, җен катыны! Сукыр түгел!

– Синең эшеңме, Сәмигулла?

– Авызыңны яп, ана бытбылдык!

– Ширпы сызган кулың корыр, җаһил!

Әтисе киерелеп сугып җибәрәм дигәндә генә, Гөлҗиһан әнисен ышыклап басты.

– Тимә!

– Монысы да анасы яклы! Кара син бу чәчбиләрне! Кара син! Ыштубы да

сүзләрне берләштерик: мин – урманда идем, кәкре аяклар! Урманда! Ауда! – Явызлыгыннан акылы таралган атасы, тагын да сискәндереп: – Ишеге дә ачык иде, өстенә крәчин сибәсе иде ул сихерче калдыгының. Шуның белән котыла идек, шайтан мөгезе, – диде.

– Ничекләр яшәрбез? Авыл безгә, бармак төртеп: «Әнә, кеше яндыручылар!» – дигәндә нишләрбез, и Аллам?! – дип үксегән әнисе дә беркатлы иде. Айтуганда әледән-әле янгын булып тора, соңыннан бичара хуҗа өмә ясап бура бурата, аны күмәкләшеп күтәрәләр, ул чакта халыкта хәлгә керү дигән нәрсә бар иде.

Ләкин, ни гаҗәп, күрше нигезендә яңа йорт төзелмәде...

...Тук-тук. Тук-тук... Урманга ишек уйганнармыни, ачыгыз, ач дигәндәй кызыл бүрекле тукран тукылдата. Уз, кошкаем, уз! Гөлҗиһан да рөхсәтсез-нисез генә яшеллек иленә керде. Әмма ул синең кебек монда иркенләп «оча» алмас. Болай да көчкә-көчкә сөйрәлгәндә, балачак хатирәләре тагылып, гәүдәсе тагын да авырая шул. Ичмасам күңелле хатирәләр булса икән! Ичмасам искә төшкән саен йөрәк җылынса икән! Еллар җиде төенгә бәйләгән кара төенчекне бүген карчык чишми, дисең мәллә? Чишә, бик чишә! Чөнки Гөлҗиһан кайтып аның дөньясын актарды. И язмыш!

Хатын тар юлда машина тәгәрмәче эзен абайлагач, тагын да дәртләнеп алга «йөгерде». Их, тимер таккан аяклар белән узышып, башта йөрәк «чаба» иде шул. Минап абзый адашып туктаган урын шушы тирәдә микән әллә? Нигә бу агач-куак, игезәкләр сыман, бер-берсенә охшаган икән соң?

Тук-тук... Тук-тук... Бәйләнмәсәнә, тукран! Эшеңне эшлә!

Юл икегә тармакланды. Әлсерәгән хатын кайсысына борылырга да белмәде. Уң җәптәгесе яктырак иде, димәк, анда агачлар сирәгәя. Яктылык һәрвакыт адәм баласын үзенә тарта: Гөлҗиһан да шунда таба теркелдәде. Барды-барды, ә беләзегендәге алтын сәгате, ашыга-ашыга вакыт санады. Карчык самавыр кайнатырга нарат күркәсе көтәдер... Бәлки, көтмидер. Бәлки аңа артык кашык кунакның югалуы хәерлерәктер.

Хатын арып-талып имәнгә аркасын терәде. Уф, авыз кипте, тел аңкавына ябышты. Алдында тау-тау кырмыска чүмәләсе иде. Ул сусыл имән яфрагы өзеп, түмгәк өстенә җәйде. Оясындагы ят әйбергә йөзләгән сакчы бөҗәк «һөҗүм» итте: «дошманы»на әчкелтем кислота сиптерде. Гөлҗиһан, кырмыскаларны кагып, «яшел дару»ны ялады. Сусау басылды кебек. Кара бөрлегән капсаң – баш әйләнүе дә бетәр иде, шәт. Яисә балтырганның бәбәнәген генә чәйнәсәң... Әй, яшеренеп үлән арасыннан гына аккан чишмә суына берни җитмәс иде!

Нишләп балачакның серле мизгелләре керфекләрне чылата икән? «Ул хәерчелектә үткән елларның ни-нәрсәсен сагынасың, елак?! Бүген син хан сараеның патшабикәсе ләбаса! Кигәнең – асыл ефәк, табыныңда – ата-бабаң гомердә тәмләмәгән затлы сый-нигъмәт», – дип, хатын үз-үзен юатса да, җанына җиңеллек өстәлмәде. Чөнки байлык бернинди зәхмәттән дә, бернинди чирдән дә коткармый, бу – кырыс хакыйкать иде...

Юл, яктырган саен яктырып, ачыклык белән тоташты. Алан иде ул. Гөлҗиһанның күзе шарланды: шушы урман дәрьясында тереклек утравы бар! Рәт-рәт тезелгән умарта ояләры янында бер ир-ат кайнаша иде. Менә ул челтәр битлеген салды, менә... Хатын агач артына посмакчы иде, аңардан юанрагы юк икән, хәтта иң калын дигәне дә Гөлҗиһаннан ябыграк иде. Теге ир дә аңа табан килә башлады. Ул куркудан куырылмаган, аның монда хуҗа икәнлеге тамак кыруыннан ук сизелә иде.

– Кхым-кхым! Сез кем?

– Кеше, – диде Гөлҗиһан. – Ә сез кем?

– Мин – умартачы. Танымадым. Нинди кеше сез? Адаштыгыз мәллә?

– Юк, юк! – Хатын артка чигенмәкче иде, аяклары җиргә береккәндәй, тыңламады. Моңарчы ул үзенең кыяфәтеннән оялмый иде, ә хәзер тир бәрде. Кыя төсле катып кал инде, йә? – Адашмадым... Буталдым гына. – Гөлҗиһан керфеген тибрәтеп тиз генә үзенә якынлашкан умартачыга карап алды. Кинәт табаны кызышып, аяклары үзеннән-үзе җирдән купты... – Хуш...ыгыз!

– Сез икенче тапкыр буталасыз, кеше исемле кеше!

«Умартачы» хатыннан көлә иде бугай. «Без буталганда, син нишләп чикләвек куагы төбенә качтың? Нишләп юл сабышмадың?!» – дип, син дә үпкәңне белдер идең дә... Фәрит ләбаса бу! Аңа муенса ясаган Фәрит! Димәк, теге көнне әбисенә ул тартма белән әйберләр китергән. Сөен, Гөлҗиһан, сөен! Ул сине танымады! Тал чыбыгыдай нәфис кыз бала белән кибән хәтле хатын арасында нинди уртаклык булсын ди!

Аксак-туксак хатынны карчык орышмады. Миңсылу гына тыртайган иде.

– Өч сәгать кайда гүләйт иттең, ваемсыз?! Вәт, синең белән чәй эч!

– Мин төрмәдәмени? – диде Гөлҗиһан. – Ирегемне кысмагыз, яме?

Аның күзеннән яшь бөртеге сытылды. Әллә үзен кызгана микән? Юк, бу эчтән бәргән утлы һава, әнә, ул тамагын көйдереп-көйдереп ала. Фәрит кул сузымында гына йөри! Фәрит... Урман егете... Нигә карчык пыр туздырып тиргәми икән? Үзе күз угы белән кадый тагы...

– Миңа нишләргә соң, Гамбәр әби? – Әлеге киеренке хәлгә Гөлҗиһан гына гаепле иде, димәк, ул хуҗабикәләргә ялагайланырга тиеш. – Күңелсез миңа, Гамбәр әби. Каядыр чыгасы килә бит инде...

– Нишләргә, димсең? Яшәргә кирәк, яшәргә, канәтем. – Карчык әзрәк йомшарды. – Адәм зур ызбасын тарсына, кош уч төбе хәтлем оясын киң итеп тоя!

– Урман артык куерган. – Әлеге минутта ялган бердәнбер саклану чарасы иде. – Агачлар игезәкләр диярсең, охшашкан, шуңа адаштырды.

– Кем син, кыз! – Кортка Миңсылуга боерды: – Кәҗәне алып кайт!

Каенсеңел чыгып киткәч, карчык, чикләвек ваткандай, тешен шыкылдатып:

– Алдак бәндә – хурлык иясе, – диде. – Син яңа дөнҗада яшисең, аның ишеге дә яңа. Элгәрегеләрне ыргыт, ерак ыргыт!

– Аңламадым, Гамбәр әби?

– Аңладың, бә-әк яхшы аңладың. Үткәнеңнән бернәмәстә дә эзләмә!

Кар иләгәндәй, хатынның аркасы өшеде. Ни-нәрсә уйлаганнары маңгаена языла микән әллә? Юк инде, юк! Карчык кыек атып туры тидерә, нибарысы шул гына.

– Таныдымы?

– Ә?!

– Онык сине таныдымы?

Хәзер инде Гөлҗиһанның аркасын утлы кисәү белән көйдерделәр. Ялганы тотылды... Ул, чынлап та, хурлык иясе иде.

– Таны... таны... мады, – диде хатын, сүзен өзек-өзек бүлеп.

Бая гына карчыкның йөзеннән шуышкан кара болыт агарды.

– Әлхәмдүлилләһ! Шулай кирәк, шулай. Оныкҗанымның минем катыма килер юлын бикләрлек кодрәтем җук, мин Аллаһның колы гына, вәләкин син – азгынны тыяр пычак телем бар. Минем ызбамда Сәмигулла кызы Гөлҗиһан яшәми, ишетәмсең?

– Әйе, Гамбәр әби.

Күз агы зурайган белекче үзалдына пышылдап утырды-утырды да:

– Синең атың бүтән, – диде. – Абага син, Абага.

– Абага?! Минме?! Көлдермә, Гамбәр әби!

– Син, син! Ант мәгәр, соңгы чырагым – оныкҗанымны сезнең каһәр суккан нәселегездән сакламасам, чын исемем... – карчык нигәдер тотлыкты һәм, сүзе бугазына төртелгәндәй, нәзек муенын сыпырды. – ...Исмем исем булмасын, – диде.

– Фәрит бит минем риясыз балачак дустым иде. Мин аңа бернинди начарлык та эшләмим, Гамбәр әби! Ышан миңа, ышан!

– Сезнекеләр – җир-күкнең битенә төкергән кавем. Әмерем шул: танытма! – Мөгезенә бау бәйләгән кәҗәне ишегалдына куган Миңсылуга да кортка ачу ташы белән орды: – Сул аягыңны күтәргәндә, уң аягыңны эт ашый, кем кыз! Җәтрәк бул! Хайванның җилене өрелеп тулган, сөте ага!

– Акса инде, җиңги. Безгә калганы җитәр әле.

– Телләшмә! Кәҗәне Абага саусын, кем кыз.

– Бәй, ниткән Абага, җиңги?

– Мин ул, мин! – диде Гөлҗиһан. – Миңа яңа исем тактылар.

– Вәт сиңа пәрәмәч! – Миңсылу тел шартлатты: – Шыпиун дигән идем лә бу кемсәне, тучны шыпиун! Алар атна саен исем үзгәртә, ди.

– Акыл сатма, кем кыз! Кичкелеккә кәҗә сөтенә солы кушып кайнат. Гөлҗиһанның бүгенгә ризыгы шул, – дип, карчык каядыр китеп баргач, Миңсылу аңа сапсыз савыт тоттырды. – Әйдә, сау!

Малкай, күрәсең, гадәт буенча үзе күтәртмә тактага менә иде. Ә менә хатынның кәҗә имчәген тартырлык тәҗрибәсе юк, акча санарга гына яраган бармаклар начар бөгелә иде. Ул савытын юри кулында әйләндерде:

– Бигрәк кечкенә...

– Аңа ике литыр сыя. Кәҗә сыер түгел. Кем дисең әле син үзеңне? Абагамы әле? Шыпиуннар гел исем төрләндерә. Кинада күрсәтәләр. Син шуларның берсе ахры, гөлкәем?

– Сөенмә, Миңсылу апа. Без икебез дә мактаулы халык: син шымчы һәм әләкче икән. Шыпырт кына артымнан күзәттеңмени?

– Ә-ә, җиңги белән бозылышкан безнең нәзберек кунагыбыз! Әйтәм аны әбиең җенләнә. Аның характерына мин генә түзәм. Әйдә, мәлҗерәмә, кәҗәне сау! Әүвәл, җиленен юып, чүпрәк белән корыт.

Кәҗә дә, карт хуҗабикәсе кебек пырдымсызлана, мөгезе белән тактаны сөзә иде. «Мин бай хатын, себереп кенә түгәрлек көнкүреш чүп-чары белән вакланам. Хурлык!» – дип йөрәк ярсыды, тик акыл аны тиз бастырды. «Ахмак! Синең акчаңның нинди кодрәте бар соң? Ул кәгазь кисәге генә. Ертсаң – ертыла, яндырсаң – яна. Син – авыл кызы, шуны онытма!» Әйе, ул бу җирдә туып-үсте. Әмма бүген кер сыккан кебек сыксаң да, аңарда авыл гадәтләренең тамчысы да калмаган иде.

– Бисмилла, – диде Гөлҗиһан. – Бисмилла... Мин үзем сайладым...

– Нәстә сайладың, гөлкәем?

– Кәҗәне! – Хатын моңсуланды. Аның хәлләре Миңсылуга караңгы иде. Лариса исемле танышы Американың иң кәттә клиникасында күкрәгән зурайтырга киткәндә, и үгетләде Гөлҗиһанны, и үгетләде! Имеш, анда тәҗрибәле профессор атна-ун көн эчендә маеңны тунап, илле-алтмыш килога ябыктырачак. Имеш, чит илдә табиблар иң заманча ысуллар куллана. Әмма күңел төпкелендә бик күптәннән бер уй кымырҗый иде шул. Могҗиза белән йөзәрләгән авыруны терелткән усал Гамбәр! Гап-гади авыл белекчесе! Менә кем кирәк иде аңа... Менә кем белән саташты Гөлҗиһан. Юлга чыгасы иртәдә исә хәбәр иреште: төргәк-төргәк доллар белән Америкага очкан танышы операциядән соң мәңгегә күзен йомган иде. Авылны сайлаган Гөлҗиһан: «Отаммы, оттыраммы – билгесез», – дисә, Алла риза

булмас. Хәрәкәтләнә ләбаса! Менә кәҗә дә сава! Җылы сөт тамчылары битенә чәчрәгәндә, ул ниндидер рәхәтлек тойды. Димәк, ул яши! Димәк, ул тере!

– Карале, кем, ышпиун Абага. Мине шымчы, дисеңме? Үтердең, валлаһи. – Миңсылу аның җилкәсеннән селкегән иде, хатын чак кына артка аумады.

– Сөт түгелә, Миңсылу апа!

– Түгелмәс! Бәнахакка рәнҗеттең әле син мине, гөлкәем. Сине юллап бармадым һич тә! Чалыш-пылыш аягымнан ташбака гына көнләшер иде. Безнең җиңги, сиңайтим, урмандагы кайсы агачка чебен кунганын да сизә. Минем авылга сәпсимгә кайткан чагым гына иде, берсендә әбиең ишегалдында җеннәре белән сугышты: көрәк-сәнәк очты, себерке сынды, утын әрдәнәсе ишелде, мин сиңайтим. Моңарчы ул мәшрикътә, мин мәгърибтә яшәгәч, аның бу тиклем дуамал икәнен күрмәгән идем, зерә курыктым. Ник кайттым дип үкенгән чакларым булды инде. Нишләтәсең, холык тау кебек, урыныннан кучми. Иртә белән безгә Рауза атлы катын килде. Әй җиңги моны элеп алды, селкеп салды, мин сиңайтим. Син, ди, төнә, ди, миңа кемне апкилмәкче идең, ди. Биш балалы ир белән чуалган фахишәгә Аллаһ бөтен юл-сукмакларны каплады, йортыма китермәде, ди. Озатканда, Рауза серне тиште үзе. Дускынае җиңгидән сөйдергеч бөтие ясаттырмакчы икән, әйдәле, минем белән иптәшкә бар, дигән. Әби синең белешең бит, дигән. Без, ди Рауза, иремнең бензаус машинасы белән Айтуганга киттек. Чалт аяз көн иде, кинәт кенә күктә болытлар укмашып, койды яңгыр, койды яңгыр, машина таеп чокырга төште дә батты, ди. Ирем трактор эзләп күрше авылга чапты, төн җитте ди. Өйдә имчәк балам каенанам белән иде, сабыем ач дип, елап беттем, ди. Мона син әйт, шыпиун кисәге, кем аларны күзәткән дә, кем җиңгигә җиткергән, ә?

Әгәр ул ике араны җайламаса, Миңсылу, җае чыккан саен, аның бәгырен кара яндырып чеметәчәк иде.

– Зинһар, гафу ит, апа җаным. Ачуланма инде, яме?

– Гел үзебезчә сөйләшәсең әле син, гөлкәем. Тач авыл кызы үзең. Бер генә дә ышпиун димәссең, – дип кеткелдәде каенсеңел.

– Авылныкы, билгеле, авылныкы. Син моннан соң миңа яратып «Абага» дип кенә эндәш, апа җаным.

– Абагамы, кукурузмы, син безнең иш түгел түлке!

Миңсылуны көйләве бик авыр иде шул. Ярар, чеметсә чеметер инде.

– Сөте азайды, апа җаным.

– Азаймады. Ят кул, шуңа качыра. Кая, кибән, кырыйгарак этел. – Каенсеңел савытка сузылган гына иде, кәҗә башын болгап җиргә сикерде. Сөтнең яртысы түгелде.

– Сиңа монысы да күп әле, гөлкәем. Нәстә каттың? Селкен!

Урманда тилерткән ашкыну кайда икән? Тән чемер-чемер ойый... Карчыкның чик-тыюлары бөтен көчен суырды. Ул – абага. Ул яшеренеп кенә төнлә чәчәк ата... Фәрит аңа юлыкмаска тиеш...

**10**

– Мәчетне саклагы-ы-ыз!

Кем шулай урман ярып кычкыра икән? Кем?

Карчык әле уңга, әле сулга борылды. Тирә-якта тып-тын. Калын дивар сыман дөньяны томалаган усаклардан да күз йөгертте. Яфраклар хәрәкәтсез иде. Тагын баягы тавыш йөрәген кисеп төште:

– Мәчетне саклагы-ы-ыз!

Ул кырмыска түмгәгенә иелде. «Бу газаплы иңрәү ияләре әллә сезме?» – диде. Ләкин адәмнәр сыман әрле-бирле чабышып, нужа куган бөҗәкләр аңа

илтифат итмәде. Корыган чыбык-чабыкны кыштырдатып, аякка ана керпе ышкылды. Ул да телсез иде...

– Мәчетне саклагы-ы-ыз!

Йа Аллаһым, еллар аша Гамбәр үзе илерә, хәтер, күгәргән энәсе белән чәнчеп, йөрәкне каната икән лә.

...Дүрт почмагыннан берьюлы ургылган ялкын телләре йорт белән каралты-кураны бик тиз ялмады. Чиләк белән су сибеп учак кына сүндерәләр шул. Мәчет исә, әйтерсең, һавадан шырпы сызып ташладылар, өстән – манарадан янарга тотынды.

– Мәчетне саклагы-ы-ыз!

Ир-ат багор белән янган такта кисәкләрен читкә тартты, хатын-кыз туфрак сипте, һәм матча ишелгәч, бозлы сулыш өргәндәй, ут диварларга күчмәде. Төнге маҗарага нокта куеп, халык та таралды. Төтен исеннән аңгырайган хатын кайнар җиргә чүгәләде. Төн кисәк кенә караңгыланды, гүя күктәге йолдызларга хәтле ялкыннан өтелгән иде.

Ул Зәйтүнә әбиләрдә кунды. Иртән, такта сәкедән торыйм дисә, аяклары тыңламады. Карчык су эчергән иде, буыла-буыла косты.

– И килен, хасталандың мәллә? – Заретдин абзасының яшьлек мәхәббәте аңа килен дип эндәшә иде. – Филшер Дамирәне чакыртыйм, килен.

– Дога укып өшкер, әби, – диде Гамбәр. – Миңа ут зәхмәте тиде.

– И килен, минем гыйлемем сыек бит. Икебезнекен бизмәндә үлчәсәң – аккурат синең яктагы тәлинкә баса.

– Синдә Коръән бар, Зәйтүнә әби. Шушы изге китапны кулыма тотсам – хәлләнер идем.

– Шыпырт, килен! – Хуҗабикә ачылмалы тәрәзәне япты. – Сәвитләр ишетмәсен.

– Син Аллаһтан гына курык, Зәйтүнә әби.

– Дөрес ансы, килен. Әнинең Коръәне чормада, хәзер апкиләм.

Яшь иде Гамбәр, җегәрле иде, тиз савыкты. Янган нигезенә бармады, туры кәнсәләргә китте. Ишек ачык, эчтә Сәмигулла белән Мирхәйдәр сөйләшә иде, хатын өйалды почмагына элгән чаршау артына кереп басты. Сәмигулла, өстәл төя-төя:

– Син, блач, минем юлыма бүрәнә тәгәрәтмә, – дип үкерсә, Мирхәйдәр аңардан да уздырып акырды:

– Эттән туган әнчек! Өрмә! Ни барына канәгать бул! Бакча сиңа, җәел-киңәй, ну түлке Заретдиннарның янган нигезенә тукмак борыныңны сузма!

– Сузсам – нишләтерсең, хәерче блач?!

– Кем ут төрткәнен ачыкламагаек, энем! Минем сакал белән шаярма, җәме? Малае Рәшит яңа йорт салыр тиздән. Закун Гамбәр катын ягында. Районга жалу язса, Арсинычның әфтәрититен буйыйсыз бит, аңгыра!

– Жалу язарлыгы җук аның. Зәйтүнәләрдә үлеп ята, ди. Җен-пәриләре таяк белән ярып сөякләрен сындырган, ди. Син, блач, ишетмәдеңме?

– Тфү, аңгыра! Әкиятең белән кеше ышандыр тагы! Исән ул!

– Нәстә һаман әфсен-төфсенне яклыйсың, Мирхәйдәр абзый? Сине ничек адәм рисвае иткән иде ул катын.

– Гаеп үземдә иде. – Мирхәйдәрнең тавышы кысылды. – Гамбәр катын, авылда ир балалар күп туды, сөннәткә утырт дип, Вәлетдин картны котырта. Өстәгеләр моны белсә – баштан сыйпамас, мәйтәм. Сәвит илендә кыргый йолаларның тамырын корытырга, диләр, сез – блач, көрәшегез, диләр. Ансат кына уйлый абзыйлар. Заретдин катыны, зәһәр, бөтен халык алдында Вәлетдингә әйтә: «Мин күземне йомам, бабай, син бу сәвит ялчысының

ыштанын төшереп тикшер, аның нәселе – иманлы булган, шаять атасы улын сөннәтле итеп үстергәндер», – ди.

– Ха-ха! Синнән егылып көлгәннәр икән, блач!

– Ыржайма, болай да аузың чалыш! – Мирхәйдәрнең тагын тавышы көрәйде. – Минем белән бозылышып, син чуртым да майтармассың! Авылда мин – закун!

– Закуныңны арт шәрәфеңә бөкләп тык!

Сәмигулла күтәрелеп-бәрелеп чыгып китте. Бу ызгышның ирексез шаһиты – Гамбәр янды-пеште, аңа оят, бик оят, ул ир-ат гайбәтен тыңларга тиеш түгел иде. Берүк кичер, Аллам! Әллә нишләде шул, котсыз гына үрмәкүч, пәрәвез сүз җебе үреп, тозагына эләктерде... Ул уңайсызланып кына бусагадан атлады. Сәвит Мирхәйдәрнең башы иелгән иде, аны күргәч, шунда ук турайды.

– Сине хаста дигәннәр ие, Заретдин катыны.

– Аллаһ ярдәме белән терелдем. – Гамбәр уртасы тишелгән иске агач урындыкка төртелде. – Сиңа йомышым бар, Мирхәйдәр.

Авыл хуҗасы аны тыңлап бетермәде, шелтәләргә керешә:

– Бала-чагаң да җук бит, чыра яндырып төн-ката нишләдең, йә? Көндезләрен такмаклап туялмаган догаңны ник төнгә дә калдырасың, йә?

– Дүрт нүешкә дүрт чыра кыстырмыйлар, Мирхәйдәр!

– Төрттеләр дисеңмени? Йә, күрдеңме? Кем иде, каһәр суккыры! Арт сабагын укытам!

– Җәза бирүче берәү генә, Аллаһ кына. Без түгел.

– Тукта, тукта, Заретдин катыны! Блач кешесе, гүпчим дә авыл хуҗасы, җинаятьчене хөкемгә тартырлык вәкаләткә ия!

– Әтәчләнмә, Мирхәйдәр. Син – көчсез, мескен җан. Синдә нәселегезнең иман чылбыры өзелгән, оныкларыңның оныклары исем-атыңны телгә алырга чирканыр. Блач кибәнен биек өйдегез, вәләкин җир-күкләрне тоташтырган давыл аны тузгытып ташлар. Салам бөртегенә ябышып кайсыгыз котылыр икән?!

– Безнең корыч партия мәңгелеккә оешты, син – кунтыр катын, камунисларга кабер казыма! Лутчы йомышыңны әйт тә әллүр кантурдан. Калхуз сиңа яңа ызба төземәс, чөнки дә хөкүмәткә ярты көн бил бөкмәдең.

– Сездән кем ызба теләнгән ди, Мирхәйдәр?!

– Ансы синең улың бар, знамы, ул тергезер.

– Улымны да борчымам. Мин Заретдин нигезенә бүтән оя кормам. Анда хәтәр ут, бик хәтәр ут калды... Берзаман ул дөрләп кабыныр. – Гамбәр үзалдына елмайды. Күңел алдан ук тантана итә кебек иде. Кичер инде, кичер, Кодрәтлем! – Гозерем бәләкәй генә: мәчетебез яртылаш янды. Ир-атка балта-пычкы тоттырып рәтләтәсе иде.

Мирхәйдәр, корчаңгы чире иярткәндәй, шатыр-шотыр beләгеn кашыды.

– Ну, сез катын-кыз, ну сез! Торыр җире җук, үзе мәчет, ди! Түлке картлар исеменнән ялынма, мин аларның әммәсе белән дә күрештем, без янган йортта намаз укымыйбыз, диләр.

– Алай икән. – Хатынның ирексездән күзе яшьләнде. – Алай икән, – диде ул, кабатлап. – Азансыз авыл – җансыз авыл.

– Динем-денем дип кешеләрне агулама, Заретдин катыны! Тирә-якларда мәчетләрне туздырып, мәктәпкәме, клубкамы бирделәр, бездә генә син башбаштакка түзәбез. Синең аркада партия кенәгәсеннән колак кагам хәзер. Үзеңне кайгырт лутчы. Дога белән генә тамагың туймас!

– Моннан ары мине мир ашатыр, – диде Гамбәр. – Бер телем ипи хакына өшкерермен. Сез мине ач-ялангач күрмәссез, иншә Аллаһ!

Җан авыруы озакка сузылды: хатын, терелдем дигәндә генә, сусыз-тәгамсез тагын ун көн сәкедә ятты. Кайчакта, җиңелчә генә һушыннан язганда, йомшак җил битеннән сыйпап аңына китерә иде. Гаҗәеп йомшак җил... Бу якларда исмәгән җил... Дала җиле... Кендек каны тамган карьясына әйдәкли... «Кайт иленә, кайт, кызый!» Кемдер аның белән бәхәсләшә дә иде. Бәлки, үзедер! «Далада ул нибарысы орлык кына иде. Заретдиннар туфрагында исә шытып, тамыр ныгытты. Аны тукландырган бәрәкәтле ашлама – иман иде».

Әрнеде, билгеле, хатын, аның әрнүе әрем әчесеннән дә әчерәк иде. Тик ул Хөкемдарга үпкәләмәде. «Холкым өчен син мине җәзаладың инде, – диде. – Торагымны адәм кулы белән утка тапшырдың. Мин синнән разый. Җиһан – ызбам, күгең – түшәмем, җирең – идәнем, мин нинди бай, Кодрәтлем», – диде.

Саесканнар хәбәр белән очкан ахрысы, авылны ят күргән, авылны сагынмаган-юксынмаган Рәшит (ата каны!) Зәйтүнә әбиләргә килеп керде. Ишек катында чүлмәкне күтәреп кенә су эчте.

– Сусадым, – диде. – Һәр минутым исәптә, әйдә, тиз, әни!

Гамбәр: «Кая?» – дип сорамады, болай да аңлашыла иде.

– Сукбай хәлендә яшәмәссең бит инде, әни!

– Ирексезләмә, улым. Зәйтүнә әбиеңнең ызбасы иркен.

– Әни, авыл сине яратмый! Яраса, каф тавы артына сөрер иде.

– Мин бер Илаһның гына яратуына мохтаҗ, улым.

– Йортны да кайсыдыр бәдбәхете яндырды!

– Улым, минем өчен хәсрәтләнмә. Үзеңнең савытың тулып ташкан, борчуың артык зур. Анаң белән киңәшсәң – бушаныр идең кана.

– Син миңа нинди киңәшче ди инде, әни-и! Сез бит тирестә генә казынган томана һәм надан авыл хатыннары!

– Ник син оныкны ирексезләп ташкалага бәйлисең, улым? Сандугачны читлектә ябып сайратмыйлар.

Кызарта-кызарта маңгаен уган (уй яндыра!) Рәшит, сәерсенеп:

– Кем әйтте? – диде. – Мин сиңа бу турыда сөйләмәдем. Уф, әни, кайчакта син бозлы су белән коендырасың. Мәрхүм әти дә синнән өркә иде. Әйе, мин оныгың Казанда төпләнер, дигән идем. Хәзер дәүләт белән галстуклы җитәкчеләр идарә итә. Безнең Фәрит алардан киммени? Тырышса, айга менә егет!

– Аларның нигезе черек агачтан корылган, улым. Тиздән сынып уала...

– Юкны лыгырдама инде, әни-и! Коммунистлар фиркасе – гранит таштан, аны беркем дә ваталмый.

– Үзең алдансаң да, балаңны алдама, улым. Дөнҗаның көе бозылды. Сез – адәмнәргә ни дә мәгълүм түгел, яхшы заманнарга өметләнмик тә. Фиркагез – бер ялган, ул җимерелеп яңа җәмгыять төзелгән тәкъдирдә, анысы да чеп-чи ялган. Җир өсте карак-угрылар, миһербансыз түрәләр, саран байлар, бетмәгән хәерчеләр, адәм каны агызган җәлладлар белән мыжлар. Син, улым, бер заманага да яраклашма, яраклашу – мескеннәр, куркаклар сыйфаты. Үзең булып яшә, улым!

– Ярар инде, телең белән чүп түкмә, әни. Җыенасыңмы?

– Җөдәтмә, улым. Ничек авылдан китим? Тамырымны куптарыпмы? Әгәр мине тапкан-баккан анам дисәң – әүвәлге-актыккы гозеремне үтә, мәчетнең өске ягына бүрәнә өстәтеп, түбәсен яптыр. Синдә анлык кына иман әсәре калгандыр, шаять, улым?

– Авыл советы рәисе Мирхәйдәр Гаделбәков та синнән зарлана, әни. Мәчет дип аның җанын кыйнама инде. Бабайлар анда йөрмибез, диләр икән.

– Йөрмәсеннәр! – Гамбәрнең йөрәк авазы җиһанны тетрәндерер иде. – Ул аягүрә килеш мәчет исемен күтәреп үлсен!!! Аягүрә килеш!

Рәшитнең тамырларында аның да каны ага, димәк, егет ясалма фиркаләрне хуплап, күпме генә бәхәсләшсә дә, иманын сатмаган иде. Улы мәчетне төзекләндереп, ишек-тәрәзәсенә аркылы-торкылы такталар кадаклаган иде. Гамбәр фаҗигадән соң беренче тапкыр шул тирәләрне урады. «Иман йорты» ятим иде инде, ятим иде... Хатын аның диварына яңагын тидереп, тыенкы гына елады да:

– Мин сине соңгы сулышыма кадәр ташламам, – диде.

Сәмигулла аларның биләмәсендә канат җәйгән, бульдозер белән йорт нигезенең кисәү калдыкларын төрттерә иде, борынын мышкылдатып Гамбәр янына килеп басты һәм, пычрак кулын сузып:

– Күрешикме соң? – диде. – Тучны күрешмисең. Безнең ишеләрдән шакшы дип җирәнәсең, тучны. Гамбәр апа, сезнең урынга ызба салам. Мирхәйдәр синнән рөхсәт, ди. Без ике күрше тату гына яши идек, менәтерә, пужар нишләтте, ә, Гамбәр апа? Тучны чыраңнан ут капты бит, Гамбәр апа! Әле бит халык тәтелди, сиңа үч итеп төрткәннәр, имештер.

– Кемнәр, ди?

– Знамы Рәшитнең дошманнары! Урман өчен сугышалар икән.

Нәфрәт хатынның йөрәген сикертте. Әгәр бу бәндә бөҗәк булса – үкчәсе белән сытар иде. Ике аяклы хәшәрәт шул. Аннары, җиңеләм дисәң, хәзер үк һөҗүмгә күч. Җиңәм дисәң – сабыр гына җаен көт...

Өченче тапкыр ул урынга ауды... Тагын билгесез чире куәтләнде. Кул-аяк, баш-муен, күз-колак аныкы түгел, чит-ят кешенеке иде. Бервакыт ул өн белән төш арасында, үзенә ике тамчы су кебек охшаган кыз баланы күрде. Кыз далада кылганнар белән куыша иде.

– Үлмә-ә-әс! Кайда син, Үлмәс?!

– Мин монда, Анам!

Хатын үзенең тавышыннан үзе куркып уянды. Җан сырхавы аның тәненә дә күчте: ирене чабырды, күз кабагы шеште.

– Адәм заты синең шифаңа өметләнеп, көн саен капка төбенә өелә, – диде хуҗабикә. – Бер ноктага текәлеп катма, килен, тор!

– Барысын да себерке белән ку, Зәйтүнә әби! Мин аларны күралмыйм! Яшеннән-картыннан җаным бизде.

– Ай Аллам, Коръән белән гамәл кылган абыстай ла син. Акылыңа кил! Турымда иртәдән бирле бер олан җылый. Көн дисәң – көн, төн дисәң – төн җыкламый, ди анасы. Аллаһ ризалыгы өчен шушы гөнаһсыз сабыйга ярдәм итче, килен.

– Мин духтыр түгел, бүлнискә барсыннар.

– Барганнар инде, барганнар. Җылавы басылмый гына ди.

– Авылда мине тиле, диләр. Тиләләр догасының файдасы шултиклем генә, – дип киреләнде Гамбәр.

– Әй килен, әби гыйбрәтле риваять сөйли иде. Тыңлап бак. Үлән-чәчәк суга тилмереп көйгәч, Сөләйман пәйгамбәр халыкны кырга – яңгыр теләргә алып чыга. И хикмәтнең хикмәте, бер кечтек кырмысканың гына догасы кабул була, килен.

Зәйтүнә карчык аны йомшартты.

– Керсен, – диде Гамбәр. Сабый гөнаһ тузанына буялмаган фирештә иде. Баласыннан уздырып анасы яшь койды.

– Апай, оланыгыз сау-сәламәт, тамагы ач, шуңа көйсез, диләр. Сөтем күп минем. Ник акыртасың дип ирем котыра, каенана оныкны җен алмаштырган, мич аралыгына яткызып талчыбык белән суктырыйк, ди.

– Авылыгыз белән тинтәкләр сез! – Белекче нарасыйны сәкегә салды. Сак кына биләүсәсен чиште. Чебеш хәтле генә малай аягын корсагына бөкли-бөкли илерде. Аның кендек ярасы да чиләнгән иде.

– Кич – кояш баеганчы килерсең, – диде Гамбәр.

Зәйтүнә карчык исә өзгәләнде:

– И килен, нишләп бордың? Нишләп оланны имләмәдең? Әнкәсен жәлләр идең. Утлар сулый бит, наныем. Мәрхүмә ахирәтем Гөлҗамалның оныгы Сәрбиназ ие ул, үземнекен кайгыртканны яратмассыз дип кенә әйтмәгән ием, килен.

– Әбекәем-бәгърем, әллә син мине бүген генә айдан төшкән дип белдеңме? Ахирәтең әле ике туганың да кана! Әйдә, булыш! Миңа әчеткән колмак чүпрәсе кирәк.

– Хәзер, килен, хәзер.

– Син камыр изеп, кабартырга кояшка куй. Мин мунча булдырам.

Карчык аңа шикләнеп карап алды.

– Нишләмәктә уең, килен?

– Һәрхәлдә әпәй пешермибез, Зәйтүнә әби.

– Кабартмамы, килен?

Хатын йорты янганнан бирле тәүге тапкыр елмайды. Димәк, әкрен генә нәфрәт-ачу йотыла... Бары тик рәнҗү генә кимеми.

– Ашау турында уйламыйк әле без, әбекәем.

Пырдымсыз хуҗабикә әледән-әле:

– Ничекләр сабыйны терелтерсең икән, килен? – дигәч, Гамбәр, аның шиген тагын да арттырып:

– Малай чирләми, ул таза-сау, – диде. – Тәне шакшы.

– Әстәгыфирулла! Сәрбиназым зерә уңган минем, көн саен су җылытып коендыра. Белдекле булып кыйланасың гына икән, килен! Алдауда икән эшең.

Туктаусыз «без-без» безелдәгән карчык аны алҗыта иде. Гамбәр үз җае белән яшәгән көннәрен сагынды. Йорт-җирсез калулар аңа көтелмәгән кыенлык китерде: ул чит кешенең көенә басарга мәҗбүр иде. Ирек тәмен тоеп, җил белән ярышып үскән дала кызы беркемгә дә яраклашмас иде.

Баласын елата-елата, яшь хатын килгәндә, камыр чыпырдап әчегән иде. Гамбәр сабыйны чүпрәгеннән арындырып, аркасына әйләндерде:

– Сеңлем, әүвәле тәненә күкрәк сөтеңне тамызып, бармак очы белән ышкып кара.

– Әннекәем! – Сәрбиназ чырыйлап кычкырды. – Нәстә бу, белекче апай?!

– Балаңның тиресе астында каты төк. Дуңгыз төге, салсаң-куйсаң – кадый. Шуңа балаң елак, – диде Гамбәр һәм, авызын ачып шаккаткан Зәйтүнә карчыкка төбәп: – Миңа дәшмәгез! Хәзер мин аны дога укып камыр белән сылыйм. Чүпрәккә чорнагач, син – сеңлем, бер-ике сәгать кулыңда йөртерсең. Иншә Аллаһ, төкләр кубар. Соңынтын мунчада юындырырбыз, кендеген канлы үлән суы белән киптерербез, – диде.

Икенче көнне туганының хәлен белергә ашыккан карчык сөенче алды:

– Олан төне буе изрәп йоклаган. И килен, үзеңә рәхмәтләр яусын. Каенанасы да шатланган. Сине ничек бәхилләтик, диләр. Абзар тулы мал-туарлары, яшь бәрән чалып бирербез, ди кияү.

Гамбәр:

– Хакым – ярты телем әпәй, шуннан артыгы миңа хәрам. Мин Аллаһ ризалыгы өчен дәваладым, – диде.

– Кодагый рәхмәтемне үз авызым белән әйтер идем, ди.

– Әйтмәсен! Ул рәхмәттә ихласлык жук! Бәндәгә нинди генә изгелек кылсам да, мине сөймәстер. Чөнки мин – үзгә оя кошы...

– Шулайрак шул, килен, – дип уфтанды хуҗабикә. – Өч хатын очрашса, телләрендә – син. Шуңа мәллә күңелең гел күңелсезләр күлмәге кигән, килен.

– Мин бәндәнең яратуына мохтаҗ түгел. Табынган затым – Кодрәт иясенең ачуына юлыктырмасын язмыш!

...«Мәчетне саклагы-ы-ыз!» Еллар катламыннан саркыган кайтаваз тынган иде. «Үткәнемдә ник һаман чокынам икән? – диде ул. – Туксан казыгымның берсе дә селкенми, мин аны нык итеп кактым ласа!» Карчык, мытыр-мытыр сөйләнеп, юлын дәвам итте. Соңгы вакытта утарга килүләр сирәгәйде. Яшь чагында тиен кебек өч кенә сикергән ара озыная ахрысы. Ә гомер чакрымнары кыскарган саен кыскара...

Утар капкасы бикләнмәгән иде. Кортка, йокымсыраган сакчы егетне уятмас өчен, галушын шудырып атламаска тырышты. Аңа атап Рәшит салдырган агач өйдә аны көтәләр, кисәү кебек кап-кара ир-ат, тәрәзәдән күргәндер, ишек төбендә тора иде.

– Ни хәл, Сәмүш? Мә, берсәк күчтәнәч. – Гамбәр карчык «кисәү»нең учына конфет сонды. – Суыр, аузың тәмләнер.

– Рәхмәт, Гамбәр апа. Ашау-эчүгә аптыратмый Фәрит. Миңа ризык ташыма.

– Үзем белермен, җәме? Мин сиңа чик сыздым, кат-кат кисәтәм, шуннан узма, Сәмүш!

– Жу-ук, Гамбәр апа, ничә ел биктә бит мин. Төнлә генә чыккалыйм, эшчеләр таралгач кына, һава сулыйм. Монда Фәрит төзетә дә төзетә. Җегет уңган, Гамбәр апа. Көн оз-ын, Гамбәр апа. Күңелсез кайчакта. Син минем мәрхүм кызым... – «Кисәү» шыңшымакчы иде, карчык таягы белән селтәнде:

– Шым бул!

– ...кызым рухына дога кыласыңмы инде, Гамбәр апа-а?..

Кортка җавап бирмәде. Ызба адәм исеннән пырныган, тынга авыр иде. Ул, иелеп галушын кигәч:

– Онык белән күрешәм, аңа сүзем бар, хуш иттек, Сәмүш, – диде.

## 11

...Гөлҗиһан, төчкерә-төчкерә, чуен казандагы тузанлы солыны кәндигә тутырды. Бу аллергиясе җитмәде тагы!

– Өч тапкыр су белән чайкатып түк, – дип баш очында кагынган Миңсылуга:

– Фу, мондый катнашма укшытмас микән соң? – диде. – Бәлки, әбигә эчте диярсең, апа бәгърем.

– Җитезрәк кыймылда, ташбака! Эчәрсең, нибуч! Газ балуны кечкенә, расхутланмыйк, сад-бакчада кайнат төнәтмәне.

Кирпечтән өеп, учак ягар өчен уентык ясалган һәм өстенә казан утыртылган җәйге мичләрне авыл халкы ызбасын корым-көлдән саклар өчен куллана иде. Гөлҗиһаннарда да бар иде ул. Әтисе шунда поши аягы өтә, һәм аның исе күрше урамнарга хәтле тарала иде. Хайван каргышы аны тиз тотты: үзе дә утта янган әнә...

Миңсылу уентыкка чыбык-чабык тутыргач, шырпы сызды.

– Боламыгыңны куертма, гел бута да бута. Кайнагач бик суытма, җылымса килеш эч. Бу сыеклык бөер хастасыннан, ди җиңги. Коссаң – үзеңә үпкәлә. Мин мәлгунь кәҗәне тышаулыйм әле.

Әтисе, утта янган әтисе... Балага җаһил ата да якын. Әгәр ул исән булса, Гөлҗиһан аңардан йөз чөерер иде микән? Бәлки, олыгая-олыгая, Сәмигулла ата тәүбә итәр һәм егерме-утыз адымдагы мәчеткә йөрер, намазга басар, бәлки, малга хирыслыгы да бетәр иде. Башкаладагы туган акча белән бергә аларга хәсрәт тә китереп аударды...

...Күршеләрнең нигезендә көле дә тузгып өлгермәде, әтисе, чүп-чарларны эттереп, яңа йортка урын әзерләргә кереште. Аның мәчеткә эче поша иде. Әлеге мәсьәләдә алар авыл советы рәисе белән эләгешеп тә алдылар.

– Матри, аңа тимә, – диде Мирхәйдәр абзый.

– Нәстә дисең, блач?

– Бәбәгеңне акайтма, тоз күз! Ни ишетсәң – шул. Мәчет сиңа мишәйтләми, ул агачлар артында ук.

– Вәт сатлык сәвит хуҗасы! Әллә тиле катын өстеңә әфсен укып өрдеме? Кара, ничек бытылдый! Ә-ә, син бит әле мәэзин нәселе белән туганлашкан адәм! Урындыгыңнан очыртам, ала карга!

– Очсам да, ерак очмам! Баш түбәңә кунып, тавык миеңне чукырмын, кабан дуңгызы! Заретдин катыны – сыйнфый дошман, мин – камунис, нишләп аңардан әфсенләтим, ди. Аны биш чакрым урап үтүең хәерле. Кабат кисәтәм, Сәмигулла энем, мәчеткә кагылма! Үз хуты белән чересен шунда. Без, сезнең нәсел сымак, иманын көмешкәгә кушып чөмермәгән, бездә вөҗдан дигән нәстә исән әле. Мона мин төбенә төшеп казынсам – сине «төрмә чыпчыгы» итеп очыртам да! Гамбәр ызбасына син «кызыл әтәч» җибәрмәдең микән?

Атасының мыек очы да селкенмәде. Ул, ишегалдында агач тукмак белән тавыкларга бәрәңге изгән Гөлҗиһанны җилтерәтеп торгызып:

– Мона кыз, блач! Аның белән ант итәм, ул төндә мин урманда идем, – диде.

Икәү якалашсалар да, әтисе белән Мирхәйдәр абзый бер табактан «ашады»: бай туганның акчасы төлке белән бүрене дә дуслаштырыр иде. Туган дигәннән, ул үзе авылда, гомумән, күренмәде. Кара костюмлы, галстуклы әзмәверләр дә төзелеш тирәсендә буталмады, ә менә кабак йоткандай түгәрәк корсаклы абзый еш килә, һәм аны һәрвакыт Мирхәйдәр абзый озатып йөри иде. Әтисе мактанды:

– Чикритар үзе миңа ызба төзешә, – диде. Кайчакта мактану сүгенү белән «бизәлде»: – Арчинычның памушниклары капчык тутырук биргән акча белән капкорсак чикритар командуат итә икән. Бугазлыйм ул этне! Акчага мин хуҗа!

Андый чакта авыл советы рәисе Сәмигулланы бик тиз «суыта» иде:

– Райунның камунислар башлыгына янасаң, авылдан сөрерләр. Ул – намуслы иптәш. Башта ук синең белән килешмәдекмени, миңгерәү?! Сиңа энәдән-җептән ызбасын, каралты-курасын салабыз. Ат, сыер һәм үзең ише аңгыра сарыклар белән шыплап абзарыңны тутырабыз. Берочтан елга аша күпер җәябез, калхуз фермасының түбәсен ябабыз. Так ышты, халыкка да туганыңның игелеге тисен, энем.

Нарат бүрәнәләрне Алташ урманыннан ташыдылар. Ялланган унбиш чуваш ирләре кара төнгә кадәр эшләде. Атасы барыбер риза түгел иде.

– Пәтичтинный гына төзеттерәләр, хайваннар! Урлыйлар, хайваннар. Акай күз чикритар акчамны җонлады. Арчинычка серне тишсәм – ыштанына кәкәй иттерә, кайтсын гына, энекәш.

Осталар йорт-җирне әкияттәге кебек күз ачып йомган арада «аякка бастырды». Авыл гөжләде. Иртән берәүнең тешсез авызыннан сызгырган сүзе, гайбәткә чорнала-чорнала, йомгак кадәр зурая иде. «Сәмигулла элгәреге байларның урманда күмгән алтын-көмешенә юлыккан», имеш. «Сәмигулла бандитлар белән банк талаган да, азактан барсын да атып үтереп, акчасын урлаган», имеш. И беркатлы халыкның беркатлы әкиятләре! «Ил аузына иләк каплап булмый», – диде әнисе, ул су сипмичә шиңгән гөл сыман көннән-көн сула иде.

Берсендә кызның үтереп теше сызлады. Салкын һавада басылыр дип, алар әнисе белән ишегалдына чыктылар. Күктәге йолдызлардан нур чәчелгән айлы төн иде... Баскычка чүгәләгән аналы-кызлы шымайды: якында гына кемдер

үксеп-үксеп елый, әмма нур белән тишкәләнгән кара пәрдә эчендә ул ачык кына күренми иде.

– Ярабби, фирештә җылый ахры? Атаң бер гөнаһсыз кешенең нигезен тузгытты бит, – дип сыкранды әнисе.

– Әнә-ә! – Куркуыннан тешенең сызлавын да оныткан кыз анасына елышты. – Әнә-ә, селкенә! Карак, әни, карак! Әтине уятыйк!

Гәүдәсен яртылаш бөгеп, бакча артыннан гына китеп барган шәүләне әнисе таныды:

– Шаулама, Гамбәр апаң бу, кызым. Ярабби, аның сызлануларын миңа күчер! Атаң бигрәк каты бәгырьле, урам яктан юлны япты, арттан гына качып килә, бахырым.

– Ник безнең әти шултиклем комсыз икән, әни?

– Эчендә оялаган шайтаны туймый, кызым.

Төзелеш эшләре төгәлләнгәч, кунак төшерү хәстәре башланды. Район хуҗасы артык вакчыл идеме, әллә, чынлап та, капчыктагы акча күзен кыздырдымы, табак-савыт, урын-җир тикшерелде. Борыны кителгән ямаулы чәйнек, ямьшәйгән калай тәлинкә, каралган алюмин кашык, кыршылган иске кәстрүл, әнисе корама тышлык белән сырган юрган, каз мамыгы тутырып күперткән мендәр, юа-юа күгәргән шадра сөлге, диварга кадакланган чигүле тукымалар Сәмигулла йортына яраксыз дип табылды. Үзәк кибетеннән алмашка яңаларын китерделәр. Тик нигезгә бәрәкәт кенә кайтмады. Кунак көткән көнне, иртән, моржа ярылды. Атасы мич остасы Фарукны кыйнап имгәтә иде, Мирхәйдәр абзый үзе менеп «ямады». Барысы да рәтләнгән, барысы да тәртиптә кебек иде. Хуҗага тегәрҗепләре дә төйнәлмәгән (күрше авылның чуваш Микулае тексте) күлмәк-чалбар, әнисенә кара итәк белән чуар кофта (муены капланган озын күлмәк совет модасы түгел, янәсе) кигезеп, икесен янәшә капка төбендәге эскәмиягә утырттылар. Кырыйга чәченә ак бант таккан «күбәләк» Гөлҗиһанны бастырдылар. «Примир симия члиннары» тамашага әзер иде. Аю биетәләрмени, урамда сабан туе хәтле халык җыелды. Район башлыгы атасына һаман акыл өйрәтте:

– Үзеңне әдәпле тот, Насыйров! Хөкүмәт кешесе белән иптәш Радий Арсеньевич дип сөйләш! Энекәш дип аңа ябышма! Табында авызыңны чапылдатып ашама. Ризыкны кызлар тәлинкәңә салгач кына чәнечкеңне ал!

– Чикритар ибдәш, камунислар патшасымы әле син, быраг? – Атасы юешләнгән борынын лышкылдатып күлмәк җиңенә сөртте. – Сәнеске телгә кадала минем, анагызны... Агач кашык куегыз миңа. Төкерәм мин сезнең култур-мултурыгызга, анагызны...

Мирхәйдәр абзый аның маңгаена чиртте:

– Иптәш чикритар белән ыспурлашма, дуңгыз!

– Ух, сүгенмәгәч, эчкә кату чыкты. – Сәмигулла муенын кыйшайтты да таш сын кебек утырган хатынына тезе белән төртте: – Әй, син, куфтылы марҗа! Боларга иреңне яклап нидер әйтер иең, хет! Җәки, кызым син? Мәптектә бишкә генә укыйсың, синдә Лилин акылы бар. Ызба, сарай, келәт, мунча, әбрәкәй күпмегә төште икән, чутларсың, кызым. Туганымның акчасын блач күселәре кимерсә, энекәштән, әй ибдәш Арчиныйчтан арт саннарын каезлатам, тучны!

Ата кеше аек вакытында түрә-мазар янында койрыгын кыса иде. Кыз сизенде: көмешкә лыкынган... Әнә, ике бит алмасы кып-кызыл... Исерсә – борыны да сулана...

Көтә-көтә күзләр күгәргәч кенә, тал чыбыгыннан үрелгән басу капкасы өстендә тузан болыты күтәрелде. Дүрт машина выжылдап алар урамына керде.

– Киләләр, киләләр!

«Беренче» салынган җилкәсен турайтты, Мирхәйдәр абзый исә өчәр-өчәр оешып тәмәке көйрәткән агай-энене читкә куды:

– Чигенегез, чиген! Мәскәүлеләр – кырутуй халык, таптатмасын.

Чабыш атлары сыман елкылдаган күгелҗем машиналардан кайсы фотоаппарат, кайсы камера тоткан кунаклар коелды. Мәлҗерәгән атасын култыклап торгыздылар. Ул:

– Ибдәш, ибдәш энекәш! Чукынмыш, Арчиныч ибдәш, – дип тәтелдәп, төркемгә каршы атлаганда сөрлекте. Мирхәйдәр абзыйның беләгенә ябышмаса, маңгае белән җирне «сөзә» иде. Ак күлмәкле, кара галстуклы озын ир-егет:

– Здрасте? – дип исәнләшкәч: – Кто у нас тут хозяин? – диде.

– Вот он сам! – Авыл хуҗасы әтисен беләгеннән «бушатты» да, уфтанып кына: – Извиняйте, Радий Арсиныч, у хужаена жар путнялся была, уж бульно бальнуй, прастудилися, – диде. Озын буй:

– Я не Радий Арсеньевич, к сожалению. Я его помощник. Шеф не смог приехать в родные места предков, а эти ребята – журналисты, из центральных газет, – дигәч, «беренче» күрешергә дип сузган кулын кире кесәсенә тыкты. Хәер, аңа игътибар итүче дә булмады. Журналистлар «О, экзотика!» диешеп, фотоаппарат чертләтте, камерасын «өч аяк»ка бастырган сакаллы ир җил селкеткән яфрак сыман калтыранган Сәмигуллага сорау биреп маташкан иде, Мирхәйдәр абзый:

– Уж бульно бальнуй хужаин, жар, вот дучкасы гаварит была, – дип, исерекне култыклап күздән үк югалды. Гөлҗиһан урысча әйбәт кенә сукалый иде, каушамады, бер күзле «өч аяк»ка чатнатып үзләренең гаиләсе турында сөйләде. Әтисе – «оста сунарчы», әнисе – «оста тегүче», янәсе. «Радий Арсеньевич нәсел-ыруы белән горурлана ала, без аңа лаек туганнар, без беркайчан да аның йөзен кызартмабыз», янәсе.

Кунаклар әрсез халык икән, хуҗалыкны айкагач, табындагы сый-нигъмәтләрне «урдылар» да, машиналарына төялешеп, Мәскәүләренә сыптырдылар. Бөтенесе дә төштә кебек кенә иде. Әнисе тиз-тиз «марҗа киемнәре»н салып, юа-юа бизәге уңган күлмәген киде, биленә алъяпкыч буды һәм, иркен сулап:

– Раббем, тагын нинди сынаулар белән сынарсың икән, – диде.

Әлеге «уен»да тагын икәү – район хуҗасы белән рәис Мирхәйдәр сыналды. Күрәк белән тау хәтле акча күрәрбез дип хыялланган абзыйлар ярык тагарак янында калган иде. Аларның сарай кырыенда ничек уфырганнарын кыз үз колагы белән ишетте:

– Өметләр акланмады, Гатиятов. Безгә Мәскәү баеннан шымытыр! Адәм көлкесе, бездән дә наив кеше юк! Разве андый очындыклар бер мескен авылга кайта ди.

– Нишләп кире уйлады икән, Гата Садыйкович?

– Үзеннән белеш, Гатиятов! Ярдәмчесе, көнен-сәгатен күрсәтеп, ике тапкыр телеграмма сукты. Без монда зурдан кубып җыендык. Хуш, өстим дигән акчасын җибәрсен иде.

– Бәрәч, Гата Садыйкович, күпер белән фирмыга сәмән калмадымыни?!

– Тиененә кадәр шушы кара мужикның хуҗалыгы суырды. Үтүт акча, Гатиятов!

– Мин тагы... Авылга файдасы булыр дип тагы...

– Зарары күбрәк булды, Гатиятов. Казанга – обком тирәсенә урнаштырмасмы дигән хыял да пыштик хәзер. Шушы хәерче районда мүкләнербез ахрысы.

Менә сарайдан дүртаякланып ярым айнык әтисе чыкты.

– Акча капчыгы кайда, анагызны, – дип сүгенгән иде, секретарь Мирхәдәр абзыйга:

– Син бу имгәктән адәм әвәләп чиләнмә, Гатиятов, эттән – эт, беттән бет туа, тфү, – диде һәм дык иттереп әтисенең арт чүмеченә типте.

Айтуганны гөрләткән шау-шу тынды. Әкияттәге төсле өч мәртәбә бармак шартлатып баеган Сәмигулла «примир симия» хуҗасы исемлегеннән тиз сызылды, ул, элеккеге гадәтен куып, киек-җанвар аулады, аты-юлы белән өйдәгеләрне сүкте. Бай туганына да тел чыбыркысы белән «кизәнде»:

– Ызбулыч син, ибдәш Радий Арчиныч! Чикритар мине акыртып талады. Син, ызбулыч малай, ник капчыкны минем үземә тоттырмадың? Ике көпшәле мылтык кирәк ие миңа, заразы ибдәш Арчиныч. Синең туганлыгыңнан ни файда?!

Кызның тормышында мондый кичерешләр бүтән кабатланмаска тиеш кебек иде. Кабатланды, тик ул әүвәлгесеннән көчлерәк, чөнки олылар уйнап туйгач онытылган уенга охшамаган, монысы – йөрәк белән бәйле иде.

Беркөнне урманда хаста әнкәсенә кара бөрлегән чүпләгәндә, аның башына имән күркәсе «яуды». Авырттырмады, алар әле йомшак иде.

– Кех-кех, – диде «имән», көлеп. – Кех-кех...

Гөлҗиһан аптырады: агачлар да җанлы микәнни? Һи, яшеллек дәрьясында «йөзеп» үскән кыз мондый әкиятләргә ышанамыни инде!

– Кайсыгыз шаяра анда? – диде ул, җитди генә.

– Мин! – диде тавыш һәм тиен төсле аска сикерде. Менә ичмасам бусы чып-чын әкият иде! Аның каршында сурайган малай авылныкы түгел, аның киенүләренә хәтле мәзәк: кыска җиңле шакмаклы күлмәген кыска балаклы ыштан бөрмәсенә кыстырган. Мөгаен, ул аның яшьтәшедер, буй озынлыгы икесенең дә бер чама иде.

– Мин – урман егете! – диде малай. – Ә син кем?

– Урман кызы! – Гөлҗиһан да тапкыр иде. – Нишлисең минем биләмәмдә, малай – күгәргән калай?

– Син дә минем аймакта нишлисең, кыз – эрегән тоз?

– Кара бөрлегән җыям!

– Һи, иренең каралса – үзем генә үбәрмен, урман кызы!

– Кит, затсыз! – диде Гөлҗиһан, тырысы белән малайга селтәнеп. – Әнә, керпене үп!

Җәйге айларда авыл урамнарында телгән чыра төсле ак чырайлы ябык шәһәр малайлары чабыша, ә көзгә табан алар, әби-бабайларының сөт-каймагы белән сыйланып, тазарып-матурая иде. Урманда очраган малай шул арык җаннарның берсе дип уйлады кыз. Зәйтүнә әби үлгәч, әнисе мәет өстенә барган иде:

– Әй Гамбәр ападан оялдым да соң, кызым, – диде ул. – Атаң бигрәк йөзебезне каралтты. Кыз-катынны рәнҗетеп төзелгән ызбаның ни рәхәте дә, ни җылысы.

– Үзеңне табалама инде, әни. Сиңа борчылырга ярамый.

– Мәет җирләгәч, шыр ялгызы күңелсезләнер инде, дисәм, Гамбәр апага җәйлеккә оныгын кайтарганнар икән. Миңа кырылмады үзе. Ачылмады да инде, артымнан гына: «Йөрәгеңнең сүрүе нечкәргән», – дип кенә әйтеп калды.

Әнисенең моңсу тавышы кызны боектырмады. Аның гомер сәгате соңгы минутларын санаганын каян белсен ди ул! Үз хәсрәте көчле иде шул. Моннан ары аңа урман егете белән сукмак кисештермәскә кирәк! Кичә башыңа имән күркәсе яудырсалар, бүген таш белән орырлар! Ул малай, һичшиксез, әбисен йорт-җиреннән сөргән адәмнең кызын дошман күрәчәк!

Кыз юлын үзгәртте. Әрсез кара бөрлегән урманның һәр тарафында үсә иде. Әмма тырысына ике бөртек җимеш салып өлгермәде, абага яфрагы астында яши диярсең, алдында хәерсез малай калыкты.

– Әһә, син рөхсәтсез-нисез генә минем байлыгымны урлыйсыңмы?

– Әй, мактанчык! Син кем соң ул хәтле! – Гөлҗиһан җавап тапса да, каушады һәм тырыстагы бөрлегәннәрне берәм-берәм авызына «озатты».

– Мин – хуҗа!

– Һе, кичә генә әле урман егете иде берәү!

– Шул егет хуҗа дип бел!

– Син дә шуны бел: без – тигез, чөнки мин – урман кызы!

Малай шытырдатып абага яфрагы өзде.

– Әйдә, алайса сиңа таныклык язабыз?

– Абау, нинди таныклык!

– Урман кызы икәнеңне дәлилләгән документ! Йә, исемең ничек?

Исем дигәч, Гөлҗиһан иренен бөрештерде. Мөгаен, Гамбәр апа оныгына дошманнарын исемләп атагандыр.

– Урман кызы, дидем ич!

– Ансы кушамат аның! Чын атың кем? Минеке – Фәрит.

Авылда ул бердәнбер Гөлҗиһан иде. Әкрен генә:

– Оныттым, – диде.

Малай башта көлде, аннары, бармагы белән чигәсен боргычлап:

– Син тегеләйме? – диде. – Акылга сай мәллә?

Мондый мыскыллау уку алдынгысының «мин-минлеге»нә тиде.

– Мин акыллы, мәктәптә гел бишлегә генә укыйм! – дип чәрелдәде кыз. – Исемем дә... Гөлҗиһан әле минем!

Юк, давыл агач-куакларны төбе-тамыры белән йолкып аудармады: малай тыныч, бик тыныч иде.

– Син чукрак мәллә? Мин – Гөлҗиһан, диләр.

Фәрит, абага яфрагын чыбык белән тишкәли-тишкәли:

– Әһе, яздым, – диде. – Син – Гөлҗиһан.

– Әти – Сәмигулла!

Бу исемне өстәгәч, һичшиксез, малайның сырт йоны кабарачак иде. Юк, ул һаман тыныч кына:

– Әтиең – Сәмигулла. Яздым, – диде. – Мә, таныклыгың әзер!

Кыз яфракны дүрткә бөкләп кесәсенә салды. Әгәр бу мизгелдә күктән дөбер-дөбер таш коелса – ул аларны берәм-берәм яңа танышына тондырып, ачуын кузгатыр, чөнки «урман егете» асылда сабыр түгел, малай махсус Гөлҗиһанның нервысында уйный иде. Нигә ике арада дошманлык уты үрләтергә тырышты соң кыз, нигә? Моның сәбәбе шул гына: беренче күргән мәлдә үк ул Фәритне үз итте. Үз итү генәме икән әле! Йөрәк әле генә бөредән ачылган зәгыйфь яфрак шикелле леперди, Гөлҗиһан гашыйк иде... Мәгәр малай әбисенә була үчләшсә – бала күңелендә бөтерелгән хис өермәсе бик тиз басылыр иде. Беркөнне әнисе аңа:

– Кызым, кара бөрлегәннән туйдым, син урманда йөрмәле, өйдә эш күп. Мин сине иркәләбрәк үстердем ахры, аш-суга өйрәнер идең, – диде. – Хәлем хәл, балам, дөнья көтүләре сиңа калса, нишләрсең? Кычкырып ачтан үләсез бит. Атаң ау дия-дия акылдан шаша, аңа ни йорт, ни урман – барыбер.

«Урманда йөрмәле...» Анасының тел төбе аңлашыла, бичара: «Гамбәр оныгына илекмә!» – дип кисәтә иде. Авыл сукырмыни! Күргәннәр...

– Әни!

– Кызым! Мине иртәрәк кабергә озатмыйм дисәң, урманда чуалма!

Хуш, урман егете! Хуш, беренче гөнаһсыз мәхәббәт! Кесәдәге абага яфрагы чиләнеп каралды. Сулышы белән өреп киптерәсе дә китап битенә кыстырасы иде... Истәлеккә... Сыйныфташ кызлары бәхетле, аларның әтиләрен канәчкеч

дип хурламыйлар. Берсендә аучы Сәмигулла ат арбасында поши алып кайтты. Хайванның бот сөяге яраланган иде.

– Хәйләкәр, заразы, оланын ышыклар өчен җүри минем каршымда боргалана. Күз алдап шылмакчы иде, шалт моңа утлы ядрә белән! Абзаңнан ычкынырсың, заразы! – дип, тиңсез батырлык эшләгәндәй мактангач, пошины абзарга япты. – Сез, матри, кыз-катын сәләмәсе, моңа күбенгәнче әпәй ашатыгыз! Көзгә симертеп суям. Тәненә ит кундырмасагыз, җиде кат тирегезне туныйм!

Көчләп әсирлеккә төшерелгән тоткын исә ипи телемнәрен иснәп тә карамады.

– И, аңарда бала хәсрәте шу-ул, – диде әнкәсе. – Атаң, дим, җаһил, никләр аны сабыеннан аерган икә-ән!

Кызның күзе яшьләнде, ана поши да Гөлҗиһанга кушылып елый, озын керфекләрендә эре-эре тамчылар җемелди иде. Киек-җанварларның ни-нәрсә белән тукланганын ишетә иде ул: мәсәлән, поши халкы агач кайрысы кимерә. Урманга берникадәр зарар китерсәләр дә, алар өчен бу иң тәмле, иң сусыл тәгам иде. Кыз, көндез әнисе черем иткәндә, якын урманга йөгерде. Пычак белән элпә кайрысы телгәләп маташканда, кемдер сызгырды:

– Фью, фью!

Аны кош дип уйлаган Гөлҗиһан чаш-чош агач тунавын белде.

– Чур, тоттым!

Кош дигәнең адәм теле белән сөйләшә башлагач, кыз пычак белән әз генә бармагын кисмәде...

**12**

...Карчык аягын чирәмгә сузды. Ул мондагы тормышка битараф иде. Югыйсә утар нәсел малы, нәсел байлыгы иде. Үпкәләде утарга Гамбәр. Аны хәтта җанлы итеп күралмады. Әүвәл бу почмак аның хәләл ирен урлады, аннан соң улы Рәшитне каптырды. Кыскасы, ни мәкерле көндәш тә таркатырга базмаган гаиләне пыран-заран туздырды. Оныгы да ата-бабасы кебек утар дип шашына. Тик, Ходайның рәхмәте, монысы ни кырыс Заретдин, ни йомык Рәшит түгел, монысы белән «ботка пешә», Зур әни дип өзгәләнгән онык, мөгаен, Аллаһның соңгы бүләге иде. Шөкер, бу бала белән очрашу сәгатьләрен сабыр гына көткән ана морадына ирешte. Кояшлы матур иртә иде, Рәшит җил капканы ике кеше сыярлык итеп киң ачып керде:

– Әни, менә сиңа малай, – диде. – Җәйге каникулда Зур әнидә яшим, ди. Онык дип һаман колак итемне ашый идең, тәрбиялә, әйдә!

Малай күптән малай күлмәгенә сыймый, озакламый борын астына мыек төртерлек үсмер иде, Гамбәр аны яратып кочаклады һәм шунда ук гаҗәеп җылы тойды. Шулай булмый ни, ялварып-ялварып сораган Аллаһ бүләге ләса! Аларның серләренә хәтле килеште.

– Зур әни, миңа шәһәрдә күңелсез, – диде онык. – Минем әти белән утарда торасым килә, ә ул, мәктәпне тәмамлагач, институтта укыйсың, диплом алгач, берәр оешмада тәҗрибә туплыйсың, ди. Син түрә өчен яратылган, ди.

– Әнкәң ни ди соң, бәбкәчем?

– Әни безнең белән яшәми, Зур әни. Ул сөяркәсе дядя Коля белән Кырымга китте.

– Шулаймыни? Ай-яй, этиеңә авыр икән. Син хәзер аның бердәнбер терәге, бәбкәчем.

– Мин икегезгә дә терәк булам, Зур әни!

Бишектәге бишкә төрләнә, диләр. Гамбәр, билгеле, башта сагайды. Иркә шәһәр гөле, бәрәкәтле туфракка күчерсәң дә, тамырланмас, диде. И кодрәтле Зат! Адәм баласының тәне белән җаныннан гайре уй-ниятенә дә син хуҗа.

Су эзен тапса – таш-кыя аша аккан кебек, колларың да, син «әйе» дисәң, мең киртәне сикереп, үз максатына якыная.

– Әни, Фәритне утардан биздер, – диде Рәшит, саубуллашканда.

– Нишләп, углым?

– Йөз кат тукыдым бит инде, әни! Бүген түрәләр заманы! Мин улымнан урман шүрәлесе ясамыйм!

– И углым, бу дәүләтеңне кем өчен төзедең алайса?

– Әти мирасы ул. Берәр байга сатармын соңрак.

– Оныкның хуҗасы – Аллаһы Тәгалә, углым.

– Йә, әни, синең белән рәтле сүз сөйләшәм димә, туры таякны бөгеп кенә кәкрәйтәсең. – Рәшит кәһ-кәһ йөткерде.

– Күкрәгеңне тикшерт, үпкәңдә кара тап бар, углым, – дигәч, ир тагын ачуланды:

– Син бозык рентген аппараты төсле, дөрес күрсәтмисең, мин таза-сау, әни!

Газиз бөртеген урман авызына хәтле озатканда, хатын:

– Углым, чирең әле тамырланмаган, баш кына алган, әйдә, үзем үлән төнәтмәләре белән имләп дәвалыйм, – дип инәлсә дә, Рәшит кирелеген калкан итте:

– Әни, зинһар, ырым-шырымнарың белән миемә чүкемә!

...Йөзләгән-меңләгән сырхауга догалы шифаңны өләш тә үз балаңны коткарма! Ана йөрәге ничек әрнемәсен! Рәшите дә җир куенында йоклый... Ә Гамбәр исән... Кайчакта ул үз-үзен табалый, җитәр, карчык, фанилыктан кисел, ди. Ә гомер бавы нык, гомер бавы никадәр генә тартсаң да өзелми. Югыйсә картлык сиздерә, бик сиздерә... Менә бөкләгән аяклар каткан, тезен уа-уа йомшарткач кына турайды. Онык – эшем кешесе шул, анда Зур әни көтә, дими. Мәрхүм әтисенең дәүләтен ишәйтә-ишәйтә, ни кылмакчы икән ул? Бүген бастырып сөйләшәсе булыр... Әйе, сөйләшәсе... Рәшит сыман кирелеге белән җанны көйдерми, анысы шөкер. Тик үзенекен дә аска батырмый. Әнәгенәк, тәки галстук дигән муенчак такмады, тәки ташкалада төпләнмәде, аны шушы урман иле тартты, Рәшит мәрхүм, монда да әнисен гаепләгән иде:

– Сиңа онык чырае күрсәтмәскә иде, әни! Син Фәритне үз ягыңа аудардың, син! – диде. Гамбәрдә адәмнең уй-теләген үзгәртерлек нинди кодрәт бар ди! Туганда ук кан тамырлары буйлап аккан ла оланның теләге, йөрәге белән бергә типкән лә. Исеңдә тот, углан, ул – Заретдин кыйпылчыгы!

...Утар капкасы зеңгелдәде. Озын борынлы кара машина, гүя ярсыган үгез, ике фара күзен акайтып, эчкә узды. Карчык алдына бөкрәя төшеп күзәтте: Фәрит, кулындагы кәгазьгә төртә-төртә, сакчы ир-атка нәрсәдер аңлатырга кереште. Холык-фигыле генә үзгә, килеш-килбәте белән ул тач бабасы: Заретдин кебек үк аның да җилкәсе киң, аяклары кәкре иде. Менә онык та әбисен абайлады. Йөзе яктырды, күзеннән шаян очкыннар чәчрәде:

– Нинди ак гөмбә ул анда, йә? – диде.

– Саумы, төпчегем? – Карчык тормак булып тезләнмәкче иде, Фәрит:

– Чү, чү, Зур әни, ашыкма, – дия-дия, аның янәшәсенә утырды. – Мин дә синең белән һава сулыйм!

– Бәй, син гелән дә һауада, бәбкәчем.

– Синең кырыңда ул шифалырак, сулаган саен үсәсең, Зур әни.

– Үсүең җитеп ашкан, бабаң сымак буйлы үзең, төпчегем.

– Җә, Зур әни, аяк талдырып ник килдең инде? Атна саен үзем хәлеңне белешәм юкса.

– Белешәсең, рәхмәт, төпчегем. Эшеңне эшлә син, безгә бик ешлама. Без

ризыклы, без җитештә. Синең белән фикерләшәсе иде, төпчегем. Әүвәл мин ятлаткан берәр догаңны укы! Бисмилласыз сүз – буш сүз.

– Хуш, Зур әни. Тыңла. Йә караңгылыкны һәм Нурны Яралтучы, йә кояшны һәм айны Яралтучы, йә йомшак Күңелле һәм Хәбәр бирүче, йә Бердәнбер Барлыкка китерүче, йә Өмер бирүче, йә һәрнәрсәне чагыштыргысыз Яхшыртучы, йә Сиңа җитәкче булмаган Зат, йә Көн белән төнне Алмаштыручы...

Карчык әкрен генә оныгына кушылды:

– ...дан сиңа, йә Аллаһ! Синнән башка Илаһ юк. Безне кайгыдан, борчудан һәм җәһәннәмнән сакла, йа Раббым! Фәрит, болар – Аллаһының гүзәл исемнәре, аларның саны туксан тугыздыр, син кечтеки чагыңда ялкауландың, күңелең гелән урман сәйранында иде.

– Орыш, орыш, Зур әни! Синең тиргәвеңдә дә бер-бер хикмәт бар. Әти бит мине беренче тапкыр кайтарганда:

– Зур әниең җенле, тыңламасаң, кычыткан белән пешекли, – дигән иде, мин ул җеннәрең белән тиз дуслаштым, шулаймы, Зур әни? Кызык кеше идең син, әйеме? Кайсыбер апа-абыйларны капкаңнан ук битәрләп каршылый идең. Теге мескеннең мескене инде, башы түбәнәйгән, борыны кендегенә тиклем салынган. Зур әни моңа ник каныга, ник җәлләми, дисәм, гөнаһлары өчен тетмәсен тетәсең икән, шулаймы?

– Шулай, бәбкәчем. Синең дә телеңә шайтан төкергән ахры, Фәрит! Артык кыткылдама, ир-атка килешми! – дисә дә, карчык сөеп оныгына бакты. Яраса ул аны баштанаяк күз нуры белән коендырыр иде. Ни Заретдин, ни Рәшит аның белән болай гәпләшмәде, ата белән ул аны ким санады.

– Тфү, шайтан төкермәсен инде, Зур әни. Минем бит әле бер хыялым бар: халык йотлыгып укырлык бөек китап язасы иде.

Карчык оныгына текәлде. Шаяртамы, җүнсез? Колагы әрекмән хәтле, каты гына борсаң шукланмас иде. Эчтән ташкын ургылдымыни, ул «ташыды»:

– Соңардыгыз, адәмнәр, соңардыгыз! Илаһи китап язылгандыр, аның исеме – Коръән Кәримдер!

– Йа, Зур әни, үзең бәләкәй генә, ә үзеңнең тавышың нинди гайрәтле, – дип, Фәрит әбисенең иңеннән сыйпады. – Борчылма, мин бит дөньяви китап турында әйтәм.

– Ахырзаманга табан шайтан гаскәре котырык таратыр: «Яз, синеке дөрес, синеке мактаулы», – дияр. Шуннан азгын күгәрек каләм күп сүз сарыф итәр, вәләкин аларның мәгънәсе сай булыр. Алар Бөек Останың хакыйкый җөмләсен күммәк теләр, гавам боларныкына ышаныр, боларныкы чын, дияр, ә алар ялган кәлимә белән күз генә буяр. Азактан барыбер дә хурлыкка дучар ителер: иҗатлары чүп-чар өеменә әйләнер.

– Мин алдашмам, Зур әни. Язар өчен җим чүплисе юк, менә синең хикмәтләрең генә дә озын-озын хикәят.

«Әй Аллаһым! Ник бу нәсел бөртегем хисләнә? Хис ир-атны хәлсезләтеп, юашландыра. Моның күңелен чистарт, Аллаһым!» – дип пышылдаган карчыкны онык тагын да «кытыклап»:

– Гасырлар үткәч тә, синең хакта: «Айтуганда нинди хикмәт иясе яшәгән икән», – диярләр, Зур әни.

– Син хикмәтне изгеләрдән эзлә, бәбкәчем. Даут пәйгамбәрнең бармагына чорнаган тимер кадагы эрегән. Зур әниеңә чәнти бармагына уарлык та могҗиза бирмәс, Раббым!

– Ул дәвалаган кешеләреңне кая куясың, Зур әни? Алар исәпсез-хисапсыз, безнең капка төбендә гел су буе чират иде. Хәтерлисеңме?

– Хәтерлим, бәбкәчем. Аллаһ ярдәме белән байтак адәм баласы чиреннән котылды.

– Соңгы вакытта әлеге кәсебеңне ташладың дигән идем, яңадан өшкерәсең бугай, Зур әни? Сиңа кемне китерделәр ул, ә?

– Сиңа монысы каян ишетелде, Фәрит?

– Урманда очрадылар, Зур әни.

– Бәбкәчем! – карчык үзәге өзелеп әйтте: – Алтатарлы шайтан-иблис киек-җанвар аулар өчен әллә кайсы кыйтгалардан җыела! Ражун барма! Алар – кансыз, алар – миһербансыз. Былтыр берәүсен үтереп, чыбык-чабык белән күмделәр.

– Мин күрәләтә өсләренә бармыйм, Зур әни! Синең кунакларыңны да чикләвек куагы артыннан гына күзәттем. Әгәр дә мәгәр... – Егет йодрыгын йомарлады. – ...законсыз ау оештырсалар, пәрмә-пәр сугыша идем. Нинди кыз-кыркын синдә? Берәр танышыңмы, Зур әни?

– Кем дә җук миндә, бәбкәчем.

– Шаян син, Зур әни! Машиналарында Җир шары кебек түм-түгәрәк шар иде бугай.

– Сырхаудан көлмиләр, җүнсез малай!

– Көлмим, Зур әни. Синең өчен борчылам. Кеше көе көйләр яшьтә түгел инде син.

– Син дә минем җанымны күдермә, кыйтаб язу уеңнан биз! Чын ир-ат, кулына балта-чүкеч тотып, дәүләт төзи.

– Төзим мин, Зур әни. Син утар капкасыннан ары узмыйсың. Ике чакрым эчкәрәк кер әле, анда агач эшкәртү заводы. Заказлар күп, тиздән безнең продукция чит илләргә таралачак.

– Ходай кушса, Фәрит!

– Әйе, Ходай кушса, Зур әни. Син юкка гына могҗизаларыңны яшерәсең. Әйтик, сукыр Сабирҗан бабай белән Кизләү мәдрәсәсенә кара ат җигеп китәсез дә ак ат белән кайтасыз. Сөйлә әле, ничек малкайның төсе үзгәрде соң?

– Безнең әкиятләрдән дә куәтлерәк эшебез бар, бәбкәм. – Карчык авырлык белән генә сулады. Тыгыз дымсу һавадан борын тишекләре кысыла иде. – Син үләнсәң, мин тынычланып китәр идем.

– Кая, Зур әни?

– Үз йортыма...

– Далагамы, Зур әни?

Карчык, урлап тотылгандай кызарып:

– Әстәгыфирулла, – диде. – Ниткән сүз инде бу?

– Бабай әтигә: «Әниең тумышы белән дала ягыннан», – дигән. Дөресме, Зур әни? Әллә бабай алдашканмы?

...Урман артка чигенә-чигенә, күз алдына гаҗәеп манзара ачылды. Зәңгәр күлмәкле кыз бала тагын кылганнар белән куыша иде. Тагын, тагын... Әлеге күренешкә җан өреп, офык читенә элгәннәр бугай... Әй ул даладагы киңлек, әй ул даладагы иркенлек!

– Үлмә-ә-әс! Кайт!

– Чакырма, Анам, чакырма!

– Зур әни! – Оныкоеган кортканың җиңеннән тартты. – Зур әни, йоклыйсың мәллә?

– Әү, бәбкәм! Үз уемнан үзем уелам кайчакта. Син миннән берни сорашма, бәбкәчем. Минеке – үткәндә, тузан белән күмелгән, синеке – бүгенге ап-аяз

көн. Үлән, Фәрит! Миңсылу апаңның бистәдә таныш катыны оста яучы, ди. Аллаһы боерса, аңа гозеребезне җиткерербез дә синә тиңеңне сайлашырбыз.

Онык туп кебек чирәмгә тәгәрәде. Кулы белән берничә тапкыр һаваны бутагач:

– Их, Зур әни, Зур әни, – диде. – Кемдер куша дип кенә өйләнәләрмени! Сине дә бабайга ирексезләп бирделәрме соң?

Карчык җиргә таянып торып басты. «Синең бу эшең уңмас, башланмас борын хәерсез тәмамланыр», – дип күңеле искәртте кана. Ике яктан ике ташкын ургыла... Берсе – аның оныгы, берсе – Ярулла оныгы... Йа Бөек Аллаһ, йа җиһан патшасы! Аларны бергә кушу-кушмау бары тик синең генә кодрәтеңнән килә! Маңгаен ташка ора-ора ялвара кол Гамбәр: каргыштан тетелгән нәсел белән кан катыштырма!

– Бабаң Заретдин белән сүеп кавыштым мин, бәбкәчем, – диде ул, киребеткән оныкка вәгазь укуның мәгънәсе юк иде. – Кузгалам, яңгырга көйли. Әнәгенәк, кырмыскалар иләвенә кача.

– Ат белән илтәм, Зур әни.

– Илтмә, җәйләрен турыдан гына юл якын. Безнең ише карт сөяккә җәяү тәпиләүләре файдалы, буыннарга тоз укмашмый, – дип, кортка тимер капкага юнәлгәндә: – Сәмүш абзаң тугарылмасын, аңа якты көн әсәре хәрәм, төн аның дөнҗасы, төн, – диде.

Онык әбисенең коры-коры гына сөйләшүләренә иялэшкән иде:

– Баш өсте, Зур әни, синең әмер үтәлер, – дип елмайды.

Яшь вакыттагы кебек аякларга «үзйөрешле» галуш кимәгән иде шул, карчык арык алашамыни, әкрен генә «юыртты». Уй, күләгә сыман, үзеннән алда «йөгерде». Ул беләк буе озын теле белән хуҗасын «камчылады»:

– Син, дим, туганнан бирле әрләштә. Башта дала албастысы Сайрәби белән көч сынаштың. Җиңдең, шөкер. Аннан ары кызыл камунис Заретдин белән көрәштең. Ул сине кяферләр сукмагында адаштыра алмады. Аны җиңдем дип кәперәймә. Бу җиңүең өчен, ай-һай, кыйбат түләдең. Хәләл ирең белән газиз улыңны үзеңнән биздердең, и горур бикә! Ә Ярулла нәселенә тешең үтмиме, җә? Алар белән салкын гүрләреңә тиклем сугышырсың микән? Орлыклары әле дә корымаган икән, әнә берсе – туфрак ертып баш күтәрә. Син аңа нишләп терек суы сибәсең икән, нишләп шырпы хәтле генә зәһәр тамызып, тамырын киптермисең икән?

Күк күкрәде, урман эчен яктыртып яшен яшьнәде. «Кичер, Аллаһым!» – диде карчык, тезенә чүгәләп алды. Юк, аны «күк камчысы» өркетми, аны шайтан калтырата, әнә бит ул – мөртәт, күңелен яман уйлар белән каралта иде. Бу четерекле хәлдән ничек чыгарлар, бер Аллаһым. Әйе, Гамбәр кортка ташкынга каршы тау өяр, тау... Ни йөрәгең белән газиз оныгыңның куенына җиз елан баласын елыштырасың ди?! Имансыз нәсел белән туганлашасы түгел! Тик кулыңдагы хәйлә бавын кыскарт: Фәрит сизенмәсен! Сизенсә – эш харап, газизең белән арагыз суынасак. Малай бит үзе сиңа тартылды, кортка. Рәшит әнисен килен белән куандырмады: улының хатынын ул ике тапкыр гына күрде. Тәкәббер бистә кызы ирен яратмагандыр, югыйсә сөяркәсе белән Кырым якларына таймас иде. Берсендә килен кеше Фәритне юллап Айтуганга кайтты. Тимер саплы пычак белән кәҗәгә чөгендер тураган үсмер әни дип егылмады, ә хатын «егылды».

– Ай, ай, баламны коллыкка сатканнар! Кара эш эшләтеп үтерәләр!

Малай:

– Әни, мин кол түгел, мин Зур әнидә кунакта, – дигән иде, шәһәр бичәсе дөнья «сасытты»:

– Аһ, син кунактамыни?! Чүплектә тирес корты гына казына, мәнсез! Тапканнар

басымчак «кунак!» Баламны авыл мужигына әйләндергәннәр. Уф, өйләре дә шапшак, таракан мыжлыйдыр, зараза ияртер әле балам. Ирнис! – Ул сөяркәсенә кычкырды. – Давай, Фәритне җитәклә! Аңгырайтканнар аны, күзе тоныкланган!

Гамбәр килене белән әрләшмәде. Самавырның суы кайнар иде, аңа күмер өстәп үрләтте, мич куышындагы бер таба коймакны табынга куйды. Муклашка шикәрне ваклады. Ел саен Ташкенттан килеп дәваланган татар хатыны аңа алты данә үзбәк касәсе биргән, һәм Гамбәр аларны комодта гына саклап тота иде, шуларны өстәлгә тезде. Чәй дигәч, ярсыган килен җирәнеп борынын җыерган иде, ире әдәплерәк икән:

– Аштан олы булмыйлар, Садыйка, – диде.

– Тартынмагыз, ни бары белән сыйланыгыз. – Хуҗабикә ачык ишектән генә оныгына эндәште: – Улым, әниең белән син дә чәйләп ал.

Фәрит җавап кайтармагач, ул аптырады. Баксаң, малайдан җилләр искән иде.

Киленнең сөяркәсе бик сусаган иде бугай, коймак бөкләп чәй шыпыра-шыпыра:

– Садыйка, игътибар ит, мондагы чисталыкка шаккатырлык, – диде. – Кул сөлгесе ап-ак, эскәтер ап-ак! Идән сап-сары юылган. Син Фәритең зараза ияртер, дисең. Бездәге пычракка ни диярсең икән, җанкаем? Кругом тузан, кругом пәрәвез оясы! – диде. – Ялкау син, Садыйка. Алай да кеше хурлыйсың.

– Сайрама, койрыксыз карга! Зато без Кырымда яшибез, тозлы диңгез суында коенабыз. Фу, монда чиста, имеш. Әбиеңә җен-пәриләре булыша. Минем каенанам кем? Әйтимме?

Гамбәргә килененең «ачышы» кызык түгел, чөнки нинди генә кушамат таксалар да, ул үзенең Аллаһ мәхлугы икәнен белә иде. Фәрит урманга шылган, ул хәзер оясындагы йомран кебек кичкә кадәр баш калкытмас, менә монысы килен өчен фаҗига иде. Бабасы Заретдин төсле киреләнсә – ни үгетләсәң дә, тәртәгә кермәс.

Фәрит, чынлап та, кич белән генә кайтты. Ярты табак кабыклы бәрәңге ашагач, күзен хәйләкәр кысып:

– Тегеләр кайда, Зур әни? – диде.

– Анаң сине эзләде, бәбкәчем. Кычкыра-кычкыра тамагы карлыкты.

– Ишеттем, Зур әни.

– Ник хәбәр бирмәдең, җүнсез малай?

– Биек агач башында идем шул, Зур әни.

– Алай ярамый, бәбкәчем. Анасын хөрмәтләмәгән бала, тәмуг кисәве булыр.

– Аңа ярыймы, Зур әни? Ул мине Кырымга өстери. Анда нәрсә югалттым ди! Миңа эти белән утарда рәхәт иде, анысы да ташкалага куа хәзер. Чистый үтерәләр!

Гамбәр ана белән бала арасына чөй какмады. Үсә-үсә Фәрит әнкәсенә карата мөгамәләсен үзгәртер, болай ук нәфрәтләнмәс, диде. Ул, Рәшитне мыскыллап, чит ирләр белән типтергән киленәнә эченнән генә әрнесә дә, гел аны яклады. «Ана – изге зат», дип бик еш кабатлаган сүзләрне, мөгаен, онык күңеленә сеңдергәндер, бүген егет ай саен Кырымга акча сала. Дүртенче ире ташлаган Садыйка бер бәйләм чир белән ялгыз гына яши. Диңгез генә исәнлегеңне арттырса, адәм баласы көн-төн суда чупырдар иде. Берсендә Фәрит: «Әнине утарга чакырыйм микән әллә? Саф һавада тизрәк савыгыр иде», – дигәч, әбисе: «Ул синең әнкәң, тәрбияләрлек рәтең бар, акча эшлисең, түр башына утыртып ашат-эчерт, бәбкәм!» – диде. «Оятсыз оялса – каты оялыр», – ди. Килен хатында: «Ни йөзем белән синең яныңа кайтыйм инде? – дигән. – Әбиең мине кичерер микән?» – дигән. Аллаһ гафу кылсын, Аллаһ!

Гаилә тәрбиясе тимәсә дә, сөбеханалла, онык тәүфыйклы булды. Кайчакта

бала-чага кебек шаяра үзе. Кыйтап яза, янәсе. Әй, беркатлы җан! Бәгъзе адәмнәр, бияләй хәтле авызын ерып: «Уйдырма!» – дип көлсен дисеңмени? Ак ат белән кара ат кыйссасы – чынбарлык иде ул, аның хикмәте юк иде. Остазы Сабирҗан карт яшьлегендә гыйлем өстәгән Кизләү мәдрәсәсен күрергә хыялланды. Күршесе: «Син сукыр бит, бабай», – дигәч: «Күңел күзем исән», – диде. Элегрәк, Гамбәр ни талпынса да, аның гозерен үти алмас, чөнки Заретдин артык «кызыл», сизсә – син мулла-мунтагай белән сәяхәт иткәнсең дип, бәгырь итен кимерәчәк иде. Соңра, ир урманына аугач, улы Рәшит исәйгәч, Гамбәр тәвәккәлләде: Сабирҗан остазны Кизләү якларыннан әйләндерергә кирәк! Ире утарда кунасы кичтә ул Зәйнетдиннән ат сорады:

– Хәтерлисеңме, абзый, кызыңны бизгәк чиреннән аралагач: «Гамбәр, мин инде сиңа мәңге бурычлы», дигән идең? Бурычыңны түлә! – диде.

– Бурыч дип... Истә ансы, Гамбәр сеңел. Ике пот арыш орлыгына ризамы син?

– Калхузда кырым җук, ишегалдына чәчәлмим. Ат бир, Зәйнетдин. Ай яктысында Кизләүгә барып киләм. Зәрә таңда малкайны кире кайтарып тугарырмын.

– Тазалары белән урман ташыйлар, Гамбәр сеңел. Абзарда чирләшкә кара айгыр гына. Мал духтыры бүген-иртәгә суябыз, хутланасы юк, ди. Әгәр син аны апкитсәң – биш адымнан тәгәрәп үлә. Шуннан перси Алпамша мине агач мылтыктан ата, валлаһи!

– Айгыр үлмәс, Зәйнетдин абзый.

– Юмаларга мачтыр син, Гамбәр. Заретдинның аты нишләгән ди!

– Заретдин түгел, син миңа бурычлы!

– Түлке иртән исән айгыр кайтарып куй миңа, матри, катын! Ай-яй, синең белән яшәгән ир җәлке, – дип зарланып, ат караучы абзар ишегенә аркылы терәгән тактаны шудырды. Малкай көчкә генә җан асрый, аның кабыргасы тырпаеп, корсагы эчкә баткан иде.

– Синдә, хайванкаем, Сабирҗан бабай белән нәни улым Рәшитне тартырлык кына көч бар әле, – диде Гамбәр. – Мин җәяү генә атлармын.

Айгыр аны ишеткән төсле өч тапкыр пошкырды. Күрше авылга хәтле юыртты ул, ләкин картның капка төбенә җиткәч, алгы аягына тезләнде. Сукыр Сабирҗан, аны капшап-капшап карагач:

– Яшь икән бахбай, моның эче эчкә ябышкан, ачлыктан ябыккан бу, – диде. – Тугар, кызым. Тугар да безнең сарайга куала. Аранда ак айгыр ирек даулап тибенә, шуны җик, ят сахралар буйласын малкаем, – диде.

Рәхмәт төшкере, каравылчының атасы заманында Сабирҗан шәкерт белән бер төркемдә укыган икән, шуңа күрә ул төн димәде, ишекне ачты, куыклы лампасын кабызды һәм бабайны култыклап бүлмәдән-бүлмәгә йөртте. Тик әлеге сәфәр аксакалның ничә еллар «мәдрәсә, мәдрәсә» дип кагынган хыял канатларын утта гына көйдерде.

– Үзгә ис килә, үзгә ис, – диде карт.

– Хәзер мәктәп бит инде монда, бабай, – диде каравылчы.

– Дога исе беткән, оланнар.

– Һи, бабай, доганың исе буламыни?

– Болын чәчәкләреннән дә хушлырак аның исе, улым.

Карт кичергән хисләр Гамбәрнең җанына сарылды. Нәкъ шул вакытта күз алдында мәчет сурәте чайкалды. Ул яна, дөрләп яна иде. Киләчәк – күрәчәк! Ерак димә, син якын, бик-бик якын икән шул.

Сәяхәтнең могҗиза дигән өлеше шуннан гыйбарәт: Сабирҗан остаз аларны

арбадан төшермәде, ак ат белән озатты. Ул кара айгырның колхоз милке икәнен уена да китерми иде.

– Бахбаеңны тәрбияләп тернәкләндергәч, кире алмаштырырбыз, бүгенгә сиңа минеке хезмәт итсен, кызым, – диде.

Вәгъдә – иман, Гамбәр елак Зәйнетдинне күрәләтә аттырмас иде, авыл изрәп йоклаганда, ул ак айгырны ферма абзарына илтеп япты. Ә Зәйнетдин өчен ат кадәр ат алмашыну табышмак иде. Ул аптырады:

– Гамбәр сеңел, ничек бер төндә кара айгыр агарды соң? Мин бит персигә син җиккән идең, димәдем. Кичтән үз төсендә иде, иртән акка әверелгән, мәйтәм. Синең исемне атасам, җиде буын бабамны кабереннән уята иде.

Сер Сабирҗан остаз белән бәйләнгән, әгәр аның төенен чишсәң – эш харап: картны ат урлауда гаепләп, хөкемгә тартачаклар, ул чорда хуҗалык рәисе – сәвит ялчысы үтә дә миһербансыз бәндә иде. Хәер, колхоз хуҗасы Алпамша мондый әверелештән бик разый иде. Ул Зәйнетдиннән берни дә төпченмәде: читәннән үргән тарантасына ак айгырны җиккәч, бәләкәй түрәнең каз муены нечкәреп тагын да озынайды. Айгыр гына камунис иптәшнең сүгенүен яратмады: тарантасы-ние белән күпердән очыртып, гаип булды. Сабыр Зәйнетдин бу юлысы тузынды:

– Ат кайда, Гамбәр катын?! – диде. – Чын хәлне персигә белгертсәм – үзеңне себерке белән Себергә сөрә!

– Мәйлең, абзый, Себердә сиңа да, миңа да урын җитәр, – дигәч, куркак пыжымлады:

– Җә, җә, Заретдин катыны! Икәү турадык, икәү чәйнәдек, дигәндәй... Куркыныч кеше син, сеңел. Абзарга ат кыяфәтендә җен япкансың, иту айгыр табылыр иде. Эзләмәгән әрәмәлек, эзләмәгән болын калмады бит!

Көннәрдән бер көнне без капчыкны тиште. Авыл шаулады, гайбәтчеләр күперткән хәбәр зурая-зурая авызга сыймаганда гына, Алпамша үлде. Кан елаткан рәисне халык кызганды микән? Шулай итеп, бәла Гамбәрне читләтеп үтте, югыйсә ат караучы Зәйнетдин белән икесен Себер салкыннары аямас иде...

**13**

– Әй, син, калын катын? Ызбага кер, яшен суга! – Миңсылу әледән-әле тәрәзәдән башын тыгып аңа кычкырды. – Саңгырау мәллә син?! Яшен суга, дим!

– Сукмас, мин агач түгел, – диде Гөлҗиһан, ә үзе «бисмилла» дип култык астын сыпырды. Балачакта әбиләр: «Җен-пәри шунда поса да, яшен ата», – дип өркетәләр иде. – Мин Гамбәр әбине көтәм. Кайда икән ул?

– Әбиең сиңа ни пычагыма? Жалу бирәсеңме? Эшләп талчыктыңмы, мескенкәй. Кәҗә савалмаган имгәк син.

– Яңгыр көчәя, Гамбәр әби чыланыр инде.

– Аның өчен хәсрәтләнмә, Абага. Син – Абага бит әле, иеме? Безнең кортка, җан кисәгем, яшен шарын учында шартлаткан бервакыт. Идән юа икән, тәрәзәдән очып кергән ут йомгагы бала бишегенә бәреләм дигәндә генә, җиңги, шалт, шарны эләктергән. Ичмасам чүт кенә дә кулы пешмәгән!

Гөлҗиһан карчык белән ачыктан-ачык сөйләшергә кирәк дигән уй кора иде. Әйе, ул – күршесен җәберләгән Ярулла оныгы! Әйе, ул аны йорт-җиреннән сөргән Сәмигулла кызы! Атасы да, баласы да – гүрдә ята. Фани дөньядан бакыйлыкка күчкән әрвахлар белән булашу килешәмени инде, ә? Гөлҗиһан алар түгел, Гөлҗиһан – аерым, аның берәүгә дә аяк чалганы яисә хәйлә-мәкер ятмәсе үргәне юк! Әгәр дәвалыйсың икән, гафу итеп, кичереп дәвала, Гамбәр әби!

Яшен камчысы белән өч тапкыр күкнең йөзенә сыдырды да, урман өстеннән ташларын дөбердәтеп, китеп барды.

Карчык кайтты, аның өс-башы юешләнмәгән, коры иде. Хатын:

– Гамбәр әби, – дип, аңа таба кузгалган гына иде, тегесе күзе белән шундый чәнчеде ки, гәүдәсе токка эләкте. Болай яндырып-көйдереп көндәшенә генә карап була иде. Шигеңне тарат, белекче, тарат! Оныгыңа ярты сүәм дә якынаймас Гөлҗиһан! Әмма син аның күңел йозагын җимереп, хатирәләрен сыза алмассың. Чөнки барысы да истә, барысы да...

...Артында «фью, фью» сызгырган «сандугач» – Фәрит иде. Кыз, оялып, кулы белән шәрә ботын каплады. Күлмәге кыска иде.

– Нишләп озак күренмәдең? Мин сине сагындым, урман кызы, – диде малай.

Дәрестә сыйныфташлары «яратам» дигән «канатлы хатлар»ны беркайчан да Гөлҗиһанның партасына очырмады, чөнки ул «явыз Сәмигулла чәчбие» иде.

«Сагындым...» Әлеге «дәһшәтле» сүздән баш исәнкерәде.

– Ник агач бозасың, урман кызы?

Бәй, агач кызгана! Моның сагынуы шулхәтле генә микәнни?

– Пошига ашатам...

– Һи, алар үзләре дә шәп кимерә!

– Ул яраланган шул...

– Ничек яраланган? Бүре тешләгәнмени?

Дәрестә тарих укытучысы пионер Павлик Морозовны мактагач, ахырдан:

– Атасын саткан малай сезнең берегезгә дә үрнәк түгел, балалар, сез алай эшләмәгез! – дигән иде.

– Бүре ахры, бүре. – Гөлҗиһан алдады. Әти аткан, димәс лә.

– Кайда ул, урман кызы?

– Безнең... безнең сарайда.

– Кайры ашап кына ярасы төзәлмәс, – диде Фәрит, олылар кебек җитди генә. – Әйдә, без аны Зур әнигә илтик. Аның кулы шифалы, момент төзәтә.

Аучы ата өйдә түгел иде, алар артбакча ишегеннән генә хайванны өстерәп чыктылар. Башта поши урыныннан кузгалмады, аягын терәп карышты, үзенең авызыннан күбекләнеп селәгәй акты, ниһаять, ул биреште. Күрәсең, балаларның нияте изге икәнен аңлады. Тел юк та, җан бар шул!

Фәритнең әбисе ишегалдында кер чайкый иде, табылдыкка шаккатмады, ә менә кыз белән малайны янәшә күреп, аның кәефе төште. Әй, Гөлҗиһан да аңгыра иде инде! Ул үзенең Сәмигулла кызы икәнен онытты бугай! Аны Фәрит тәмам саташтырды бугай! Күзең терәп атаң рәнҗеткән кеше каршысында басып тор, имеш!

Өйдә исә әтисе әле әнисенә, әле Гөлҗиһанга җикеренде:

– Пошины качыргансыз, әрәм тамаклар! Измәгезне изәм хәзер!

Бу юлысы кыз аның әче теленнән гарьләнеп еламады: ул бәхетле иде. Гамбәр апа, шешәгә имезлек кигезеп, пошига ниндидер сыеклык эчертте, ярасына кара мазь сылады һәм Фәриткә:

– Урманга куала, баласын юксына, бахыр, – диде.

Кызык, ирektә боек хайван җанланды, озын сыйраклары белән куаклыкка сикерде.

Фәрит сердәшен:

– Иртәгә дә күрен, миңа синнән башка күңелсез, – дип озатты.

Беркөнне атасы, яман сүгенеп, кызының толымыннан каптырды:

– Син анда кемнәр эте белән иснәшәсең, кәнтәй?!

Ул Гөлҗиһанны яклап маташкан хатынына да йодрыгы белән тамызды:

– Гамбәр күсәге белән чуала себеркең!

– Алар бит әле сабый гына, уен уйнап кына йөриләр, – дип яклаclose да, әнкәсе соңыннан кызны утлы табада биетте:

– Нинди башбаштак син, бала? Пошины син генә бавыннан ычкындыргансың! Мин дә кызганам хайванны, тик бит инде атаң белсә – үтерә иде! Син Гамбәр апага да кайгы юрыйсың, күргән хәсрәте әзмени аңа? Атаң үчле, аның оныгын урманда сагалап буып ташлый. Сәмигулланың ерткыч икәне бөтен авылга мәгълүм бит инде! Ант ит, бүтән ул малай белән күрешмим, диген!

– Ант, әни, ант...

Тик Гөлҗиһан антын бозды, әтисе белән әнисе болында печән чапканда, урманга йөгерде.

– Мин сине тоташ дүрт көн көтәм, ник син һаман килмисең, урман кызы? – диде малай һәм күлмәк изүеннән тыгылып муенса алды. – Мә, сиңа бүләк. Кыздырган камыт энәсе белән каштан чикләвеген тишеп, ат кылына тездем. Тагасыңмы, урман кызы?

– Тагам...

– Мәңге сакларсыңмы?

– Саклармын...

– Нигә син моңсу, урман кызы?

– Болай гына... Әниләр мине ерак әбиләргә җибәрә. Әби чирләгән...

Әнисе өйрәткән гөнаһсыз ялган иде бу.

– Кайсы авылга? Әйт. Мин сине эзләп табам! – дип кайнарланган малайны Гөлҗиһан, үзеннән дә ялган өстәп, тиз сүрелдерде:

– Әби кала бүлнисендә аңсыз ята, ди. Миңа көн-төн кизү торасы, ди.

– Кайту белән хәбәр бир, урман кызы, яме?

Беренче егетләр бүләге... Кадерле бүләк... Аны өйдәгеләрдән ерак яшерәсе иде... Муенса «сата»: Фәрит һәр чикләвеккә «Ф+Г» дип, нәни генә тамга уйган иде...

«Кайту белән хәбәр бир...» Менә ничәмә елдан соң гына кайтты... Тик озын толымлы чандыр Гөлҗиһан белән симергән шәһәр бичәсе икесе ике кеше инде. «Исәнме, мин – урман кызы!» – дисә, мөгаен, Фәрит аның кыяфәтеннән имәнер иде.

...Өйдән комган тотып карчык чыкты, яулыгын артка чөеп бәйләде, оегын салып, буй-буй ыштанының балагын бөкләде һәм пыш-пыш укып тәһарәтләнде.

Миңсылу, карчыга төсле аның һәр адымын күзәтеп, кирәксә-кирәкмәсә дә сүз кыстыра иде:

– Җиңги, аягыңа көч килмәсен, дисәң – таякка ныграк таян.

– Аксак ничек йөрергә, сукыр ничек күрергә, чулак ничек кул көрәштерергә үрәтә, – диде кортка, ул баягы кебек ачулы түгел, күзеннән рәхим-шәфкать нуры сирпелә иде. – Яңгырдан соң күл кабаргандыр, син, кем кыз, өч банкы юып киптер!

– Бәй, җиңги, шуның кадәр суалчан ниемә сиңа? – дип гаҗәпләнгән каенсеңлесенә ул җавап биреп вакланмады. – Менә гел шулай! – Миңсылу намазга ашыккан җиңгәсе артыннан үртәлеп калды. – Нәрсәдер сорыйсың икән, йә дәшмәс, йә пырылдар! Син дә, Абага, нәстә көләсең әле?

– Сөлек белән суалчанны бутыйсың ич, апа җаным.

– Син бутамассың, бәлкем, гөлкәем! Иртәгә синең дә күрәселәрең бар әле!

«Иртәгә, иртәгә...» Хатын көннең беренче яртысында үзен әйбәт кенә хис итә, хәле бетми, аяклары да армый, шуңа күрә ул тагын муенсасын караштырмакчы иде. Фәрит белән очрашу өчен сәбәп эзләмәде Гөлҗиһан. Юк, һич юк! Балачактагы оялчан-тыенкы хисләр бүгенге көн белән ялганып дөрләп кабыныр дип өметләнми дә иде.

...Аерылу хәсрәтен иң көчле дару да басалмас иде. Әнисе яңа уку елына базардан чүәкләр сатып алды. Алар матур иде, җир җиләге төсендә иде. Шатланмады кыз. Күтәрмә якалы ак кофта да сөендермәде. Гөлҗиһан урман егетен сагынды. Ә ишек-капкалар бикле... Дөнья ишегалды белән генә чикләнә... Август азагында авыл урамнары ятимләнде: шәһәр балалары кошлар сыман туган якларына очты. Фәрит тә киткәндер, бит ул да мәктәп укучысы иде. Язга табан колхоз рәисе, өлкән сыйныф кызларын директор бүлмәсенә җыеп:

– Кем җәйге айларда җәйләүдә сыер сава? – дигәч, Гөлҗиһан исемлеккә беренче язылды. Тик әнисе аның теләгенә каршы иде.

– Син – нәзберек җан, ничту сыер, кәҗә имчәге дә тарталмыйсың, кызым!

– Мин үзем акча эшлим!

Әй, акчада идемени хикмәт! Ул иреккә тиенәчәк! Иреккә! Җәйләүгә юл урман аша үтә, димәк, Гөлҗиһан көн саен Фәрит белән күрешәчәк.

Әмма... чираттагы җәйнең бер яме дә булмады. Чөнки урман егете әбисенә кунакка кайтмады. Кырымда икән быел, әнисе белән ял итә икән... Әгәр малайны чиратка салсалар, димәк, ул икенче юлысы Айтуганга киләчәк.

Кыш үтте, яз җитте. Май ахыры иде, авыл юлларының пычрагын изеп-таптап, ике «УАЗик» Гөлҗиһаннарга табан ыргылды. Әтисе мылтык чистарта иде, капкага типкән ят әзмәверләргә көпшәсен төбәп:

– Стуй, ызбулычлар, атам! – диде.

Әзмәверләр артында чөгендер кебек кып-кызыл Мирхәйдәр абзый сурайды:

– Тс-с, Сәмигулла! Чапай заманындагы алтатарың белән Мәскәү кешеләрен көлдермәсәнә, – диде ул. – Бу иптәшләр – сиңа хан сарае салышкан Радий Арсиныч памушниклары.

Атасы кояштай балкыды:

– Драсти, иптәшләр! Мишук динга апкайттыгызмы, тауаришлар? Миңа хуруши мылтык нады била.

Әзмәверләр бер-берсенең колагына пышылдашты.

– Акча димәле син, Сәмигулла. – Мирхәйдәр абзый, күрәсең, дулкынлана – маңгае тирли иде. – Радий Арсиныч кайгыда ди әле. Синең Гөлҗиһаның чамасындагы кызы абариедә үлгән, ди. Болар ни, энем, – сәвит хуҗасы «телсез» ярдәмчеләргә ымлады, – Гөлҗиһаныңны апкитәбез, диләр. Арсиныч аны мәрхүмә кызына охшата ди, вәйт! Карышма, Сәмигулла, боларның билендә синең ише генә Чапай мылтыгы түгел, боларныкы – чын тимер, берне гөпелдәтсәләр – башың агач төсле унга чәрдәкләнә.

Бу хәбәрдән әнисе йөрәге белән ауды, әтисе исә попугай кебек:

– Мишук динга нады била, – дип кабатлады.

– Без ашыгабыз, аңгыра мужикка ниятебезне яхшылап төшендерегез, – диде әзмәверләрнең берсе, тупас кына.

Мирхәйдәр абзый:

– Кунаккамы, иптәшләр? – дигәч, икенчесе:

– Бөтенләйгә, – диде. – Радий Арсеньевич өченче ел сездә төшергән видеофильмны карагач: «Кыз чая», – дигән иде. Кайгырмагыз, шеф аңардан леди ясаячак.

Әнисе Мирхәйдәр абзыйның изүенә ябышты:

– Мөртәт! Кызымны кемгә сатасың?

Аны көчкә генә куптардылар. Гөлҗиһан ыспай ир-егетләрнең урысча такылдавыннан чамалады: чынлап та, бай карендәше сеңлесен башкалага алдырта... Укыта... Эшкә урнаштыра... Зур дөнья белән таныштыра... Айтуганда

мәктәп директорында гына бердәнбер телевизор бар иде. Аның хатыны, урыс теле һәм әдәбияты укытучысы, өч уку алдынгысын атна саен үзенә чакырып, «тартма»сын кабыза, билгеле, андагы сурәтләр тоныклэкин шәйләнгән хәтлесе дә Гөлҗиһанның хыялын баета, кызның да кинодагы чибәр артист апалар кебек матур киенәсе, тешләрен җемелдәтеп елмаясы һәм зур көзге, йомшак диван-кәнәфиләр белән җиһазланган зиннәтле бүлмәләрдә яшисе килә иде.

Гөлҗиһан тиз җыенды. Киндер букчасына ике күлмәк, оек бөгәрләп тыкты. Гәзитә битенә кат-кат төргән каштан муенсасын төпкә үк яшерде. Машинаның арткы утыргычында юл буе йоклады ул. Чакрымнарның туган җиреннән аерганын да тоймады, бары тик таш йортлар белән чуарланган шәһәргә җиткәч кенә, үзенең бөтенләй чит-ят дөньяга эләккәнен аңлады. Алар тышкы диварына арыслан рәсеме чәпәгән йортның өченче катына күтәрелделәр. Тупас әзмәвер кыңгырау төймәсенә баскач, эчтән:

– Кем? – дип сорадылар.

– Без, Радий Арсеньевич кешеләре, – диде тупас. – Объектны кабул итегез!

Ишекне ачкан бөдрә чәчле хатын кызны кадерле кунагыдай якты йөз белән каршылады.

Бай туганының ярдәмчеләре сүзне кыска тотты:

– Шефның күрсәтмәләрен төгәл үтәгез, Софья Ивановна!

Башта ташкала тормышы кызны ялыктырды. Монда каядыр ашыгалар да ашыгалар, көн белән көн бер-берсенә охшамый, вакыйга өстенә вакыйга өелә, ә авылда, киресенчә, яшәү арбасының тәгәрмәче җай гына үз көенә келтери иде.

Гөлҗиһан өчен махсус яллаган марҗа Софья Ивановна берьюлы укытучы да, тәрбияче дә һәм... хезмәтче дә иде. Авылда җитмеш төрле вак эш эшләп үскән кыздан ул тузан да сөрттермәде, хәтта ки ваннада юынган Гөлҗиһанның тәнен сөлге белән корытты, йокларга урын җәйде, чәчен тарады.

– Гүзәлем! – Софья Ивановна, ул һәр иртә дәфтәреннән көн тәртибен укый иде. – Бүген без әбәткә кадәр үзәк универмагтан сиңа өс киемнәре сайлыйбыз. Төштән соң ике сәгать дәрес. Русчагыз аксый, диктант язабыз. Кичкә «Победа» кинотеатрында яңа фильм карыйбыз. Әйдәгез, гүзәлем, меню да төзик. Сез нинди блюдалар яратасыз? Нәрсә пешерим?

– Итле бәрәңге, – дигәч, тәрбияче-хезмәтче, җирәнгәндәй:

– Авыл ашы чтоли? – диде. – Гүзәлем, мин сезне яшелчәдән әзерләнгән ризыклар белән тукландырырмын. Төрле ярмалар файдалы. Свежий балыкка заказ бирермен. Алма, кишер соклары эчәрсез.

Әллә хыял белән чынбарлык игезәкләр микән? Гөлҗиһанның иркен һәм якты бүлмәсендә күн белән тышланган диван-кәнәфи, идәндә нәкъ яшел чирәм – йомшак келәм, телевизор да киң экранлы, аны «түбәсе»нә йодрык белән сугып кабызасы түгел. Ә табында ниләр генә юк! Йөзем, өрек, гомер тәмләмәгән әфлисун...

– Мәктәптә безгә укытучы метро турында сөйли иде, Софья апа..

– Гүзәлем, мин – Софья Ивановна, – диде марҗа.

– ...менә шул, Софья Ивановна, мине җир астында йөрт!

– Миңа син, димәгез, гүзәлем, авыл гадәтен ташлагыз, зинһар. Метрода йөртү минем вазифама керми. Сезнең өчен Радий Арсеньевич шәхси машина билгеләде.

– Туйдым мин гел машинада селкенеп!

Гөлҗиһан үзенең нинди урын биләгәнен аңлаган иде инде. Ул – кечкенә генә патшабикә, аның кечкенә генә тәхете бар. Кулындагы тылсымлы таягы белән селтәнсә – марҗа хатыны: «Боерыгыз, гүзәлем!» – диячәк. Софья Ивановна

каядыр шылтыратты һәм: «Патшабикәм, кичерегез, теләгегезне кичектереп кенә үтим», – дигән сыман башын иеп:

– Гүзәлем, метрода иртәгә көндез сәяхәт итәрбез, диделәр.

– Абау, безгә рөхсәтсез берни дә эшләргә ярамыймыни?

– Гүзәлем, Мәскәүдә минут саен кеше югала. Ә сез зур абзыйның сеңлесе, әгәр адашсагыз, Радий Арсеньевич ботыбыздан аса.

– Һи, бездә нинди куе урман! Адашмадык әле.

– Гүзәлем, монда ике аяклы бүреләр күп, – диде маржа. Кайчакта аның Гөлҗиһанны балага санап сөйләшүе саруны кайната иде.

– Мине кайчан туганым абый белән күрештерәсез, Софья Ивановна?

– Чакырганын көтәбез, гүзәлем, чакырганын!

– Бигрәк инде сез! Үзебез барыйк.

– Ярамый, гүзәлем.

Беркөнне иртән кыз, уяныр-уянмас, караватында иркәләнеп ятканда, аш бүлмәсендә тәрбияче-хезмәтче хатын ниндидер ир-ат белән чүкердәшә иде. Алар авызга-авыз куеп сөйләшсә дә, урманда ике чакрымда елан шуышканын да ишеткән сизгер колак, локатор сыман, авазларны тота иде.

– Кыргый зат Москвага ияләшәме, Софья?

«Кыргый зат», әлбәттә, Гөлҗиһан иде.

– Ой, шәһәрдә туган диярсең! Мин аны аңгыра сарык бәрәнедер дигән идем, бик акыллы кыз. Уже минем белән командовать итә.

– Мотор нәселе, точно!

«Мотор», мөгаен, туганының кушаматы яисә Матуров фамилиясенең кыскартылган варианты иде.

– Мотор белән кайчан очраштырасың, Сергей Владимирович? Сеңелкәш дулый.

– Шефның кәефсез чагы. Былтыргы сайлауларда тибелгәч, үзгәрде ул.

– Нәрсә икән, акча әз төртте микән, Сергей Владимирович?

– Һо, аңардагы байлык! Эчәгесе-ние белән илеңне сатып ала. Көндәшләре усал иде, җиңделәр. Кызы Наталья да нык сындырды шефны. Бу кыргый мәңге Москва чырае күрмәс иде, Наталья үлмәсә. Шундый хәлләр, Софья Ивановна. Давай, артыгын лыгырдамыйк, без синең белән бәләкәй ялчылар, акчасын яхшы түли Мотор, тузанлы эш түгел. Гуляй, Васька!

Көндәлек режим катлауланган саен катлаулана иде. Маржа:

– Гүзәлем, балет мәктәбендә биш-алты дәрескә язылдым. Сезгә гәүдәгезне төз тоту буенча күнекмәләр кирәк, – дигәч, Гөлҗиһан киреләнде:

– Мин болай да төз! Мине кино артистлары кебек чытыкланырга өйрәтегез!

– О Боже! – Тәрбияче-хезмәтче, кызу каптымыни, гәзитә белән битен җилләтте. – Как низко! Алар ведь бозык халык! Алар бер-берсенең ире яки хатыны белән йоклый. Радий Арсеньевич сезнең бу теләгегезне бер дә хупламас, гүзәлем.

Ахырдан гына Софья Ивановна күз яше түгеп зарланды: баксаң, аерылган ире артисткалар белән чуалган икән.

– Гүзәлем, син ужасно ябык, это не красиво. Врач-диетолог белән киңәшик әле, – дип, маржа кызны табибка күрсәтте. Пеләш башлы, юан духтыр өч рецепт язып тоттырды:

– Немедленно шушы даруларны эчерегез! Тазармаса, бөерләре сәлперәеп аска салына.

Аппетитны ача торган төймәләрне иртә-кич йотасы икән. Ай дигәндә Гөлҗиһанның йөзе түгәрәкләнде, арык тәненә ит кунды. Нәтиҗәсе дистә еллардан гына ачыкланды. Табигать үзенең иҗатына тыкшынганны яратмый

шул: әлеге «чудо» төймәләр гормональ препаратлар булган, һәм алар матдәләр алмашын бозган. Киләчәктә кызның тутырган тавыкка әйләнәчәген марҗа белгәндер. Хәер, ул ник пошынсын ди! Байның туганы аның кулына вакытлыча гына уйнарга бирелгән курчак кына иде ләбаса!

Ике айда Гөлҗиһанның урысчасы шактый гына шомарды.

– Акцент сизелми, – диде Софья Ивановна. – Сез банк мәктәбендә укыячаксыз, гүзәлем. Сезне сөендерим әле, иртәгә сез Радий Арсеньевич белән күрешәсез.

– Абый безгә кунакка киләме?

– Юк ла, гүзәлем. Ул сезне кунакханәдә көтә.

Серле туган күптән инде күңелне кытыклый иде. Нинди ул? Сәмигулла әтисе кебек тупасмы? Йөз-кыяфәте белән аңа тартыммы? Карендәшләр ләса.

...Кара машина, арка сыман тар гына аралыктан үтеп, таш бинаның ишегалдына керде. Марҗа белән кыз агач култыксалы баскычтан өскә менделәр. Озын коридорның иң түрендә ике ир гәпләшә иде, берсе кулы белән: «Туктагыз!» – дип ишарәләде.

Икенчесе Софья Ивановнаның сумкасын капшады.

– Тәртибе шулай, әнкәсе булса – аны да тентиләр, – диде марҗа хатын.

Авылда кунак-мазар төшерсәләр, хуҗаларның аягы тыз да быз йөгерә: «Әйдүк, җәмәгать, әйдүк, сез безнең тансык кешеләребез», – дип, телләре тегермән төсле зыр-зыр әйләнә, алар кергән номерда исә авыр тынлык, җитмәсә тәрәзәләргә калын пәрдә корылган иде.

Софья Ивановна бусага төбендә аның кулыннан тартты:

– Ашыкмагыз... Исәнмесез, Радий Арсеньевич?!

Гөлҗиһан аптырады: кем белән исәнләшә апаң? Менә дивар буендагы кәнәфидән бер гәүдә калыкты, ул болай да кояш төсе күрмәгән караңгы бүлмәдә кара күзлек кигән иде.

– Тәртипме, Софья? – дигәч, гәүдә кире кәнәфиенә чумды. Әйтерсең, ул кыз белән беренче тапкыр гына очрашмый, әйтерсең, алар кичә генә бергә чәй эчкән иде.

– Барсы да әйбәт, Радий Арсеньевич. – Марҗа кыска гына «доклад» сөйләде. – Сеңлегез гаҗәеп акыллы, һәрбер нәрсәне тиз үзләштерә. Белемгә омтылышы зур.

Менә монда туган абыйсы, һичшиксез, Гөлҗиһанны кочаклап алачак иде. Юк, кочакламады. Башын артка ташлап:

– Яхшы, – диде. – Исемен Джиган Самуиловна Насровская дип үзгәртегез! Ул Москвада туган. Милләте – яһүдә. Ясно?

– Ясно, Радий Арсеньевич.

– Миңа бер дә ясно түгел. – Аждаһа авызыннан көлтә-көлтә ут бөркелдемени, кызның ирене пеште. – Исемемә тимәгез! Әтинекен дә бозмагыз! Фамилиям Насыйрова, аңа да әллә ниткән койрык такмагыз!

– Ну и характер! – диде туган абый һәм яңгыратып тамак кырды. Уң яктагы диварда идәннән түшәмгә кадәр эленгән картина «аякланды», ул яшерен ишек икән, хуҗа шунда кереп китте...

Софья Ивановна юл буе ухылдады:

– Ой, гүзәлем, үтерәсез, честно? Нигә сез Радий Арсеньевичка каршы дәшәсез? Ул әнә ничек сезнең хакта кайгырта.

– Мин – Сәмигулла кызы Гөлҗиһан Насыйрова. Татар мин, татар, ахмак!

Бүтән әлеге проблеманы кузгатмадылар. «Мин җиңдем», – дигән кыз үзенең

җиңелгәнен беренче сентябрьдә генә таныды. Куратор укучыларны исемлек буенча барлаганда:

– Насровская Джиган, – диде. Беркем дә торып басмагач, ул исем-фамилиясен тутырып:

– Джиган Самуиловна Насровская, – диде.

– Миндер инде андый кеше. – Гөлҗиһан үзенең яңа роленә күнегергә тиеш иде...

Ике елдан соң мәгърибтән мәшрикъка кадәр сузылган «киң вә широкий» ил таркалды. «Хакимияткә бармагын өздергән демократ килде», – диделәр. Гөлҗиһан-Джиган ушлы иде, җәмгыятьтәге үзгәреш җилләренең кая табан искәнен бик тиз чамалады. Төптәге «хәшәрәтләр» яктыга үрмәләде, бәйдәге «этләр» чылбырын чәйнәде. Марҗа хатын гына аны өлгермәгән яшел җимеш дип саный: һаман өйрәтә, һаман тәрбияли иде. Шул баласытуы нәтиҗәсендә Софья түти «тәпиен» капкынга кыстырды да инде. Алар Радий Арсеньевичның ярдәмчесе Сергей белән әшнәләр иде, күрәсең, илдәге түнтәрелеш бу икәүне «батырлык»ка рухландырган иде.

– Гүзәлем, безнең сезгә сүзебез бар, – диде Софья Ивановна. – Әйеме, Серёжа? – Кич иде, кыз дәрес әзерли иде. – Сез әти-әниегезне сагынасызмы?

– Сагынсам, нишлим? – диде Гөлҗиһан.

Яңгыр алдыннан кояш бик нык кыздырса, «көнне чеметә», диләр иде, аның да йөрәген сагыш чеметте.

– Ай-яй, безнең шеф каты бәгырьле! – дип көлемсерәде Сергей.

– Ужас! – Марҗа да аны җөпләде. – Аңарда туганлык хисе нуль! Ике ел да дүрт айда Джиган Самуиловна белән өч кенә күреште!

– Мин шефны уговорю, шушы көннәрдә сезне авылыгызга алып барып кайтабыз. – Ярдәмче егет үгезне мөгезеннән эләктерде. – Только баш на баш! Тиздән Радий Арсеньевич сезне чакыртыр, Джиган. Сез диван астына бер төргәк куеп калдырыгыз.

– Нинди «төргәк?»

Марҗа белән егет бер-берсенә караштылар.

– Сюрприз. – Сергей көчәнеп кенә көлде. – Да, сюрприз! Шефның туган көне җитә. Без аны оригиналь рәвештә котламакчы идек.

Гөлҗиһан башындагы шөрепләрен тиз-тиз «борды». Кем бүләкне диван астына ташлый инде, йә? Болар авыл баласы дигәч тә, аңгыра, диләр микәнни?

Соңгы дәрестән ул табан ялтыратты. Һәр адымын тикшергән Софья Ивановнада шымчы таланты көчле иде. Туганыңны шартлатырга җыенганда, ничек кисәтмисең ди! Каты бәгырьле, имеш! Гөлҗиһан моны үзе дә белә.

Радий Арсеньевич кунакханәдә иде. Бу юлысы кызны тентемәделәр. Димәк, ышаныч яулады. Туган абыйның «яңалык»ка исе китмәде:

– Тынычлан, Джиган, син яшәгән фатирдагы «жучоклар» секунд эчендә миңа жуелдый, – диде. – Хыянәтчеләр! Дошманга сатылганнар! Исеңдә тот, Джиган, бизнес – сугыш кыры, йә көндәшең сине дөмектерә, йә син аны. Таракан урынына сытам кабахәтләрне!

Мөгаен, сыткандыр, фатирда бүтән хезмәтче хатын тузан суырта иде. Бу вакыйгадан соң Гөлҗиһан уйланды. Әйе, Мәскәү аны еш уйлата иде. Туган абый дигәнең кем икән ул? Ни-нәрсә белән шөгыльләнә икән? Сорасаң, синең эшең түгел, диячәк. «Мин сине ашатам, киендерәм, укытам, сиңа тагын ни кирәк?» – диячәк.

Берсендә Арсеньевич яртылаш ачылды. Нибарысы яртылаш! Гөлҗиһан банк

мәктәбен тәмамлап, сәүдә институтында укый иде. Туган абый аны су өстендәге көймә-ресторанга чакыртты. Залда биш тән сакчысыннан гайре (алар да ишек артында!) адәм заты юк иде. Гадәттәгечә, Радий Арсеньевич кара күзлектән иде.

– Сеңлем, сиңа унсигез яшь тула. Туган көнеңә нинди бүләк әзерлик?

Кичке аш шулай башланды.

– Берәр атнага авылга җибәрегез.

– Авылны онытып тор!

– Биш ел онытгым инде, абый.

– Тагын ун ел оныт!

– Паспортымны алыштырганда, чын исемемне яздырам.

– Ә син, сеңлем, дядя Радий ни өчен болай эшләде икән дип баш ватмадыңмы? Яһүд булып яшәве җиңелрәк! Аларга туганда ук шома юл түшиләр, шуңа алар беркайчан да безнең шикелле абынып борын канатмый!

Кайнар шулпа буы пыяласын тирләтте ахрысы, туган абый күзлеген салды. Гөлҗиһан йотлыга язды: Радий Арсеньевичның уң күзе хәрәкәтсез иде. Пыяла! Ясалма!

– Сеңлем, үзәктә Сәүдә йортын аукционга куйдылар. Шуны унсигез яшеңә бүләк итәм.

Бүләктән битәр сыңар күздән тетрәнгән кыз:

– Кемгә, кемгә? – диде.

– Сиңа, Джиган Самуиловна, сиңа, чёрт побери!

– Миңа?! Мин... мин студент бит әле, абый! Кайчан сатарга вакыт табам, ди.

– Сатма! Синең өчен урыс негрлары эшләр. Арендага бирсәң дә, акча ул! Банкта акча яна, ә шәхси милек – тора! Конфет фабрикасын да, шәт, сиңа аткарырмын.

Кыз бик күп нәрсәләрне ком кебек сеңдерә, әмма монысы – чишелеше мең кат җеп белән төйнәлгән катлаулы мәсьәлә иде. Туган дигәч тә, җиденче ботак кына лабаса Гөлҗиһан! Әллә тау-тау мөлкәтен вакытлыча гына аның исеменә яшерә микән?

Әнә бит, икътисад фәне укытучысы, профессор Субаров лекция саен: «Хәсрәт демократлар кода-кодагыйларына, абый-сеңелләренә ярты тиенгә генә завод-фабрикаларны өләшә, илнең байлыгын карак байлар бүлгәли», – дип сызлана.

– Мин тиздән икътисад белгечлеге алам, үзем акча эшлим, – диде Гөлҗиһан. – Сез милкегезне берәр якын карендәшегезгә күчерегез.

Шул сыңар күзгә карамас өчен, кыз чәнечкесе белән тәлинкәсендә казынды. Ул зәңгәр күз океанга охшаган, менә аның төбеннән акула йөзеп чыгар да кабып йотар төсле иде.

– Хезмәт хакы белән генә баесалар иде, Джиган! Син минем бердәнбер туганым. Безнең нәселне коммунистлар Себердә үк корытмакчы иде дә, бабайлар үзләренә үзе су сибеп терелткән.

– Ә нишләп алайса сез шулар мөнбәренә үрмәләдегез?

– Власть – көчле корал, сеңлем. Әгәр ул акча белән дә ныгытылса, син – корыч гигант! Сине беркем дә аударалмый!

– Партия дә үлде, абый.

– Берсе үлә, икенчесе туа, чүп үләне әрсез, тиз үрчи, Джиган.

– Абый, мин сезнең хакта берни дә белмим. Туган, әйе, туган. Сез кем? Гаиләгез кайда?

Селкетсәң – корыч гигант та ава икән. Сыңар күз яшьләнде. Гөлҗиһан мәгънәсез соравы белән аның йөрәк ярасын кузгатты.

– Минме? Мин – татардан яралып, рус кабыгына төренгән ир-ат. Син

канәгатьме? Ә гаилә... Гаилә юк. Хатыным белән кызым авариягә эләкте. Син минем Натальямның күчермәсе. Холкыгызга кадәр бер үк. Ул да акыллы иде. Банк мәктәбеннән соң Сәүдә институтына керер, киләчәктә үзенең бизнесын оештырыр дигән идем. Булмады... Кызымның дәвамын синдә күрәм, Джиган. Давай, өметемне акла, сеңлем!

Менә бит язмыш! Әгәр Наталья үлмәсә, хәерче Сәмигулла кызы Гөлҗиһан «Татардан яралып рус кабыгына төренгән» Матуровның ике ятып бер төшенә кермәс иде.

Туган абый кузгалгач, ишек төбендәге сакчылар үрә катты. Берсе артыгы белән ялагай иде, шеф машинага утырганда, кулъяулыгы белән җәлт кенә аның түфлиләрен сөртеп алды. «Бу ялагай бәндә синең белән уртак табактан ашар, уртак түшәктә йоклар», – дисәләр, кыз: «Тәүбә, тәүбә», – дияр иде. «Синдәге байлык ташкын кебек агар, ун елда ул ун тапкыр ишәер», – дисәләр дә: «Җүләр мәллә сез!» – дияр иде. Ишәйде бит, ишәйде... Ә авыл нишләде? Ул акча томанына күмелеп ерагайды. Әнисенең үлем хәбәрен аңа ике атнадан соң гына ирештерделәр... Аның каравы Радий Арсеньевич белән аралар җылынды.

– Синең папашаң ышанычлы кешеме? – диде туган абый.

– Әти белән унбиш ел күрешмәдем ич. Йомышыгыз бармы әллә? Мине җибәрмәдегез!

– Приказ үтәргә синнән башка да егетләрем буа буарлык! Син лучше кыяфәтеңне кара, Джиган! Көннән-көн симерәсең, – дип шелтәләде карендәш.

Ярты елдан соң Матуров үзе офиска килде. Ул хәтта сакчыларын да ияртмәгән иде.

– Мин синең белән горурланам, сеңлем, син – талантлы җитәкче. Бизнесың чәчәк ата, – диде. – Только симерүеңнән тукта. Москвада шәп клиникалар до черта, тикшерел. Алар булышмаса, Германиягә оч!

– Радий Арсеньевич, авыл сагындырды...

– О, авыл! – Туган абый озак кына кулындагы күзлеген әйләндерде. – Авылыңа төкер, Джиган. Сездә кыргый халык, көнләшеп йортыгызны яндырганнар. Папашаң да янган. Но тормыш дәвам итә, сеңлем!

– Нинди тормыш! Әти үлгән, әти-и! – Шундый зур фаҗига турында тыныч кына сөйләгән «сыңар күз» Гөлҗиһанны чыгырыннан чыгарды. Кансыз! Җансыз! Чирканчык бәндә!

– Чырылдама! – диде тимер тавыш. – Минем дә кызым кабердә ята! Однако яшәргә кирәк! Сиңа егерме сигез яшь, иртәгә киявең белән таныштырам. Так что, бизән-ясан, Джиган Самуиловна!

## 14

...Ул биштәрләргә берәр-берәр пыяла савыт салды:

– Аркагызга асыгыз!

– Әй, җиңги, икебез аксак, беребез чатан дигәндәй, әкияттәге сыман ай барасын көн барырбыз инде, – дип мөкелдәгән Миңсылуга:

– Чатаны синдер дә, аксагы кемдер, – диде.

Кыр казлары кебек тезелештеләр. Карчык иң арттан атлады. Ул «чыбыркы», халык әкрен кыймылдаса, теле белән «суктырачак» иде. Күл ерак, ди, каенсеңел. Ялкаулансаң – кашык та авызга ерак. Иншә Аллаһ, чакрымнар хәлдән тайдырмас. Һәй, яшь чагы булса, боларга ялыныр идемени? Карт тәннең канын ни ач сөлек тә суырмый икән. Һай элек уптым илаһи кабалар иде кана! Алдындагы «кыр казы» җанланды:

– Гамбәр әби! Син мине Аллаһ ризалыгы өчен генә сихәтләндерәсеңме?

– Кодрәт иясенең ризалыгына өметләнмәгән гамәл – шайтан гамәле.

– Мин синнән куркам, Гамбәр әби, чын мәгәр! Алай да сорыйм: мәрхүм этине кичердеңме син?

– Кичерү-кичермәү бер Аллаһ кодрәтендә.

– Беркөнне: «Башта синнән зыян күргән кешедән гафу үтенергә кирәк», – дигән идең, Гамбәр әби. Әгәр мин этине ярлыка дип, сиңа ялварсам, мәрхүмгә карата күңелеңдәге таш эрер идеме?

– Миндә таш жук! – Ул таягы белән хатынның аркасына берне тамызмакчы иде, «әүвәл үзеңне кыйна, Гамбәр!» дигән боерык ишетте. Бу – хакыйкать тавышы иде. И-и, кортка, кортка! Син судан пакь, сөттән акмыни?! Ничәмә-ничә ел ялган белән яшисең! Сине кем шуңардан арындырыр менә... Бастыр ачуыңны, бастыр! Ызбаңнан Аллаһка тапшырылып, дога укып чыктың... Жаныңны бимазалама... Әнә, им-томың ничек килешә: Сәмигулла кызы аягын сөйрәми, Ходайның рәхмәте. Чүпрә сыман күпергән гәүдәсе дә шактый шиңде. Синең генә тырышуларың нәтиҗәсе микән, йа? Кемсәне гыйшкы җилкетә, гыйшкы... Жу-ук, аны онык белән кавыштырмас өчен таулар ишелсен, җир убылсын!

Күл кырыенда кизләү бар иде, карчык юлдашларын шунда таба борды:

– Сусадыгыз, эчегез, – диде.

– Абау! Бу бит безнең балачак чишмәсе, – дип, Гөлҗиһан әле карчыкны, әле Миңсылуны кочаклады. – Әби бәгырькәйләр, без Фәрит белән монда каен яфрагы йөздерә идек. Ул миңа: «Суда синең кебек бер чибәр кыз сурәте чайкала», – дия иде. Әллә нинди матур сүзләр уйлап таба иде Фәрит. Китаплар язса, дөньяга танылыр иде.

«Синең йөрәгеңә язган кадәресе дә җитәр», – дип, моның авызын томалыйсы иде дә... И Аллаһым, тагын ачулана кортка! Алай да ул:

– Кизләү шул ук, бәндәләр генә бүтән, – диде.

...Күл өсте нәкъ пыяла, бассаң – чатнар кебек иде. Карчык озын ыштан балагын тезенә кадәр күтәрде һәм «бисмилла» дип суга керде:

– Жылы, оланнар. Хәзер сезнең чират, кем кыз, кем... – Гөлҗиһан дигән исемнән тел бизгән иде. – Кем...

– Кем димә, Гамбәр әби, мин – Абага-а!» – Хатын, кулын өскә сузып, күл буен яңгыратып көлде. – Мин – чәчә-ә-әк!

Аның көлүе тагын карчыкның җеннәрен кузгатты. Моның кыланмышына ничек түзәсең ди, Аллаһым! Ул таягы белән аңа кизәнмәкче иде, Гөлҗиһан:

– Бу күл дә миңа таныш, без монда Фәрит белән тәпиләребезне юа идек, – дип, суга кереп басты, ләкин озак очынмады: – Ой, кемдер тешләде! – дип чинап, ярга ыргылганда, аның чәлтеренә биш сөлек кадалган иде. Кортка:

– Болар ат сөлеге, имгә яраксыз, – дип, бишесен дә күлгә ыргытты. Чупылт, чупылт... Каенсеңелнең дә табышы сыек, өч сөлекнең икесе «брак» иде. Чупылт, чупылт...

– Хет шул хәшәрәтләрне күлгә кире ташлама инде, җиңги, безнең яңадан каныбызны эчәләр бит алар. – Каенсеңел шыңшымыйча гына бернәрсә дә эшләми иде.

– Яшәсеннәр, кем кыз!

– Атныкымы, адәмнекеме – нинди аерма, бөтенесен дә җый, җиңги.

– Аерма зур: көн – якты, төн – караңгы, җугыйсә икесе дә вакыт күчәрендә әйләнә.

– Әй, синең яшең дә туксан, үз туксаның да туксан, җиңги!

Бүген күл юмарт иде: савыт бик тиз тулды. Карчык төбе-тамыры белән канлы

үлән йолкыды. Дымлы туфракта алар сусыл, сабагын сындырсаң, кан тибә иде. Беренчесендә сөлек аз эләкте, бу юлысы, иншә Аллаһ, яшь бикәчнең башыннан аягына хәтле утыртыр... Чыдар, чыдамый ни! Хастаны җәлләсәң – чире отыры аза. Зәхмәтне каз мамыгы белән сыпырма, тырма белән тырна! Чишмә дә, күл дә таныш, ди. Кара син! Агач ботагыннан егылгач, кабыкка яткырып билен турайткан иде Гамбәр, анысын онытмады микән? Хәтерлидер, моңарда хәтәр-хәтер...

Кайтканда, ул юлдашларын тагын чишмәгә туктатты. Икегә бүлсәң, юл кыскара иде. Әмма каенсеңел белән Гөлҗиһан барыбер арды.

– Җиңги, мин хәзер ятакка авам, – диде Миңсылу. – Абага, капканы ач!

– Аума, кем кыз, эшең бетмәде кана. Бакчадагы кисмәктә су җылынгандыр, сәфәрдәшеңне сабынсыз гына коендыр. Сөлек ят ис яратмый.

– Вәт бәби! Юындыр, коендыр. Мин бу калын катынга хезмәткә ялланмаган ла.

– Аннары, биштәрдәге канлы үләнне агач кашык белән изәрсең, кем кыз.

– Монысы ниемә тагы?

– Шуңар ярты ыстакан кайнаган су өстәрсең, кем кыз. Сөлектән соң тәнгә сөртү кирәк.

– Бәй, сөртмәсәң тиресе бозылып черемәс әле, – дип телләшсә дә, Заретдин сеңлесе ул кушканнарны эшләп куйды.

Сәке тутырып яткан хатын, мең сөлек тешләсә дә, авыртуны тоймас иде. Ара-тирә маңгаен җыерып, нәрсәдер исенә төшереп маташты Сәмигулла кызы. Килгән мәлләрдә ул үзенең чире белән генә мәшгуль, дөньяны су басамы, җир тетриме – битараф иде. Ә хәзер бак, хәлләнә, анда да, монда да борын тыга...

– Гамбәр әби...

– Җә, нәстә?

– Әти белән әнинең каберен зиярат кыласы иде. Дога өйрәтсәң – баш очларында укыр идем.

– Атаң янды...

– Җаны янмаган ла, сөякләрен генә күмгәннәр, Гамбәр әби!

– Мәрхүмнәр рухына, каберстанга бармыйча, ызбаңда гына укысаң да, кабул була.

– Ә нишләп үзең һәр пәнҗешәмбе зират урыйсың, Гамбәр әби?

– Кем әйтте?

– Миңсылу апа шулай ди. Өрәк төсле каргалар куркытып йөри, ди.

– Миңсылу үзе өрәк! – диде карчык һәм аягы белән сәке астын «капшады». Каядыр сынык себерке сабы ауный, шуны тәрәзәдән генә ишегалдында туңкаеп бәрәңге әрчегән каенсеңлесенә очырмакчы иде, туенган сөлекләр хатынның тәненнән куба башлады.

– Зиратта сез эзләгән – сезнеке тегел, – дип мыгырдана-мыгырдана, җәймәгә коелган бөҗәкләрне чүпләгәндә, кинәт кенә йөрәк чәнечте. Моңарчы сиздерми иде, димәк, хәбәр килә, хәбәр... Ерактан, ерактан... Даладан да кебек... Кайда соң теге кыз бала? Нишләп ул җил белән куышып уйнамый?! Нишләп аны беркем дә чакырмый?

– Үлмә-ә-әс!

– Гамбәр әби, торыйммы? – диде хатын.

– Жук, ят, балакаем. – Карчык аны чәченнән сыйпады. – Миңсылу, дим, син, кем кыз, дим. Канлы үлән суы белән Гөлҗиһанның тәнендәге яраларын киптергәч, баллы су эчерт. Кан тамырлары киңәйсен. Раббым, шифасы синнән, тик синнән генә, Раббым. Бәндәңне үзең саулыкка тиендер. Мин мәчет тирәсен караштырганда, шаять, бәрәңге боламыгы да пешәр. – Ишектән кергән каенсеңлесенең дә ул йомшак кына аркасыннан чәбәкләде. – Себерке сабы гына телеңнән тыймас шул, кем кыз.

«Һы, янәсе мәчет тирәсен караштыра. Сукмак димәсәң – хәтере калыр, ерып үтәрлек түгел, агач-куак белән капланган. Йа кодрәтле Затым! Гомер юлым чытырман да чытырман иде. Мин фәкать синең ярдәмең белән генә тереклек иттем. Сиңа табындым, сиңа сыендым. Туганда ук фәрештәләр өммәтеннән идем, җиргә иңгәч, ике канатым да пычракка буялды... Үч мине каралтты, үч, Кодрәтле Затым!»

...Беркичне Гамбәрнең тәрәзәсен шакыдылар. Ул узгынчыларга ияләнгән иде инде: йә су сорыйлар, йә адаштык, диләр. Тик бу төнге кунак авыл кешесе иде. Сәләмәсе җилдә җилфердәгән бакча карачкысы кебек ир өйалды нүешенә чүгәләде.

– Туңдым, Гамбәр апай!

– Син бит Газизҗан? – диде хатын. – Төрмәдә идең бит син. Качтыңмы?

– Ике ай элек үк инде, Гамбәр апай. Айтуганда этем дә белми. Колхузның өч атын урлаган өчен биш елга таш капчыкка яптылар, паражитлар! Күп чәпәделәр, паражитлар. Мине аучы Сәмигулла үзендә яшереп асрый. Өстемдә аның күлмәк-ыштаны. Без Сәмигулла белән төскә-биткә дә охшаш, дөресме, Гамбәр апай? Син дә, бәрәч, элгәрегә күршем дигәнсеңдер, дөресме?

– Төрмәңә кайт, зур бәладән котылырсың, Газизҗан.

– Тү-тү, Гамбәр апай! Миңа монда рәхәтрәк! Күсәге белән кабан дуңгызы ите кимереп, кикереп кенә яшим мин. Ашау – байдан, үлем – Ходайдан. Сәмигулла нәрсәдер болгата түлке. Аның капкасына кеше-фәлән бәрелми, тыныч иде, ну кичә ике урыс килде. Идән астында тыңлап ятам, нәрсәдер таптыралар Сәмигулладан. Сундук та сундук, диләр. Үтерәбез, скутина, диләр. Син җиде кат җир астындагы хикмәтләрне күрәсең, ди, Гамбәр апай, карале, нинди сандык икән ул, ди, аңа нәмәстә төягәннәр икән?

– Башымны катырма, үзеннән сора, Газизҗан энем.

– Әйтер ди сиңа! Ике көпшәле мылтык сатып алган, тиле сымак шуның белән сүләшә. Зур акча түләдем сиңа, малай, ди.

«Төрмә чыпчыгы»н Гамбәр куып җибәрде. Язмышлар төялгән арба көн саен аның капка төбендә туктала, көн саен аннан кемдер чирен, кемдер аһ-зарын, кемдер күз яшен, ә кемдер чүп-чарын түгә, аларның барысына да илтифат итсәң – акылдан язарга мөмкин иде. Ә бит Газизҗанның гозере аны сагайтырга тиеш иде. Чөнки шул ук төндә Сәмигулланың йорты янды. Кеше рәнҗеше түшәп корылган нигездә кайчандыр бер ут үрлисе мәгълүм иде. Янгында хуҗа үзе дә кисәүгә әйләнгән, диделәр. Авыл халкы ялгышты: Сәмигулла исән иде. Өч көннән соң хатын ябык мәчеткә барды. Сөрелгән кыр кебек кап-кара җир җанны өшетә иде. Ул сөенмәде. «Илаһым, зинһар, начар уй-теләкләрдән күңелемне чистарт», – диде. Тик бу теләк ихлас түгел, аны үч каралта иде. Мәчет артындагы куерып үскән куаклыкта үлеп-бетеп яткан «кисәү»не Гамбәр башта төрмә качкыны Газизҗан белән бутады. Ир бәндәсен, әйтерсең, кызган тимер белән өткәннәр, иягенә кадәр битенең тиресе суелган, керфеге-кашы, чәче өтелгән, борын ямьшәеп, ирененә салынган иде.

– Бәладән котылырсың, төрмәңә кайт, димәдеммени, и адәм! – диде Гамбәр. «Авыл хуҗасы Мирхәйдәргә әйтәсе булыр, бүлнискә илтсен», – дигән уй кызгану хисе белән алышынды: миһербансыз блач егетне төрмәгә озаттырачак! Газизҗан бала гына иде әле, бервакыт хатын, аягы таеп, сулы чокырга егылгач, малай көчәнә-көчәнә аны тартып чыгарган иде. Энә очы кадәр генә яхшылык эшләсәләр, син аңа тау хәтле изгелек белән җавап бир!

Гамбәр, мәчет ишегенең такталарын каерып, «тере мәет»не эчкә сөйрәде. Монда аулак, кеше йөрми, ә качышлы уйнаган бала-чаганы әби-әниләре: «Заретдиннарның иске йортында җен-пәри мыжлый», – дип куркыта иде. Хатын көн дә килеп «кисәү»нең йөзенә үлән суы бөркеде, телемләп чи бәрәңге

япты. Ниһаять, мәрткә чумган Газизҗан «ы-ы» дип ыңгырашып, керфексез күзен ачты... Түшәме ишелдемени, Гамбәр ишеккә ташланды. «Тере мәет» – Газизҗан түгел, «тере мәет» – Сәмигулла иде...

Хатын аңа ләгънәт укымады, юк, укымады, исән калуына гына шаккатты. Кабахәт җанны күкләр дә кабул итмәгән иде.

– Ишет, мин сине таң белән үләт базына ыргытам, – диде ул. – Ишет, мөртәт!

Ләкин иртән Сәмигулланың «су, су» дип инәлүе хәлне үзгәртеп куйды. Үлгәндә кешенең иренен чылатмасаң – гөнаһ. Хатын «кисәү»нең авызына су тамызды, тегесе теле белән ялаган саен ыңгырашты. Имансыз! Киек-җанварларны яралагач, алар да тән авыртуына түзәлмичә бәргәләнгәндер.

Һай, мөртәтне үләт базына ыргытмады шул Гамбәр. Нәфрәт – иң көчле хис, диләр. Кайда иде соң ул көч, кайда, Аллаһым?!

Менә Сәмигулланың теле дә кыймылдады:

– Күрше апа, мине агулап үтер, җәме?

– Җан алмак – Газраил эше, – диде белекче. – Савыккач – үз ишең – Мирхәйдәргә дөресен сүлә. Миндә Газизҗан качып яшәде, зиратта аның кабере, диярсең!

Әле кайчан гына дөньяның сыртына атланып чапкан иблис, менә, койрыгы тәбәгә кысылган тычкан кебек чиный.

– Газизҗан идән астында иде, янганмыни? Мине бит урындыкка бәйләп ике башкисәр җәзалады, күрше апа.

– Сандык өченме?

– Син каян беләсең, күрше апа?! Әһе, знамы беләсең, калдун бит син. Шушы башкисәр урыслар төртте ызба белән абзар-курага. Тучны блач Мирхәйдәр котыртты аларны! Тагын этләрне өстерәчәк. Лутчы синең кулыңнан үләм, күрше апа! Агула мине! Янә башкисәрләргә эләксәм, турам-турам тураклый тегеләр! Мәскәүдән алар, тучны! Гөлҗиһаным бит анда. Кызым ни хәлдә икән? Арчиныч кабахәт, җир йотсын үзен. А-а-а!

Сәмигулла аңын җуйды. Күз алдында адәм икенче затка әверелде. Канәчкеч бәндәдән юаш, мескен ир-ат туды. Соңгысының йөрәген курку камаган иде. Курку! «Тегеләр» эзләп табар да, сандык өчен икенче мәртәбә тереләй яндырыр. «Кызым исән микән? Үтермәделәр микән?» Үтермәделәр. Тик синең өчен ул дөньяда юк инде, юаш Сәмигулла! Туган якларына бер кайтыр Гөлҗиһанның, әмма аның да эти диярлек кешесе «исән» булмас... Минем үчем бу, минем үчем!!!

– Синең агуың үзеңдә, – диде хатын. – Чаян күек тәнеңә чак, Сәмүш. Әйе, моннан ары син – Сәмүш, бәндәм.

Ирнең кутырлап төзәлгән бите мүкләнгән агач кайрысы төсле ямьсез, өстәвенә сул күзе йомылыр-йомылмас калган, әгәр сине клуб сәхнәсенә менгезеп: «Бу кем?» – дисәң, авылдашлары танымас иде. Аның сүгенә-сүгенә карлыккан тавышына хәтле нечкәрде. Салам кисәге белән кәҗә сөте суырта-суырта хәлләндергәч, Гамбәр «кисәү»не әкрен генә атлатып утарга алып китте. Атасы белән яшьтән үк бергә яшәгән Рәшит күршесенең төсен-битен хәтерләмәгәндер, хәер, ул аңа күз дә салмады, чөнки ашыга иде.

– Әни, йорт сиңа атап төзелгән, ул синең карамакта, кемне кундырсаң да – миңа барыбер, – диде.

Сәмигулла-Сәмүш, мирас төсле, улыннан соң оныгына күчте. Ызбага «оялаган» авыру агайның чыгышы белән Фәрит тә кызыксынмады. Зур әнисе яшәтә икән, яшәсен! Заретдин чылбырындагы ир-ат эре иде, вакланмый иде. Гамбәр дә серен эчендә саклап картайды. Һәй, чамасыз авыр үч йөге иде ул, чамасыз авыр... Җан талкынды, йөрәк ите ашалды, ә кортка барыбер йөген бушатмады...

## 15

– Саумысез, каеннар, саумысез, усаклар? Мин урман кызы-ы-ы!

Яфраклар лепелт-лепелт шаулашты, гүя алар хатынның сәламен аңа да тапшыралар иде. Бәлки, ул ишетер... Түзә, Гөлҗиһан, түзә, ләкин түземлекнең дә бер чиге бар! Карчык тыйган саен, эчтән әрнү кузгала. Йә, Фәриттән качты, ди. Урман егетеннән танытмады, ди. Ә менә балачак хатирәләре җанын айкаганда, тиле йөрәк хис өермәсе кузгатса – нишләргә? Сакчы Миңсылу арып йокыга түнгәч, Гөлҗиһан урманга тайды. Кортка, гадәттә, мәчет тирәсендә озак юана иде. Ул арада хатын муенсасын эзләр, бәлки... бәлки, аны да очратыр. О, тыелган алмага ымсынсаң, бик тиз җиргә сөрерләр! Гамбәр кунагымны җәннәтемдә рәхәт чиктерәм дип шәбәрә ләбаса! Әмма «җәннәт»тә аяк-кул богаулы иде шул. Хәер, хатын Мәскәүдә дә иреккә туенмады. Акча бөтен ябык ишекләрне ачтырса да, ул аркасын чәнчегән «сыңар күз»нең карашын һәрдаим тоеп яшәде. Хак, байлыкка күмгән туган абыйсына сеңелкәш рәхмәт кенә әйтергә тиеш иде. Аның өчен кайгырта ла! Тик бу кайгырту майлы калҗа кебек үтләтә иде. Томана Сәйфи белән дә ул гына көчләп кавыштырды.

– Син – бизнес леди, сиңа эт сымак тугры ир кирәк, Джиган. – «Сыңар күз» телгә оста иде. – Фас дип өстерү белән, дошманыңның ботын умырсын! Өр, дисәң – өрсен, пос, дисәң – поссын. Вот так! Мәхәббәтме? Сафсата! Яратасыңмы, җирәнәсеңме? – анысы миңа караңгы. Акча – елан, хисләнгән хатын-кыз кулыннан тиз шуа. Салкын акыл белән эш йөрт, Джиган. Только бер киңәш: этне бәйдән ычкындырма! Финанс мәсьәләләренә катнаштырма! Только сөяктән генә өзмә, тыгынсын!

Туган абый нотык сөйләгәндә, Гөлҗиһан бүлдерми иде. Ярамый! Ләкин бу юлысы ризасыз гына:

– Сезнең Сәйфиегез бигрәк котсыз, – диде.

– Ха-ха! Котсыз икән! Тырнак буяп, чәчен майлап йөргән «зәңгәрләр» ямьлеме? Шундыйлар белән парлашыр идеңме, Джиган? Һо, башсыз кыз! Озын сүзнең кыскасы: иртәгә Сәйфи белән загста язылышасыз! Кич белән туй!

«Кияү егете»н керттеләр. Күлмәк якасы бөгәрләнгән, корсак турысында сәдәфе каптырылмаган, ә чәче, җил тузгыткан сыман төрле якка тырпайган егет, чынлап та, тугры эт иде, ул – гәүдәсен кечерәйтеп, күзен яртылаш кысып, хуҗасын сәламләде:

– Ватый мин, Радий Арсиныч. Нәстә боерасыз, сразы үтим!

– Мондарак кил! Таныш, бу – синең хатының, Сәйфи!

– Минем катын?! – Егет балчык изгән сыман урынында таптанды. – Көләсез, ватый, Радий Арсиныч. Джиган Самуиловна – асылбикә, ә без – кара мужик.

– Кем сине агартырга җыена, холоп! Буялган килеш тор!

– Хи-хи, Радий Арсиныч, шаяртмыйсың ахры. Джиган чибәр үзе ни ди соң? – Сәйфи кызга карап ыржайды.

– Сине өзелеп сөям, ди, дуңгыз! Әгәр тагын мыркылдасаң – маңгаеңа ядрә чәпим!

– Гафу, гафу, хуҗам! Сезнең сүз – закон! Кунаклар эсписеген төзикме суң?

– Төзегез! Без өчәү – мин, син, Джиган.

Өч кешелек туй дөнья тарихында булды микән? Туган абый тулы бер ресторан алган иде. Зур концертлар залы монда күченгәнмени, аларга иллеләп җырчы, биюче, цирк артистлары шоу-тамаша күрсәтте. Яшь кәләш:

– Дусларыма нәрсә диярмен инде, Ходаем? Берсен дә чакырмадык, – дигәч, «хуҗа», һәр сүзенә диярлек басым ясап:

– Таныш-белешләр, Джиган! Таныш-белешләр! Дус юк ул, дошман белән көндәшләр генә бар. Син шуларны бәйрәмеңдә биетер идеңме? – диде.

«Нинди бәйрәм?! Сез миңа матәм көне оештырдыгыз!» – дип тузыныр гына идең, филгә тибеп кенә кырмыска җиңәмени!

Күңелсез мәҗлес тәмамлангач, туган абый өстәлгә ачкыч бәйләме ташлады.

– Миннән туй бүләге! Шәһәр читендәге коттедж сезнеке. Тату гына яшәгез. Кстати, мин берникадәр вакытка югалам әле, яшьләр.

«Югалу» йә атна-ун көнгә, иң күбе – берәр айга сузылыр дигән иде Гөлҗиһан, тик ул ялгышты: туганы шуннан бирле гаип. Телефоны да сүнгән...

– Ватый, табышмак! Радий Арсиныч кайда икән? – диде Сәйфи. – Наверняка безне айдан гына күзәтәдер, шайтан. Памушниклары Замир, Володькалар белән без пачти ахирләр иек, аларны да җир җытты шту ли?

Еллар буе хуҗа үзенең «тугры хезмәтчесе»нә күрсәтмәләр бирми икән, димәк, ул аның белән арасын өзгән дип уйлады яшь хатын. Сәйфинең дә үз-үзен тотышы үзгәрде. Элек ялагайланып койрык болгаган «эт» калдыкпостык сөяккә генә риза түгел иде инде. Гөлҗиһан, билгеле, аңа артык акча исе иснәтмәде. Дындык ирнең финанс документларына теше дә үтмәс иде. Әмма идарә дилбегәсен әкрен-әкрен генә үз кулына эләктерде Сәйфи. Акырубакыру буенча шәп «белгеч» иде ул, кемнедер эштән куу, кемнеңдер хезмәт хакын кисү аның вәкаләтендә иде. Гөлҗиһан, туганының киңәшен истә тотып, «эт»не бәйдән ычкындырмас иде дә, котылгысыз рәвештә чир якынлашты. Гәүдәсен май басып, килеш-килбәте ямьсезләнгән хатын дөньяга күренергә ояла башлады. «Әле монысы баласы гына, анасы алда икән», симерү, соңгы ноктасына җитеп, урынга еккач, Сәйфи үзен бердәнбер милек хуҗасы итеп хис иткән әнә. «Нindидер кәгазьләр әзерли», – ди Минап абзый. Әйдә, әзерләсен!

– Син ниткән җәһүдә?! Син алкаш Сәмигулла кызы Гөлҗиһан икән! – диде берсендә Сәйфи. Мондый мәгълүматны, мөгаен, туган абыйсының «памушниклары» саткандыр. – Паспортың җалган синең, симезкәем. Хафаланма, полициягә җәвит итмим, фчүтеки син минем катын. Үзем дә мактанам ватый дусларга, мин – мишәр, катын – шимбә, дим. Ну малай, көнләшәләр!

«Симергән эт» өстенә ташланганда, туган абыйсын сагынды Гөлҗиһан. Даими күзәтүе белән интектерсә дә, ул аны җил-яңгырдан ышыклаган икән. Сикертер иде хәзер Сәйфине, сикертер иде! Сыңар күзен алартса да, ир бәндәсе чалбар төбен юешләтер иде. Шулай ук башбаштак сеңлесен дә акылга утыртыр иде. «Авылга кайтма!» – дип кисәтте ул, ә хатын колагына да элмәде: кайтты. Нәфрәт Гөлҗиһанның бәгырен өтәргә тиеш иде. Авылдашлар туган йортын яндырган... Кайсының битенә төкерәсең, ә? Айтуган дигән авыл юк, бердәнбер тере җан – Гамбәр карчык... Ул да хатын кебек үк билгесезлектә яши: шырпы сызган бәдбәхет аңа нәмәгълүм. Белгертмә, Гөлҗиһан, зинһар, белгертмә! Сәмигулла исемен, никадәр якын булса да, казып чокырга күм!

– ...Мин – урман кызы-ы-ы! – Хатын шомлы уйларыннан арынырга теләде. – Мин урман кызы-ы-ы!

Урман аңа усал гына җавап бирде:

– Булмагаең ни! Кая болай чаптырасың, азгын бия?

Миңсылу икән, уянган, артыннан куа. Кушаматка ифрат баеды Гөлҗиһан, көн саен яңасын өстәп кенә торалар. Симезбикә, абага, азгын бия... Ә ул барыбер урман кызы!

– Миңсылу апа, икәүләшеп һава сулыйк әле!

– Һава кайда да бертөсле! Син яхшы чакта борыл. Иту җиңги үтерә үзеңне. Сөлектән соң кеше хәлсезләнә.

– Ә мин, киресенчә, җиңеләйдем, Миңсылу апа.

– Акылга җиңеләйгәнсең ахры. Бугазыңны ертып хет көн-төн акыр, сиңа кем дә «ау-у» димәс. Борыл, диләр!

Кызулык белән генә «сәяхәт»кә чыккан икән Гөлҗиһан, кичкә табан и күңел болганды, и күңел болганды... Кысылып кечерәйгән ашказанында нинди тәгам ди, карчык бит аның ризыгын бөтенләй чикләгән иде. «Сөлектән агуландым» дигән шик аяк табанын яндырып төште. Әнә, Миңсылу нәрсә ди, бер хатын сөлек ярасын кашып үлекләткән дә, туганнары, син бинабат, дип чүт кенә җиңгине кыйнамаган, ди. Ит яхшылык, көт яманлык, саклану чарасын хаста үзе күрергә тиеш, ди. Тамагына сөяк кадалгандай укшыган хатынга карчык:

– Косыгыңны коскың, – диде.

– Дару бир! – Гөлҗиһанга дөньясы агуланган кебек иде.

– Нинди дару?

– Соң, Гамбәр әби, сездә костыруга каршы дару бардыр бит инде? Цивилизация гөрләгән чорда яшисең лә. Сәдәф инде сезнеңчә, сәдәф!

– Ниткән дару? Коскың! Чистарыну вакытыңны сузма! Эчегезгә былчырак җыела, адәмнәр! Тәнегезне юып кына пакьләнмәссез, адәмнәр!

Хатын:

– Миңа сөлек ярамады-ы, – дип ыхылдаган иде, белекче күкләр күкрәтте:

– Синдә чирле кан иде, бәндә баласы! Алар үзләре агу суырды. Мин алардан кичерү сорадым намаз арты!

Аннары жу-жу баш шаулады. Аның авыртуыннан күз пыяласы чатный иде. Монысын да карчык тиз генә ибенә кереште. Сөлге белән башын урагач, уклау кыстырып әкрен генә уңга-сулга боргалады.

– Баш чүмечең зурайган, – диде. – Илаһым, кулыма шифаңны иңдер, Илаһым... Адәм яралганда, аның күңел казаны төрледән-төрле булыр: берәүсенең алтыннан, берәүсенең көмештән, берәүсенең җиздән, берәүсенең бакырдан, берәүсенең тимердән. Изгелек, мәрхәмәтлелек, юмартлык тимерне дә алтынга әүештерер, яман уй, хөсетлек, көнчелек, комсызлык алтын савытны да күгәртер дия иде Сабирҗан остаз.

– Миндә... миндә нindirәк казан икән, Гамбәр әби, – диде Гөлҗиһан, кыяр-кыймас кына. Уклау бер дәваласа, бер сыртыңны да кашыр! Әнә карчык йөзгә төрләнә.

– Һе, ул иллә дә чын алтын димә! Бордарың малына кызыктың ла.

– Кем ул бордар, Гамбәр әби?

– Туганың инде, туганың! – Миңсылу аның беләгән чеметте. – И шәһәр сарыгы!

Баш авыртуын әллә уклау, әллә «бордар» бастырды: хатын «терелде»: чү, хәзер Радий Арсеньевич сеңелкәшкә кирәкме соң? Бу бик четерекле сорау һәм аңа төгәл генә җавап та юк иде.

Сәйфинең арт сабагын укытыр өчен генә туган абыйсын сагына түгелмени Гөлҗиһан?

– Дөнья кызык ул, Гамбәр әби: бүре оясына ояласаң – бүре кебек улаттыра. Бүген көчленеке – замана.

– Үлем сукмагында әммәгез дә тигезләшә. Газраил фәрештә алтын-көмешкә алданмас. Аңар бай нә дә, ярлы нә. Ахырзаманда имансызларның хәсрәте артыр, ди китап.

– И-и, синең эшең гел куркытуда инде, җиңги. – Миңсылу уклау очына сөлге бәйләп өскә күтәрде. – Вәт шулай, байраклар болгап җәннәтләргә барып керсәң иде, Алла кушып. Утын әрдәнәседәй өеп яндыртмас әле Аллаһыбыз. Без бит аның газизләре, әйеме, Абага?

Карчык каенсеңлесенә ачуланмады. Әйдә, сабый бала, шаяр инде дигәндәй, каш астыннан гына карап торды. Ул, кызуы сүрелгән көзге кояш төсле, сүлпәнәйгән иде.

«Уйнап» туйгач, Миңсылу кичке ашау тәртибен барлады.

– Бәрәңге быгыр-быгыр кайный, җиңги.

– Әз генә май җилпеп боламык яса, кем кыз.

– Абагага нәстә ашатабыз, җиңги?

Гөлҗиһанга коры кашык кына эләкте.

– Ул җиде тамыр суы эчәр, кем кыз.

– Шул гынамы, җиңги?

– Шул гына, кем кыз!

– И Ходаем, тиздән һава белән генә тукланыр инде, бичара, – дип, Миңсылу әллә кызганды, әллә үртәде.

– Ул тук, – диде карчык, канәгать тавыш белән.

Чын мәгәр, ризык теләнеп ашказаны талкымый, әйтерсең, Гөлҗиһан сыйнигъмәттән сыгылган табын яныннан әле генә кузгалган иде. Менә өши-туңа, шунысы әкәмәт. Җәйге тымытык кич ләбаса. Беләгенә хәтта каз тәне чыкты. Кортка:

– Калтыравык эчендә, хәзер, кем кыз, җылы төнәтмә эчергәч, җылынырсың, иншә Аллаһ, – диде.

Вакыт-вакыт канга тоз салса да, аңа Миңсылу белән мөнәсәбәтләрне көйләргә туры килә иде. Чемодандагы һәркайсы берәр кат киелгән күлмәкләрне, фасоны бозылмасын өчен, химчисткага тапшырасы иде. Каенсеңел бистә дигәннәрен мактый, ул нәкъ шәһәр кебек, ди, йортлары таш, кибетләре бихисап, ди. Якында гына тормыш гөрли алайса.

Буйга ят, дисәң, аркылыга сузылган киребеткән Миңсылу аның үтенечен кире какмады.

– Ие, бистәдә аю тиресен дә чистарталар, гөлкәем, – диде. – Таң атсын әле, күз күрер тагы.

Иртән киребеткән су кайнарлатты да эскәмиягә ләгән куйды:

– Вәт сиңа пырачка, гөлкәем. Әйдә, керләреңне жу!

– Саташтың мәллә, Миңсылу апа?! Син бит бистәгә барабыз, дидең.

– Кит аннан! Барабыз, дидеммени? Күз күрер, дидем шикелле.

– Минем киемнәрем бик затлы бит, Миңсылу апа. Су тидерсәң, бозыла! – Гөлҗиһан кулындагы төенчеген чиште. – Менә бу күлмәкне Париждагы модельер теккән иде, монысы – Зайцев салонынннан. Мин аларны яратып кия идем. Киң инде болар, таза чагымдагы, тарайтырга кирәк. Ябыгам бит, Алла бирсә.

– Хи, черегән агачка ясалма яфрак ябештергән төсле икән.

– Нинди «черегән агач», Миңсылу апа?

– Син ул, калын катын, син! Тыштан ялтырыйсың, эчтән калтырыйсың, бахыркаем.

Гөлҗиһан үпкәләмәде, чөнки Миңсылу хаклы иде. Икеләтә авыру иде ул, аңа әле мал чире дә йоккан иде.

– Мәйлең, керләрне кул белән уам. Порошок бармы, Миңсылу апа?

– Каян килеп?

– Сабын бир!

– Сабын да жук! – Каенсеңел мунча миченнән соскыч белән көл көрәп чиләккә томырды. – Селте суы, гөлкәем. Берчәк тонсын әле. Пырашук ише генәме! Пычрагын сыгып ала. Җиңги борын-борыннан шулай жуган. Әнәгенәк,

сөлге-тастымаллары ап-ак. Бистә дигәч тә, анда кем безне илтә, ди. Арбага җиңгинең җеннәрен җиксәк кенә, гөлкәем.

«Мин – гап-гади авыл кызы. Нишләдем соң, ә? – Хатын күлмәкләрен суга чумырды. – Чүпрәк кызганам... Гөлҗиһан белән Джиган икесе ике кеше ләбаса! Үз асылыма кайтыр идем, кайда ул могҗиза сукмагы, кайда?!»

**16**

«Мәңгелек йорт»ка шушы каһәр суккан йөк белән китсә, кертерләр, кертми ни. Тәмуг капкасын киң итеп ачарлар, чөнки гөнаһысы тар тишеккә генә сыймас. Ялган өстенә ялган! Атасы өчен кызы, кызы өчен атасы дөньяда юк, имеш. Ә кортканың хөкемдар булырга ни хакы бар?

Карчык уйларын ияртеп юлына кузгалмакчы иде, баскычта Гөлҗиһан күренде.

– Иртүк кая ашыгасың, Гамбәр әби?

– Далага, олан.

– Ул дала кайда соң? Сездә урман эчләрендә урман ла!

Йа галәмнең Раббысы! Дала, диме? Дала, ди шул... Күңелдә бөреләнгән – телдә яфрак ярган: туып-үскән илләр сагындыра. Хәтер сүрүен ертып, зәңгәр күлмәкле кыз бала кылганнар белән куыша... Тамырым белән Заретдин аймагының туфрагына беректем, дип яшәде... Яшәде... Үз-үзен алдадымы?

Ул җанына сарылган сагыштан тиз арынды.

– Кулыңның тиресе суелган, – диде. – Селте суы ашаган. Кем кыз, кайларда син?

Миңсылу шымчы кебек койма буенда тыңлана иде:

– Әү, җиңги?

– Чи бәрәңге телеме яп монауның ярасына. Мәгәр аны эшкә кушсаң, азагын уйлап куш.

– Әй, төзәлерсәнә. – Гөлҗиһан, бармакларын тырпайтып, өф-өф өрде. – Мин дә синең белән барам, Гамбәр әби.

Карчык кырыс кына:

– Кая? – диде.

– Соң, шунда, синең «далаңа!» Утарның күчермә мәгънәсе бит инде ул! Аны миңа Фәрит бер тапкыр күрсәткән иде. Курыкма, мин үземне танытмам, юлдашың итеп кенә иярт, Гамбәр әби.

«Бу әрсез катынны кара син! Утар, ди. Танытмам, ди. Йа Аллаһым, синең әмерең белән генә гыйшык дәрьясын буар Гамбәр, вәләкин ул ташый икән, мин – колың, йомычка күек, дулкын өстендә генә чайкалырмын...»

– Миңа койрык нәмәстәгә, Сәмигулла кызы? Юлда һәрчак озатучым – Газиз Затым бар.

– Хи-хи, Абага! Җиңгигә синең сымак ташбака ниткән юлдаш ди! – Миңсылу яулык очы белән авызын ябып көлде. – Безнең әбиебез яшь поши баласы төсле юырта урманда. Ну түлке, җиңги, берчәк тизлегеңне киметсәң дә ярый: балалаган әнкә кабан очрамагае.

– Аллаһ язганны гына күрә адәм. Сез, кем кыз, Гөлҗиһанның кулын имләгәч, икәү утын кисегез. Пычкы-пила сарайда, нүешкә сүәгән.

– Син нәстә, җиңги! Энекәш ел саен трактор белән ташый кана! Бу калын катынны нечкәртер өчен бүтән җәза беткәнмени? Артыңнан чаптыр! – дип чәрелдәгән Миңсылуга ул галушын салып очырмакчы иде, иелгәндә бил сөяге черт итте. Ходай кисәтә: гел усаллык белән җиңмә, ди.

– Кисәсез дигәч, кисәсез, кем кыз! – диде карчык, билен угалап. – Каршы дәшмә!

– Дәшмим лә, дәшмим. Абага әбәттә ни-нәстә чемченер икән? Әйтеп калдыр, җиңги.

– Кара әпәй телеменә ярты кашык көнбагар мае тамыз. Шул анең тәгаме, кем кыз.

– Хи-хи, сыерым ач торырга өйрәнгәч кенә җан тәслим кылды, дигән ди бер агай. Хуп, җиңги.

Ниятсез эшкә шайтан аяк чала, диләр, ул оныкъ белән катгыян хәл ителәчәк мәсьәләне төнлә үк кат-кат уй иләгеннән иләде. Бүтән сузасы түгел... Юл уңае кортка, Аллаһның гүзәл исемнәрен атап, туксан тугыз каен яфрагы өзде. Кайнар суда изрәтеп эчерсә – хатынның эчендәге былчырагы тышка куылыр. Тырышу – бәндәдән, нәтиҗәсе – Кодрәт иясеннән. Сәмигулла нәселенә никадәр генә үч тотса да, ул кыз баланы саулыкка тиендерергә тиеш. Күк идарәчесенең фәрманы шундый...

Биш адымга соңарса, Фәрит белән аймылыш булалар иде, шөкер, зур тимер капка янында очраштылар.

– Зур әни, җир астында метро бар мәллә? – дип, оныкъ аны кочагына кысты.

– И-и, бәләкәй дә инде син, Зур әни.

– Буйда тегел, акылда хикмәт. Иртәнең иртәләрендә кайларга канат җилпедең, бәбкәчем?

– Аргы як урман кырыендагы юлны киңәйтәбез, Зур әни. Боерса, җәренгә синең авылыңны да агач коллыгыннан коткарам. Куакларны тапатам – әрчетәм, кыскасы.

Яшьлек – ялтырый, картлык – калтырый икән... Кемдер дөнья колачлаганда, кемдер соңгы гомер җебен төйни...

– Берочтан иске мәчетеңне дә төзекләндерәм, Зур әни. Сиңа әйтмәдем генә, мин аны ачтым бит. Идәненең аратасы черемәгән, нигезенә сап-сары салам түшәлгән. Бабайның зирәклегенә шаккаттым!

– Бабаң андый нәстәләрдән чирканыр иде, туганыбыз Мифтахетдин абзый җәйдерде саламны. Мәчеткә бүтәнчә кагылма син, бәбкәчем. Минем хатамдыр ул, бәлкем. Адәм баласы үз күңелендә манара торгызсын да, иман оеткысы әүвәл шунда салынсын икән. Кайчак ялгышабыз шул, ялгышабыз, бәбкәчем. Монысын куй әле, синең – минем Аллаһ каршында бурычыбыз үтәлмәгән, бакчи. Тыңлап бакчы, бәбкәчем. Адәмнең гомер кибәне өч кисәктән гыйбарәт: туды исә – берсен, насыйбын ярәште исә икенчесен өя. Инде дә фанилык белән хушлашканда, икесен дә бергә кушып, актыккысын очлый.

– Зур әни, әйдәле, машинага кер, йомшак утыргычта хәл җый. Соңгы вакытта әллә нинди аңлаешсыз телдә сөйләшәсең.

– Телем – ил теле, бәбкәчем. Урманыгыз торып торыр, бистәгә – яучы абыстайларга барабыз.

Фәрит рульгә авышып көлде дә:

– Синдә һаман кысыр хәсрәт икән, Зур әни, – диде. – Мине өйләндерәсең килә инде, ә?

– Аллаһ парлыларны сөя, бәбкәчем. Башлы-күзле итсәм – тынычлап китәр идем.

– Син гел каядыр китәм, дисең. Әйт кенә, үзем илтеп куям.

– Көлмә, бәбкәчем. Миграҗ сәфәренә кузгалыр сәгатьләрем якын, бә-әк якын. Сез, онытасыз, бәбкәчем: Илаһка кире кайтарылу бар.

Карчык кызулык белән оныгын битәрләп ташламакчы иде дә, сабыраеп калды: егетнең күзе сагышлы иде. Моның йөрәген кемнәр ачкыч белән бикләде икән? Йә, дивана кортка! Белмәгән кыланма... Ачкыч хуҗасы синең ызбаңда яши! Ә син барыбер торының өчен көрәш! Ике арада тау кебек калык!

– Сиңа иманлы йорттан димләр абыстай, бәбкәчем. Нәсел-нәсәбен тикшереп, бәбкәчем.

– Зур әни, мине юл төзүчеләр көтә. Әйдә, кичкырын сезгә сугылам. Иркенләп сөйләшербез.

– Сугылма! – диде кортка һәм шушы кискенлеге белән Фәриткә шик уты үрләтте:

– Туктале, Зур әни, әллә нинди катлаулы табышмакка әйләндең әле син. Элек сирәк киләсең, дия идең, хәзер йортыңа китермәс өчен үрсәләнәсең. Синдә кем ул?

– Кем дә тегел. Бер чирле кыз-катын.

Онык, көлемсерәп:

– Усалдыр, әйеме? Мине тешләр инде, әйеме, Зур әни? – диде.

«И барча галәмнең Раббысы, син үзең шаһит, онык мине ирештерә, чын мәгәр. Аңарда минем каным, минем сизгерлегем, ул да карт әбисе күек җиденче тоем белән тоядыр».

– Хаста кыз-катын чит-җат ирләрдән кыенсыныр, бәбкәчем.

– Әй беркатлы да бит син, Зур әни! Замана хатыннары әрсез, алар беркемнән дә оялмый.

– Шуңа хафалана бит Зур әнкәң! Бәдбәхет нәсел баласы белән бәйләнеп, йөрәк маең сызмасын, дим, бәбкәчем.

Ник ерактан гына суктырасың кортка?! «Ызбамда Сәмигулла атлы бәндәнең кызын асрыйм, син – малай актыгы, аның белән бутала күрмә, ризалыгым юк», – дип ачыктан-ачык әйт!

– Тынычлан, Зур әни. Киленең асыл кеше булыр. Мин бит аны гомерем буе эзлим, – диде онык. – Син хәзер нишлисең? Егетләр кунак йортына озатсынмы? Чәй эчәрсең, ял итәрсең.

– Җук, бәбкәчем. Эшем хәттин күп.

Фәрит аны машинадан күтәреп төшерде. Карчык алъяпкыч кесәсен капшады. Әйе, эше хәттин күп шул. Менә каен яфракларыннан төнәтмә ясыйсы... Өстендә торып дәваласа, бәлкем, Сәмигулла кызын ташкаласына кайтарып җибәрер. Ярабби, анда тиклем аларны аслан (һич тә!) кавыштырма-а!

Ул урман сукмагына борылмакчы иде, капка сакчысы эндәште:

– Әби, әби, әнә теге карт сиңа кул болгый!

Һай, бүген кортка бер генә дә «тере мәет» белән көрешергә теләми, эчендә тәгәрәгән ут йомгагы җанын көйдерә иде. Оныкны вәгазьләрлек түгел... Ни хәлләр итәргә икән, бар Галәмнең Раббысы?!

– Ни йомыш, Сәмүш? – диде ул, ачуланып. – Нишләп җулымны бүләсең? Тамагың ачмы?

– Тук, күрше апа, тук. Фәритнең кешеләре ризыктан өзми.

Ябык Сәмигулла кер бавында киптергән чүпрәк кебек җилферди иде, карчык аны баскычка табан этәрде. – Утыр! Җә аварсың, җилбәгәй. Сүзең ни?

– Сүзем озын, күрше апа.

– Кыскарт!

– Үлем турында уйлата никтер... Төннәрен аерата шомландыра, күрше апа.

«Үлем турында уйлата, имеш. Иман белән сугарылган адәм баласы ахирәткә шатлык-сөенеч белән күченә. Син, шайтан таягы, тикмәгә генә шомланмыйсың, син ил-көнне хәтсез җылаткан кабих идең».

– Фанилыкта нә үкенечләрең кала, Сәмүш?

– Кыз... кызым Гөлҗиһан кайларда күмелде икән, күрше апа? Күземнең чите

белән генә каберен күрәсе ие. Болай нәстә инде... – Ир җиңе белән җимерек борынын ышкыды. – Шымытыр калсынмы миннән. Анда үзең белән нәстә дә апкитмисең. Кулың буш була.

– Кулың буш та, җан сандыгың тулы, – диде карчык. Ул күңеленнән генә Сәмигулланың бәгырен теләрдәй җөмләләр төзеде. Тик сүз оешмас борын чәчелә дә чәчелә иде. – Дөнҗалыкта ни кылсаң – сандыгыңа шул төялер, Сәмүш.

– Көн саен маңгаемны идәнгә ора-ора синнән гафулар сорыйм, күрше апа.

– Аллаһтан сора, гөнаһ шомлыгы!

– Блач Мирхәйдәргә үпкәм зур. Ул гына акчага хирыслатты. Урыс калдыгы Арчиныччны ул апкилмәсә, ата-баба йортымда тыныч кына яшисе идем. Урман ашата ие, эһе. Блач мине урысларга... – Сәмигулла ухылдады, – ...сатты, зыбани. Ничек үлде соң үзе? Мирхәйдәр, дим? Кызыл әләмгә төреп күмгәннәрдер, шәт. Камунис ие бит, зыбани.

– Икегез дә шакшы кәнди яладыгыз, Сәмүш! Хәзер мәрхүмне яманламактамы эшең? Тфү! Күпме сикерсәгез дә, үз буегыздан ары сикертмәде Ходай. Мирхәйдәр җан бирәлмичә азаплангач, мулла дәштереп, ясин укыттылар.

– Вәт блач! Вәт зыбани.

«Кисәү»нең ачудан муен тамырлары бүлтәйде. Моның белән дустанә әңгәмә кору – мәгънәсезлек иде. Кара карга юып кына агармый!

– Хуш, Сәмүш, сиңа бүтәнчә сугыласым юк!

– Гамбәр апа, ашыкмале, сүзем бетмәде, Гамбәр апа! – «Тере мәет»нең инәлүе аркасын пешерде. – Гафу сорама, дисең дә, ничек сорамаска, йортыңа мин ут төрткән ием, Гамбәр апа.

Хәер, аркасы тиз «суынды». Бу аның өчен иске яңалык иде.

– Соңладың, Сәмүш, соңладың. Андук кем шырпы сызганын күкләр белгертте, – диде ул. – Яңа ызбаң нигезенә дә шушы шырпыңнан үзең үк чаткы чәчрәттең, Сәмүш!

– Гамбәр апа, тагын күпме гомер сәгате текелдәр, оныгыңа минем кемлегемне әйт син! Элгәреге күршебез Сәмигулла абзаң ул, диген. Фәритең мәрхәмәтле синең, мужыт ул кичерер мине?

– Юк! Син – оныгым өчен җыр
актан килгән Сәмүш!

– Рәнҗемә инде, күрше апа...

Карчык: «Миндә рәнҗү юк, миндә үч кенә», – дисә, үзенең гөнаһысы ачыла. Әгәр бизмәннәрдә үлчәсәң, нәкъ менә кортканың тәлинкәсе аска басар да әле. Йөк лә, йөк! Чамасыз авыр йөк!

Ул ял итә-итә кайтты. Аллаһы Тәгалә бу дөньяны шул тиклем матур итеп төзегән ки, ни-нәрсәгә генә баксаң да, тирә-юнь күреп туймаслык гүзәллек белән камалган иде. Агач-куаклардагы яфраклар, оста тегүче кисеп теккән кебек, һәркайсы үзенчә матур, һәркайсына яшел тукыманың йә куе, йә җете, йә ачыграк төсе сайланган иде. Чәчәкләр дә, ал сарысын, ал зәңгәрен, ал кызылын – Бөек Кодрәт иясенең камилләрдән камил иҗат эше, аларның берсенә дә төзәтмә кертерлек түгел иде. Кортка, гәрчә мең-мең тапкыр ишетсә дә, бихуш булып кошлар сайравын тыңлады. Раббымыз адәмнәргә җирдә энә очы кадәр генә җәннәтен биргән, дияр иде Сабирҗан остаз. Фанилык шундый да матурлык белән бизәлгәч, оҗмахтагы хикмәтләрне тасвирларлык кәлимә табылыр микән?

Әлеге манзарадан әсәренгән кортканың күңел төпкеленнән сагыш саркыды. Ул туып-үскән дала да үзенчә матур иде.

Далаларда актин ак кылганнар,
Сагынуларга нә чаралар кылганнар.
Чит мәмләкәт капкалары, аһ, тардыр,
Эчем-тышым тулы зардыр, –

дип моңланган карчык:

– Ләхәүлә! – диде. – Ләхәүлә! Мәлгунь шайтан аны хисләндереп, нинди җырулар җырлата!

**17**

...Энә бармагын чәнчеде, җеп чуалды... Икенче көн күлмәк тарайта, тик берсенең дә җүнләп очына чыга алмый, чөнки хуҗалыкта аның өчен генә «балалап» торган эшләрнең исәбе-хисабы юк иде. Утын кистеләр, әрдәнәгә тезделәр, урак белән кәҗәгә печән урдылар, аны таратып, кояшта киптерделәр. Бакча кырыендагы яшь куак үсентеләрен тападылар. Капчык-капчык нарат күркәсе җыеп сарайга ташыдылар. Биш ел самавыр кайнат! Карчык селте суы белән ызба юдырды. Бүрәнәләрне мунчала белән ышкый-ышкый беләкләр тала иде. Идән астындагы бәрәңге сабагын түгү, базны чистарту, кәҗә саву, мич ягу, бакчада чүп утау һәм болардан тыш кортканың кырыкмаса кырык дәвасы – мунчада тирләтүләре, үлән сулары белән коендыруы, йөзәр тапкыр бау аша сикертүләре, чирәмдә мәтәлчек аттырулары (хәрәкәт үзенә күрә дару янәсе), иллешәр сөлек салулары берни дә түгел, иң зур «җәза» чирәмнән борчак чүпләү иде. Муен ката, бил ката, аяклар дерелди. Аның ничек газаплануыннан тәм тапкан Миңсылу, белекче әйткән норманы да арттырып, ишегалдына ярты чиләк борчак сибеп җибәрә дә:

– Әйдә, тавык, рәхәтлән, – дип авыз ера иде. – Түлке чүмәшмә, тезләнмә, сыныңны яртылаш кына иеп аша!

Әлбәттә, әлеге шөгыль файдалы, ул ябыктыра иде. Кортка никадәр генә кырылса да (дошманы Сәмигулла кызы ла!), чын күңелдән дәвалый иде. Өч ай элек ишек-капкага сыймаган симезбикәнең гәүдәсе, әйтерсең, кайрысы юынган агач, нәзегәеп калды. Менә күлмәкләренә берьюлы өч Гөлҗиһан кереп утыра. Ямау-тегү кебек эшләргә Миңсылуның да осталыгы юк иде ахрысы, әнә, келәттәге әйберләрне дөбер-шатыр китерә. Кисмәктән борчак соса микән? Ләкин Миңсылу тартма кочаклаган иде.

– Уф, безнең җиңгинең келәтендә ат аягын сындыра, билләһи. Тау хәтле әрбир актарып көчкә таптым, – дип, ул тартмасын каерды. – Яшьлегем истәлеге, тегү машинасы. Тегә, нибуч. Элгәреләр лутчы чыдам.

– И рәхмәт яусын, Миңсылу апа!

– Яумасын әле, яумасын! Күлмәгеңне иртәгә җөләрбез, гөлкәем!

– Юк, хәзер үк! – диде хатын. Хәлбуки, бу йортта ул карусыз кол гына иде.

– Хәзер үк?! Кая көязләнәсең син, гөлкәем? Ә-ә, – каенсеңел маңгаена шыкылдатты, – әү-ү, шөрепләрем, әү-ү, тутыктыгыз мәллә? Безнең чибәркәебез көн дә урман буйлый. Җиңгидән качып! Димәк ки, шөрепләрем, нәтиҗә ясыйбыз: Абага аулакта кем беләндер гыйшык боткасы пешерә!

Гөлҗиһанның чәч бөртекләренә хәтле кызарды.

– Әһә, каракның бүреге яна! – Миңсылуның кармагына эләксәң, мәңге ычкындырмый иде. – Әле бит җиңги сине ят ир-аттан ояла, ди. Безгә Фәрит килсә, сине чаршау артына качыра.

– Арттырма, Миңсылу апа.

– Арттырмыйм да, киметмим дә, гөлкәем. Энекәш урман чистарттыра, инде пычкы чыжлаганы безгә дә ишетелә. Шәт, шундагы берәр мыекбай белән

имән төбендә серләшәсездер, йа? Җиңгигә ләм-мим. Яшь чак – дәртле чак, мин сине гаепләмим. Мәгъшукаң кем? Ач сереңне, Абага?

– Андый кешем юк!

– Һи, күзгә төтен өрмә, симез... Һәй лә, нәзек катын! Сез – байбичәләр ир өстенә ир тотасыз, ди.

Нинди сер ачсын икән ул? Озакламый Мәскәүгә китәр... Ә муенсаны урман бирми! Чөнки хыянәтен кичерми! Әйе, әйе, кайчандыр «Мин – урман кызы» дип җилкенгән Гөлҗиһанның байлыктан күзе тонды. Ул, ялтыравык кәгазьдән биек тәхет түшәп: «Мин – дөнья патшабикәсе», – дип очынды. Табигать исә ни акча, ни элемтәләр белән дәваланмый торган чир җибәреп, тәхеттән бәреп төшерде. Менә, күр, хатынны биленә киндер алъяпкыч будырып, аягына кызыл эчле галуш кидертеп, хуҗалыкта эшләтәләр... Берәү дә аңа Джиган Самуиловна дип төчеләнми. Мәскәүдә ун ателье күлмәк тегәр иде, ә ул монда бармагын каната-каната үзе җүли. Миңсылуга аклануы да көлке. «Андый кешесе юк», имеш. Аны алдасаң да, үзеңне алдама инде, Гөлҗиһан. Дөрес, син муенса эзлисең, әмма яшертен генә хыялың да янәшәдән бара: бүген килеш-килбәтең матур, гәүдәң ыспай, каршыңда «очраклы гына» урман егете пәйда булсын иде. Очраклы гына! Шул вакытта карчыкка «танытмыйм» дигән вәгъдәң дә бозылмас иде. Фәрит сирәк кенә әбисенең хәлен белешә, ишегалдында йөренгән егетне тәрәзә пәрдәсенең читен генә шудырып күпме күзәтергә мөмкин!

– Миңсылу апа, миңа яла якма, яме? Минем ирем берәү генә, – диде хатын. – Күлмәкне нишләтәбез?

– Сүтеп тарайтабыз, гөлкәем. Артык тукыма – миңа, куфты тегәм.

– Мин сиңа чемоданы белән калдырам. Сүт тә тек, сүт тә тек. Тик миңа тиз генә берсен эшлә инде, зинһар!

– Ай, әрсез бикә! Үзенә дигәндә – аягы идәндә! Түлке шыпырт, җәме? Җиңгине уятмыйк.

– Иртәдән бирле йоклый, Гамбәр әби.

– Төнката дога укыды. Җиңги сәерләнде, бакчи. Арый микән? Син дә аңа җәфа инде, гөлкәем. Кайчан ташкалаңа кыякларсың, ә? Бистәгә кадәр үзем илтешәм, аннан тимер юл бакзалына абтабуслар йөри. Син бит инде ничауа, нәп-нәзек катын бүген. Җиңги үз җае, үз көе белән яшәсен картлык көзендә, айт-двага бастырма инде аны бүтән, гөлкәем!

– Минем әле шактый борчак чүплисем бар. – Гөлҗиһан уенга бормакчы иде, Миңсылу:

– Синең өчен тавык чүпләр! – диде.

Әй, кадерле ядкаре табылса, йөрәге бик-бик әрнесә дә, авыл белән хушлашыр иде Гөлҗиһан. Өметнең дә өметсезе була? Урман егете белән очраштырмас язмыш... Әгәр муенсаны яратмаган кешесе бүләк итсә, бу кадәр өзгәләнер идемени хатын?! Гамбәр карчыкка ни, кит, югал! Син – каһәрләнгән нәсел баласы...

Әкрен генә кайнашсалар да, тотылдылар, корткa, уянып, «тегүчеләр» янына чыкты. Гөлҗиһанның берәм-берәм күлмәкләрен тотып карады. Аның хәрәкәтләре салмак, гүя ул үзе бәллүр савытка үрелә, үзе аны төшереп ватудан курка иде.

– Тышкы кабык ни! Ходай каумнең эчке гүзәллеген сүәр! – диде карчык һәм, каенсеңлесен битәрли-битәрли, көч-гайрәте суырылган карт аю кебек уң ягына янтаеп, ишеккә атлады. – Син, кем кыз! Телеңә елан чаккыры! Монау катынны (Гөлҗиһанны, билгеле) куалама, җәме? Аның мосафир капкасы икәү, әүвәле каюсы ачылыр – ул шуннан җул энәсе саплар. Мәгәр вәгъдәсен бозса – минем зәһәремә юлыгыр!

Хатынның тәне куырылды. Нинди капка? Нинди юл?

– Зинһар, шәрехлә, Миңсылу апа! – дип ялынды Гөлҗиһан.

Теше белән җебен тешләп тарта-тарта күлмәк сүткән Миңсылуга борын чөяр өчен шул җитә калды.

– Шәрехләрбез ансы да... Түлке мин, җиңги сымак, бушка тәтелдәмим!

– Күлмәгемнең барысы да сиңа, дидем ич, Миңсылу апа.

– Мин инде җиңги белән яши-яши аның ым-кинаясенә төшенеп беттем диярлек. Ике капка – ике тарафтыр. Берсе тучны Мәскәвегез, икенчесе... Ну син хәйләкәр икән, гөлкәем. Урман кисүчеләрнең нәчәлниге белән мәхәббәт яңартам, дисәң – ни инде! Аңа ияреп китүең бик ихтимал. Ансын, бакчи, җиңги хупламый. Нәстә ди, минем зәһәремә юлыгыр, диме? Сиңа ачулана, гөлкәем, сиңа! Ниткән вәгъдә ул, ә?

– Борчагыңны сип әле, Миңсылу апа, – диде кәефе кырылган хатын. Карчыкның һәрдаим кисәтүе аның бәгырен телә иде. Хафаланма, Гамбәр әби! Очраклы гына күрешсәк иде дигән уй нибарысы хыял гына лабаса. Син мине шушы нәни генә бәхетемнән дә тыйма, зинһар!

Миңсылу:

– Әй, җан күеге бит син, гөлкәем! Борчак кына эч пошуларыңны бастырыр микән? Бар, урманыңа шыл! Җиңгигә күркәгә җибәрдем, диярмен. Түлке чиләк ал! – дигәч, аңа канатлар үсте...

Көннәр көзгә тартым иде. Тиздән рәссам-табигать кылкаләме белән, каен-усакларны сагышка төреп, яфракларын сары төскә буяр... Сәйфинең Мәскәүдә тып-тын гына ятуы сәер иде. Нинди хәйлә кора икән, астыртын бәндә? Берәр айдан ул бай хатынын алырга килер. Килми ни! Акча колы Сәйфи Гөлҗиһаннан башка төкергән төкерек кенә!

Хатын йөз кат эз салган таныш сукмактан урман ешлыгына чумды. Тәбәнәк куак ботакларына сарган пәрәвез җебе киң итәгенә сыланды. Ул аны сыпырмады, аулакта кем өчен көязләнәсең ди! Һаман эчкәрәк узды һәм... мең яшәр имән яныннан үткәндә, беләгенә аскан чиләккә өстән шап итеп каты әйбер очып төште. Аңа югарыга күтәрелеп карыйсы иде, ә ул, артыннан бүре кугандай, кире авылга йөгерде.

– Урман кызы-ы-ы! – Ишетте Гөлҗиһан, ишетте. Карчык йортына хәтле озаткан кайтаваз һаман колакта зеңгелдәде: – ы-ы-ы...

Буш чиләк төбендә шылдыраган «имән бүләге» – муенса иде... Ул аны кесәсенә шудырды. Капка төбендә чүмәшеп сулышын тигезләде. Йөрәк дөп-дөп кага иде. Агач башына кем кунакласын, әлбәттә, Фәрит иде. Әйтерсең, үсмер малай, ничек шаяра! Җитәкче ир-егет югыйсә... Килешми дә кебек югыйсә... Их, Гөлҗиһан, Гөлҗиһан! Нигә син качтың икән? Нигә син дә:

– Урман егете! – дип кычкырмадың икән?

Елыйсыңмы? Ела! Бөтен байлыгыңны тау итеп өйсәң дә, ул синең бер тамчы күз яшеңә тормас иде. Кычкыра алмадың шул, вәгъдәң телеңне йозакка бикләгән иде...

Келдер-келдер теккән Миңсылу «күркәләр» дип бәйләнмәде, үз почмагында йоклаган карчык та өн-тын чыгармады. Кич белән ул үзе самавыр кайнатты. Беренче мәлләрдә күңелсез тоелган авыл тормышы аңа ниндидер рәхәтлек бирә иде. Карлыган яфрагы, тукран чәчәге белән хуш исле чәй пешерде. Ә кул әледән-әле кесәсендәге табылдыкны капшады. Түзмәде, келәттә он иләгәндә, муенсаны бер такты, бер салды. Шатлык-куанычтан җан җылынса, сагыш-юксынудан бәгырь өтелде. Таныды лабаса Фәрит. Нишләп ул артыннан чапмады? Димәк, әбисе аны да шәп кенә боргычлаган...

Кичке аш гадәттәгечә бик саран иде. Миңсылу кара ипигә май ягып

сыйланса, карчык баллы чәй белән хушланды. Гөлҗиһанның менюында да кәҗә сөте генә иде. Хәер, тамактан ризык үтәр иде микән? Урмандагы хәлләр, нәкъ кинодагы кадрлар кебек, әйләнә дә кабатлана, әйләнә дә кабатлана иде. Табынны җыештыргач, ул кортка янына керде. Бөгәрләсәң учка сыярлык өрфия яулыкны карават тимеренә элде:

– Гамбәр әби, бу сиңа сәдакам. Әти белән әнинең рухына хәер-дога кыл әле, китәсе көннәрем дә якынлаша, кызыбыз безне искә алмады, димәсеннәр, – диде.

Мендәренә аркасын терәгән кортка:

– Дога укыганда җыелган фирештәләрне качырма, – дип, өрфия яулыкны аның башына япты. – Әгүүзү билләһи минәш-шәйтаанир раҗииим, бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим...

Көйләп укыган дога ни аңлатып та аңлап бетермәслек сагыш-юксыну белән җанны камады. Һәрвакыт боек әнисе, һәрвакыт тупас әтисе күз алдына килеп басты.

Карчык, укуын тәмамлап, мәрхүмнәр рухына багышлаганда, ул да кулын кушырды. Учыннан йөзенә кайнар дулкын бәрелде. Догачы «амин» дип битен сыпыргач, хатын, ике тезенә сугып имгәткәндәй, идәнгә тезләнде:

– Әби җаным, син бит әтинең исемен атамадың! Син әтине калдырдың! Ник алай эшлисең инде, Гамбәр әби?! Мәрхүм сине бик рәнҗетсә дә, кичер, Гамбәр әби!

Аны бүлмәдән Миңсылу куалап чыгарды.

– Җиңгине җәдәтмәсәнә! Әллә картлык баса, әллә сезнең ише халыктан чир-зәхмәт йога, әбиебез илла дә начарайды. Сөрт күз яшьләреңне, гөлкәем, күлмәгең әзер, ки!

– Явыз син, Гамбәр әби, илләрендә бер явыз, – дип үкседе Гөлҗиһан. – Әрвахларны санаганда, әтинең исемен атамадың! Мәрхүм белән һаман көрәшәсең икән, Гамбәр әби!

Миңсылу:

– Һай, гөлкәем, үзеңне савыктырган кешене шулай гаеплиләрмени! – дисә дә, ул озак тынычланмады.

Йөрәген кабарткан давыл иртәгесен тагын да көчәйде: һич көтмәгәндә, Сәйфи Бариевич «борынлады». Ир бәндәсе ялгызы гына иде.

Җыелган-җыйнакланган хатынны күргәч, аның күзе шакмакланды:

– Атакайгынам, синме суң, бичә? Ватый ничек нечкәрткәннәр. Әбиҗан, әллә суң моны пычак белән тунадыңмы?

Карчык түмәрдә кояшта җылынып утыра иде, ни исәнме димәде, ни хуш димәде, капыл гына арт бакчага теркелдәде. Миңсылу да җәлт кенә ызбага тайды. Агач тагаракта тавыкларга ипи телемнәре уган Гөлҗиһан, кулын суда чайкатып:

– Нишләп йөрисең, Сәйфи? – диде.

– Ват сорау! Синең хальләреңне белмәк булдым.

– Ай ярымнан үзем дә кайта идем.

– Анда тиклем важный эш бар, бичә. Машинаның тәгәрмәче тишелде, башта шуны хутлыйм, аннары чүкердәшербез. Кая, бер кочаклыйм үзеңне, бичә.

Авыл һавасын сасытып, ир бәндәсеннән арзан хушбуй исе аңкый иде. Затлы әйбергә өйрәнмәде Сәйфи, аның өчен яшәү мәгънәсе – лыкынганчы ашау һәм бармагын төкерек белән юешләтеп акча санау иде. Ир тәгәрмәч белән кайнашканда, Гөлҗиһан икеләнде: карчыкның сихәт дәресләре төгәлләнә кебек. Сәйфи белән китәргә мәллә? Белекче ялгыша: юл бер генә, һәм ул караңгы ташкалага табан сузылган...

Ире таушалган портфелен култыгына кыстырган иде. Баудагы шадра сөлгегә пычрак кулын сөрткәч:

– Ардым, – диде. – Җарты сәгәт кенә җокыга түнәм, – диде. Портфелен ычкындырмады, мөгаен, «важный эш»е шунда иде. Әмма хатын аңа «түнәргә» ирек бирмәде.

– Минап абзый кайда, Сәйфи?

– Кайда, кайда? Айда! Минап белән сугым пычагы кайрыйсыңмы? Сүәркәң тегелдер, шай! Кудым, күп сүли. Җокы качты, чукынмыш. Колак төбемдә жуылдыйсың, катын.

– Ашыгыч эш, дидең бугай, Сәйфи.

– Да, эш, Джиган Самуиловна, эш. Мона монда кыягазлар, син шуларга имзаңны сырлале.

– Нинди кыягазлар? Кая, бир, Сәйфи?

– Укып вакыт уздырма, юрич Иванов бар да тәртиптә, дир. Закунлы, дир.

– Юрист Иванов ал да гөл дисә дә, мин документларны үзем тикшерәм, Сәйфи! – Хатын иренең кулыннан кәгазьләрне тартып алды. – Нәрсә бу, ә? Ничек бөтен милек синең исемгә теркәлә?

– Москывада хәлләр хөртиләнде, Джиган Самуиловна. – Ир бәндәсе күзен дә йоммыйча хәйләләргә кереште. – Рикит дигән бандитлар кыз-катын җитәкчеләрнең бизнесын талый. Үтерергә дә мужыт алар. Миңа тимәсләр, патамушты мин – мужик. Син миңа тере килеш кирәк, алтыным, – дип, тигәнәк төсле сырышкан Сәйфине ул этеп җибәрде:

– Кочаклама!

– Укаң коеламы, катын? Җә, канны кыздырма, кушканны эшлә! Иту... – Ир йодрыгын һавада уйнатты. – ...башыңны сугып җарам. Монда кеше жук, таптап-таптап күмәрмен, катын!

– Култамгам гына кирәкме, Сәйфи? Шул гынамы?

– Шул гына, алтыным! Синең өчен җанам-күәм, штубы бандитлар харап итмәсен, дим.

– Кая, каләмең бармы?

– Да, да, алтыным. Мә! Маладис син, ушлы син! Ватый аңлаштык та. – Телендә сандугач сайраткан ир бәндәсе имзалар куелгач та, шәбәренеп: – Хазер дөния минеке! – диде. – Колагыңа киртлә, син хәерче шушы маминттан, хәерче! Үтүт синең акча-макчаларың! Мин барсына да хуҗа! Мин! Безнең борынгы бабалар судка җөрмәгән, катыннарына өч кенә кычкырган. Талак сиңа Сәмигулла кызы, талак, талак! Җәшкә үләнәм, миндәй бай әбзиләрнең муенына сразы ун кыз асылына!

Гөлҗиһан кытыклангандай көләргә тотынды. Аңа кушылып чыпчыклар да чыркылдашты.

– Сиңа убырлы карчык та бармый, Сәйфи! Син ул менә Мәскәүнең иң хәерче бәндәсе. Мин март аенда ук паспортымны Гөлҗиһан Сәмигулловна Насыйрова исеменә алмаштырдым. Ахрысы син минем Радий сеңлесе икәнемне оныткансыңдыр. Хәйлә чиратына ул мине синнән алдарак бастырган иде, Сәйфи.

Бу хәбәрдән соң бая гына канаты белән дөньяны колачлаган «әтәч»нең кикриге шиңәр дигән иде Гөлҗиһан. Куендагы портфеле җиргә кадалгач, ир аны тибеп үк җибәрде:

– Әбзәң белән мактанма, бичә. Беләсеңме кем иде әбзәң? Ата бандит! Алтын талап сатты, сукыр бәбәк! Кыйбатлы ташлар сатты! Күтенә су керә башлагач, сандыгы белән сакларга дип, синең атаеңа илттерде. Миңа әммәсен дә җан сакчылары сүли иде. Атаең, бирән авыл мужигы, мылтыкка акча бирәләр дип,

сандыкны политсага сдавайт итә! Тимер белән энҗе-мәрҗәнне аермаган утын бүкәне! Арсиныч җегетләре кире алмага килсәләр – үтүт җемелдекләр! Радий җалчыларына: «Җырты-ние белән бергә үзен дә җандырыгыз», – ди. Так шту, атаеңны сүекле абзаң Арсиныч үтертә. Җалчылары сине дә дөмектермәкче була, ну бандит туганың: «Наталия ике тапкыр үлми», – дир. Ватый, аның кызы аркасында асмыйлар сине, бичә!

Сулышы киселгәндәй, хатын катып калды. «Сүекле абзаң Арсиныч үтертә... Арсиныч үтертә...» Яла бу, яла!

– Алдашма, Сәйфи! Туган абый тимер кисәкләре өчен генә этине яндырмас!

– Тимер кисәге? Ул сандыктагы бриллиантлар чит илдә илле җыл типтереп җәшәргә җитә, дир, җүләр катын! Синең бандит әбзәң җөз кешене аттырды-астырды. Сиңа гына ул фәрештә. Җә, татулашыйк, алтыным. – Сәйфи аяк астында аунаган портфеленә тагын бер типте дә капканы ачты. – Дабай, ыспурлашмыйк, үгә катябыз, Джиган Самуиловна, ну, Гөлҗиһан Сәмигулловна. Ну төлке дә үзең, да-а! Җаңа дәкимүнтләр әтмәлләгәнсең, да-а!

Ир бәндәсе көлгән итенде, тик бу астыртын көлү иде.

– Минем әби-бабайларның гореф-гадәтләренә хөрмәтем зур, шуңа күрә синең талагыңны кабул иттем. Без хәзер чит-ят кешеләр. – Гөлҗиһан, ниһаять, һаман саен өтер генә төрткән тормышының бер өлешенә «тәмам» дип, нокта куйды. – Хуш, Сәйфи!

– Хуш, дирме, ана төлке?! Ватый, чәчбигә – мал-мөлкәт, Сәйфигә – шымытыр икән!

– Син дә, мин дә хәерче, Сәйфи. Барысын да акчага әйләндереп, авыру балалар үзәгенә күчертәм.

– Күчертермен, ватый! – Ир хатынны кулыннан боргычлап капкага сөйрәде. – Үгә катябыз, үгә! Мин сине дураклар җыртына җаптырам!

– Кая өстерисең, аждаһа, тимә аңа! Бәбәгеңне тырныйм! – дип өйдән Миңсылу атылып чыккан иде, Сәйфи аңа аяк чалды.

– Прәс, мачы! Җаклама! Ватый, симез чагыңда акыллырак идең, бичә! Маең белән бергә акылың да эрегән, бичә!

Гөлҗиһанның карышырлык хәле юк, Сәйфидә ат куәте бар иде. Кинәт гайрәтле тавыш күк гөмбәзен урталай ярды:

– Җибәр, юкса атам!

Аңын җуя башлаган хатынны көчле куллар җирдән күтәреп торгызды:

– Нихәл, урман кызы?

## 18

«Әй, кыз олан! Ник син кылганнарны таптыйсың, җүнсез!

– Үлмә-ә-әс...

Чү, Анам кемгә эндәшә? Ишетәмсең, кыз олан?

– Үлмә-ә-әс...

– Әй, Анам, нишләп болай җиде ятларга инәләсең икән син? Бердәнбер терек балаң – мин монда кана!

– Миңа эндәшә, Анам, миңа. Үлмәс мин ул! Ә син – хыянәтче! – Зәңгәр күлмәкле кыз ачу белән кылганнарны йолкый иде. – Син кардәш-ыруыңны, ата-анаңны ташлап чит аймакларга качтың. Синең хәсрәтеңнән Анамның йөзенә көзге дала сарысы сукты...

Әй, кыз олан! Телең ни әйткәнне колагың ишетәме, йа? Мин аңа хыянәт итмәдем, мин гомерем буе: «Раббымыз, барча хәер-теләкләремне ахирәттә

ирештереп, җәннәтләреңнән әйлә», – дип, Анама дога кылып яшәдем. Кит, мөрәвәтсез!

– Кит, имеш. Үзеңне үзең куасыңмы? Син исемеңә дә хыянәт карасы тамыздың: әүвәлге атыңны үзгәртеп, Гамбәр дип куштырдың. Бел, мин – Үлмәс сине соңгы сулышыма тиклем каһәрлим!

– Әй, кыз олан! Мин бер Аллаһның гына каһәреннән куркам. Өзмә кылганнарны, алар Анамның ап-ак чәчләрен хәтерләтә...»

Карчык фанилык белән бакыйлык уртасындагы күпердә адашып-саташып йөргәнен анык тоя иде. Үсмер чак күренешләре вакыт-вакыт еллар комы аша саркый да, бөтен халәтен биләп ала иде. Әнә Үлмәс сурәтендәге кыз бала ничәмә-ничә көн, ничәмә-ничә төн җанын талкый. Үз-үзең белән көрәшүе, һай, авыр икән. Үлмәс – усал, бер сүзеңне ун чәнечкеле сүз белән каплый. Усал булмаса, мөгаллим Заретдинга тагылып китәр идемени?! Кичә оныгы:

– Зур әни, менә төгәл генә әйт әле, син кайсы яклардан соң? Әти каяндыр – җәһәннәм читендәге даладан, дигән иде.

Әби кешенең төзәлмәс күңел ярасы иде бу, ул, артык җәелмичә генә:

– Ерактан, бәбкәчем, ерактан, – диде.

– Сагынасыңдыр, әйеме? Бүген выж-выж самолётлар оча, поездлар чаба, әйдә, көнендә генә туган җирләреңне урап кайтабыз, Зур әни.

Энәнең очын гына да җан ярасына тидерергә ярамый иде, карчык оныгын ишетмәгән төсле:

– Кайчан үләнәсең, тискәре малай? – диде.

– Миңа беркемне дә димләмә, йөрәк үзе сайласын, Зур әни. Менә син нишләп миннән кунагыңның исемен яшерәсең икән?

– Ниткән кунак, бәбкәчем?

– Йә инде, Зур әни! Сездә Гөлҗиһан яши! Син аны тәмам өркеткәнсең ахры, урманда яфрак селкенсә дә кача.

– Гөлҗиһан? Кит, куй, бәбкәчем, – диде карчык. – Кемгә охшаттың тагы ят кала катынын?

– Мин бит бала-чага түгел, ышандырырга тырышма инде. Оныталмадым мин аны, аңла инде, Зур әни!

Әйе, Фәрит бала-чага түгел, аны алдап-йолдап йөртеп булмый, күрәләтә Сәмигулла кызы белән дә кавыштырып булмый иде.

– Безгә ул елан нәселе күп чакты, бәбкәчем.

– Гөлҗиһанның ни гаебе бар, Зур әни?

Фәрит тә үзсүзле иде шул. Ни хәлләр итәсе, йа Аллаһым? Оныкны гыйшык тозагыннан араларлык көч-гайрәт көннән-көн сүнә... Әйтерсең, филтәсе янып, уты сүрәнләнгән сукыр лампа Гамбәр. Менә ятып торудан гайре шөгыле дә юк. Өч тәүлек элек бистәдән сырхау белән килгәннәр иде, чыгып та бакмады, бүлмәдән генә:

– Карт сулыш, – диде.

– Бабай ул, яше зур, – дип пышылдады каенсеңлесе. – Нәстә дияргә, җиңги?

– Гумер тәмәке тарткан, үпкәсе бозык, табиблар даруласын!

Табиб, дигәч, Миңсылу аның үзен дә хастаханәгә барырга кыстаган иде дә, кортка:

– Картлыкка дәуа җук, – дип кырт кисте.

Иң соңгы туеңа әзерлән, Гамбәр... Мәңгелеккә илтәчәк сәфәреңнең сәгатьләре кыскарган саен кыскара...

Ишегалдындагы ир-ат тавышы аның уйларын бүлде. «Ни-нәрсә икән?»

– дип гаҗәпләнмәде, ул аны көтә иде. «Катыныңны япраклар коелгач алып китәрсең», – дисә дә, адәм заты түзмәгән кана. Җә, хәере белән... Сәмигулла кызы тизрәк ташкаласына озайсын... Онык аңардан араланса, иншә Аллаһ, иман нуры белән өретелгән берәр кәләштән баш тартмас...

Шулай дисең дә, кортка... Ә үзең нишләп пошынасың икән соң? Сөенечеңнең койрыгы өзелде ләса... Бу килбәтсез адәмнең уй-ниятен сизеп тә бер-бер хәл кылмасаң, кыямәт көнендә кабереңнән кем сыйфатында кубарылырсың икән?

Карчык ятагыннан кузгалды. «Миңа көч бир, Раббымыз, – диде. – Хәлсез аяк-кулларыма әз генә җиңеллек өстә», – диде һәм баскычта сарык йоны теткән каенсеңлесен ым белән генә: «Ызбага кер», – дигәч, арт бакча ягына атлады. Урман белән җенләнгән оныкны чакрымнарга сузылган биләмәсеннән эзләсәң – кич җитә иде, ул, капка сакчысының кулындагы кара тартмага төртеп:

– Улым, монауга әйт, Фәритне чакырсын! – диде.

«Тартма» сүз тыңлады, оныкны җилтерәтеп китерде.

– Гөлҗиһан бәлагә тарды, ашык, бәбкәчем! Мин үз җаем белән генә кайтырмын. – Карчык көчкә генә сулыш алды. «Үз җаем»ның да җае бар: агач йорт тәрәзәсендә таныш шәүлә селкенә иде. Кортка аңа:

– Кил, – дип кул изәде.

Ике аяклы «кисәү»нең кыяфәте мунча җененнән дә куркынычрак иде.

Гамбәр карчык, беренче тапкыр авыз тутырып:

– Сәмигулла, – диде. – Бит-йөз – адәмнең көзгесе. Кырын, юын, ару күлмәкыштан ки, сиңа бүген кунак килә.

– Кем икән суң, күрше апа? Илләрендә бер көтәр кешем юк.

– Хуш, Сәмигулла! Мин сине бәхилләдем.

– Гамбәр апа, чынмы? Кичерәсеңме? – дип, алдына тезләнгән ирнең карчык аркасыннан какты:

– Кичердем, Сәмигулла, кичердем...

...Капка төбендә көлешә-көлешә Фәрит белән Гөлҗиһан сөйләшә, алар балалар кебек кулга-кул тотынышкан иде. Өлгергән онык, шөкер. «Тагын ун гына адым атларлык көч өстә, Аллаһым», – дип, кортка бөкрәйгән гәүдәсен турайтып, иңбашларын төзәтте. Күк дөбердәткән, җир тетрәткән белекче соңгы мәлдә генә мескен рәвешендә хәтергә уелып калмаска тиеш иде.

Яшьләр аны ике яктан култыкламакчы иде, ул кырыс кына:

– Мин бөтәшмәгән кана, – диде. Тик йөрәктә катылык юк, йөрәктәге таш уалган иде. – Кызым, хәзер үк Фәрит белән утарга барыгыз. Анда, агач ызбада сине Сәмигулла көтә. Исән атаң, исән, – диде.

Җилкәне баскан авыр йөк кинәт кенә аска шуды. Рәхәт һәм җиңел иде. Яшь киленнәр көнләшерлек җитезлек белән ул коедан су ташып мунча якты, каен себеркесе пешекләде. Әчегән катыкны ярты гына аш кашыгы көнбагар мае белән туглады. Чәчне киптереп тузгытмый. Юынгач, ак киндер күлмәген киеп, ак яулыгын бәйләде. Көндез каенсеңлесе черем итәргә ярата иде, аның өстенә юрганын япты. Җылынып йокласын! Караватка яткач та, пыш-пыш догаларын укыды. Чү, кай тарафлардан иркә, йомшак җил исә икән? Йа Раббым, дала җиле.

– Үлмә-ә-әс!

– Әү, Анам?

– Кайт, Үлмә-ә-әс!

– Озак тордым шул, кайтам, Анам, хәзер кайтам...

## АНА ТЕЛЕ «ӘЛИФБА»ДАН БАШЛАНА

**Каршымда катлам-катлам өелгән сарай калка. Хыялымдагы белем-гөрзи белән сарайның капкасына орам...**

**Бер... Ике... Капка шыгырдап ачылып китә. Җыр ишетелә... Моң...**

**Әй мөкатдәс моңлы сазым...**

**Татар көе... Тукаебызның аһәңе лә бу. Ә күңел, күзләрне ачыттырып ургылган яшьләрне бар дип тә белми, сөенеч кошларын иреккә очыра. Күз яшьләре аша елмаям. Тарих тузанының тәүге бөртекләренә татар җыры, татар моңы сеңгән бит, ни сөенеч!!! Җыры гынамы соң, татар теле үзе үк иң көйле җырлардан да көйлерәк, иң моңлы көйләрдән дә моңлырак бит дип, уйлана-уйлана, өстәлемдә тезелгән иң якын, иң кадерле китапларымны барлыйм. Нинди генә китаплар юк араларында. Минем игътибарым барлык китапларның да, барлык фәннәрнең дә патшасы булган, нәниләрне белем дөньясына алып кереп киткән «Әлифба» китабыма юнәлде. Юкка гына уйларым татар халкы, татар җыры, татар моңы белән бәйләнмәгән икән. Менә шушы китап бит инде һәр татар баласын үз юлыннан алып кереп киткән.**

**Хыялым гөрзиенә тагылган кыңгырау чыңлап куя. Гүя ул миңа шул кадерле китапны кулыма алырга, тагын бер тапкыр аның битләре буенча сәяхәт итәргә куша.**

**Ике... Өч... Шыплап өелгән китаплар арасыннан балачагым истәлеге булган «Әлифба» китабымны кулыма алдым. Әнә бит аның тышындагы укучы кызы гына да ни тора! Ул безгә, әйтерсең, күз кыса. Әйдәгез, минем арттан. Бу китаптан башланган белем юлы – иң озыны, иң куәтлесе, иң көчлесе!**

**Өч... Дүрт... Тагын бер орынам ишеккә. Акрынлап зиннәтле капкадан кергән шикелле, калтырана-калтырана, китабымның эченә үтәм. Менә кайда ул затлылык, менә кайда шагыйранә гүзәллек, менә кайда ул белем һәм тәрбия үрләре.**

**Нәкъ беренче сыйныфта, беренче хәрефләремне өйрәнгән шикелле, бармакларым белән төртә-төртә, «а-у, у-а, и-а» авазларын чыгарам. Рәхәтләнеп хыял диңгезендә йөзәм. Күңелемә шундый рәхәт, җанымда ниндидер тынычлык.**

**Дүрт... Биш... Хыялымдагы белем гөрзие тагын капкага орына. Уйлана-уйлана, яраткан китабымның эченәрәк үтим дигәндә, әнием килеп, җилкәмә кагылды. Үз хисләрем, уйларым, фикерләремне әнием белән уртаклаштым. Әнием дә минем кулымдагы шушы юка, әмма олы китапка үзенең соклануын белдерде. Ул миңа «Әлифба» китабының кешелек өчен ни дәрәҗәдә мөһим булуын сөйләде. Әниемнең ул сүзләрен гомерем буена күңелемдә йөртәчәкмен. Әнием миңа И.А.Крыловның «Аккош, чуртан һәм кысла» мәсәлен исемә төшерде. Геройларның ахмаклыгыннан рәхәтләнеп көлдем. Озак кына уйлап утыргач, бу мәсәлдә хаклык барын аңладым. Әнием юкка гына әлеге мәсәлгә тукталмаган икән. Йөк бит ул – безнең туган телебез... Аккош – татар халкы... Чуртан – замана, ә Кысла – җәмгыять... Тирәннәнрәк уйлап карасаң, мәсәлдәге һәр образ да йөкне бер юнәлешкә тартып, телебезне тиешле югарылыкка күтәрсеннәр иде. Ә бу югарылык, әлбәттә, «Әлифба»дан башлана.**

**Рәмзия ЛАТЫЙПОВА,**
*Балтач районы Пыжмара урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*



Рифә
Рахман

# ШИГЫРЬ АША ТЕЛНЕ ӨЙРӘТТЕМ

## Минем туу

Йолдызларның аңы киткән чакта,
Йолдызларның төсе уңганда –
Туганмын мин –
Инеш, елга суы
Ярларына тәмам тулганда.
Күзләреңнән йолдыз тама, дисез,
Яшьне нәни йолдыз күрәсез –
Исәр йолдыз кебек яшисең, дип,
Нигә мине һаман сүгәсез?
Гаҗәпмени йолдыз нурларына
Минем шулай ия булуым?
Моңа сәбәп
Яңа йолдыз белән
Бер вакытта минем тууым.
Бик газаплы, диләр, йолдызларның
Яралуы  галәм эчендә.
Мин дә йолдыз кебек җан алганмын…
Шуңадыр да  йолдыз төсендә.
Йолдызларның һушы киткән чакта
Җиңелмени исән калуы?!
Шундый еллар бит бу,
Шундый еллар!!!
Сүнәм,
Кабат китәм кабынып.
Күкнең һичбер буп-буш торганы юк.
Сүнсәк,
Башка йолдыз табылыр.
Ул без булмас,
Син дә, мин дә түгел –
Килер буыннарның һичкеме.
Тик алар да йолдызларга карар,
Шуннан очып килгән шикелле.

---

Рифә РАХМАН – *шагыйрә, прозаик, галимә; «Онытырмын димә», «Йолдызлар төстән язганда», «Таулар һаман ерак» һ. б. исемдәге күпсанлы китаплар авторы. Ф.Хөсни, Г.Исхакый исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

## Татарстан урамыннан барам

Татарстан урамыннан барам,
Казан үзәгенә илтә юл.
Тукай бакчасында бер тын алам,
Адымымны җиңел итәр ул.

Бер тын алам, тимер утыргычның
Тәнгә үтеп керә салкыны.
Һәйкәл тирәләре чәчәк кенә...
Таҗларында миңа ят җылы.

Таҗларында бии күбәләкләр
Миңа таныш түгел көйләргә.
Тукталган ла идем Тукаема
Үз телемдә шигырь сөйләргә.

Аңлый алса мине Шагыйрь аңлар,
Таш тәнендә бардыр күк җаны.
Утыргычка килеп утырдым да
Укыдым мин аңа Тукайны.

Аһәңнәрен сайлап, тынышларын,
Мәгънәләрен – аңлый алганча.
Һәм сөйләштек аннан Тукай белән
Ана телебездә таңгача.

Һәйкәл тирәләре  чыклы чәчәк...
Янар чыклар – парга калганчы.
Татарстан урамында таптым
Бу төн татарчаны аңлаучы.

Иптәш таптым җанга, төндәш таптым.
Шигырь кебек типкән йөрәкне
Хәтта чәчәкләргә тыңлаттым мин,
Шигырь аша телне өйрәттем.

Татарстан урамыннан кайтам,
Минем өемәчә илтә юл.
Тукталышта тагын бер тын алам,
Адымымны уйлы итәр ул.

## Төннең көнгә карышуы

Төннең көнгә карышуы шулдыр, диден.
Карышкач тән, синең назга калып сабыр.
Көннең әле җиңми китеп барганы юк...
Тап бер юлын, син бит – талант, син бит – шагыйрь.

Төннең көнгә карышуы шулдыр, диден,
Ишегемнән кертми сине торганымда.
Син син булып калалмассың, уза калсаң:
Таң ишеген ача да... төн юкка чыга.

Бусагадан узмый гына үптең дә син,
Төннең көнне үбүе күк булды, дидең.
Төн салкындыр, син салкындыр, инде китәм,
Ишегеңнең тыш ягында туңмыйм, дидең.

Төннең – көнгә карышуы, минем – сиңа.
Шулай... Шагыйрь күңле һәрчак чагыштыра.
Әйткән сүзе, кайчак миндәй тотнаклының,
Татлы булса, аякларын чалыштыра.

## Әткәй иңе

Әткәң иңе кирәк таяныргa.
Әнкәң сүзе кирәк – исәндә,
Йөзгән ярың бик тә ерак булса,
Йөзгәнеңдә хәлең киткәндә.
Алар янына күк йөзәсең син,
Кинәт шулар искә төшкәнгә.

Ярларыңны эзләп табасың син,
Яр бар икән, димәк, бар офык.
Яшәү диңгезләре ярлы булсын,
Ә офыклар торсын ымсытып.
Хыял диңгезе дә ярлы булсын,
Хәл алдырсын, сине утыртып.

Диңгез арты диңгез кичә ал син,
Офык артларында тап офык.
Хыялларның ярын билгели бел,
Әниеңнең сүзен син тотып.
Тормыш яры сиңа хәл алдырсын,
Әткәң иңе кебек утыртып.

## Кызым, кайтам, диде

Кайтам, диде кызым, берәр вакыт,
Тик вакытын әйтмим әлегә,
Болай да бит, синең йөрәккәең
Мине көтеп яшәү хәлендә.

Болай да бит, мине уйлый калсаң,
Йокыларга китми ятасың,
Ишегалларына чыгам, дисең,
Тавышларың белән саташып.

Кайтам, дисең, кызым, кайтам, дисең,
Кайтуларың шундый озактыр.
Көнем синсез генә уза торыр,
Ишегендә сиңа йозактыр.

Вакытларын әйтми генә миңа,
Бирсәң дә син кайту хәбәрен,
Көтүләрем бик көчәеп китә,
Авыраеп китә хәлләрем.

Поездларның барам каршысына,
Телефонны йөртәм кесәмдә...
Мин булырга тиеш тик Казанда,
Кайчан гына кайтып килсәң дә.

Почта ящикларын карамыйм мин,
Электронка карыйм, таң туса.
Мин эшемә белми китәрмен дә,
Син көтәрсең кебек атуса.

Ишек төпләрендә көтәрсең күк,
Бакча эчләрендә көтәрсең,
Дәресемне минем бүлдермим, дип,
Телефоннан хәбәр итмәссең.

Кайтам, дисең, кызым, кайтам, дисең,
Вакытларын шуның әйт, зинһар.
Вокзалларда Мәскәү поездларын
Белмичә дә шуны көткән бар...

## Суламаган көн

Бу беренче тапкыр әле. Там беренче!
Мондый хиснең булганы юк гомеремдә.
Ул гашыйклык түгелмени, якын итү?
Бармас төсле бу хисемә бер исем дә.

Синсез яши алмау хисе, аны ничек
Атарга соң, ничек итеп исемләргә?
Синсез – тынсыз! Моңа кадәр
Ир исеннән исерерлек идем мәллә?!

Яздым шигырь, яратам, дип – яратмыйча.
Уен иде яшәвем дә, язуым да.
Шул уеннан уймак ясап куйдым, ахры.
Инде хисем сыеп бетми уеныма.

Инде шигырь бик авырдан килә телгә,
Мөмкин түгел башаяктан күмелергә.
Уйламадым синең кебек җебекләрдән
Мөмкиндер дип шул арада җиңелергә.

Нинди хис бу? Аны ничек исемләргә.
Синсез яши алмау хисе, дисәм – озын.
Синсез – тынсыз! Суламыйча яшәдем мин
Үз гомеремдә беренче кат һәм көнозын.

## Яфрак-яфрак

Кар коела яфрак-яфрак булып:
Шул хәл кышны көзгә якынайта.
Көзнең агы булмас димә икән!
Сукмакларда кар-кар яфрак ята.

Куркытсаң да, миңа өмет бирми,
Рәхәт тә соң: барам янәшәңдә.
Кар-кар яфрак. Яфрак-яфрак сукмак...
Их, яшәргә иде, их яшәргә!

Ак яфраклы йөз-мең сукмакларны
Их, үтәргә иде иренмичә.
Их, сөяргә иде сибелмичә,
Кеше көнләвенә бирелмичә.

Көзнең агы булмас димә икән:
Гомер көзем минем нинди якты.
Көзне ап-ак иткән сукмакларга
Төшкән кары учтай яфрак чаклы.

Синең кулга әллә тотынганга,
Рәхәт тә соң: барам ипле генә.
Эзне эзгә әле кушмый гына,
Синең яннан ерак китми генә.

**Редакциядән:**
*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Алмаз
Хәмзин

# ...ДИСӘҢ ДӘ БУЛА

ШАЯН ӘҢГӘМӘ

– Әхмәт, Әхмәт!..

Ишетми, үзе музыкант, югыйсә. Ниндие генә әле – атаклы Камал театрында эшли торганы! Уйга баткан ахрысы, ашыга. Артыннан йөгерәм, сыртына баянын асса да, куып җитәрлек түгел.

– Әхмәт!

Ниһаять, борылды.

– Ай-яй, малай, кызу да йөрисең инде.

– Син икәнсең... Кем кычкыра соң миңа Алмаз тавышы белән дип уйлап алдым алуын.

– Ни хәлләр?

– Әйбәт, дисәң дә була...

– Кая юл тоттың?

– Язучылар берлегендә кемнеңдер, үзем дә белмим, юбилей кичәсе ахрысы, шунда барам, җырчыларга уйнарга. Ә үзең монда ничек килеп чыктың?

– Сине эзләп. Театр зур премьера әзерли бугай?

– Премьера, дисәң дә була инде...

– Сиңа, бәлкем, Берлеккә барасы түгелдер, Әхмәт, «Татарстан» кунакханәсенең ресторанына чакырылгансыңдыр... Анда бүген өлкән язучыларны хөрмәтләү мәҗлесе.

– Ә-ә, шулайдыр әле ул. Керик, юл уңае бит.

– Мин дә шунда җырларга тиеш. Син уйнамассың микән дип килүем иде. Сиңа җырлау үзе бер рәхәт.

– Һәй, эшлибез аны!

Мәҗлескә җырлап килеп кердек.

Бездә биек таулар бар ла,
Тау астында таллар бар.
Талда яфрак, миндә сагыш
Сездә нинди хәлләр бар?

Шәп узды ул кичә: без язучыларның рәхмәтле карашында коендык. Ихлас алкышлар шавы җаныбызны иркәләде, дәртләндереп җырлатты һәм уйнатты.

---

Алмаз ХӘМЗИН (1947) – *прозаик, шагыйрь; «Озак яшисегез килсә» китабы һәм күпсанлы җырлар, юморескалар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

– Күпме чыгыш ясадык без синең белән бергә! – дип башлады сүзен Әхмәт, театр фонтаннары каршындагы эскәмиягә утыргач. – Концертлар, мәҗлесләр, бәйрәмнәр... Санап бетерерлек түгел, ә, Алмаз! Гомер буе сәхнәдән төшмәдек бит. Сабантуйларны гөрләттек, кайларда гына йөрмәдек – Мәскәве дә, Ленинграды да калмады...

– Ленинград, дигәннән... Безгә синең белән комсомолның Бөтенсоюз удар төзелешендә катнашырга туры килде бит әле. Ленинградны су басмасын өчен, Фин култыгында күтәрелә торган дамба эшчеләренә концерт куярга җибәргәннәр иде. Татарстанның байтак артистлары белән бергә, әлбәттә. Хәтерлисеңме?

– Хәтерлим, дисәң дә була...

– Барып төштек Рәсәйнең төньяк башкаласына. Урнаштырдылар, ашаттылар, эчерттеләр. Кунакханә яхшы, тамак тук. Син – егет кеше, күршедәге бүлмәгә Казаннан килгән кызлар белән танышырга кереп киттең. Бераздан чыктың. Әллә «тамак чылатып» алырга да өлгергән идегез инде шул арада? Битең кызарган, хәер, син аның ише нәрсә белән чуалмыйсың бугай. Кызаруың – берәрсенә гашыйк булгангадыр. Ошаткан кызың каршында күз кысышып утырсаң да, биткә кан йөгерә дип язалар бит. Шулайдыр.

Миңа син:

– Йокларга җыеналар, – дисең.

– Әллә берәрсенә гашыйк булдыңмы? – дим.

– Әйе, теге кечерәк гәүдәлесенә. Бухгалтер икән...

– О-һо! Алай булгач, бай инде ул! Ә икенчесе кем?

– Анысы синең кебек – клуб директоры.

– Шәп икән!

– Ниме соң?..

– Нәрсә ни?..

– Әйдә, кер, анысы сиңа булыр.

– Юк, – мәйтәм, – мин өйләнгән кеше, килешмәс.

– Соң, алар да ялгыз түгелдер инде. Миңа дигәне ниндидер ишарәләр белән өмет бирә бирүен.

– Калырга кушамы?

– Калып нишлисең инде анда? Тегесе карап ята бит.

– Анысы шулай...

– Безнең бүлмә ике кешелек, аларныкы да шулай...

– Алышыйк, дисеңме?

– Монда директор керер, ә мин – аның бүлмәсенә...

– Бар, әйтеп кара тегесенә!

Кабат кереп киттең. Ах, мин әйтәм, риза булмасалар гына ярар иде. Синеке – матур матурын, ә миңа дигәненә – илле бишләр чамасыдыр. «Ташы»ң кызган, нишләргә белмисең. Кызганам инде үзеңне. Ризалашсагыз, сөйләшеп кенә утырырга карар кылдым.

Озак тормадың, кире килеп тә чыктың.

– Нәрсә, – мәйтәм, – эшләр пешми мәллә?

– Синеке карышып маташа. Үзең кереп юмалап чыкмыйсыңмы? – дисең.

– Әхмәт, син нәрсә, әби кешегә утыз биш яшьлек егет ялынырга тиешме?

– Юк инде кәнишне. Күзен дә йоммый, борылып та ятмый. Юрганыннан тишек калдырып карап ята. Тукта әле, тагын кереп чыгыйм.

Шулчак кызлар бүлмәсенә атылдың да күп тә үтми кабат каршыма килеп бастың.

– Алмаз, сәгать ничә ул?

– Төнге бер.

– Шулай икән шул, дөрес икән. Тагын керим әле.

– Йөрмә инде, Әхмәт?!

– Минеке дигәне бит мөлдерәп карый...

Озак кына торганнан соң, инде шунда калдың бугай дип йокымсырап киткән генә идем, синең аяк тавышлары үзебезнең бүлмәдә.

– Йокламыйсың ахрысы?

– Юк.

– Сәгать ничә?

– Ике.

– Минеке дә... ике, дисәң дә була. Нигә соң караңгы төшми? Мин бит караңгы төшкәнне көтеп йөрим. Теге «директор киресе» һаман күзен йоммый.

– Әхмәт, Ленинградта «ак төннәр». Шундый чак.

Беркавым авызың ачып түшәмгә карап тордың да:

– Их, авылга кайтып, гади генә бер сыер савучы кызга өйләнсәм, хатыным Герой соцтруда гына булса да, сөт кенә эчеп, бу язвылар булмас иде, – дип, урын-җиреңне җәймичә, киенгән килеш караватыңа аудың.

Кызлар мәсьәләсендә юашрак идең ахрысы, Әхмәт. Үзең әйткәнчә, гел уңышсыз килеп чыга бугай мәхәббәт маҗараларың.

– Әхмәт, ул ак төндә теге бухгалтер кыз белән эшләр уңдымы соң?

– Уңды, дисәң дә була... Алмаз дус, син беләсең бит инде, үзең дә гармунчы кеше, клубларда тирләп-пешеп баянда уйнап утырасың кич буе. Яшьләр бииләр, җырлыйлар, күңел ачалар да, кайтыр вакыт җитәрәк, дерт итеп урыннарыннан кубалар. Һәм таралып та бетәләр. Утырып каласың баяныңны тотып. Караңгы урамга чыгып, үзеңә яр эзләп кара, барысы да парлашып беткән була, ә син, баяныңны тартып, өеңә атлыйсың.

Әй, гармун, гармун,
Яшьлек юлдашым,
Син йөрәгемдә
Сөю уяттың.
Моңланса минем
Кайгылы башым,
Җырларың белән
Мине юаттың.

Кем синең күңелеңә керә дә, кем сине аңлый. Гомерем буе баяным белән сөйләшеп, серләшеп яшәдем инде. Бары тик ике яраткан кызны гына оныта алмыйм. Мәктәптә укыганда ук булды аның беренчесе... Анысы да калды күңелдә. Якты дөньядан бик иртә китте ул. Бик иртә...

Баяным белән ялгыз калам да уйга батам. Гел моңлы көйләр уйныйм. Моң юата мине...

Елама, өзлегерсең, баяным,
Авыр чакта сиңа таяндым.

Безнең авыл тулы гармунчы иде бит, Алмаз дус. Дүрт абыем да хромкада теттерә, каршыдагы йортта, янәшәдәге күршеләр – ярышып уйныйбыз. Әти әнине җырлата. Алар миңа «уйнасын» дип куәт кенә биреп торалар иде. Аннан соң самоучитель сатып алдым, грамотно уйнарга өйрәнер өчен. Радиодан Марс Макаровны тыңлыйм, Рәфкать Гомәровны. Шулар кебек буласы килә, малай! Аларча уйнаган булып шактый остардым. Бөтен авыл һәвәскәрләрен җырлатам. Җырчыларга ничек уйнарга кирәген дә аңладым. Радиога колак белән ябышып, баянчыларның

Габдулла Рәхимкуловка, Зифа Басыйровага, Рәшит Ваһаповка, Таһир Якуповка, Илһам Шакировка, Әлфия Авзаловага ничегрәк уйнаганнарын тыңладым.

Авыл малае булгач, табигать кочагында җилнең ничек искәнен, шаулаганын, сызгырганын, чишмәләрнең ни төсле чылтырап акканын белеп, суының тәмен татып үсәсең бит инде ул. Кояшның көлгәнен, айның сагышланганын, йолдызларның җемелдәшкәннәрен күргән бала бит мин. Икмәк иккән, терлек караган кеше; сандугач, тургай сайравына сокланган; адәм хәсрәтен, шатлыгын уртаклаша торган йөрәгем бар.

Ул Фаянур сеңлемнең, Нәфига апамның игелекләрен гомергә онытасым юк. Күршем Сабирҗан абыйның, колхоз рәисе булган Равил Әмин улының, гомумән, туганнарымның, барлык авылдашларымның нинди гүзәл кешеләр икәнен сөйләп бетерерлек түгел. Күңелем тула, күзләрем яшьләнә...

Эх, дускай, бер озаклап очрашып, рәхәтләнеп сөйләшергә җай табыйк әле. Бетмәс бу дөнья мәшәкатьләре! Синең җырдагыча матур итеп яшисе килә!..

Сыерчыклы, сандугачлы,
Тургайлы һәм гармунлы,
Сагнам, сагнам ал кояшлы
Туган-үскән ягымны.

Ниһаять, очрашырга сүз куештык. Баянын да алып килергә куштым. Үзенә көй язарга бер җыр тексты да әзерләгән идем.

Нинди көннәр килде безгә:
Сиблә нурлар өстебезгә,
Уңда дуслар, сулда дуслар –
Бүләк булсын бу җыр сезгә!

Мин онытылып шигыремне укыган вакытта Әхмәт яныма килеп баскан булган.

– Каяле, каяле, – дип, җыр өчен язган текстны кулымнан алды да, уйнап, җырлап та җибәрде.

Нинди көннәр килде безгә:
Сиблә нурлар өстебезгә...
............................................

Кәгазьгә карап, ахырына хәтле канатланып җырлады ул аны. Көен әллә хәзер генә уйлап чыгарды шунда, әллә әзер көе бар идеме? Сорап тормадым. Анысы әһәмиятле түгел – нәтиҗәсе әйбәт!

Әле һаман кул биреп күрешә алганыбыз юк, уйный да уйный. Икенче көйгә тотынды – бергә эшләгәндә җырлап йөргән көйгә.

Күптән инде, күптән очрашкан юк,
Хәтерлимсең бергә чакларны?
Күңелләрдә йөргән татлы сагыш –
Шул чакларның моңлы ядкәре.

Мин дә кызып киттем.

– Әхмәт, әйдә, булгач булсын, тегесен дә сыздырыйк. Үзебезчә...

Уңда юллар, сулда юллар,
Юлларга кемнәр чыгар.
Таңда егет җырлап узса,
Кыз йөгреп каршы чыгар.

Әхмәт, җырның мәгънәсен кирегә борып: «Чыгар, бар!..» – дип тора.

Әхмәт, җырны бозып торма,
Чыгар да сугып егар.

– Куй әле баяныңны! Сөйләшик, искә төшерик бергә чакларны, үткәннәрне. Хәтерлисеңме теге иртәнге биштә дворниклар өчен куйган концертны?

– Хәтерләмим, дисәң дә була... Рәхмәт сиңа, сүземне тыңладың.

– Ничек тыңламыйсың ди. Син бит ул – Син!

– Сөйлә үзең, мин шуны кырык тапкыр тыңларга әзер.

– Берзаман син миңа, Алмаз, сорарга да кыен инде, кәнишне, бармасаң да үпкәләмим, – дисең.

Мин нәрсә әйтергә теләгәнеңне аңламый торам. Аңлата башладың:

– Үзең беләсең, анда булганың бар, подселениеле фатирның бер бүлмәсендә существую. Яшим, дисәң дә була.

– Әйе, беләм, күрдем, минәйтәм.

– Ул почмак миңа дворник булып урнашкан өчен бирелгән иде. Аңлыйсыңдыр. Мин, кәнишне, урам себереп йөрмим, ләкин бәйрәмнәрдә йортлар идарәсенең барлык мероприятиеләрендә уйнарга кирәк. Менә шуның өчен бирделәр ул комнатны миңа. Акчасын кемдер ала инде аның, чурт с ним, кирәкми – ләкин йокларга урын бар, – дидең.

– Әйе, нәкъ шулай.

– Менә шул комнатада яшәүне оправдать итү йөзеннән, «Кызыл почмак»та дворникларга сәгать биштә концерт куярга кирәклеген әйттең. Мин ничек каршы килим инде. Син миңа гомер буе булышып йөр дә... Әйттем, әбизәтелне киләм, дидем. Куллар бирештек тә аерылыштык – икебез ике якка. Иллешәр метр киттек микән, син миңа кычкырасың:

– Алмаз, туктале, әйтергә онытканмын, ул кичке биштә түгел, ялгыша күрмә, иртәнге биштә, – дидең.

Нәрсә инде, вәгъдә биргән, иртәнге тек иртәнге...

Кичен иртәрәк ятып йокладым да иртән дүртенче яртыда хатынга сиздермичә генә торып чыгып киттем. Шәһәр транспорты йөрми. Күк – болытлы, төн – караңгы. Этләр кайтып беткән, мәчеләр генә йөри урамда. Кайсыдыр түбәдә мәхәббәт куертып йөргәннәр, күрәсең. Ялгышып кына берәр транспорт куып җитмәсме дип, артка карый-карый, син әйткән җиргә – автовокзалга төшеп җиттем Совет мәйданыннан. Кайда икән инде бу домоуправление, дип, төнне актарып йөри торгач, бер йорт артыннан син пышылдап кычкырасың:

– Алмаз, Алмаз, монда кил, монда... Юл буе уйлап килгән идем, мәйтәм, кем булсын инде иртәнге сәгать биштә концерт карарга килүче. Син миңа барышлый концертны ничек башлау өчен күрсәтмәләр биреп өлгердең.

– Хәзер керәбез, син, чишенеп, концерт кәчтүмеңне кия торырсың. Мин сәхнәдә «Совет Армиясе маршы»н уйныйм. Минем уйнау сиңа күренеп торачак. Син шул арада киенеп бетәргә тырыш. Мин дә сине күрәм, өлгермәсәң, яңадан уйный башлыйм.

Шунда уйлап куйдым: «Ничек була икән инде бу – 8 нче Март – Хатын-кызлар көнендә «Совет Армиясе маршы»н уйнау? Килешеп бетәр микән?..»

Ярар. Киендем. Сәхнәгә чыгуым булды, әллә кайлардан чиләкләр, көрәкләр, ломнар ишелеп төште. Мин җырлап җибәрдем.

Дарите женщинам цветы,
Как символ поклонения...
............................................

Менә шулай, начальниклар дворникларга бүләкләр өләшеп, бездән җыр тәкъдим итеп, сәгать ярымлап бәйрәм тантанасы үткәрдек. Исеңә төштеме?

– Әйе, төште, дисәң дә була... Ну шәп чыкты ул концерт, әйеме?

– Кәнишне, безнең икәү бергә куйган концертның кайчан начар булганы бар, Әхмәт дус?!

– Синең булышлык белән инде, Алмаз туган.

– Юк, уңыш – безнең бердәм булуда.

Шуннан соң өйгә кайтып яттым бит инде шәһәр транспортында. Трамвай-троллейбуслар йөри башлаган иде.

Берзаман хатын касыкка төртә:

– Тор, хөрәсән, йоклап ятасың, син бит Әхмәткә концерт куярга барырга вәгъдә иткән идең, – ди.

– Концерттан кайттым бит инде, – мәйтәм.

– Алмаз дус, мин үземнең язмышымның музыка юнәлешендә китүенә бик сөенәм. Музыка дөньясы мине милләтебезнең зур шәхесләре белән очраштырды. Күңелемне баетты. Бергә эшләгән еллар да заяга үтмәде. Син булмасаң, Ленинград хәтле Ленинградны күреп кайта алыр идемме? Телевидениедә еш күренә башлавым да шул чорда. Син җырлаганда уйнавым күп җырчыларны кызыктырды, аларны да аккомпаниатор буларак җырлатуга каршы килмәдең, киресенчә, хуплый гына идең. Бер сүз белән әйткәндә, бик шат, бик канәгать мин үземнең баянчы булып китүемә.

– Әхмәт, ә бит бәләкәй чагыңда табиб буласың килгән.

– Әйе шул. Мин, әниләргә ияреп, үләннәр җыярга ярата идем. Һәр үләннең нинди авыруга каршы дәвалану өчен кулланылуын белеп үстем. Хәзер дә берәр чир ябышса, аптекадан дару алырга ашыкмыйм, җыйган үләннәремнән файдаланам. «Бакаларга» да операция ясаганым булды. Кайчак баян ватылгалый. Аның да эчен актарып, кирәкле дәвалау чаралары үткәреп алам. Менә әле баянның сулыш алу системасын төзәткәннән соң, бер җыр яздым.

Минем хыялымда яши иде күптән
Синең кебек чибәр яр табу.
Җиңә алмам кебек кыюсызлыгымны,
Дәвам итәр инде бу яну.

– Оныта алмыйсың икән шул син «икенчесен»...

– Аның белән укыганда таныштым. Тулай торакта күрдем мин ул кызны. Безнең блокта тора иде. Ошаса ошый бит, нишләтәсең аны?.. Бик күңелемдә калды. Исеме – Галиябану иде.

Таң әтәчләре кычкыра,
Әллә таң ата микән...
......................................

Карарак кына, түгәрәк йөзле... Безнең аның белән саф мәхәббәт булды. Яраткач шулай – кул тотышып йөри алсаң да, үзеңне бәхетле сизәсең. Кәнишне, бер мәртәбә... Ни... Ярар, анысын кирәкми әйтергә...

«Мине көт!» – дим. «Ярар, көтәрмен», – диде. Укуын тәмамлады да авылына кайтып китте, ә миңа тагын бер ел укыйсы калган иде. Бәлки, миңа аны җибәрмәскә кирәк булгандыр?.. Нишлим соң, торыр өчен юньле җирем дә юк, бандитлар белән янәшә яшим. Үзем дә, алай-болай була башласа, ягъни ишекне ватып керсәләр, өченче этаж тәрәзәсеннән тышка бау асылындырып калдыра идем бит, чыгып качарга.

Шулхәтле йөрәгем сызлады, кияүгә чыгуын ишеткәч. Тормышымның яме калмады. Бу халәттә баяным юата иде.

Менә тагын күзләр җитте,
Менә тагын яфрак коела.
Салкын көзнең сары төсе
Сагыш сала, күңел боега.
Кайдан сине эзлим икән,
Кошлар белән китим микән?!
Иңнәремдә талмас җилкән,
Юлларымда сары чирәм.

Алмаз дус, сине дә сөйгән ярың армиядән көтеп алмаган түгелме соң?

– Шулай булды шул. Шуңа күрә мин синең ул чактагы хәлеңә керә беләм.

Кил син, кил син, үзең кил,
Яратам – шуны бел.
Кил син, кил син, үзең кил,
Әлегә соң түгел.

Әхмәт, хәтерлисеңме, безне, Тау Иле дигән авылда концерт куйгач, төн кунарга балалар бакчасына урнаштырдылар. Анда Җыр һәм бию ансамбленнән Извил дә бар иде, концерттан соң табын оештырдык. Мин кызыл шәраб бүләм, Извил, инде аның тәмен күптәннән тоеп, иренен ялый. Ансамбльнең Япониядә концертлар куеп кайткан чагы гына бу. Извил китәр алдыннан сиңа: «Әхмәт дус, әйт, Япониядән нәрсә алып кайтыйм үзеңә», – дигән. Ул вакытларда ил буйлап чыра яндырып эзләсәң дә, теш пастасы табар хәл юк чак. Тоткансың да әйткәнсең, булдыра алсаң, теш пастасы алып кайт, дип. Ярар, дигән Извил. Менә кайтканнар болар. Мактана ди теге, егетләр, Япониядән төсле телевизор апкайттым, килегез, бергәләп карап утырырбыз, янәсе.

Әйе, төсле телевизорлар да булганын ишеткәнебез бар, әмма күргән юк. Ну Извил мактаныпмы-мактана ди. Үзе чокырындагы шәрабын авызына чөмәлтә дә колбасага үреләә. Син, аның кулына сугып, колбасасын бәреп төшергәч:

– Кончай, Извил, телевизор турында сөйләргә. Син миңа теш пастасы алып кайттыңмы? – дигәнсең.

Тегесе алып кайтмаган, күрәсең, әллә оныткан, үзенекен туглый:

– Мишәйт итмә әле, Әхмәт, сөйләп бетерим. Егетләр, парнуха күрсәтә торган видик апкайттым. Сезнең андый нәрсәне гомерегездә дә күргәнегез юк.

Ә син яңадан Извилгә:

– Кончай парнуха! Син миңа теш пастасы апкайттыңмы?

– Әхмәт, дим, тыңлап бетер. Бөтен гаиләмә җитәрлек спортивкалар алдым. Балаларга кечкенәдән алып үскәнчегә кадәрле – төрле размердан.

– Извил, не испытай терпение! Последний раз сорыйм, син миңа теш пастасы апкайттыңмы?

– Юк, Әхмәт, оныткан мын.

– Вәт, дус, дигән була. Мин сиңа иртәгә булачак концертта уйнамыйм. Теш чистартылмаган – паста юк!..

Исеңә төштеме, болар, Әхмәт?

– Төште, дисәң дә була... Ну, менә, уйнамыйм дип әйткәнем хәтердә калмаган.

– Да Извилне кызык иткәнсең син анда. Бетереп ыргыткансың, бөтен Япун дифициты белән... Кстати, синең үз ишләреңне генә түгел, зур гына кәнәфидә утырган дәрәҗәле җитәкчеләрне дә төп башына утыртканың булды. Хәтерлисеңме?

– Геннадий Васильевичнымы?

– Әйе. Профком председателен.

– Ничек иде әле ул?

– Хәзер сөйлим, Әхмәт. Менә болай. Мин бу кызыкны төгәл беләм. 9 нчы Май – Җиңү көне иде. Клуб каршында, Бөек Ватан сугышында һәлак булган төзүчеләргә куелган обелиск янында концерт куярга кирәк. Халык күп, моңа хәтле уйнаган музыка тынып тора, һәр адым җаена чутланып яңгыраган чекелдәү тавышына төзелештә эшләп дан казанган егетләр чыршы ботакларыннан җыелган озын гирлянда чыгаралар. Аны обелиск постаментына ипләп куйганнан соң, кызыл тасмасына язылган сүзләрне укырлык итеп төзәткәләп алалар. Клуб баскычында – район җитәкчеләре, хезмәт батырлары. Озакламый шуларның кайсысы булса да тантаналы доклад укый башлар. Аннан соң – безнең концерт. Мин син килеп чыгарга тиешле клуб почмагына карыйм. Нишләп күренми соң инде бу Әхмәт һаман, дип пошаманга төштем. Син килеп җитмәсәң дә, вокаль-инструменталь ансамбль егетләре белән концерт куябыз инде куюын. Ләкин син булсаң, тагын да яхшырак. Мин – бу бәйрәмгә җаваплы кешеләрнең берсе – клуб директоры, чүтеки.

Юк, күренмәдең. Бөтен җырларымны син киләсе якка карап башкардым. «День Победы»ны җырлаганда, Геннадий Васильевич та кушылып торды әле янымда. Соңгы аккордны бирү белән:

– Кайда безнең Әхмәт? – дип сорап куйды.

– Кайдадыр монда, – дигән булдым.

– Күренү белән миңа керегез. Эштән куам мин аны! – ди.

– Мин ул көнне теге кызның кияүгә чыкканын ишеткән идем. Үземне үзем кулга алалмыйча азапландым. Беләм, клуб янында бәйрәмдә уйныйсымны да, үземнең кирәк булачагымны да. Сезне уңайсыз хәлгә калдырачагымны да уйлыйм. Нәрсә әйтсәләр дә әйтерләр дип, соңга калып булса да килдем мин ул көнне.

– Менә хәзер генә әйтәсең бит әле сәбәбен, бүген генә. Аннан соң Геннадий Васильевич чакырды. Кердек бүлмәсенә. Торабыз ишек катында сүзсез. Мин әйтәм:

– Менә, Әхмәт!

– Күрәм. Әхмәт, син нигә эшкә йөрмисең? – ди. Тыныч кына сөйләшә кебек үзе.

– Менә бит килдем, – дисең.

– Пожардан соңмы? – ди бу, җәелебрәк китеп. Нәрсәдер әйтеп бетерми, һаман тыныч. Ручкасы белән өстәлгә шакылдата. Пауза. Көтәбез, тагын нәрсә әйтер?..

– Алмаз Наилович үзе өчен дә, синең өчен дә, башкалар өчен дә бәйрәмнең башыннан ахырына кадәр берүзе пахал.

Мин сөйләшү, катлауланып, кире якка китмәсен дип әйтеп куйдым:

– Әйбәт баянист!

Геннадий Васильевич кызып китте.

– Яхшымы, начармы, ул турыда сүз бармый. Мин үзем дә беләм аның шәп музыкант икәнен. Ләкин ул эшкә йөрми бит. Безгә андый кешенең нигә кирәге бар, ә?..

Син дә кыза башладың.

– Дөресен әйткәндә, Геннадий Васильевич, синең урында эшләргә много ума не надо. Монда любой кеше эшли ала, шул исәптән мин дә. Менә мин сиңа хәзер баян алып киләм, шиш син анда уйный аласың...

– Әхмәт, эш бит анда түгел, теләсә нинди урында эшкә йөрергә кирәк! Понял!

Син бөтенләй башка тонга күчтең:

– Эх, Генка, Генка?!. Мин сиңа әйтер идем дә инде... Монда хөрмәтле Алмаз Наилович бар...

Әле генә «Геннадий Васильевич» идең, шундук «Генка»га күчтең! Әллә инде Геннадий Васильевичны «ераккарак» җибәрмәкче буласыңмы дип котым очты.

Геннадий Васильевич, ни әйтергә белми, телсез калды. Аптырап торды-торды да өстәл тартмасыннан бер ярты чыгарып, дык итеп өстәлгә утыртты. Син моны күрдең дә:

– Вәт, күптәннән шулай итәләр аны. Ату куам да куам дип куркытасың! – дидең.

– Утырып салдык та аңлаштык. Шуннан соң, әле мин клубтан киткәч тә, син аның белән байтак еллар бергә эшләдең, әйеме?

– Шәп егет иде Геннадий Васильевич! Исән-сау микән?

– Соңгы елларда күрешкән юк, ә менә элегрәк, инде без эшләгән клубның нигезе дә калмаган чакта да әле, еш очраша торган идек. Һәрвакыт кочагын җәеп каршыга килә, сезнең кебек талантлы егетләр бүтән булмадылар клубта, дия торган иде.

– Үзең дә син, Алмаз дус, теләсә-нинди җитәкчене төп башына утырта торган идең. Бермәлне, клубта «День советской семьи» үткәрәбез. Андый бәйрәмнәрдә конфет-прәнникләрне кибеттән клубка китертеп саттыралар иде. Кеше тамаша карарга түгел, шул прәнникне алырга кызыга. Чират, ызгыш, талаш. Райкомнан берәр тикшерүче килә ул көнне. Бәйрәм ничек бара, оештыру дәрәҗәсе нинди, кино күрсәтәләрме, концерт куялармы, янәсе... Безнең фойе матур – гөлләр кыш буе чәчәк атып утыра. Менә шул матурлыкның, оешканлыкның бөтен яме прәнник сатканда югала иде инде. Гөлләр шау-шуны, сүгенү, талаш-елашны кичерми, сула, диләр. Дөрес икән, бәйрәмнәрдән соң бөгелеп төшә гөл сабаклары.

Карап торам урам якка. Фойе бит гел пыяладан. Клуб каршысына бер «Волга» килеп туктады. Ай, сылу да, ай, чибәр дә ханым килә түгелме клубка. Керде дә:

– Нинди тәртипсезлек бу?! – диде акырып. Бөтен матурлыгы коелып төште минем күңелдә. Гөлләр дә, лып итеп, тагын да ныграк аска иелделәр.

Райкомның идеология секретаре икән.

– Директорыгыз кайда? – ди, тагын да яманрак җикереп. Син шунда гына йөрисең бит инде. Каршына бастың да:

– Мин, – дидең.

– Нигә монда шаулыйлар?

– Прәнник, кәнфит алалар. Бәйрәмгә китерделәр. Әйтегез әле, сез үзегез кем соң?

– Райкомнан, тикшерүче.

– Хөрмәтлем, менә мин сиңа нәрсә әйтәм, клуб ашамлык сата торган урын түгел, аның өчен махсус кибетләр бар. Ә шау-шу мәсьәләсенә килсәк, миңа калса, сез башкаларга караганда үзегез ныграк шаулыйсыз...

– Кабинетыгыз кайда? – диде бу сиңа.

– Сезнең бу клубта моңарчы бер мәртәбә дә булганыгыз юк, хәтта директор кабинетының кайда икәнлеген дә белмисез, – дидең дә ирләр туалетына төртеп күрсәттең. Ә ул әллә ни карап-нитеп тормыйча керде дә китте шунда һәм атылып килеп тә чыкты. Анда шушы район малайлары, шырпы яндырып, түшәмгә атып яталар икән.

Машинасына утырып шылды мадам райкомына. Ун минут та үтмәде, Геннадий Васильевичтан: «Син анда нишләдең тагы, кил әле минем янга», – дигән хәбәр килде.

Шуннан әйләнеп кайткач аңлашылды, теге мадам: «Эштән куарга!» – дигән фәрман биргән. Ә Геннадий Васильевич: «Синсез мин нишлим, давай болай итәбез, директорлыктан төш, худрук бул, мин сиңа тагын бер полставка өстим», – дип шатландырган. Өстәвенә аркадан сөеп: «Молодец!» – дип тә куйган.

– Әйе, кулны кысты, настоящий татарин икәнсең! – диде.

Шуннан соң бернәрсә дә үзгәрмәде, клуб эше шул ук дәрәҗәдә гөрләп барды. Аерма шунда гына иде: минем хезмәт хакым 40 сумга артты.

Әхмәт, клубта Гариф абый Ахунов кичәсен үткәргәнне хәтерлисеңме?

– Хәтерлим, дисәң дә була... Син башта аның бөтен әсәрләрен укып чыктың. Аннары шул әсәрләрдән тамашачыларга өләшер өчен сораулар яздың, тараттың.

– Халык күп, залда аяк басар урын юк иде.

– Ә сәхнәне ничек әзерләдек? Болай да кечкенә сәхнәгә Вокаль ансамблнең бөтен инструментларын баскыч ясап урнаштырдың, иң өскә барабаннар куйдырттың, Гариф абый алдында торачак журнал өстәленә микрофоннар тездерттең, алтысының берсе генә эшли иде, кырыйларда гитаралар, шуларның икесе генә уйнарга яраклы, баян, гармуннар – төзек дип чутлардай инде. Залга һәм сәхнәгә төрле нурлар чәчеп әйләнүче шарны түшәмгә элдерттең дә, аны колга белән әйләндереп тору өчен, бер егетне яллadың. Ул, ишек артына качып, шарга төрткәләп торды. Икенче малай кичәнең ахырына кадәр шул шарга прожектор нуры җибәрү белән мәшгуль иде.

Менә син Гариф абый белән сәхнәгә чыгып киләсең. Зал алкышларга күмелде. «Дулкын» вокаль-инструменталь ансамбле егетләре, кичәнең музыкаль прологын төгәлләп, сәхнәдән чыгып киттеләр. Гариф абыйга сүз бирелде.

Әй, рәхәтләнеп тә, хозурланып та сөйләде инде Гариф абый. Үзенең кайда, ничек туганын, ниләр кылганын, әсәрләренең геройларын, дусларын, гаиләсен... Үзенең, җитлекмичә туганга күрә, җылына алмый йөдәгән чакта, ипи калагына салып мичкә тыгып алуларына хәтле сөйләде.

Халык сораулар бирергә тотынды. Яудыралар гына син язып биргән кәгазьләрне. Үзең дә молодец, төрле почерк белән кыландыргансың.

– А как же, шикләнергә мөмкин даһиебыз...

– Гариф абый, бармакларыннан тарак ясап, куе чәчләрен ыргытып тарый. Кыяфәтендә – бөеклек! Шулай булмый, әнә нинди сораулар бирәләр бит! Ялкынланып җавап бирә әдибебез! Залга карап: «Минем иҗатымны нык өйрәнгән укучыларны бу хәтле күптер дип белми идем», – ди.

Озак барды кичә, ләкин бер тын белән, сизелмәде дә ике сәгать вакыт үткәне. Соңгы сорауны син бирдең:

– Гариф абый, 18 сентябрьдә туганнарга син ничек карыйсың?

Бу сорауның хәйләсе яки сере бардыр ахрысы, дип, әдип уйга калды. Кирәккән хәтле генә тынып торды да сүзен дәвам итте.

– Беләсезме?.. 18 сентябрьдә туган кеше... бик тырыш, уңган-булган, талантлы, тышкы кыяфәте дә начар түгел, хәтта – чибәр... – Кыза әдибебез, матур сүзләрне мулрак тезә... – ...зыялы, кешелекле, рухи яктан бай, мәдәниятле, язучы булырга да мөмкин, галимлек тә ерак йөрмәс, даһи... бер сүз белән әйткәндә, минем кебек булырга тиеш, – дип тәмамлады.

Син шунда: «Гариф абый, синең 18 сентябрьдә туганыңны беләм, менә син минем дә шул көнне туганлыгымны беләсең микән? Рәхмәт сиңа, мине дә бик югары күтәргәнең өчен, дип әйтеп салдың.

Ну гөрләде инде халык, торып кул чаптылар. Ни дисәң дә, алларында, Гариф абый фаразлаганча, ике даһи басып тора икән бит.

– Шулай, Әхмәт, ул вакытта Казанның барлык күңелле кичәләре безнең клубта үтә иде шул. Мәдәни учагыбыз – үзәккә әйләнде. Синең дә өлешең зур монда.

– Алмаз дус, мин синең кешелеклелегеңне хөрмәт итәм. Үзеңнең бер игелегеңне искә төшерим әле... Беләсең син, минем бик якын дустым бәлагә дучар булгач, дөресрәге төрмәгә эләккәч, ярдәм кулы сузудан баш тартмадың.

– Әйе, исемдә әле синең ул чактагы кайгырып йөргәннәрең. Беләм, юктан гына эләккән иде бит ул анда. Шуңа күрә, аның хөрмәтенә, аның гаиләсенең иминлеге өчен, синең белән минем дуслык хакына берсүзсез ризалык бирдем... төрмәгә барып концерт куярга. Күңелем белән сизә идем, син бит бу гамәлеңне аның өчен эшләдең. Бераз утыру срогын киметмәсләрме, азрак аңа карата җылырак мөнәсәбәте булмасмы дип уйлагансыңдыр инде, әйеме?

Минем гомергә дә төрмәне күргәнем юк иде. Безне бер татар майоры каршы алды. Икәү, төрмә ишекләрен ача-ача, алдан баручы артыннан атлыйбыз. Кайбер борылмаларда тоткыннар утыра. Нигә аларны анда куйганнар? Без үткәндә, тыйнак кына торып басалар. Һәр җирдә чисталык, пөхтәлек, тынычлык. Менә бер зур бүлмәгә килеп чыктык – актовый заллары шушыдыр инде. Сәхнәсе бар, урындыклар тезелгән. Безгә әзерләнергә аз гына да вакыт калдырмыйча, авыл клубларындагы кебек шау-шулы булып түгел, тыныч кына, залга тоткыннар кереп тулды. Майор, башлагыз, дигәндәй, кулын изәде. Мин Мартыновның: «Посидим по-хорошему, Пусть виски запорошены...» дигән сүзләренә язылган җырын башлап җибәрдем. Уф Алла, нишлим мин?.. Сүзләре нинди бит – «посидим по- хорошему...» Нишләп бу турыда уйламаганмын, вәт җүләр... Бу җыр монда җырлый торган түгел ич. Оятымнан уң якка карадым. Стенаның куе зәңгәр буявы өстенә «У нас в гостях» дигән стенд ябыштырганнар, анда Миңгол Галиевның егермеләп фоторәсеме миңа карап тора. Үзем җырлый торам, үзем уйлыйм – шул гына җитмәгән иде дип. Ирексездән сул якка борылдым. Анда да без белгән таныш артистлар рәсеме. Шундый ук «У нас в гостях» стенды. Ярый әле саташмыйча җырымны тәмамладым. Сиңа нәрсә? Син уйныйсың да уйныйсың, изге эш башкарасың. Һәм шулчак зиһенем ачылып китте: нинди зур игелекле гамәл кылганнар шушы Миңголлар һәм артистлар монда килеп. Мин дә шул юлда. Күңелдә горурлык уянды. Беренче җырны башкаруым мәзәк булса да, изгелек, игелек кылуым мең мәртәбә әһәмиятлерәк икән бит.

Кырык минутлык концертыбызны яратып карадылар. Мин кайчандыр җинаять эшләгән кешеләрнең күзендә яшь тамчылары күрдем, йөзләрендә киләчәккә матур өмет чаткылары чагылуын тойдым.

Аларга безнең кулны кысарга, рәхмәт әйтергә рөхсәт бирделәр.

Без төрмәдән якты хисләр белән урамга чыктык. Анда җил купкан, кайсыдыр чүплектән һавага күтәрелгән сасы кәгазь кисәге битемә кагылып үтте, нindidер исерек, сүгенә-сүгенә, машиналарны туктатып, ярамаган урында каршы якка чыгып китте, автобустан билетсыз бәндәне тибеп төшерделәр, юл кырыенда басып торган итәксез кызны таллыкка өстериләр.

Без, яңадан халкыбызга әхлак тәрбиясе бирергә, сәнгатебезгә чумдык.

Хәтерлисеңме, Әхмәт дус, мин 2007 елның 24 июлендә «Ватаным Татарстан» газетасында бер мәкалә бастырган идем.

– Хәтерлим, дисәң дә була... Минем турыда язылган иң матур мәкаләләрнең берсе ул.

– Синең белән, Әхмәт, без – совет чоры кешеләре, безнең башка тәрбия:

«кешенекенә тимә, кагылма, намуслы бул һәм башкалар»... – дигән юллар белән башланган иде ул. Һәм дәвам иттем... Бик килешеп бетми безгә хәзерге җәмгыять. Сорый да алмыйбыз, биргәненә шөкер дип яшибез. Син әйтәдерсең: кая ул артист дигән бәндәгә үҗәтләнү, хирург яки милиция түгел бит без, диярсең.

Ул елларда синнән еш кына, нәрсә, Әхмәт, ямансулап йөрисең, бер-бер хәл булмагандыр бит, дип сораштыра идем. Җавабың бик анык...

– Яшь бара, Алмаз дус... Менә уйлап йөрим әле, бер рәт юк инде, малай, безнең братка. Нигәдер якты дөньядан артистлар бик үкенечле китә. Кемнәрдер гомер буе эшләп танылмыйча онытылалар, кайсылары ачы язмышын аракы белән агулап йөри, күпләре соңгы көннәрен хәерчелектә үткәрә, кемдер фатир да ала алмаган. Минем әле, Аллага шөкер.

– Син һаман шул өчкә өчтәме?

– Кайда булыйм инде – шунда.

– Соңгы җөмләләрен хәтерлисеңме ул мәкаләнең?

– Бик хәтерлим. Йөрәк өзгеч итеп язгансың син ул юлларны.

«Аның тәрәзәсеннән Татарстан урамына ниндидер көй агыла. Яңа җыр яза бугай. Ничек язып утырганы күз алдыма килә. Тар бүлмә. Өстәл. Бер урындык. Баянын ныгытып тартып җибәрсә, сул кул ягы стенага шакылдатып, күршеләрнең сабыен уятырга мөмкин. Уйна, Әхмәт дустым, җайлап кына уйна, бәлки, әлеге сабый синең моңга изрәп йоклыйдыр. Ә минем колакта синең ачынып әйткән сүзләрең яңгырый. «Мин якты дөньядан кайчандыр китәрмен. Баяным калыр. Алырлар, уйнарлар. Ләкин минемчә булмас...»

– Ашыкма, Әхмәт дус, алай уйларга. Әле синең алачак иркенрәк фатирыңда, киерелеп, баяныңны тартасың бар. «Фатир бирергә!» дигән кәгазьгә күптән кул куелган, менә шуны эзләп кенә табасы бар», – дигән идем мин шул сагышлы мәкаләдә.

– Минем данлыклы Галиәсгар Камал театрында эшли башлавым – гомеремнең иң матур чоры. Андагы җитәкчеләр, артистлар яшәүгә, иҗат итүгә дәртемне арттырдылар. Мин андагы һәр артистны әүлия итеп күрәм, беләсеңме? Бөтен җитешсезлекләре белән. Театр гаҗәп нәрсә икән ул! Театрдагы бөтен кеше – бер гаилә. Бөтенесе якын, хәтта вахтёрлары да, вешалкада эшләүчеләре дә, администраторлары да... Күп алар анда... Менә шул гаиләнең бер бәләкәй генә «шөребе» турында сөйлим. Үзең беләсең, күргәнең дә бар, чишенгәнең дә. Театрда хезмәткәрләрнең, шул исәптән килгән-киткән кешеләрнең өс-киемнәрен элеп кую өчен аерым бүлмә бар. Шунда бик тә сөйкемле апа эшли иде. Стенасы пыяладан корылган шушы бүлмә тәрәзәсеннән аны күрүгә, чишенмәс җиреңнән чишенерсең. Мин аның янында озак туктап торам. Дөнья, театр хәлләрен, артистлар тормышын, үземнекен дә сөйлим шунда. Рәхәт, яныннан китәсе килми. Әйтәм ич, үзенә тартып, җәлеп итеп тора, дип. Театр директоры Шамил Зиннурович кадрлар таба белә иде инде ул. Апа әңгәмәбезне гел Шамил Зиннуровичка рәхмәт әйтүдән башлый. Килгән саен, күргән саен. Әкренләп сүзебез мин килгәнче аның яныннан үтеп киткән Равил абый Шәрәфигә күчә. Үтереп мактый инде аны. Аннан сүзе Хәлим Җәләловка борыла. Белә ул аның минем якын дус икәнен. Шамкай театрдан китте бит инде, дип куя. Аның өчен борчылуын белдерә. Әйт әле, килсен, интегеп йөрмәсен анда әллә кайларда концертлар куеп, ди. Алалармы аны яңадан театрга, юкмы, анысы мөһим түгел. Ләкин апаның күңеле киң, кешегә игътибарлы, мәрхәмәтле. Пышылдап кына: әй, нәрсәгә йөрсен инде ул монда, шушы пүчтәк акчага, дип тә ала, як-ягына каранып. Сөйләшәбез шулай. Ара-тирә яныбыздан артистлар үтеп китә. Кайберләре белән кочаклашып исәнләшәбез. Яраталар үзеңне,

ди апа, үзең дә әйбәт кеше шул син, дигән була. Ничек сөйләшмисең инде шундый кеше белән, ничек туктамый китәсең?!

Хушлашканда, ул миңа нинди дә булса дөньяви хәсрәтен әйтеп, уфтанып куя иде. Әхмәт, җаным, Шәймиев китә ди бит, нишләрбез икән инде, ди. Әй, апа, мәйтәм, хәкимияткә кем килсә дә, сиңа вешалкада эшләргә, миңа авыллар буйлап концертлар куеп йөрергә инде, дим. Әй, кычкырыплар көлә инде. Көлгәч, ул тагын да матурая иде.

Менә шундый матур кешеләр эшли икән театрда. Рәхәтләнеп җанымны биреп йөри башладым шунда. Илебезнең кайсы гына почмакларында булмадык, кайларга гына барып чыкмадык. Беләсеңме нәрсә, берзаман миңа армиядә булган җиргә – Ашхабадка барып чыгарга туры килде. Мин бит Төркестан хәрби округында Хәрби-һава флоты гаскәрләрендә элемтәче булып хезмәт иттем. Шунда безне Ашхабадтан ерак түгел җирдә, тау куышындагы бер километр аска төшкәч барлыкка килгән табигый күлдә су коендырдылар. Табигать могҗизасы, ышанасыңмы? Ничек барлыкка килгән ул анда? Суы шулхәтле җылы, дәвалый торган да икән әле. Менә шуны театр артистларына яңадан күрсәттеләр. Мин мактандым инде, коенганым бар бу күлдә, дип.

– Әхмәт, бер кергән суга ике тапкыр кереп булмый, диләр, син кергәнсең. Моны яхшыга юрарга кирәк!

– Беләсеңме, минем солдатта чакта парашют белән самолёттан да сикергәнем булды!

– Кит аннан! Ну, Әхмәт! Ничек булды ул?

– Учениеда. Парашют кидерделәр дә самолётка утырттылар. Вакыты җиткәч, самолетның ишеген ачтылар, һәм солдатлар берәм-берәм ачык һавага сикерә башлады. Мин икеләнеп тора идем, төрттеләр дә төшерделәр. Әй, малай, күктәге рәхәтлекне күрсәң! Төшәсең, төшәсең, төшәсең... Төшәсе дә килми, гел һавада эленеп торасы килә.

– Карале, Әхмәт, син, мөгаен, җир өстеннән аска бер километр төшкән, ә җиргә өстән биш километрдан парашют белән сикергән бердәнбер бәхетле кеше икәнсең бит дөньяда.

– Әйе, бәхетле, дисәң дә була...

– Баянчы да әле үзең! Өйләнмәвең белән дә уникаль шәхес! Тагын бер нәрсә әйтәм...

– Нәрсә инде?..

– Мин синең 50 яшьтә узган банкетыңның видеоязмасын карадым. Анда музыкаль җитәкчең Фоат Әбүбәкеров тост күтәрде. «Әхмәт, давай, өйлән, хәзер өйләнсәң дә соң түгел, 60 яшьтә 9 яшьлек балаң була», – диде. Синең шул сүзләргә кылың да кыймылдамады, ягъни колагыңа да элмәдең. Әллә 60 та өйләнеп карыйсыңмы, 70тә шундый ук яшьтә малаеңмы, кызыңмы булыр иде?

– Шаяртма әле, Алмаз, – диде дә йомды Әхмәт бу теманы.

Ә бит үз гомерендә өзелеп ике кызны гына яратса да, байтагының башын әйләндергән егет!

Баштарак, кызлар мәсьәләсендә юашрак, дип йөргән идем, алай ук түгел икән. Беркөнне, әле клубта эшләгән чак. Әхмәт кирәк. Халтура концертына чакыралар иде. Эзлим, эзлим, юк бу. Клуб вахтёры әйтә, каршыдагы тулай торактагы дусты белән ул, ди. Кызлар да булгандыр әле? Туган көне икән дустының. Таптым боларны. Инде концертка барырга соңга калган идек. Ярым шаярып, Әхмәттән сорыйм:

– Эшләр «пештеме» соң?

– Пеште, дисәң дә була инде, – ди.

Бер юньләп төгәл әйткәне булмас шуның. Әхмәтнеке дигәне тузганак чәчле – шуны тарый. Барып башына өрсәң, бөтен чәче очып китәрдәй.

– Кочакладыңмы соң? – дим, «тузганак башка» баш белән ым кагып.

– Кочакладым, дисәң дә була инде, – ди, колак артын кашып.

Беләсе килә бит боларның нигә монда качып ятуларын.

– Үптеңме соң?

– Үптем, дисәң дә була инде...

Вәт бит, малай, тәки ахыры ничек беткәнен әйтмәде. Сүз белән әвәләп бетерде. Шундый инде ул Әхмәт.

Аның белән йөргән чактагы кызыклар күп булды. Бер җәй көнне Таһир Якупов, Әхмәт, мин мәктәп ишегалдына килеп кердек. Аулак урын. Иртән, кайдадыр концерт куйганнан соң, өчәү көне буе кәеф-сафа корып, кесәләрне такырайтып, Әхмәт уйнап, без җырлап йөрдек. Шул мәктәп бакчасында Әхмәт кинәт исенә төшерде: «Егетләр, мин бу мәктәптә эшлим бит, бәлки, акча бирә торган көндер, кереп чыгыйм әле!» – диде.

Көтәбез, көтәбез Әхмәтне, юк бу. Әллә кайтып китте инде, дип шикләнеп куйды Таһир.

Мин әйтәм, баяны монда бит.

Берзаман чыга Әхмәт. Боек. Егетләр, мине күптән увольнять иткәннәр икән инде, ди.

Камал театрында эшли башлагач булган бер кызыгы бар әле аның. Сөйләделәр.

Кайсыдыр бер спектакльдә, «Зәңгәр шәл»нең «Качкыннар» эпизодындамы, артистлар бик еш «чөнки» дигән сүзне кулланалар икән. Ул спектакльдә музыкантлар оркестр чокырында утыралар бит инде. Оркестрда татарчасы бик үк яхшы булмаган бер егет Әхмәттән сорый ди: «Скажи, пожалуйста, Ахмет, что за слово «чөнки»? Ул бу сүзне урысчага тартымрак итеп әйткәндер инде. Әхмәтнең спектакльне бик үк игътибар белән карап утырмаган чагы булгандыр, теге малайдан бу сүзне ничек ишеткән, шулай тәрҗемә иткән дә биргән. «Это такие маленькие собачки, которые бегают», – дип.

Дөрес әйткән, «Щенки» дигән акцентлы сүзенә тәрҗемә сорамасын иде.

Әхмәт, бик якын дустым булгач, төшкә дә еш керә. Соңгысын сөйлим.


«Күрәм, Камал театры сәхнәсендә берүзе концерт куя бу. Зал шыгрым тулы. Мин дә шунда нишләптер йөрим. Сәхнәгә менмим. Уйный да уйный үз көйләрен баянда, уйный да уйный. Халык шашып кул чаба. Шунда Әхмәт янына, зур чәчәк бәйләме тотып, бик чибәр ханым белән аннан да чибәррәк кыз менде. Бер-берсенә бер тамчы су кебек охшаганнар. Әхмәт аларны тамашачылар белән таныштырды: «Монысы – хәләл җефетем, ә монысы – кызым», – диде. Күзем шар булып карап каттым һәм халыкка кушылып кул чабарга тотындым». Әллә теге гомер буе көткән?..

...Уянып китсәм, кул чабып ятам. Әллә чыннан да шулай микән?.. Тиз генә Әхмәткә шалтыратып, төшемне сөйләп чыктым. Тавышында нindидер канәгатьлек, көлә генә... «Өйләндем, дисәң дә була инде...» – дигән гадәти сүзен кабатлады тагын...

Ышан аңа!..

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Данис
Хәйруллин

# КҮККӘ БАГА, КУЛЛАРЫНА ДОГА АЛЫП

## Кем ?

Эх, бу яраклашу – шашу, –
Яратмасаң – ят алар,
Яраклашсаң – ярканат, дип,
Төн-пәригә саталар.
Очсаң очкылык тоталар,
Очмасаң – очсыз, диләр.
Көчлегә акыл нәрсәгә,
Бик җиткән өч сүз, диләр.

Без! Без!! Без-без!!! Безелди дә
Йә тешли, йә ук кадый.
Хөкемдар кем? – Ар диңгезнең
Аръягында шук казый.

## Әллә?

Киләчәк, дип, көннәр уза, төннәр уза,
Җәйләр җәйләп, кышлар кышлап туннар туза.
Гомер бакый туар белән туендырып,
Әләмнәрен суллар суза, уңнар суза.

Шәп җилферди... Бәлки... ди дә күнә халык,
Сайлауларда сайраша да сүнә халык.
Куш вәгъдәдән, буш вәгъдәдән гаҗиз калып,
Күккә бага, кулларына дога алып:

Йә, Раббым! Без күнеккән – иман, диеп,
Үстерделәр: Иманлыга – инан, диеп.
Вәгъдә – иман! Бу – иманны сату мәллә?
Киләчәккә барабыз, дип, кайту мәллә...

Данис ХӘЙРУЛЛИН (1945) *– шагыйрь; «Хәтер», «Йөрәк тибеше», «Казлар ник көлә?» исемле китаплар авторы. Чаллыда яши.*

## Дөнья белән әңгәмә

– И, дөнья! Син нигә мондый,
Нигә андый булмадың?
– «Андый» булсам – «мондый», – дисең, –
Үзең шундый бул, наным!

– И, дөнья! Игелек белән
Милек нигә бутала?
– Буталмый – игелек кала,
Ә милекне ут ала.

– И, дөнья! Нигә бу акыл
Бераз гына тулмаган?..
–Тулган заманнар булган ул,
Ул чакта син булмаган...

Минем соравыңа җавап – бер, –
Һәркемнең үз дөньясы:
Берәүдә – оҗмах кояшы!
Берәүдә – җен оясы!

Аннарымы... Җаннарнымы
Кайсын кайда куясы?
Үз төсенә буясы да
Үз ташына уясы...

## Барлы-юклы

Туып туймаучылар да бар,
Туып уйнаучылар да,
Ник туганына үкенеп,
Туар-тумаучылар да.

Сабыйны санга сукмыйча,
Туйга батканнар да бар.
Бер кочак бала үстереп,
Чәчәк атканнар да бар.

Бар булгач, бар!
Бар өстенә
Төкереп ятканнар да бар.
Акча, дисәң, ач пәригә
Денен сатканнар да бар.

Барны – юк, дигәннән генә
Юк булмый.
Юк-юк – булмый!
Бу дөнья шундый үзгәрде –
Уңнан сулга укылмый.

## Аптырау

Әллә ничек хәзер, әллә ничек –
Йә ачылмый, йә ябылмый ишек.
Сагындыра салмак тибрәлүче
Матча кадагына аскан бишек.

Бишек урынына гамак корып,
Юксынабыз юкны, тамак кырып:
Утыр идең утызыңа кадәр,
Бишегеңнән аяк салындырып...

Ни майтардык, бишекләрдән төшеп?
Күәс төпләрендә әчеп-төчеп,
Күбекләнеп бер күпергән идек,
Йөрү әле менә әйрән эчеп...

## Язмыш...

Нишләргәме?
Нишләсәң дә, синең кулда!
Фәрештәң бар озатырга озын юлда,
Яшим, дисәң, бер Ходайга башың иеп.
Тагын нинди киңәш бирим, нәрсә диеп?

Матур килеш калыйм, дисәң – иртә кит син...
Моно Лиза булыйм, дисәң – иргә кит син!
Байыйм, дисәң – байга чыгып баеп кара!
Сайладыңмы?
Әнәтерә юлың бара...

Язмыш юк ул!
Күпме генә язсалар да –
Язылмый ул, язылмаган «яса»ларда.
Фиркалегә бирелә ул фиркаләрдә...
Сатылганга сатыла ул кассаларда...

## Кимү

Күп балалы – бал эчмәс, дип, шикләнәбез,
Сан өчен бер сабый белән чикләнәбез;
Әнә, алар ! – Көне-төне үрчеми, дип,
Көнбатышның кабыгына бикләнәбез.

Кысмыр нәсел тиз кысыла, чыдыйк ласа,
Кояш кебек көнчыгыштан чыгыйк ласа.
Ишәйгәннәр исәя бит – искитмәле!
Кибетләрен күбекләнеп товар баса...

Шатлык нигә – илең илә шатланмасаң?
Мәгънә нидә – нәсел-нәсәп сакланмаса?
Тамырларны танучылар каян килсен,
Саныбызны санарлык та сан калмаса?

## Сорау – җавап

Сорыйм әле алагаем кубып зурдан:
Нишләттегез, кая китте Алтын Урдам?
Бурдан кала, уттан калмый, дисәләр дә, –
Бернәрсә дә калмый икән бур убырдан.

Бер сорагач сорыйм инде: кая ханлык?
Ниләр калган, кемнәр калган кеше санлык?
Чит ояга күкәй салыр күкеләр күп...
Алтыннар күп күл төбендә – сандык-сандык...

## Хөсет

Кая ул, таныш-белешкә юл сабу,
Бар эше – тырнак астыннан кер табу.
Шатлана, шәрран яра – шәрә бу! – дип,
Чак ачылып китсә дә итәк, чабу.

Үзе бер ялдыр аңа – яла ягу.
Нидән бу?
Каян килә мондый агу? –
Хөсетлек сөте әчи дә күперә, –
Юк, чаянга тиң түгел мондый чагу!

Ни чара күрик? – Бичара болай да.
Кемгәдер бик кирәк тә ул, кулай да...
Белми тик, теле тәмам корыр көнне,
Тап, җавап тотасын бер Ходайга.

## Чиксезлек

Чиксезлекне оныт, туган!
Бу дөнья – бу! Ул – башка!
Чиксезлекне аңлау өчен
Бераз гына тулмаска,
Тулып җитмәскә тиештер
Акылың да, аңың да...
Чиксезлек ул синнән читтә
Һәм гел синең яныңда:
Яшәү чиксез – туган чакта,
Хыял чиксез – үскәндә,
Өмет чиксез – чәч агарып,
Тәңрең искә төшкәндә.

Чиксезлекне оныт, туган –
Бернинең дә чиге юк!
Туганнар шикләнүчән ул,
Тумаганның шиге юк...

Чиксезлекнең очы, кыры
Булмаган да, булмас та!
Бу каян төшкән таяктыр
Безнең авыртмас башка...

Галәм ничек туган?
Уйласаң, уең җитмәс,
Үрелсәң, буең җитмәс;
Зур шартлау булган галәмдә –
Аңлыйсыңмы син, иптәш?

Галәм яралган шулчак, –
Валлаһ, аттырмыйм борчак, –
Тарыдай таралган күккә
Йолдызлар кочак-кочак.

Күк үзе дә булмаган,
Бушлык та – буш, тулмаган...
Акыл җитәр эш түгел бу –
Бул даһи син, бул надан.

Энә күзеннән миллион,
Миллиард тапкыр кечерәк
Җисем шартлаган да, имеш,
Дөнья туган чәч(е)рәп.

Вакыт, киңлек яралган,
Тавыш, тынлык таралган.
Киләчәктә яралырга
Тагын ниләр каралган?

...Көн тәртибе вәссәлам,
Тукта инде, и каләм:
Шартлаудан туган галәм ул
Шартлаудан булыр тәмам...

Аңлашыйк аек баштан,
Арынып уһтан, аһтан:
Нәрсә бар, булган, булачак –
Барысы да Аллаһтан!

*«Иң шәп хикәя» конкурсына*



Сирень
Якупова

# УРАН

хикәя

Бөтенләй дә төш күрмим, әллә нигә бер күргән кебек булсам да, уянгач, берни искә төшерә алмыйм диючеләрне чын күңелдән кызгана идем мин. Төш күрми генә нинди йоклау ди ул? Иң кызыгы да төштә була бит инде: бер төнне болытларны кулың белән аралый-аралый кош кебек очасың, икенчесендә диңгез дулкыннарын колачлап йөзәсең, өченчесендә биек кыя-тауларга менәсең, чәчәкле келәм түшәлгән болыннарда йөрисең, өрфия итәкле күлмәкләр киясең... Әгәр дә инде төшнең төслесе керсә, ул иртәдә, әкияти дөньяда яшәп кайткан сыман, нindидер бер тылсым ачкандай, яңа туган көнгә серле елмаеп уянасыңны көт тә тор.

Мин үземне белгәннән бирле көн саен диярлек, дөресрәге, төн саен төш күрәм. Тик менә ул төшләр бала чакта, яшьлектә бик матур, якты булып, еллар үтү белән, төсләрен бөтенләй югалтыр, аклы-каралы, күп очракта караңгы, куркыныч саташуга гына әйләнер дип кем уйлаган?! Соңгы елларда йокым да сандугач йокысы шикелле кыска. Ләкин шул арада да әллә нинди борчулы уйларга салырдай төшләр күрергә өлгерәм, билләһи.

Бүген дә шулай булды. Авыр, шомлы төш күреп уяндым. Хәер, таң алдыннан гына күргән төшем белән бәйле хатирәләр мине балачактан ук эзәрлекли. Димәк, элек матур төшләр генә күрә идем, дигәнем дә бераз арттыру булып чыга инде. Тәүге тапкыр бүген күргәненә игезәктәй охшаш төштән сискәнеп, елап уянганда, миңа ун яшьләр чамасы булгандыр. Хәтеремдә, ул кышкы кичне безгә күршеләребез Рәшидә әби белән Фатыйма апа керде.

Алар бик озаклап, иркенләп кич утырдылар: әбекәй йон җегерләде, Фатыйма апа бәйләм бәйләде. Ә әнием безнең теткәләнеп беткән оекбашларга ямау салу белән мәшгуль иде, билгеле инде, кунаклар өчен чәй өстәле әзерләгән – алдагы көнне генә бөкләп туңдырган пилмәннәрне кабартып алган арада.

И ярата идем дә соң мин бу кич утыруларны! Беренчедән, өйдә нинди тәмле әйбер бар, барысы да өстәлгә чыга, аңа күрше әби-апалар кыстырып кергәне дә өстәлә әле. Икенчедән, әни безне, ни кылансак та, ничек йөгерешеп уйнасак та диюем, чамадан артмаса билгеле, ачуланмый, өченчедән... Дөресен генә әйткәндә, миндә ул чакта уен кайгысы да, ашау кайгысы да бик булмый торган иде. Бөтен шөгылем, әни әйтмешли, колакларымны кыр куянындай сагайтып, күзләре песиебезнекенә охшап кысылган, иреннәре тыйнак кына елмайган әби-апаларның көйләп кенә сөйләшкән-серләшкәннәрен тыңлап, күңелемә сеңдереп утыру.

---

Сирень ЯКУПОВА – *шагыйрә, прозаик; «Йолдызлы уйлар», «Яшәү сере», «Кар юлы» исемле китаплар авторы. С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. Чаллыда яши.*

Шуңа да ул буранлы кичне әни сөйләгәннәр бүгенгедәй истә калган...

«Нинди тынычлык сөймәс ил соң бу Әмрикы дигәннәре? Һаман саен бумбы белән яный. Үзләре исән калырбыз дип уйлыйлар микәнни? Атом бумбысына чикләр юк ди бит... Нурланышы бик куркыныч икән аның... Теге елларны хәтерлисезме, чак шул зәхмәтне атышмый калдылар. Хәтта, өй борынча йөреп, тәрәзләрне замаскы белән сыларга куштылар. Газ үтеп керә алмас, имеш. Күпме генә утыралырсың икән бәрәңге базында качып... Моңарчы Аллам саклады инде, алдагысын кем белә...»

Әнигә кушылып Фатыйма апа әйткәннәрдән дә нәни йөрәгем куырылып-кысылып куйганын бик анык хәтерлим...

«Бумбы шартлаганда, төтене кап-кара зу-ур гөмбә фурмасында була икән аның. Алтмыш икенең көзен әйтәм, уктәбернең унында бөтен туган-тумача белән бергә җыйналдык бит. Күрше авылдан да килделәр. Саубуллашып, бәхилләшеп таралыштык. Насыйп булгач, яшибез әле...»

Нәкъ шул төнне, күршеләребезне озатып, йокларга яткач, күрдем дә инде мин әлеге төшне. Имеш, үзебезнең өйдә, тыныч кына, ялгызым сандык өстендә калдык-постык чүпрәкләр белән курчаклы уйнап утырам. Кинәт нindидер гүләү ишетелә башламасынмы! Бу тавышка тәрәзә пыялалары, шкафтагы чынаяклар зеңгелдәве дә кушылды. Шул мизгелдә җан-тәнемне аңлатып булмаслык курку хисе биләп алды. Сикереп торып, пәрдәне ачып җибәрсәм, авылыбызны бөтен яклап чолгап алган тау-калкулыклардан багана-багана кара төтен күтәрелә, имеш. Таулар да, җир дә менә ярылам, менә шартлыйм дигәндәй дерелдәп тора. Нindидер коточкыч фаҗига буласын сизенгән йөрәгем туктар дәрәҗәгә җиткәч... уянып киттем. Кычкырганмын да бугай. Әнием аяк өстендә иде. Ул: «Кызым, начар төш күрдеңме әллә?» – дип башымнан сыйпап тынычландырырга ашыкты.

Таң атканын керфек тә какмый көтеп алгач, торып тәрәзә каршысына килдем. Сизелерлек дерелдәгән бармакларым белән чеметеп кенә тотып, ак челтәр читен күтәргән идем, ә анда... Тархан тавы артыннан бөтен дөньяны балкытып кояш чыгып килә! Алтын нурлары йокыдан уяныр-уянмас изрәп яткан тыныч тау итәкләре буйлап авыл өстенә тәгәри. Мин җиңел сулап куйдым һәм бу төш турында уйламаска, аны бөтенләй онытырга тырыштым. Барып кына чыкмады. Дөрес, ул саташу башка кабатланмады, ләкин телевизордан илҗиребезгә куркыныч янаган вакыйгаларны күргән саен яки радиодан шомлы хәбәр ишеткән саен, кылт итеп искә төшә торган булып калды.

Нигә бүген кабат күрдем икән соң мин аны? Кичә телевизор да кабызмадым, интернетка да кермәдем, көне буе башым-күзем тондырып дигәндәй кибет-базарда йөрдем. Авылдагы туганнарыма бүләк-күчтәнәчләр җыйдым. Кичен сумкамны тутырдым да, арып-талып, иртәгесен авылым белән күрешү минутларын уйлап, татлы хыялларга чумып, бик тиз генә йоклап та киттем шикелле. Ә менә таң алдыннан гына нәкъ балачактагы кебек теге төшне күреп, шабыр тиргә батып уяндым. Торгач та иң беренче эш итеп балконга атылып чыктым. Аннан офык та, кояш та күренмәде күренүен, чөнки безнең каршыда, йөзләгән күз-тәрәзәсе белән чекерәеп, тугыз катлы соры йорт басып тора, ләкин урамда яп-якты, чагыштырмача тыныч иде. Кыскасы, бар да кичәгечә, элеккечә... Мин кабат теге чактагы кебек җиңел сулап куйдым һәм юлга җыена башладым.

Күп чакрымнар үтеп, авыл урамына кергәч тә, таныш тыкрыктан төшеп, туган йорт капкасы төбенә килеп туктау иң бәхетле мизгел ул минем өчен. Бүген дә менә: «Аллага шөкер, исән-имин кайтып җиттем!» – дигән сүзләр белән талган аякларымны газиз туфракка тидерүем булды, шунда ук туган җир җылысы, тамырлар буенча таралып, бөтен арганнарны юып алгандай итте. Як-

ягыма каранып, тирән итеп сулыш алуга, авылымның шифалы һавасына ияреп, җанга аңлатып булмаслык рәхәтлек иңде. Күзләр дымланды... Ул да булмады, капка ачылды, һәм аннан, кояштай балкып, энемнең унөч яшьлек малае Айзат килеп чыкты. Хәтта аның аягына урала-урала атлаган Актүш тә елмайгандай тоелды миңа. Айзаттан нәкъ бер яшькә олы ул. Эт гомере белән исәпләгәндә, байтак яшәгән инде дөньяда, колагы да начар ишетә, йөрүе дә салмакланган. Ләкин кунак каршыларга иренми үзе, рәхмәт. Алар артыннан ук ачык йөзен, тәмле телен кызганмый торган киленебез күренде. Йорт хуҗасы, нигезебезне туздырмый саклаучы энем эштә икән. Менә-менә кайтып җитәргә тиеш, ди. Туганнарым белән күрешкәннән соң, тагын бер күңелгә рәхәтлек бирә торган минут җитте, ул да булса машинадан шәһәр күчтәнәчләрен бушату. Айзатыбыз – үзе хәтле олы карбызны, калганнарыбыз төрле тәм-том тутырган төенчекләрне тотып капкадан керергә генә тора идек, артта энемнең көр тавышы ишетелде:

– Безгә дә күчтәнәч калдырыгыз!

Мин энекәшнең көннәр буе ачык һавада йөреп җилләгән йөзенә карап елмайган булсам, очлы күз Айзат аның куенындагы тере йомгакны күреп, түбәсе күккә тигән икән.

– Безгәме ул көчек, әти? Бигрәк матур!

Кочагын тутырган карбызны кая куярга белми әтисенең каршысына атылган малаен энем көчкә туктатты:

– Чү әле, улым, кулларың буш түгел ич, ишегалдына керик. Безгә инде, кемгә булсын... Посадкада адаштырып калдырганнар үзен. Апа, сау гына кайтып җиттеңме? Җизни сменада эштә, дисең инде. Алай да сирәкләдең авылга... Көттердең...

Аның кулындагы көчекнең дә көтәр әмәле калмаган иде бугай, ул шыңшып тыпырчына ук башлады. Энем, безне дә узып, капкадан керергә ашыкты һәм: «Бүгеннән бу – синең дә йортың; ярат, сакла, хуҗаларыңны тыңла», – дип сөйләнә-сөйләнә, көчекне җиргә төшерде. Тегесе йөгереп тә китте, бакча коймасын «билгеләп» тә куйды, аннан, борылып, төймәдәй түгәрәк кара күзләрен мөлдерәтеп, «ни әйтерләр» дигәндәй безгә карап тора башлады. Кулындагы карбызын җәлт кенә өйалды идәненнән боулинг шары кебек тәгәрәтеп җибәргән Айзат көчек янына чүгәләде. Этнең нәни башын бераз сыйпаштырган иде, тегесе, койрыгын күз иярмәс тизлек белән селки-селки, абыйсының кулын яларга кереште. Дуслаштылар болар. Актүшебез исә «кыйланып карагыз инде» дигәндәй, тыныч кына оясы эченә кереп ятты.

– Исемен ничек кушабыз соң? – дидек без, бер-беребезгә елмаеп.

– Табылдык дип кушсак кына инде, – диде бу нәни җанны туендыру хәстәрен күрергә ашыккан киленебез.

– Галиевлармы? Тынычлык урамы, икенче йорт!

Дәррәү тавыш килгән якка борылдык. Каршыбызда, җир астыннан үсеп чыккандай, форма кигән ике полиция хезмәткәре басып тора иде.

– Әйе, Галиевлар булабыз, – диде энем, миннән аермалы буларак, йөзенә аптырау, гаҗәпләнү билгеләре чыгармыйча.

– Ишеткәнсездер, нефтьчеләрнең бик кыйммәтле, секретный контейнерлары югалды.

– Беләбез инде, үзем шунда эшлим. Кыр-посадкаларны айкап аяктан егыла яздык, шул бочканы эзләп. Менә бу тере йомгактан ары берни табылмады әлегә, – диде ул, көчеккә күрсәтеп.

– Без дә алты сәгатьләп авыл буйлап йөрибез...

– Тентү ясарга телисезме әллә? – диде килен ачу белән. – Кибетчедән колак

читем белән генә ишетеп кайткан идем, ул әйбер бер дә яшереп саклый торган нәрсә түгел икән бит! Аннан мең киламитр качарга кирәк икән!

– Тентүме-түгелме, келәт-сарайларыгызга күз салырга тиешбез. Кушканны үтәүчеләр без. Сәлимә апа, Вәрис абый, керегез! Шаһитлар булырсыз.

Капка артында тыңлап торганнар, ахры, җитәкләшеп дигәндәй күршеләребез килеп тә керде. Үзләре гаепле кешеләрдәй күзләрен яшерәләр. Минем сәламемә каршы җавап та бирергә оныттылар, мескеннәр. Ул арада кыяфәтләрендә арыганлык катыш битарафлык билгеләре дә күренә башлаган ике погонлы иптәш өстән-астан дигәндәй каралты-кураларны тикшереп чыкты, келәткә кереп әйләнде. Аннары кәгазьләренә нидер язып, күршеләрдән дә, энемнән дә кул куйдырдылар.

– Тәртибе шундый. Ары-бире без эзләгән әйбер турында ни дә булса ишетсәгез, кичекмәстән хәбәр итегез!

– Әбәзәтелне! – диде Вәрис абый, артларыннан кычкырып.

– Чисть кенә бирмәдең инде, күрше, – диде энем, аның җилкәсенә кулын салып. – Әллә мин урлап кайткан дип уйладың инде син теге уранны?

– Ә?!

Инде миңа чынлап шаккатырга чират җитте.

– Уран, дисеңме, энекәш?! Каян килгән ул безнең авылга? Җитмәсә, бочкалап?

– Уран, апа, уран. Татарча әйтсәк, баетылган уран...

– Ниемә соң ул монда? Атом бомбасын шуннан ясыйлар түгелме?

– Шартлатучы инженерларның машинасыннан юкка чыккан...

– Ничек инде? Сакчыларсыз булганнармыни?

– Как положено, бөтен саклык чараларын күреп алып килгәннәр дә соң. Һәрхәлдә үзләре шулай дип ант эчә...

– Ант эчүләрен белмим, ә менә юл чатындагы кафеда мәйне шәп кенә төшергәннәр икән дип ишеттем, – диде киленебез. – Сез ир-атлар барыгыз да бер калыптан инде. Шунсыз эшегез бармый да, кайтмый да!

– Йә, хатын, кеше ышанмасны чын булса да сөйләмә, диләр. Ничек инде уран хәтле уранны...

– Энем, тәки аңламадым, уран белән ни эшлисез соң сез? Җир астында шартлатулар хакмыни?

– Шулайрак, апа. Технологиясе катлаулы инде аның... Авылыбыз алтын өстендә утыра, диләр бит.

– Су өстендә утыртып калдырырга җыеналар инде болар. Бер көн килеп убылып төшмәсәк! – Килен һәрвакыттагыча турыдан ярды.

– Тархан тавыннан кыеклатып авыл уртасына тиклем җирне тишеп кергәннәр икән, дип сөйлиләр. Дөресме соң ул, Рәшит?

Күрше Вәрис абыйның соравы җавапсыз калды. Чөнки нәни дустын күкрәгенә кыскан Айзат, күзләрен зур ачып:

– Апа, авыл тирәсендә скважиналар беләсеңме ничәү хәзер? Чуты юк! Әле син кырга чыгып карасаң. Ерак кырны да, Совет чокырын да танымыйсың. Бөтен җирдә торба да торба. Көмеш еланнар сыман боргаланып яталар кояшта җемелдәп. Чын! – дип әйтергә ашыкты.

– Ярый, җитәр! Сүз боткасы белән тамак туймас. Апа – юлдан кайткан кеше, мин – эштән, дигәндәй. Ашлап-чәйләп алыйк. Бераз ял итәм дә кабат чыгып китәм. Табасы иде бит инде ул зәхмәтне, күңел гел урынында түгел!

Энем артыннан без дә өйгә атладык. Киленнең:

– Күршекәйләр, әйдәгез, кала күчтәнәчләре белән сыйланырга! – дигән

сүзләре һавада эленеп калды. Вәрис абый белән Сәлимә апа ничек кинәт пәйда булган булсалар, шулай юкка да чыкканнар иде.

Ашаганым аш түгел, таш булып төште дип нәкъ менә минем табын артыннан кузгалгандагы халәтем турында әйтәләрдер. Хәер, туганнарым да дәшми-тынмый тиз-тиз генә капкаладылар да амин тоттылар. Күчтәнәч кәнфитләргә, гөбәдия, җиләк-җимешкә кагылмадылар да хәтта. Башка чак булса, үпкәлим дия-дия, һәрберсеннән авыз иттерми калмас идем. Бүген... бүген барыбыз да җан тынычлыгын җуйган көн иде шул. Көпә-көндез машинадан югалган уран тәмам ушны алды.

Ишегалдында елаган авазлар чыгарып шыңшыган эт баласы янына ашыккан Айзат артыннан мин дә һавага чыктым. Гадәттәгечә, капка төбендәге эскәмиягә барып утырдым да ирексездән: «И Ходаем, табылсын гына иде инде бу исемен дә әйтәсе килмәгән нәмәрсә! Акылга сыймаслык хәл бит...» – дип кабатладым. Кылт итеп теге төш искә төште. Менә ни өчен кергән икән ул! Кисәтү булган, димәк... Дөньядагы әллә ничә миллиард кеше берьюлы күрсен иде дә бит шушы төшне. Һәммәсе сискәнеп, куркып уянсын да уйлансын иде дә соң... Юк шул. Балачактан бирле мине генә тинтерәтә бугай ла ул.

Югыйсә бик яхшы беләбез: иксез-чиксез Галәм киңлекләрендә бәллүр шардай очып йөргән Җиребезгә мизгел саен куркыныч яный. Тыз-быз килеп кометалар оча, йолдызлар, планеталар, метеоритлар, тагын әллә ниләр шунда. Ә бит әле Җирнең өстендә дә күпме бомба, ракета, атом корылмалары тулып ята. Болары инде кешелекне, бар тереклекне юк итү өчен кешеләр үзләре уйлап табып үрчеткән кораллар! Моны ничек аңларга һәм аңлатырга соң?! Елга бер тапкыр таяк та ата ди. Ул җимергеч корал да көннәрдән бер көнне акыл көченә буйсынудан баш тартса?! Менә бит мисалы – гади генә авылда уран хәтле уран югалсын әле...

– Көчегебез тәки исемсез кала бугай, апа! Әллә соң Уран дип кушабызмы? Уран эзләгәндә табылды бит!

Капкадан эт баласын ияртеп килеп чыккан Айзатның очкынланып янган күзләреннән, тәвәккәл кыяфәтеннән, мин шулай телим, риза булсагыз-булмасагыз да, көчек Уран булачак дигәнне аңларга була иде. Мин «ярар» дип баш кактым һәм, авыр сулап:

– Теге уран табылмады бит әле, энекә-ә-ш, – дип суздым.

– Анысы да табылган! Мастер шалтыратты. Эш сәгате бетте, килеп йөрмә, табылды «гасыр югалтуы», ди.

Тәрәзә күзләрен томалап үскән сирень куаклары арасыннан ишетелгән бу хәбәрдән урынымнан ук сикереп тордым. Ачык тәрәзәдән башын тыккан Рәшитнең йөзен рәтләп күрмәсәм дә, сорау арты сорау яудырдым:

– Кайда булган контейнер? Ачылмаганмы? Кем тапкан?

– Ачылмаган, ачылмаган. Кинодагы кебек, ни сәбәпледер машинадан тәгәрәп төшеп калган. Сәфәргә чыккан күрше авыл агае күреп алып, туктап, бишекле матаена җайлап кына салган да өенә алып кайтып киткән үзен. Хуҗалыкта кирәге чыгар, диптер инде...

Энем көлгәндәй авазлар чыгарды. Мин телсез калдым. Менә сиңа мә! Куе яшел яфраклар арасыннан туганымның тавышы кабат ишетелде:

– Кич утырып сөйләшербез, апа. Кер инде өйгә. Әнә озынборыннар да чыккан. Шәһәр кунакларын бигрәкләр дә «яратып» тешли алар!

– Тешләсеннәр. Туган авылым озынборыннары бит, әйеме, Уран!

Барыбызга да тере кисәтү булып аяк астында бөтерелгән эт баласының күзләреннән, сагаеп, миңа Галәм карап тора иде... Бүген дә тыныч-имин үтте көнебез.



Асия
Юнысова

# МОҢ АГЫЛА НУРЛЫ КАЗАННАН

## Орлыгың ни...

Әй татарым, орлыгың ни –
Тарымы син, бодаймы син?
Идел-Урал тарласына
Сипкән сине Ходаймы соң?

Алып килеп монда сине
Диңгезеңнән, тауларыңнан,
Иген сыман чәчкән сине,
Учлап-учлап тубалыннан.

Киң колачтан сипкән сине
Идел-Урал арасына.
Белгән Халикъ хөр рухыңны,
Тар урынга сыймасыңны!

Әй татарым, орлыгың ни?
Бик тересең – тарыдыр син!
Корылыкка бирешмәгән
Тары сыман катыдырсың.

Әй татарым, арыштыр син –
Сокланалар егәреңә.
Бирешмәгән орлык көче
Меңәр еллык җилгәрүгә.

Югалтмыйча орлык аслын,
Меңәр елны кичкән бодай,
Тегермәннән исән чыккан,
Ак-пакь калган – ул син бугай!

---

Асия ЮНЫСОВА – *шагыйрә, прозаик; «Айлы юл», «Сагынырсың әле», «Асылташ» һ.б. күпсанлы китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Татарстан журналистларының Х.Ямашев һәм С.Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

Он иткәндә таш тәгәрмәч,
Әверелдең калачка син.
Кояшка тиң ипи тотып,
Ил каршына чыккан да син!

Әй татарым, орлыгың ни –
Тарымы син, бодаймы син?
Орлыгыңны яшәтергә
Балаларың калырмы соң?

## Мирас

«Кайда, – дисең, балам, – безнең эзләр?
Кайда соң ул Колизейлы калам?
Кайда, – дисең, – мәрмәр хан-сарайлар,
Таш диварлар анда, кальгам?»

Сорауларың, балам, җиңел түгел.
Нәрсә әйтим сиңа, ни диим?
Җавап табар иде һун бабаңнар,
Сөйләр иде кыпчак әбиең.

Алар сине белмәгән дә килеш
Далаларда курган корганнар.
Курганнардан танып табарсың, дип,
Тын йокыга шунда талганнар.

Бай мирасың бар ул синең, балам,
Мирас калган сиңа таш-таулап.
Күл-елганы ике кыйтга буйлап
Һун бабаңнар куйган тамгалап.

Калалармы? Булган алары да.
Сүзләремә дәлил исемнәр.
Атамалар сиңа азимут ул,
Мирасыңны эзләп килсенгә.

Сиңа тагын бабаңнардан әле
Татар дигән мәгърур ат калган.
Синең телең белән – төрки телдә –
Далаларда җырлый ут-кылган.

## Озын көй

«Чын безнеңчә, матур, милли көй», – дип,
«Әллүки»не сузган заманнан:
«Җыр тирәли җыел, татарым!» – дип,
Моң агыла нурлы Казаннан.

Бар дөньядан җыйнап татар җырын,
Ул үзендә әүвәл туплаган.

Сагыш барда күңел буш түгел лә –
Мөлдерәмә тулы тустаган.

Иделләргә чумып исән калган,
«Озын көй»ләр белән юл алган,
Язмышының очын чуалтырга
«Карурман»га кереп югалган.

Татарлардан хәбәр килеп тора –
Киерелгән Татар бугазы.
Кыр казлары кебек моңлы җырлар!
Кайтып җитә илгә бик азы.

Ерак кыйтгалардан милләттәшем
Каурый саен тезеп моң сала!
Йә «Җиһанша» кайта, йә «Фатыйма»,
«Аһ, Ырымбур кала, аһ, дала!»

Ачы язмыш, олы сагыш көйдә.
Тыя аламыни иреннәр?
«Озын көй»дән ятып еладым мин –
Аермагыз мине илемнән.

## Түбәм карлы минем

«Чәчләреңә инде карлар яуган!» –
Кимсетергә мине ашыкма.
Күрмәдеңме, ап-ак карлар ята
Биек-биек таулар башында.

Биек таулар мәһабәт һәм горур,
Кеше яши, тауга сыенып.
Бер мизгелдә таулар уяна да,
Дөнья кала утка коенып.

Күкрәгенә вулкан сыйган таулар
Горурлыкның белә бәясен.
Янартаудан алган очкыным бар –
Уятмагыз Таулар иясен!

Биек таулар мулла кебек сабыр –
Түбәләрдә ап-ак чалмалар.
Куәт булмаса да, дер селкетер,
Сискәндереп алыр чамам бар!

## Туган көндә

Безгә язган инде туган көндә
Бер тын алу, туктап уйлану.
Кеше гомерен яшәп йөргән җирдән
Бер сискәнү, кинәт уяну.

Авылымнан киткән идем дә мин,
Өзелгәндәй кинәт анадан.
Казан кала күккә чөйде мине,
Канат куйды миңа яңадан.

Җитез аяк идек без яшьлектә –
Журналистка кирәк бу сыйфат.
Төне буе яздык мәкаләләр –
Мәртәбәнең әҗере ай кыйбат!

Хискә төреп язган мәгънәле сүз –
И чыдасын гына бу йөрәк! –
Чурту аны – бу йөрәкне, дисәң,
Сәламәтлеге дә бик кирәк.

«Дошман тугыз, без утыз!» – дип яшик,
Сынатмаска иде бит әле.
Кемдер анда кара коелганда,
Минем бүген бәйрәм бит әле.

***

Яратулар һаман бар микән ул,
Булып тора микән гашыйклык?
Үкенүдән елаучылар бармы,
Юкка гына, диеп, ашыктык?

Без яратыр өчен яратылдык,
Килдек җиргә янып сөяргә.
Бер караштан очкын була белдек,
Әверелдек гаҗәп чибәргә.

«Җирдәгеләр хәзер сөя белми», –
Дип әйтсәләр әгәр беркөнне,
Мәхәббәтсез Җирдән мин китәрмен,
Йөрәгемә төяп милкемне.

Төянгәнем минем төрле булыр:
Яну, сөю – тигез, бер чама.
Җирдәгеләр мине күрмәде, дип,
Күктәгене ләкин борчымам.

***

Ялгышлардан сабак алыр өчен,
Бу бер гомер миңа аз булды.
Уй-хисләрем минем, яшәлмичә,
Шигырь итеп кенә язылды.

Януларым гел ихластан иде.
И түктем лә шуны кәгазьгә!
Каләм очындагы ут-яктыдан
Кара төннәр шашты беразга.

Кәгазь өсләренә юллар салды
Гамәлемә шаһит каләмем.
Беләм хәзер гомер сабакларын
Әҗер-савап итү әмәлен.

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Рәүфҗан Закиров

# ҖИЛКӘНСЕЗ ДИҢГЕЗЧЕ

БӘЯН-ХАТИРӘ

Йокы мәсьәләсендә Рәфикъ хатынынннан ак күңлешү белән күңлешә. Ул, башы мендәргә тиюгә, дүрт-биш минут узмый, салмак кына гырлап та җибәрә. Рәфикъка караганда иртә ята, соң тора. Шуңа күрә күне буе кәефе яхшы. Оекбаш бәйли-бәйли сериалларын карый, ун-унбиш мәртәбә телефоннан сөйләшеп ала. Ул арада аш бүлмәсенә чыгып ризык әзерләргә тотына. Арып китсә, тагын ятып йоклап ала... Җаны тыныч. Инде бергәләп ничәнче дистәне ваклыйлар. Шул гомер эчендә ник бер мәртәбә «Китәм!» дип әйтсен. Ялгышып та әйткәне булмады. Ул сүзне әйтер өчен җитди сәбәп кирәк бит. Күрәсең, Рәфикъ андый сәбәп бирмәгәндер. Әнә, хатынының бер дусты, сәбәп эзләп тормый – китә дә бара. Әллә ике, әллә өч мәртәбә аерым торып карадылар... Берсендә судлашып аерылыштылар да. Һәм әле дә булса бергә яшиләр. Ире Рәсүл – дөньяның бер әүлиясе инде менә. Эчми, тартмый, сулга йөрмәде. Сүзен үлчәп кенә сөйләшә, сүгенүнең ни икәнен дә белми. Аны Рәфикъ белән чагыштырырлык та түгел, җир белән күк арасы...

Гомер узган да киткән әллә ни арада. Әнә, картлык ишек кага. Ишек кенә какмый, инде бусаганы узган. Озак дәвам итәрме икән бу картлык? Бер Ходай гына белә. Әллә каян гына авырулары килеп чыгып тора. Рәфикъ карт бүлнис, шифаханә юлларында йөреп, берсен уздырып җибәрде. Чиратта икенчесе. Чирдер инде бу начар йоклау. Бүтәнчә булмас. Хәер, хезмәттәш дустының әйткәне бар: иртән уянганда бер җирем дә авыртмаса, үлдем микән әллә? дип уйлыйм, дия иде. Шаярта кәнишне. Әле дә булса эшләп йөри. Авырса, эшли алмас иде. Ни хәлләрдә яшәп ята икән ул. Рәфикъ флотта хезмәт иткән калада? Шалтыратып хәлен беләсе булыр.

Әллә шул сабакташ дустын уйлап, әллә Каспий диңгезеннән Сүриягә очырган канатлы ракеталарны телевизордан күргәнгәме – бу иртәдә флотта хезмәт иткән еллары исенә төште әле. Бер генә мизгеле дә онытылмаган, бар да исендә. Озакламый флоттан кайтканына да ярты гасыр була, югыйсә.

Менә ичмасам ул вакыттагы йокы йокы иде! Бигрәк тә беренче ярты елда, өйрәнү мәктәбендә хезмәт иткәндә. «Отбой» командасы булуга, ятакка ава.

Рәүфҗан ЗАКИРОВ (1951) – *«Без үткән юллар», «Дәрьялар гизеп» китаплары авторы. Әтнә районы Олы Мәңгәр авылында яши.*

Күз үзеннән-үзе йомыла, ә «подъём!» командасына ачыла. Сигез сәгать үткән дә киткән була. Әллә йоклаган, әллә юк. Корабльгә килгәч кенә Рәфикъның азмы-күпме йокысы туя башлады. Анда төшке аштан соң бер сәгать «тихий час» дигән йокы бар. Флотта аны «мёртвый час», диләр. Ә корабль йөзүдә булса, ул тагын да озыная. Төшке ашны тизрәк ашасаң, ике сәгатьтән артып китә. Инде көндезге сәгать өчтә үзенә күрә бер «подъём». Нинди дә булса бер төрле сок бирәләр. Хезмәт итәргә алынганчы, аның мондый сокларны татып караганы түгел, күргәне дә юк иде. Хәер, Казанда, һөнәр мәктәбендә укыганда, «Томатный», «Яблочный» дигәннәрен айга бер мәртәбә биргәлиләр иде бугай, сыек кына итеп, стакан төбенә салып. Пешекче хатыннарның һәммәсе дә ашханәдә су өстәп чыга, күрәсең. Үзләренә дә кирәк бит. Эшләрен төгәлләп, ул хатыннарның өйгә таралганын Рәфикъның күргәләгәне бар – ике кулларында икешәр букча, көчкә күтәреп кайталар.

Корабльдә, камбуздан[1] ул сокларны бочковой[2] кубрикка[3] алып килә, савытын ачып, кружкаларга бүлә. Ширбәтнең кружкага бик агасы килми. Шулкадәр куе, кашык белән ашарсың. Нинди генә җиләк-җимеш булса – һәммәсенең дә үз исемендәге согы барын Рәфикъ корабка килгәч кенә белде.

Хәзер генә ул, акчаң булса – ни телисең, шул бар. Рәфикъ карт бүлнистә ятканда, гемоглобинын күтәрәбез дип, балалары ул сокларның ниндиен генә алып килмәделәр. Эчеп-эчеп карады, ләкин гемоглобин күтәрелмәде. Күчтәнәчләрне икенче килгәндә балаларның үзләренә биреп җибәрде.

Картның салмак кына аккан уй-фикерләре тагын чуалып китте. Сәгатькә карады. Әле торырга иртәрәк. Хәтерен яңартып ята башлаганына да сәгатьтән арткан. Хәзер торып йөри башласа, корткасы уяначак.

Аның йокысы бүленсә – эш харап. Юк-бардан гаеп табып, әллә кайчангыларны искә төшереп, бәйләнергә генә тора. Имеш, Рәфикъ яшь вакытта өйгә кайтып кермәгән, балаларны карамаган һәм башкалар, һәм башкалар. Диңгезче белән гомер кичергәнен тәки аңларга теләмәде...

Кай турыда тукталып калды соң әле аның фикер агышы?..

Рәфикъ хезмәт иткәндә, хәзер Каспийдан Сүриягә очкан канатлы ракеталарны сыныйлар гына иде әле. Ул хезмәт иткән корабта булмаса да, флотка яңа килгән крейсерларның барысына да куеп чыгаралар иде аларны.

Бер сынау вакытында Рәфикълар корабы «Грозный» крейсерын озатып йөрде. Сынауларны төнлә генә уздырдылар. Ракеталарны корабка төяү-бушату да төнлә генә башкарылды. Үтә дә яшерен корал иде. Ракеталарны ракета белән бәреп төшерә башлагач уйлап табылган нәрсә дип аңлаттылар. Юнәлешен, очу биеклеген гел үзгәртеп оча торган булгач, аны берни дә юк итә алмый. Кеше үтерер өчен ни генә уйлап тапмыйлар...

Рәфикъ хезмәт иткән кораб илленче еллар ахырында төзелгән, эскадра миноносецы зурлыгы белән икенче рангта. Өч йөзләп кеше хезмәт итә. Төп вазифасы – диңгездә миналар кую. Су асты көймәләрен эзләп таба һәм юк итә ала. Үзен-үзе саклар өчен куелган туплары да утызга якын – һава һөҗүменә каршы тора торганы да, яр буена, судагы корабларга ата торганы да. Урта бер җирендә торпедо аппараты утыра. Рәфикъ хезмәт иткән дәвердә, Аллага шөкер, бу коралллардан өйрәнү атулары гел булып торса да, чынлыкта исә бер мәртәбә дә сугышчан ату булмады. Ә миналар куйдылар...

[1] Камбуз – корабта ризык әзерли торган урын.
[2] Бочковой – чират белән камбуздан ризык китерүче, савыт-саба җыештыручы матрос.
[3] Кубрик – матросларның яшәү урыны.

1971 елның февраль төнен Рәфикъның һич онытасы юк.

Севастопольдән миналар төяп чыккач, көне буе Феодосия тирәсендә арлы-бирле йөзделәр. Егерме градус чамасы суык.

Диңгез буйлары боз белән капланган, дүрт-биш баллы шторм котыра.

Палубага чәчрәгән тамчылар минуты белән боз булып ката, шул исәптән миналарга чәчрәгәне дә... Кечкә бөтен кораб тоташ бозга әйләнде. Төнлә, сәгать бер белән ике арасында сугышчан тревога күтәрелде. Бар да дөбер- шатыр сугышчан постларына йөгерә. Рәфикъ идарә иткән бүлекчәнең урыны палубада, миналар янында. Клусас исемле матросны да сөйрәп, култыклап алып чыгарга туры килде. Ул мескен, аз гына шторм булса, ятагында мәет булып ята. Ашамый-эчми, укшый да укшый, төсе-бите зәңгәрләнеп бетә. Суыкка чыккач, бераз рәтләнде тагын.

Корабтагы барлык утларны да сүндерделәр. Рубкадагы җиһазларның күрсәткечләрен кесә фонаре яндырып кына карыйлар. Миналар куярга дигән боерык булды. Миналарның шартлаткычы диңгезгә төшәр алдыннан гына куела. Перчатка, бияләйләр киеп булмый, ялан кул эшләргә кирәк. Берничә мина төшергәч, Рәфикъның бармаклары берни дә тоталмас дәрәҗәгә җитте. Шартлаткычларны команда старшинасы белән алмаш-тилмәш урнаштыра башладылар. Бүлекчәнең калган матрослары тая-егыла миналарны тәгәрәтә. Куеп бетерергә берничә мина калганда, Рәфикъның инде аяклары да берни тоймый башлады. Ул арада шинель итәге мина белән аның арбасы арасына кысылган. Чүттән генә мина белән бергә үзе дә диңгезгә китми калды. Бәхетенә, янәшәдәге Платонов фамилияле матрос кулыннан тотып калды. Ул эләктермәсә, мина белән бергә диңгезгә чумасы иде. Суга төшкәч, минадан ычкыналса бер хәл, ә ычкына алмаса – арба белән төпкә... Ул вакытта аны уйлап торырга вакыт булмаган. Миналарны куеп бетерәсе бар. Ниһаять, соңгы мина диңгезгә чумды.

«Отбой боевой тревоги» командасы яңгырады. Кораб иң зур тизлеге белән бара башлады. Ярты сәгатьләп вакыт узгач акрынайды, барлык утлары да кабынды. Рәфикъ бүлекчәсендәге матрослар тулы состав белән корабның пар казаны бүлегенә юнәлделәр. Иң җылы урын шунда. Анда вахтада торган матрослар майкадан гына йөриләр. Бераз җылынып алгач, телләре ачылды: кем ничә мәртәбә егылган, палубага беркетелгән ыргаклары бозга каткач, минаның ычкынмый торулары һәм башка шуның ише искә алулар. «Йөзлек» киеп тугансың икән, иптәш старшина, дип, Рәфикъның аркасыннан кактылар. Ул үз чиратында Платоновка рәхмәт әйтте, хәрби уеннарда үткән ул мизгелне беркайчан да онытмам, диде.

* * *

Рәфикъ карт үз уйлары белән тагын берьялгызы калды. Төшке аштан соң ятып, бераз черем итеп ала. Флоттан калган гадәт. Тиз ашау гадәте дә шул вакыттан калган. Анда, утырган өстәлдә, кем иң соңыннан ашап бетерә, шул савыт-саба җыештыра иде. Гел савыт-саба җыештырасы килмәгәч, тиз ашарга өйрәнде. Юкса «тихий час» вакыты бик аз кала. Хәер, корабны өйрәнеп имтихан тапшырганчы, «мёртвый час» аларга бөтенләй эләкмәде. Аз гына буш вакыт булуга, корабны өйрәнеп йөрделәр. Рәфикъ, баштарак, ничекләр өйрәнеп бетәрмен, дип курыкты. Кат-кат йөри торгач, истә кала башлады. Бергәләп өйрәнгәндә, дөрестән дә, истә кала икән. Бер-береңнән сорыйсың. Павлов кына бик авырдан истә калдыра. Рәфикълар белән тапшыра алмас ахры имтиханны.

Имтиханны старпом белән мичман Косатый бергә алалар икән. Марченко белән Рәфикъ беренче мәртәбәсендә үк тапшырдылар, ә Павлов буталып бетте, тапшыра алмады. Старпом, Онуфриенконы чакырып, шелтә белдерде.

– Павловны өйрәтмәгәнсең, корабтан өеңә соңгы кеше булып китәрсең! – диде.

Аның бүтән чатаклыклары да җитәрлек булган. Шуларны искә төшерде.

Шул атна шимбәсендә Онуфриенко Павловны: «Кораб өйрәтәм!» – дип кубриктан алып чыгып китте. Кичке аш алдыннан вахтенный, Рәфикълар кубригына кереп:

– Душ бүлмәсендә сезнең Павлов аңсыз ята. Барып алыгыз! Шолохов, син медикларның берәрсен алып кил! – дип кычкырды.

Марченко белән Рәфикъ душ бүлмәсенә барсалар, дөрестән дә, Павлов идәндә ята. Киемнәре манма су. Үзеннән аракы исе килә. Дәшкәнгә җавап бирми. Икәүләп аны чишендерделәр, киемнәрен сыктылар. Рәфикъ Павловны иңенә алып, кубрикка алып китте. Марченко киемнәрен алды. Кубрикта санинструктор көтеп тора иде инде... Бүлмәгә нашатырь спирты исе таралды. Бераздан Павлов акрын гына, теләр-теләмәс башын чайкады, тешен шыгырдатты, күз кабакларын күтәреп карады.

Болай яраланган, сынган җире күренми. Нык кына кыйнаган булырга тиешләр. Кара янмаган бер генә җире дә юк. Биленә тимер белән сукканнармы шунда. Тар гына буй сызык булып күренә.

Рәфикъ Павловның, юл капчыгын алып, чишеп, коры киемнәрен алды. Өчәүләп, көч-хәл белән Павловны киендерделәр. Ул күзен ачмый, гәүдәсен тота алмый, ичмасам ыңгырашмый да.

Онуфриенко тиз-тиз ашады да рубриктан чыгып тайды. Сиздермәскә тырышса да, салмыш икәнлеге күренеп тора.

***

Онуфриенконы нәкъ «сәвитчә» хөкем иттеләр. Павловның хәле яхшыргач, психик тайпылышы булган авырулар янына күчерделәр. Имеш, ул тән җәрәхәтләрен үзенә-үзе салган. Замполит бик тырышкан инде, атна саен госпиталь бусагасын таптаган. Чынбарлык флот штабына барып ирешсә, старпомнан башлап мичманга кадәр, барысына да эләккән булыр иде. Онуфриенконы хәрби трибуналдан шул «чүпне читкә чыгармау» галәмәте генә коткарып калды. Яңа ел алдыннан аны Херсон өлкәсендәге бер туганы килеп, өенә алып кайтып китте. Корабтагы күп кеше белми дә калды. Шыпырт кына, музыкасыз гына озаттылар.

Уйламаганда-көтмәгәндә генә Рәфикъны бүлекчә командиры итеп куйдылар, старшиналар мәктәбенә укырга җибәрделәр. Укып кайтканда инде яңа килгәннәр белән кораб тулган иде. Рәфикъ бүлекчәсенә дә өч матрос өстәлгән. Николай аларга кораб өйрәтә башлаган.

– Сине бүлекчә командиры итәргә дигән тәкъдимне мин әйттем. Мине бик кумассың инде! – дип шаярта Николай.

Әйбәт егет ул. Ул булмаса, яңа килгәннәр белән Рәфикъ берүзе ни эшләгән булыр иде?! Шайт та бик булыша. Старшиналар мәктәбендә аның белән дуслашып беттеләр. Укырга бик яратмаса да, бер дә белмәгәне юк. Шайт урында тик тора белми, гел хәрәкәттә. Флотка килгәнче, гимнастика белән шөгыльләнгән. Кайда аркылы тимер күрә, бертуктаусыз тартыла. Сальто ясый ала, алга да артка да. Тик корабта ясап кына булмый, палуба тимер. Старшиналар мәктәбендә рәхәтләнде инде чирәмдә мәтәлчек атып. Новиков аны ун көнгә ялга җибәрде. Пятигорск шәһәрендә яшиләр икән. Рәфикъка ялга кайту бәхете кайчан татыр? Сагындыра туган яклар, бик сагындыра. Бер генә атнага булса да кайтып килергә иде. Кораб, төзәтелеп чыгып, кабат йөзә башлагач, йә кайтаралар, йә юк әле.

Корабта күселәр күбәйде. Көндез дә курыкмыйча палуба буйлап чабып йөриләр. Атна-ун көн докта[4] торганда, коры җирдән күчтеләрме, әллә ярты елдан артык корабның йөзмәве үрчеттеме аларны? Хәзер, әнә, ризык эзләп хәрби постларга, кубрикларга керәләр. Кораб командиры, ун күсе тоткан кешегә ун көн ял бирелә, дип игълан итте. Ярыша-ярыша күселәргә ау башланды. Нинди генә ысулларын кулланып карамыйбыз күсе аулауның, тик тозакка сирәк эләгәләр. Шулай да, бер ай дигәндә өч матроска ялга китәргә боерык булды, күсе аулаган өчен. Исәбен медик Кофман алып бара.

Әллә инде күсе аулый башлыйсы? Кайтасым килә...

Николай, өченче елын хезмәт итә башласа да, ялга кайта алганы юк. Күсеауларга ныклап тотынды. Бер атна дигәндә ике күсе тотты. Бу шөгыльгә яңа килгән матросларны да җәлеп итә башлады үзе.

– Сынки, сезгә әле ялга китәргә иртәрәк, өегездән яңа килдегез. Күсе тотсагыз – миңа бирегез! Үз кешеләр, ничек тә исәпләшербез. Берегезне дә буш калдырмам. Исән-сау ялга кайтып килә алсам, Дон балыгы белән сыйлармын. Әни карчык та: «Өй түбәсеннән су үтә, кайтсаң төзәтеп килер идең!» – дип яза.

Рәфикъ та берничә тозак куеп карады. Тик эләкмиләр генә. Ай дигәндә, сугышчан постындагы тозагына зур бер күсе эләккән. Нечкә чыбыктан ясаган элмәккә, кабельдән чабып барган көйгә башы белән кереп, асылынып калган. Рәфикъ күреп алганда, суынып та бетмәгән иде әле. Николайга бирде.

– Рәхмәт, командир, мәңге онытмам. Сиңа күсе тотмасаң да ял бирерләр, вакыты җиткәч.

Николайның гадәттәгечә авызы ерылды.Үлгән күсене коерыгыннан тотып Кофманга күрсәтергә алып китте. Хәзер ул Рәфикъка «сынок» дип әйтми, «командир» ди, «иптәш» дигәнен әйтеп тормый.

* * *

Көннәрдән бер көнне корабны, ачык диңгезгә алып чыгып, юан-юан кабельләр белән чорнап бетерделәр. Янәшәдә торган корабтан ут ялгап, тәүлектән артык тоттылар. Шартлаткычлары магнит көченә көйләнгән миналарга, торпедоларга каршы тору сәләтен арттыру өчен кирәк дип аңлаттылар. Шуннан кайтканнан соң, акрынлап, корабка корал ташый башладылар. Башта БЧ-2[5] ләр үзләренең базларын снаряд белән тутырды. Аннан соң Рәфикъларга да чират житте. Реактив һәм тирәндә шартлый торган бомбалар кабул иттеләр. Иң читене торпедо кабул итү булды. Өйрәнү торпедосының аппаратка һич кенә дә керәсе килми. Торпедо китергән корабның кранда эшләүчесе тәҗрибәсез булдымы, торпедо аппаратка яртылаш керде дә ни алга, ни артка бармый. Кире чыгарып, яңадан кертергә туры килде. Кычкыра-кычкыра тавышларыбыз бетте. Әллә аппаратка керткәндә, торпедоны имгәттеләр. Әллә атар алдыннан тиешле тирәнлек бирмәделәр, әллә көйләүче җиһазлар командиры аппаратны дөрес юнәлешкә бормады – атканнан соң торпедо югалды. Өйрәнү вакытында ике кораб берсенә-берсе торпедо җибәрде. БПК[6]дан җибәрелгән торпедо Рәфикълар корабының нәкъ уртасына йөзеп килде, бәрелергә илле метр чамасы кала, туктап, вертикаль рәвештә басты, аклы-кызыллы тасмалап буялган өлеше су өстенә чыгып калды да, башындагы җирән уты янып сүнә башлады...

[4] Док – корабны аерым урынга кертеп, анда суны агызып төзәтү урыны.
[5] «БЧ-2» – корабта артиллерия бүлеге.
[6] БПК – су асты көймәләренә каршы көрәшүче зур кораб.

Ә Рәфикълар корабы җибәргән торпедо эзсез юкка чыкты.

Ике көн, ике төн эзләделәр. Торпедоны беренче булып күргән кешегә ун тәүлек ял биреләсен игълан иттеләр. Артиллеристлар үзләренең ике йөз илле мәртәбә зурайтып күрсәтә торган везир җайланмасын, чиратлаштырып, төрле якка әйләндереп эзләделәр. Аккустиклар постларыннан ашарга да чыкмыйча, колакчыннарын киеп, торпедо җибәреп торырга тиешле тавыш сигналын тыңладылар. Радиометристлар, бертуктаусыз антенналарын әйләндереп торып, радар белән эзләделәр. Сигнальщиклар сәгать саен алышынып, кайвакыт барысы бергә, бинокльләр белән диңгезне күзләделәр. Ялга кайту – һәр диңгезченең зур хыялы иде. Торпедоны эзләп өченче тәүлеккә чыккач, базага кайтып киттеләр.

Алмашка килгән ике тральщик белән берничә торпедо катеры торпедоны эзләп калдылар. Таба алмаганнар, күрәсең. Торпедо кем гаебе белән югалган: аны эшләгән заводмы, саклап, хезмәт күрсәтеп торган арсенал хезмәткәрләреме, диңгезчеләрме? Белә алмадылар. Ул югалуның кайтавазы байтакка кадәр барды. Мичманның хезмәт итү шартнамәсен озайтмадылар, лаеклы ялга китәргә берничә генә ел калган иде, югыйсә. Корабка штабтан килгән өйрәнүләрне тәэмин итәргә тиешле флагман белгечен запаска озаттылар, бик чибәр, төз гәүдәле, яртылаш агара башлаган дулкын-дулкын калын чәчле, бик килешле мыеклы икенче рангтагы капитан иде. Ерак йөзүгә китәр алдыннан, старшиналарга бер ай шәһәргә чыкмаска дигән җәза бирделәр. Әллә кем булып кукраеп йөргәннәрнең кикриге шиңде. Погонга өстәп тагарга алтын укалы тасмалар әзерләп куйган ишләребез дә бар иде. Шул ике токмачлы погон белән кайтып китәрләр инде...

1970 елның Хәрби диңгез флоты көнен Севастопольнең нәкъ уртасында, мина стенкасында каршыладылар. Кораб өр-яңадан буялган, ялык-йолык килеп, янәшәдә йөргән кораблардан аерылып тора. Иртәнге тезелүгә бар да ап-ак киемнән бастылар. Командир бәйрәм белән котлады. Барлык төр көйләү-сынау эшләренең беткәнлеген, озакламый ерак йөзүгә китәселәрен әйтте. Замполит бәйрәм көнендә узачак чаралар белән таныштырды. Башта – кораб командалары беренчелегенә, соңыннан стенкада торган бүтән кораб командалары арасында аркан тарту буенча ярыш буласы икән. Көн уртасында корабтан егерме кеше, шул исәптән Рәфикъ та йолдызлар йөзүенә барасылар. Алдагы елны бу йөзүдә ул Калининград шәһәре күлендә катнашкан иде. Мамоново шәһәреннән Калининградка туксан чакрымны ачык машиналарда утыртып алып бардылар. Күлнең бер читендә чишенеп, сафларга тезелеп, акрын гына суга керделәр. Башка кигән ап-ак бескозырканың чехоллары гына күренеп калды. Чехолга йолдыз беркетелгән. Ул йолдызлар кояш нуры белән ялтырап-ялтырап китә. Шуңа да йолдызлар йөзүе дип атаганнар, күрәсең. Кулны өскә чыгармыйча, дулкын ясамыйча, акрын гына йөзәргә кирәк. Шул ук вакытта сафларның тигезлеген сакларга: буйга да, аркылыга да. Күлнең икенче ягына йөзеп чыктылар да, җәяүләп күлне әйләнеп, чишенгән урыннарына кайттылар. Севастопольдә корабларда ук чишенеп, су трамваена утырдылар. Трамвайлар бухта уртасында туктагач, акрын гына суга кереп, сафларга тезелделәр. Тигезлек саклап, баткан корабларга куелган һәйкәлгә табарак йөзеп киттеләр. Судан чыккач, яланаяк асфальтка басып, җәяүләп корабларга кайттылар. Кызган асфальтка яланаяк басу бер мәртәбә авыр булса, кораб трабыннан менеп, кызган тимер палубадан кубрикка бару күп мәртәбәләр авыррак булды. Душ бүлмәсенә барып, тәнгә сеңгән диңгез тозын юып төшергәч кенә, хәл җиңеләйде, акрынлап бәйрәм халәте кире кайта башлады. Кичен үзешчән сәнгать белән шөгыльләнүчеләр концерты булды. Ә андыйлар корабта җитәрлек.

* * *

1970 елның чалт аяз август иртәсендә, «Славянканың хушлашуы» көен яңгыратып, Рәфикъләр корабы ерак йөзүгә кузгалды. Озата килгән хатын-кызлар, бала-чага, үзәк бухтага борылганчы кул болгап тордылар. Марченконың Наташасы да килгән. Рәфикъ аны Марченко күрсәткән фотодан таныды. Төскә-биткә Марченко кебек үк чибәр булмаса да, гәүдәсе бик күркәм, бар нәрсәсе үз урынында, тел-теш тидерерлек түгел. Кыска итәге, кояшта каралган, төз, матур аяклары гәүдәсенә аерым бер нәфислек биреп тора. Күргән саен күрәсе килә үзен. Ул, офицер, мичман хатыннары төркеменә кушылмыйча, бер читтәрәк басып калды.

Кораб, Акъяр бухтасын ябып торган капканы узгач, бер озынча гудок бирде. Ике-өч мәртәбә өзек-өзек кара төтен бөркеде, тизлеген арттырып, көньяк-көнбатыш юнәлештә, диңгезнең вак дулкыннарын ярып, алга ашкынды. Ярты сәгать чамасы йөзгәннән соң, Кырым ярлары күздән югалды. Иксез-чиксез диңгез. Кояш үзенең иң югары ноктасына таба үрмәли. Болытның әсәре дә юк. Бик биектә, күренер-күренмәс очкан бер самолётның ак юлы сузылып бара. Торпедо аппараты янында кайнашкан Марченко Рәфикъны чакырып алды. Өч-дүрт дельфин кораб белән ярышып йөзәләр икән. Шул дельфиннарны күрсәтергә чакырган. Йөзеп барган көйгә, алмаш-тилмәш су өстенә калкып чыгалар да, берничә метр күренеп барып, кабат суга чумалар. Кайвакыт парлап күренәләр. Байтак вакыт корабка ияреп бардылар да кисәк юк булды үзләре.

Төшке аш вакыты җитте. Бүген камбузда кок Погорелый чираты икән. Тәмле дә пешерә инде украина борщын, ашап туймаслык. Ул әзерләгән тары боткасында аерым тәм бар. Сыер ите белән дуңгыз итен кушып әзерләгән кәтлитләре авызда эри, чәйнәп торасы да юк. Корабка килүенә берничә генә ай, командир приказы белән ике тапкыр макталды инде. Марченконы офицерлар кают-кампаниясенә гарсон итеп куйдылар.

Погорелый ризык пешергән көнне савыт-сабаны юасы да юк. Офицерлар тәлинкәләрен ялап куялар. Борщны өстәп сорыйлар...

Ул беренче, икенче ризыкларны камбуздан ала. Мичман-офицерлар да, матрос-старшиналарга да ризык бер үк казанда пешә. Марченко шуларны өләшеп бирә.

Кораб бер юнәлештә, бер үк тизлек белән йөзә дә йөзә. Дүрт сәгатьтән дүрт сәгатькә вахталар алышына. «БЧ-2» белән «БЧ-3»ләргә рәхәт, аларда вахталар юк, сәяхәтчеләр кебек диңгез күзәтәләр. Коралларның саклагыч җәймәләрен җыештырып куйганнар да, эшләре бетте. Бетмәгән икән шул, кичке аш алдыннан – «Боевая тревога». Дошман самолётлары һөҗүме! Кораб тизлеген йә арттырып, йә киметеп, уңга, сулга кисәк борылып йөзә башлады. БЧ-2нең туплары хәрәкәткә килде. Әлегә атмыйлар һәм атмадылар да.

«Тревога» өйрәнү өчен генә булган икән. Озак та үтми «Отбой» командасы яңгырады. Музыка куйдылар. Кичке ашка белдерү ясадылар.

Төнге сәгать бердә кабат «Боевая тревога». Дошманның су асты көймәсенә һөҗүм ясарга. Монысы инде турыдан-туры Рәфикъләр «БЧ»сына кагыла. Акустиклар аларның кубригы белән янәшә. Бүлекчә командиры Рәфикъка башын изәде. – Ягъни, бернинди дә су асты көймәсе юк. Барыбер сугышчан постка басарга кирәк. Ярты сәгать тә узмагандыр, тагын «Отбой» командасы. Йокы ачылды...

Туган як басулары исенә килеп төште. Комбайннар бар куәтенә сугалардыр инде. 8-9нчы классларны бетергәч, ул ике ел рәттән комбайнёр ярдәмчесе булып эшләгән иде. Бигрәк тә 1967 елгы урак өсте истә калган. Икмәк бик уңды. Вакытлы-вакытсыз яңгырлар да яумады. Чык төшмәгән көннәрдә төнге

сәгать берләргә кадәр суктырдылар. Ул елны колхоз да икмәкне мул өләште. Илле капчык арыш, илле капчык бодай тутырып алып төштеләр амбардан. Икмәк куярга урын калмады. Унбиш капчык арышны ишегалдында брезент җәймәгә төреп калдырдылар – тегермәнгә алып киткәнче дип. Капчыклары нинди бит әле, ике кеше чак күтәрерлек.

Әтисе горурланды да, мактанды да, аерым хуҗалык булып яшәгәндә дә бу кадәр икмәкнең безнең йортка кергәне булмады, диде.

Читтән генә карап китәргә иде комбайннар эшләгәнен, әтисенең иртән комбайннарга нәрәт биргәнен... Рәфикъ шуларны уйлап ятып йокыга китә язган, «Аврал» сигналы булды. Босфор бугазына килеп җиткәннәр икән. Корабның тизлеге акрынайган. Еракта Төркия ярлары күренә. Ул арада кораб бөтенләй туктап калды. Сул як якорьны диңгезгә чумдырдылар.

– Лоцман[7] килгәнче тик торабыз. Босфорга кергәнче иртәнге ашны ашап өлгерсәк ярар иде.

Берәр сәгатьтән тиз йөрешле катер лоцманны китерде. Ул траптан менде дә тиз-тиз адымнар белән ходовой рубкага атлады. Якорьны күтәрделәр. Кораб акрын гына Босфор бугазына йөзеп кереп китте. Бугазда томан. Урыны-урыны белән бик куе, берни күренми. Анда булган барлык суднолар сигнал бирәләр. Кайсы озын-озын итеп, кайсы кыска гына, ачы итеп кычкырта. Сарылы, кызыллы утлар яна-сүнә. Шул томан аркасында Стамбул шәһәрен күрми калырлар микәнни? Кораб акрын гына баруын дәвам итә. Менә бераздан томан тарала башлады. Инде шәһәргә кергәннәр дә икән. Кояш та күренеп алды. Сул як ярдагы исәпсез-хисапсыз мәчет манараларының айлары кояш яктысында ялык-йолык килә. Уң як ярда әллә чиркәүләр дә бар инде... Машиналар, кешеләр төялгән паром Рәфикълар корабы алдыннан аркылыга йөзеп чыгып китте. Кечкенә генә бер катер алар корабы белән янәшә йөзә башлады. Өстендәге курткасының башлыгын башына каплаган бер кеше Рәфикълар корабын бертуктаусыз фотога төшерә. Фотоаппаратының берсен ала, берсен куя. Берсенең объективы ярты метрлап бардыр. Күп тә үтмәде, корабның уң ягына чыгып төшерә башлады. Акрынлап шәһәр ерагайды. Бугаз киңәйде. Кораб туктады. Боцман командасыннан ике матрос тиз генә трап төшерделәр. Лоцманны калдыралар икән. Каршы алган катерга күчкәч, лоцман, артына борылмый гына уң кулын югары күтәрде.

Үзенчә хушлашуы булгандыр. Катер рубкасына кереп китте.

Кораб тагын кузгалды, тизлеге артты. Алда – Мәрмәр диңгезе. Биредә инде табигатьнең үзгәргәнлеге сизелә. Урманнары куе яшел төстә. Әллә көн кичкә авышканга, шулай караңгыланып торамы? Ул арада кып-кызыл кояш диңгезгә чумды. Кояш баюга, бераз гына эңгер-меңгер булып торды да, бөтен дөнья караңгылыкка чумды. Дарданель бугазын төнлә уздылар ахрысы. Иртән бернинди ярлар да күренми иде инде. Кораб тизлеген арттырган. Каршыга искән дымлы, җылы җил тәнгә рәхәтлек бирә. Күктә каурыйсыман болытлар. Сундук Глазов тропик киемнәр өләшә башлаган. Күләгәдә температура утыз градустан артса кия торган. Бик җайлы кием.

– Бу кай тирә икән? Ярлар юкка чыккан. Эгей диңгезе булырга тиеш. Озакламас, вак-вак утраулар күренә башлар. Бер-ике көннән Урта диңгезгә җитәрбез, Алла боерса. Анда инде берәр «точкага» куялар, йә Америка корабларына тагылып йөрербез. Ундүртенче ноктага куйсалар, әйбәт булыр иде. Анда давыл бик булмый, күбесенчә штиль генә. Рәхәтләнеп балык тотарга була.

[7] Лоцман – корабны диңгезнең тирән җиреннән алып чыгучы.

Тагын тревога. Бу юлысы – торпедо атакасы. Өйрәнү торпедосы юк, барысы да сугышчан торпедолар. Әле берсенә яңа уйлап табылган шартлаткыч куелган: «ул уртасынарак туры килсә – ике йөз метрлы крейсерны да минут эчендә диңгез төбенә җибәрергә мөмкин...

Шөкер, өйрәнү тревогасы булган. Озакламый «Отбой» командасы яңгырады.

* * *

Корабка яңа килгәннәргә тиз арада кушамат тагалар, шул исәптән мичманнарга да. Бу мичманга «Чебурашка – 2» дип кушамат такканнар иде, ничектер ябышмады, «Ушастый» ныграк ябышты. Мичманның үзенә дә «Ушастый» дип әйткәлиләр. Ул үпкәләми. Иялэнгән, күрәсең. Мичманнар мәктәбендә дә шулай атап йөрткәннәр үзен. Ул – үз авырлыгында бокс буенча Кара диңгез флоты чемпионы. Флотның иң яхшы акустигы дигән исеме дә бар. Ә турникта күтәрелү буенча аны узган кешене күргәнем юк әле. Менә шулай, егетләр, белеп торыгыз!

Ул балалар йортында үскән. Үзеннән зур малайлар гел җәберләгәч, спорт белән шөгыльләнеп, мускулларын ныгыткан. Аннан соң берәүгә дә үзен җәберләргә ирек бирмәгән.

Бу мичманның сәерлеге тышкы кыяфәтендә генә түгел, акыл-фигылендә дә бар. Тәмәке тартмаса да, башка матрослар янына килеп басып тора. Югославиянең Риекка портына ялга туктагач, бер серб кызына гашыйк булды. Аны яхшы белгән кешеләрнең дә моңа исе китте. Портка урнашуның икенче көнендә дүрт-биш матросны, старшинага яки мичманга ияртеп, шәһәргә чыгара башладылар. Мичман күзәтчелегендә алар бүлекчәсе тулы состав белән шәһәргә чыга. Шәһәр буйлап йөргәндә, аякларын ял иттерергә дип, бер бакчага туктыйлар. Шунда теге мичман урындыкта ялгыз гына утырган бер кыз янына килеп баса. Сөйләшеп китәләр. Русча сөйләшкәннәрдерме, сербчамы, ләкин әңгәмәләре озакка сузыла. Мичманны көтеп утырган матрослар ялыга башлый.

Көтә-көтә туеп беткәч, шыпырт кына, бакча кырыендагы кафега китәләр. Бәяләргә күз төшерсәң, коньяк кызыл аракыдан бераз гына кыйммәт, ә аракыга якын килә торган түгел. Уйлаштылар да берәм-берәм кафега киттеләр. Буш өстәлгә барып утырып, булган динарларны җыйнап, йөз иллешәр грамм шәраб алдылар, кабымлыксыз гына. Коры шәраб кына булды ахрысы, кече телләренә дә йокмады, кая ул «башка китү»!.. Торып китәргә дигәндә генә, яннарына урта яшьләрдәге бер ханым килде. Официантка булса кирәк: бер кулында тәлинкә, икенчесендә чүлмәккә охшаган кара шешә. Кулындагы әйберләрен өстәлгә куйгач, бармен янына барып, рюмкалар алып килде, тәлинкәгә персиклар куйды. Шешәдән рюмкаларга кызгылт сыекча агызды. Коньякка охшаган. Кулы белән барменга таба ымлады. Анда, бөтен йөзе белән елмаеп, карт кына ир басып тора. Уң кулында безнеке кебек рюмка, яртылаш тулы. Рюмка тоткан кулын күтәреп, эчәргә ишарә ясады. Бер-берсенә карашып, рюмкаларны күтәреп куйдылар. Тәлинкәдән персик алып каптылар. Ул арада, теге хатын килеп, рюмкаларга кабат коньяк агызды. Мичман күренмиме икән дип ишеккә карадылар да, рюмкаларны тиз генә күтәреп куеп, теге ханымга да, барменга да рәхмәт әйтеп, кафедан чыгып киттеләр. Ә мичманның матросларда эше юк, кулларын селки-селки теге кызга нидер аңлата. Анысы елмаеп, баш селкеп тора. Пар күгәрченнәр дип белерсең. Ни эшләргә?

Корабка кайтыр вакыт та җитеп килә. Мичман каршынарак килеп, сәгатькә ишарә ясадылар. Ул үзенең сәгатенә карады да урындыктан торды. Теге кыз кунакларны бераз озата барды һәм, «воздушный поцелуй» биреп, үз юлы белән

китеп барды. Нәрсәләр сөйләштегез бик озак, нинди телдә дип сораганнар иде. «Рус телендә инде. Мин сербча белмим бит. Кызу сөйләшмәгәндә аңлашып була икән. Мәктәптә азрак русча өйрәткәннәр аларны. Иртәгә корабка киләм, сөйләшәсе сүзләр күп әле аның белән», – дип җавап бирде мичман.

Замполит шәһәргә чыкканнарны трап янында үзе каршы алды.

Мичман «Ушастый»ның мәхәббәт маҗаралары моның белән генә бетмәде. Иртәгесен шәһәргә чыгу булмады. Шәһәр кешеләрен кораб карарга үзләрен керттеләр. Кораб кеше белән тулды. Басып торыр урын юк. Кайберләре балалар җитәкләп килгәннәр. Портта тагын әллә никадәр халык керергә чират тора.

Шәһәр бакчасында очраган кыз корабка беренчеләрдән булып керде. Мичман «Ушастый» аны трап янында ук каршы алды.

Кыз, буйга мичман чамасында, чәчләрен юка тасма белән ураган. Төскәбиткә әллә ни түгел. Киң балаклы чалбар кигән, аякларын яшерә булса кирәк. Гадәттә, матур аяклы кызлар кыска итәк кия. Күкрәкләре калку түгел, тәнен кысып торган кыска җиңле итәксез күлмәгеннән беленер-беленмәс кенә төртеп торалар. Биле нечкә. Шул нечкә биле гәүдәсенә ямь биреп, үзенә җәлеп итеп тора да инде. Рәфикъ алдагы кичтә Волковның кыйссасын ишетмәгән булса, бәлкем, аңа игътибар да итмәгән булыр иде әле.

Мичман кызны җитәкләп палубадан түбән алып төшеп китте, үзләре яшәгән каютага булса кирәк. Артларыннан Сафонов та иярде. Бер каютада яшиләр. Сафонов озак тормады. Каютадан чыгып, Рәфикълар янына килде.

– Хәерлегә булсын, безнең Иванов та хатын-кызларга игътибар итә башлады. Мичманнар мәктәбендә ике ел укып, атна саен диярлек шәһәргә чыгып, бер кыз белән дә танышмады, бер кызга да хат язмады. Туган-тумачасы юк. Физкультура белән физика укытучыларына хат язгалый торган иде. Алары да ирләр.

– Безнең Ушастый «зәңгәрләр» токымыннан түгелдер бит? – Николай, соңгы елын хезмәт иткәч, мичманнардан бик тартынып тормый.

– Юк. Анысы-монысы сизелмәде. Андыйларны флотка кем алсын?! «Зәңгәр» булса, серб кызына гашыйк булмас иде әле. Башаягы белән гашыйк булган. Каютадан мине куып диярлек чыгарды.

– Сәер. Союзда кызлар беткәнме? Монда килеп, серб кызына гашыйк булып йөрмәсә... Әле кызы нәрсә? Үпсәң – үбәр җире юк, тотсаң – тотар җире... Безнең Дон казачкаларына җитми инде, – дип авызын ерды Николай.

Иртәгесен Рәфикъларга да шәһәргә чыгарга рөхсәт булды. Офицерлар үзләреннән бер адым да читкә җибәрмәделәр. Аларның кибеттән-кибеткә йөреп, хатыннарына, балаларына әйбер җыйганнарын карап йөрделәр. Офицерларга динарны мул биргәннәр, күрәсең. Рәфикъларга өләшкән ише илле-алтмыш динар гына түгелдер.

Рәфикъларның шәһәрдә җиңел машиналарның күплегенә исе китте. Урамнарның ике ягына да тоташ машиналар тезелгән. Шәһәрдә трамвай-троллейбуслар бөтенләй юк. Сирәк-мирәк кенә автобуслар күренгәли үзе. Халык күбесенчә җәяү йөри. Бензин бик кыйммәт – Союздагыдан биш мәртәбәгә артыграк ди. Ишегаллары да машина белән тулган. Шәхси гаражлар юк дәрәҗәсендә икән. Гаражлар машинадан ике-өч мәртәбә кыйммәтрәк, дип аңлаттылар. Ирләрнең күбесе чит илләргә чыгып эшли икән. Илгә җиңел машиналарны шулар алып кайта ди. Италия, ФРГ машиналары, сирәк кенә «Волга» белән «Москвич»лар да күренгәли.

Йортларның беренче катында – тоташтан кибетләр, кафелар, төрле салоннар. Шәһәрдәге ярты халык портта, суднолар төзү заводында эшли, ә калганнары

шуларга хезмәт күрсәтә. Бер үк газетта латын шрифты да, кириллица да катнаша. Өч-дүрт тел белмәгән кешеләре сирәк. Аз-маз русча да сукалыйлар. Матур киенәләр. Порттагы эшчеләр бар да махсус киемдә. Шәһәрдә шорты киеп йөрү – гадәти хәл. Төрле сурәтләр төшкән футболкалары – күзең камашырлык.

Чит илгә чыгу һәммәсен дә нык каушата, кайда, нәрсәгә килеп тотынырга белмиләр. Бала уенчыклары, төрле футболкалар җыйдылар. Киоскта шәрә хатын-кызлар төшерелгән журналлар алырга акча кызгандылар. Сатучыдан сорап, актарып карыйлар да, бәясен ишеткәч, кире бирәләр. Рәфикъ барлы-юклы динарларына төрле открыткалар, значоклар, зажигалкалар җыйды.

Рәфикълар корабка кайтканда, трап янында замполит басып тора иде, ә «Ушастый» аннан нидер ялынып сораган сыман күренә. Йөк машинасы ышыгында теге серб кызы басып тора. Күрәсең, мичманның кыз янына чыгасы килгәндер... Кормовой пушка тирәсендә берничә тартма балык тора – тереләр – авызларын ачып-ябып яталар. Бар да бер зурлыкта, сайлап алгандай бер үк төрле. Коклар ул тартмаларны камбузга ташыйлар. «Бар да тәртиптә!» – дип, замполитка рапорт бирделәр. Рәфикълар кубрикка керергә ашыкмадылар. Ул арада серб кызы, һавада үбү ишарәсе ясап, йөк машинасына утырып китеп барды. Бераздан мичман берүзе басып калды. Башындагы уй-фикерләре йөзенә чыккан. Күзеннән яшьләр мөлдерәп тамар төсле...

Ул кичне, караңгы төшкәч, кораб койрыгындагы тупны 90 процентка борып, кино экраны элделәр. Инде бишенчеме, алтынчымы тапкыр «Кавказская пленница» фильмын әйләндерәләр. Экран пирстан да күренә. Порттагы халык кино карарга җыйналды – йөз кешеләп булгандыр. Аягүрә карадылар да, кино беткәч, озак итеп кул чабып таралдылар.

Корабның кабат диңгезгә чыгар вакыты да килеп җитте. Китәр вакытны каян белгәндер, теге серб кызы кораб янына тагын килгән. Мичман Иванов та трап тирәсендә чуала. Ләкин замполит аны бер адым да үзеннән читкә җибәрми, Риекка портында калыр дип куркамы? Менә арканнарны ычкындырдылар, трапны алдылар. Мичман кызга таба нидер ыргытты. Ыргыткан әйберсе кызның аяк астына диярлек килеп төште. Кыз, ул әйберне иелеп алып, кулындагы кечкенә сумкасына салып куйды.

– Нәрсә ыргыттың? Нигә миннән рөхсәт сорамадың? Корабта «аврал» тревогасы, иптәш мичман, нигә сез үз урыныгызда түгел?

– Иптәш өченче рангтагы капитан, Сез дә үз урыныгызда түгел бит. Балдак ыргыттым. Мин ул кызга барыбер өйләнәм.

– Әкият сөйләмә! Сиңа кем рөхсәт бирсен ди чит ил кызына өйләнергә. Марш үз постыңа! Ике секунд вакыт сиңа! – Замполитның сабырлыгы бетә башлады, тавышы катыланды. Рәфикъ ул вакытта вахтада иде, аларның бөтен сөйләшкәнен ишетеп торды.

– Шакиров, әгәр мичман Иванов портта калырга омтылыш ясаса, кисәтүсез-нисез ат! Вәт сиңа, кирәк булса – «Ушастый»... – дип, флотча, биш-алты катлап сүгенеп китеп барды ул.

Замполит та сүгенә белә икән.

Порт белән ике ара ерагайганнан-ерагая. «Аврал» тревогасы бетте. Кулына бинокль тотып, мичман, дикъкать белән портны күзәтә башлады.

– Иптәш мичман, Сез теге кызга нәрсә ыргыттыгыз? Замполит сорады.

– Мин аңа әйттем бит инде, балдак, дип.

– Балдак анда кадәр үзе генә оча алмый. Ул бит каз күкәе кадәр иде.

– Каз күкәен белмим, күргәнем юк. Ә балдакны хатка төрдем дә ипи йомшагы белән әвәләп түгәрәкләдем.

– Ә балдакны каян алдыгыз соң?

– Шакиров, син милиция тикшерүчесе кебек, бертуктаусыз сорау бирәсең. Өлкән матрос Волков бирде. Ул анда икәү-өчәү.

– Вахтаны тапшыргач, замполитның чакырып сорау алуы бар. Мин сорашканга ачуланмагыз инде. Вахтенный ни булганын белеп торырга тиеш бит.

– Балдакны кемнән алганны әйтмә! Алтын кибетеннән алган, диген! Волковны да чакырып башын катырмасын.

– Бәлки, анысын сорамас та. Андый балдаклар корабта ике кешенең берсендә бар.

– Замполит мине чакырып тормас инде, сөйләшүне Севастопольгә кайткач дәвам итәрбез! – диде.

Севастопольгә кайткач, ни сөйләшкәннәрдер, анысы Рәфикъка караңгы. Ә менә базага кайтып, атна-ун көн үтүгә, мичман Иванов, әйберләрен җыйнап, корабтан бөтенләйгә китеп барды.

Балдакны өлкән матрос Петров ясый, Америка бронзасыннан. ГОЙ пастасы белән чистартып җибәрсәң, алтыннан да катырак ялтырый. Тик бармакта озак йөрсә, бармак шәмәхә-кара төскә керә. Сабын белән генә юып бетереп булмый, бензин яки одеколон белән юарга кирәк. Заводта торганда, Петров андый бронзаны күп әзерләгән, шайбалар кырырга дип. Хәзер буш вакытында үз карамагындагы токарь станогында кырып балдак ясый, шомарта, ялтырата, теләгән кешегә сата. Акчасы булмаганнар сигаретка алыштырып ала.

Рәфикъка да бер шөгыль табарга кирәк. Буш вакыты күп. Кораб китапханәсендәге китаплар укылып бетте диярлек. Хатлар айга бер, күп булса ике килә, танкер белән. Ул танкер яңа фильмнар да алып килә. Корабта булганнарын инде күпме кирәк – карадылар. Кайберләрен унар мәртәбә әйләндергәннәрдер, шәт. Артистлар әйткән җөмләләрне ятлап бетерделәр.

Менә Николай әйткән 14нче ноктага бастылар, танкер көтәләр. Күктә болытның әсәре дә юк. Җилсез. Диңгез өсте пыяла кебек тигез. Ара-тирә бик вак, шадра дулкыннар гына пәйда була. Кармагы булганнар балык тота. Коклар ике як шкафутка да кырыгар метрлы алюмин савытлар чыгарып куйдылар. Бер сәгать үттеме икән, икесе тиңентен тулды. Бар да бер зурлыктагы ставрида балыклары. Менә кораб командиры Новиков та, үзенең җыелмалы урындыгын җәеп, борт кырыена килеп утырды. Аның кармак сабы озыная торган, калкавычлы, кылын җыйдыра торган кәтүге бар. Кармагына җим дә кертәсе юк. Калганнарның кармаклары сапсыз. Донка дип атала икән. Кылын гел селкетеп, тартып, җибәреп торырга кирәк. Балык эләккәне бармакка сизелә. Кайберәүләр берьюлы икешәр, өчәр балык тартып ала. Аннан соң, бушаган кармакларга ит кисәге, дуңгыз мае яки тоткан балыкны кисеп киертәләр. Менә Новиков кармагына да балык чиертә. Калкавыч бер уңайга бата-чума йөзеп китте. Командир тырыша-тырыша кармагының кылын җыя. Тарткан уңайга кармак сабы бөгелеп-бөгелеп килә. Ул да булмады, су өстендә кара-кучкылт зур гына бер нәрсә күренеп китте. Аның тыпырчынуыннан як-якка дулкыннар тарала. Рәфикълар авылының инешендә, су уртасына кереп, ата казлары канат кагынгач, шундый дулкыннар тарала иде. Новиков кармак сабын корсагына тери-тери тарта, бертуктаусыз кармак кылын җыя. Аның янына Рәфикъ кебек карап торучылар җыйналды. Командир катерын йөртүче өлкән матрос Кравцов та шул тирәдә булган икән. Тиз генә катер чехолы астыннан багор чыгарды. Ләкин багор да суга кадәр җитмәде. Боцман командасыннан ике

матрос тиз генә трап төшерделәр. Кармакка эләккән теге җанвар уңга-сулга йөри, борт янына якын киләсе килми. Траптан багор белән үрелеп, кармак кылын берничә кат чорнаттылар да теге җанварны тартып китерделәр. Һәм багор ыргагына эләктереп, ул җанварны судан алдылар. Эссе тимер палубага килеп төшкәч, ул берәр генә сикерде дә тынып калды. Гадәти камбала. Мин диңгез ташбакасыдыр дип уйлаган идем.

Рәфикъның моңарчы мондый да зур камбала күргәне юк иде әле. Авыл кибетенә кайткан камбалалар уч төбе кадәр генә, ә бу коклар алып чыккан унбиш литрлы чиләккә көчкә сыйды. Ике күзе дә өске якта икән. Аскы ягы аксыл-саргылт, тәңкәсез, ә өске ягы шәмәхә-кара төстә, вак тәңкәле. Камбаланы карарга ярты кораб халкы җыйналды. Балтика диңгезе буенда яшәгән латыш, эстон егетләренең дә , Кара диңгез буенда яшәгән абхаз, аджар егетләренең дә мондый камбала күргәннәре булмаган.

* * *

Туксанынчы елларның икенче яртысын хәтергә алса, Рәфикъ карт үзен-үзе күрә алмас хәлгә килеп җитә. Тормыштагы иң зур ялгышлары шул чорда булды бугай.

Шул чор агымына кушылып, сату-алу белән шөгыльләнеп карады. Чыкмады аннан алыпсатар, насыйп булмады баерга. 1998 елның августы барын хәл итте дә куйды. Ярый әле гаиләсенә зыян килмәде. Кайберәүләр кебек башы-аягы белән кереп чуммаган иде ул алып-сату эшенә. Шуңа да күргән зыяны да әллә ни булмады, аяктан екмады. Юк, сәүдәгәр булып тумаган ул. Нәсел-нәсәбендә сәүдәгәрләр юк – ни әтисе ягыннан, ни әнисе ягыннан. Татарча әйткәндә, канында юк, фәнчә әйткәндә, генында юк...

Аның белән бергә милиция академиясендә укыган сабакташ дусты алдырып китте. Артык зур эшкуар булмаса да, урта кулдан югарырак. Менә аның канында бар. Мәрхүм әтисе гомере буе кулланучылар җәмгыятендә эшләгән, күп өлешен рәис булып. Малай вакытта әти сәпит алып бирде. Безнең урамда миндә генә. Барысының да йөреп карыйсы килә. Сәпиттә йөрергә өйрәткән өчен илле тиен ала идем, йөреп килергә сәпит биреп торган өчен – ун тиен. Күрше авылга рус мәктәбенә укырга йөрер өчен, яңа сәпитне үз акчама сатып алдым, дип сөйләгәне хәтердә калган.

Шул дусты сөйрәп кертте дә инде сату-алу шөгыленә. Дефолт чорында дускае ныклап аягына басты. Ничектер җае туры килде. Доллар җыйган булган. Байлыгы дүрт мәртәбә артты. Байлыгы артты, саулыгы китеп барды. Акча түләп табибларга күренгән иде, унике төрле чир таптылар. Акчаны никадәр күбрәк түләсәң, шулкадәр күбрәк чир табалар икән. Иң начары – шикәр чире таптылар. Хәзер менә яраткан ризыкларын да ашый алмый.

Ни эшлисең, саулыкны акчага сатып алып булмый. Хатыны, балалары үзе исән чакта ук байлыгын бүлешә башладылар. Алла сакласын...

Байлык булмагач, тыныч, Рәфикъның бүлешәсе юк. Әлегә дәүләт биргән пенсия очын-очка ялгап барырга җитә. Биш-алты ел саен кабатланып торган кризислар гына эчне пошыра. Тынычлап яшәргә ирек бирми.

Кая калды икән ул яшь чаклар? Берни турында да кайгырасы юк. Чат саен белдерү тактасы. Егермеләп җиргә эшкә чакыралар. Балаларга әйтсәң, ышанмыйлар. Бигрәк тә төпчеге эш эзләп изаланды. Армиядә хезмәт итеп кайтып, җиде ай эшкә урнаша алмый йөрде.

Алда ни буласы анык кына билгеле түгел. Тагын 70-80нче еллардагы кебек

ашкынып кораллану башланырмы икән? Тигезлек саклыйбыз дигән булып, тагын бөтен акча коралланугa китеп бетәрме? Алай булса, эш харап. Союз вакытында коралланyны гади халык әллә ни сизмәде. Бары тик акча тотып йөреп, кирәк әйбереңне генә алып булмый иде. Алган очракта да зур танышлык белән, итәк астыннан гына... Хәзер начаррак булачак. Союз таркалган. Аннан бүленеп чыккан биш-алты дәүләт Рәсәйгә каршы. НАТО гаскәрләре ишек төбенә килеп җитте. Калининград өлкәсе чолганышта калды. Сатучысы күп булса да, алучысы юк. Монысы бигрәк тә начар! Сатучыдан дәүләткә өлеш керми. Әйбер сатылмагач, җитештерү туктала. Тагын дәүләткә зыян. Эшсезләр саны артачак.

Юк, тарта алмаячак Рәсәй бу йөкне. Тиз генә нидер кылмасалар, эшләр харап. Корал көчләре тигезлеге элек тә булмады, хәзер бигрәк тә булмаячак.

Юклы-барлы корал белән Урта диңгездә Американың туксанышар очкыч төягән, йөзмә күк аланнары (авианосецлар) артыннан чабып йөрделәр. Бозау кадәрле эт артыннан бияләй кадәрле көчек чәңгелдәп йөргән кебек. Сугыш хәрәкәтләре була калганда, ул Урта диңгездәге безнең дистәләгән корабларның минут эчендә юк ителәчәге билгеле иде. Нигә кирәк булды икән ул корабларны анда тоту?

Рәфикълар корабы ай буе Американың «Энденпенденс» авианосецы артыннан йөрде. Ягарга – ягулык, эчәргә су бетте. Авианосецны ике яктан ике танкер 25 узел тизлек белән барган көйгә ягулык белән тутыралар. Ә Рәфикълар корабын туктатып, ягулык һәм төче су белән ярты көн буе тутырырга кирәк. Аннан соң инде берничә тәүлек буе туктаусыз, иң зур тизлек белән артыннан куаларга кирәк. Ә бервакыт, никадәр кусалар да, куып җитә алмадылар, югалттылар. Италиянең бер портына тукталган икән. Нейтраль суларда атна буе көттеләр аның порттан чыкканын. Телевизордан атна буе Италия киноларын карадылар, тавышын ябып куеп. Ачканга карап барыбер берни аңлап булмый. Рәфикълар корабында итальянча белүче юк. Киноларның иң кызык җирендә реклама күрсәтеп алалар, аннан тагын кино дәвам итә. Сәер, бик тә сәер булды ияләнгәнче. Дөньяда «кока-кола», «пепси-кола» дигән эчемлекләр, дистәләгән төрдә шоколад һәм сагыз барын, хатын-кызлар гына куллана торган төрле кирәк- яракларны, бизәнү әйберләрен беренче мәртәбә шул рекламалардан күрделәр. Рәфикълар тукталган Югославиянең Риекка, Дубровник шәһәрләрендә, Мисырның Портсәет, Александрия портларында андый әйберләрне сатмыйлар иде әле.

Бигрәк тә Александрия порты хәтердә нык уелып калган.

Портка якын килә торган түгел иде... Нинди илләрнең нинди генә кораблары юк анда. Безнең илнекеләр дә дистәдән артык – әле күренгәннәре генә. Күренмәгәннәре никадәр булгандыр. Архангельск пароходчылыгының кораблары такта бушатканны көтәләр. Такталарны шулкадәр күп төягәннәр – салам йөге диеп белерсең! Мурманск пароходчылыгының суыткычлы кораблары күренә. Одесса, Новороссийск танкерлары рейдта чират көтә. Ашлык ташучы кораб стенкага ук баскан. Кайсы пароходчылыкныкыдыр – язуын күреп булмый. Мачтасында җилфердәгән байрагыннан гына танып була. Янәшәдән бик акрын тизлек белән «МАЗ» машиналары төягән Ленинград пароходчылыгы корабы стенкага таба йөзеп китте. Арада берничә «Волга» машинасы да күренә. Трюмында ниләр бардыр? Күп йөк төягәнлеге әллә кайдан күренеп тора, ватерлиния сызыгы суга баткан. Борынындагы ак сызык кына су астыннан күренеп-күренеп китә. Калининград пароходчылыгының бөтен йөге җаймә белән капланган. Текәлеп карасаң, танклар икәнлеген шәйләргә була. Бүтән төрле корал да булырга бик мөмкин. Мачталарда нинди

генә илләрнең байраклары җилфердәми. Хәтта японнарныкы да бар. Япония кая да Мисыр кая? Америка кораблары затлылыгы белән мактанырлык – без кем дип, әллә каян кычкырып торалар. Диңгезчеләрнең күбесе негрлар.

Рәфикъләр корабына стенкага килү мәҗбүри түгел. Әйбер төйисе, бушатасы юк. Ике якорьны да төшереп рейдка бастылар. Сигнальщиклар бертуктаусыз кемнәр беләндер сөйләшәләр, йә ут белән, йә флаглар белән. Янәшәләрендә кораб командирлары басып тора.

Килеп урнашуга бер сәгать вакыт үттеме икән, кораб янына бер кечкенә генә көймә йөзеп килде. Көймәдә кара бөдрә чәчле, йөзе, беләкләре кояшта нык янып каралган бер яшүсмер утыра. Негр түгел, гарәп булса кирәк. Көймәсе шулкадәр кечкенә. Тагын берәр кеше утырса, батып китәр кебек. Ишкәкләре дә уенчык кебек, метрдан артык булмас. Кораб бортына якынрак килгәч, ишкәкләрен, судан алып, көймәсенә урнаштырды. Көймәнең нәкъ уртасында булган зур гына агач сандыгын ачып куйды. Сандык капкачына әйберләр тезә башлады. Ниләр генә юк. Шәрә хатын-кыз сурәте төшкән открыткалар, зажигалкалар, значоклар, уенчыклар, тагын әллә ниләр. Рәфикъләр корабының боцманы: «Әссәламегаләйкүм, Ибраһим», – дип, көймәдәге егетне сәламләде. Егетнең бик тә күңеле булып, бөтен эшен калдырып, торып басып, уң кулын күкрәгенә куеп, берничә кат гәүдәсен билдән бөкте. Аның бу хәрәкәтләреннән көймә чайкалып-чайкалып куйды. Егет-малай тиз генә урынына утырды, ап-ак тешләрен ялтыратып елмайды. Кулы белән ишарәләп, товарларын тәкъдим итте. Боцманга: «Шпашибо, командир!» – диде. Әллә каян замполит килеп чыкты. Уң кулында пистолет. Ул пистолетлы кулын болгый-болгый кычкырды:

– Хинде хох! Прочь отсюда! – Аннан инглизчә дә берничә сүз әйтте. Ибраһим ике кулын да күтәрде, уч төпләрен корабка каратты.

– Не ругай, командир! Ибрахим хороший. Ибрахим любит русских!

Ибраһимның йөзеннән елмаю качты, ләкин курку юк, ялыну да юк. Ишкәкләрен кулына алып, берәр мәртәбә кирегә иште. Көймә шул ишкәнгә корабтан бер ун метр чамасы ераклашты. Бик тә җиңел, хәрәкәтчән көймә иде.

Замполит уң як шкафутка җыйналган матрос, старшиналарны куалый башлады. Ходовой мостиктан командир карап тора икән. Ул замполитны үз янына чакырып алды. Замполитның киткәнен күргәч, Ибраһим тагын бортка якынайды. Корабта күптән түгел генә хезмәт итә башлаган бер дагыстанлы егет Ибраһимга нидер әйтте. Әллә үз телендә, әллә гарәп телендә. Ибраһимның тагын авызы ерылды. Сандык капкачына тезгән әйберләрнең берәм-берәм бәяләрен әйтә башлады. Гарәпчә дә әйтә, русча да кабатлый. Инглизчә дә сүзләр кыстыра. Аның гарәпчә әйткән сүзләрен дагыстанлы аңлый. Үзара байтак сөйләшеп алдылар.

Ибраһимга рус акчасы кирәк түгел икән. Ленин башы төшкән, кызыл унлыкларны берәрне алырга мөмкин. Аның чүп-чарына кем унлык чыгарып тоттырсын. Доллар алам, ди. Долларга әйберләрне арзанга бирергә вәгъдә итә. Ләкин Рәфикъларга доллар каян килсен...

* * *

Иртән бер төркем диңгезчеләргә портка чыгарга мөмкин булуын әйттеләр. Чыгасы килмәгән кеше, Севастопольгә кайткач, Мисыр акчасы урынына чит илләр белән сәүдә итү банкының чегын алачагын белгерттеләр. Севастопольдәге «Берёзка» кибетендә юньлерәк әйбер алырмын дип, Рәфикъ шәһәргә чыкмады. Гомумән, шәһәргә чыгарга ашкынучылар бик юк иде. Кичтән «БЧ – 2» мичманы,

ике матрос белән ютка ике тартма граната чыгарып куйды. Беренче гранатаны диңгезгә ул үзе ыргытты, дүрт секундтан соң «Р5Д-1» гранатасы суда шартлады, су өстенә зур булмаган өермә бәреп чыкты. Тагын егерме минуттан соң юттагы вахтенный икенчесен ыргытты. Шул рәвешле, вахтенныйлар, алмаш-тилмәш, төне буе граната шартлатып чыктылар. Ул граната шартлавы палубада әллә ни тәэсир ясамаса да, кубрикта яңгырап ишетелә, йокыдан уята.

Рәхәтләнделәр инде граната шартлатып... Җамыяк өеп макарон китергәннәр иде. Макаронына караганда ите күбрәк. Ашыйлар да граната ыргыталар, ашыйлар да граната ыргыталар. Дежур офицер, килеп, берәрне ыргытып китте. Әле ераккарак ыргыту буенча ярышып та алдылар.

* * *

Александрия портын калдырып, диңгезгә чыкканда, ком бураны күтәрелде. Вак ком өермәсе күкне тоташ каплап алды. Җил чүлдән диңгезгә исә. Үзе белән күзгә күренми торган ком тузаны алып килә. Бу ком күзләргә, авыз-борынга тула. Кием белән тән арасына кереп кычыттыра. Давыл сәгатькә якын корабка ияреп барды. Вакыты-вакыты белән кояшны каплый, көн караңгыланып китә. Ком бураны ничек башланган булса, шулай бетте дә. Менә бер заман судан балыклар чыгып, һавада оча башладылар. Зур балыклар түгел. Рәфикъләр авылы инешендәге такта чабакка охшаганнар. Вак тәңкәләре кояшта елык-елык килә. Биш-алты метр чамасы һавада очып баралар да кабат диңгезгә чумалар. Дистәләгән балык берьюлы оча, төрлесе төрле җирдә. Кайберләре икешәр метрга кадәр күтәрелә. Рәфикъның инештә такта чабакның судан чыгып черки аулаганын күргәне бар. Монда да шундый хәл ахры. Ләкин черки диңгезгә кайдан килгән? Давыл куып китергәнме?

Корабтагы бөтен кеше диңгездә балык очканны карарга палубага чыкты. Кораб белән командир үзе идарә итә икән. Балыкчы буларак, ул да бу күренешне күзәтә. Корабны акрынайтты. Балыклар кораб янәшәсеннән үк оча башладылар. Берсе очкан көйгә кораб бортына бәрелә язды, ләкин бәрелмәде, суга чумып өлгерде. Дөрестән дә, диңгездә черки бар икән. Кайберләре диңгезчеләрнең ялангач ботларына, беләкләренә куна башладылар. Табигатьтә һәр җан иясе ничек тә булса яшәргә, җан асрарга маташа. Черкигә дә ризык кирәк, аны аулаган балыкка да.

Кояш баеп, көн караңгылангач, бар да юкка чыкты. Корабның зур тизлек белән кая барганын командир да бер Ходай гына белә. Шул рәвешчә, тәүлектән артык йөзгәч, еракта Американың бер авианосецы күренде. Бу – Рәфикъларга таныш булганы түгел, бүтәне. Урта диңгезгә Америка ярларыннан яңарак кына килгән. Якынрак килгәч, ни өчен бу корабны эзләп йөзгәннәре билгеле булды.

Александриядән Рәфикъләр корабына утырып чыккан ике кеше Америка авианосецын бертуктаусыз сурәткә төшерә. Очкычларның палубага төшеп кунганын кинокамера белән язалар. Алар янында КГБшник Хомяков кайнаша. Ярты көнгә якын авианосец янәшәсендә йөзделәр. Бер алдына чыктылар, бер артына. Шулкадәр төшерүгә ничек тасмалары җиткәндер. Көн кичкә авышкач, авианосецтан ерагаеп, көнчыгышка таба йөзделәр. Икенче көнне Крит утравы янында аларны кечерәк кенә бер кораб көтеп тора иде. Бу корабта корал-фәлән юк. Диңгезчеләр дә гади киемнән. Бортына «Фәнни тикшеренү корабы» дип язылган. Одесса пароходчылыгыннан икән.

Күптән су күрмәгән командир катерын диңгезгә төшерделәр. Моторы байтакка кадәр кабынмыйча маташты. Чых-пых килә дә сүнә. Кай җирендер актаргач, эшләп китте тагын. Зур-зур тартмаларын күтәреп, теге ике кеше катерга төшеп утырдылар. Новиков белән Хомяков озата килделәр.

* * *

Яңадан ике мәртәбә ерак йөзүгә барса да, ничектер, беренче мәртәбәсе Рәфикъ картның хәтерендә ныграк сеңеп калган. Хәтер йомгагын ныклабрак сүтсәң, соңгылары да берәм-берәм искә төшәр иде дә...

Гибралтар бугазын узып, Атлантик океанга чыкканда, бер алюмин кружка диңгез суы эчкәнен дә хәтерли. Суны бер ул гына эчмәде. Бар да эчтеләр. Беренче мәртәбә зур сәяхәткә чыкканда, йоласы шундый...

Ерак йөзүгә китүгә караганда, аннан әйләнеп кайтуы күңеллерәк. Бик тә тантаналы итеп каршы алалар. Бөтен кеше елмая, кайтучылары да, каршы алучылары да. Бигрәк тә бала-чага шатлана – ничә айлар күрмәгән әтиләре кайта, буш кул белән генә түгел – моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән әйберләр алып кайта. Ярты шәһәргә ишетелерлек итеп музыка уйнап тора. Флот штабыннан да каршы алырга килгәннәр. Араларында адмирал погоны такканы да бар. Бу күренешне язып һәм сөйләп кенә аңлатып булмый. Үз башыңнан уздырырга кирәк.

Менә шундыйрак итеп яшәде Советлар Союзының хәрби диңгез флоты узган гасырның җитмешенче елларында. Кораблар йөзде. Ерак диңгезләргә, океаннарга чыктылар. «Ерак йөзгән өчен» дип бирелә торган күкрәк тамгасын ясап, өлгертеп, өләшеп бетерә алмадылар. Дөрес булса, орден-медальләр эшләнә торган урында ясыйлар икән. Ул тамга орден-медальләргә тиң иде.

Ә туксанынчы еллар?! Ходай күрсәтмәсен, бүтән кабатланмасын. Чирек гасыр узгач, тагын булды Рәфикъ карт хезмәт иткән данлыклы Севастополь каласында. Шәһәр тоныкланган. Күп йортлар сипләү сорый. Машиналар, автобус-троллейбуслар – һәммәсе дә совет чорыннан калган. Юллар ватылып бара.

Ә корабларның барысы да бухтада. Зурлары – уртада, кечерәкләре – яр буенда. Сәгатьләр буе утсыз утыралар икән. Ягарга ягулык юк. Дистә елга якын яңа буяу күрмәгән бортларында, өс корылмаларында күгәрек тибеп чыккан. Коралларны каплап торган җәймәләре төсен югалтып, искереп сүсәргән.

Диңгезчеләрнең йөзендә елмаю күренми. Үзләре әлегә ач булмасалар да, ничек итеп гаиләне асрарга дигән кайгылары бар. Биш-алты ай түләнмәгән хезмәт хакын, Мәскәүгә барып, капчыклар белән алып кайталар. Җыйналган әҗәтләрне түләгәннән соң, очын-очка ялгарга чак җитә. Ярты халык эшсез. Җир читенә барып эшләргә ризалар. Тик эш кенә булсын.

Сирәк-мирәк Украина диңгезчесе киемен кигән хәрбиләрне дә күрде. Аларның хәле тагын да мөшкелрәк. Хезмәт хаклары Рәсәй диңгезчеләренекенә караганда өч-дүрт мәртәбә ким. Аны да әле көне-сәгате белән көчен югалта барган гривнялата түлиләр.

Бик тә, бик тә күңеле төшеп кайтты Рәфикъ картның ул шәһәргә баруыннан.

Яңа Россия үлә барган флотны терелтте. Кораблар йөзә башлады. Аз булса да яңалары төзелә. Диңгезче йөзәргә тиеш. Чери барган корабта, бухтада якорьдә утырырга тиеш түгел. Флотка ул диңгез-океаннарда йөзү, ил-җирләр күрү хыялы белән килә.

Рәфикъ картның инде Кырымга барып, терелә барган флотны күреп кайтасы килә. Барыр, Алла теләсә! Күпер генә төзелеп бетсен дә, Ходай гомерне генә бирсен!



Әлфия
Ситдыйкова

# ВАКЫТ – ҖИТЕЗ БОЛАН

СОНЕТЛАР

**1**

Язмышыңа әгәр язган булса сагыш,
Яба вакыт сары яулык алсу йөзгә.
Күңел күген күкселләтеп болыт йөзә,
Аваз сала кара төндә әрсез байгыш.

Усал җилләр тәрәзәне килеп кага,
Тынлыкның да тавышыннан чыңлый колак.
Җан сыктаудан тамырларны иңләп-буйлап,
Дөрли-дөрли ут сулышлы ялкын ага.

Тилергән хис өндә түгел, төштә сыный,
Күзәнәкләр уяна да, сагыш сулый,
Әйтерсең лә куып торган кара каргыш.

Төннәр озын, таңнар атмый интектерә,
Торган йортың кайчак гүя була төрмә,
Ялгызлыкка дучар булсаң әгәр ялгыш.

**2**

Җилләр исә дулый-дулый, болыт тузгый,
Өзеләләр яфраклары агачымның,
Җиргә төшә әҗереме адашуның,
Кемнәр әйткән, гомер, диеп, зая узмый.

Өшегәндә тәнем түгел, җаным туңып,
Сыенырлык, җылытырлык юк якыным.
Саран ай да җәлләп сибә нур-яктысын.
Салкын мендәр, эчем-тышым ялкынлы ут.

Айлар арты еллар ага алга таба,
Вакыт җитез болан кебек һаман чаба,
Син еракта башка ярлар куенында.

Сөю эзләп, назлар көтеп узган гомер,
Юанганмын, бер килмәсә, дип, бер килер,
Югалтулар откanмын фал уенында.

**3**

Чәчләремә бәс төшкәндә, син җан өрдең,
Йөгереп кердем дөрләп янган ут эченә,
Кергән идең син күптәннән бер төшемә,
Мин ул чакта ак гөлләрдән такыя үрдем.

Ак чәчәкләр – аклык төсе. Якты хисне
Сакларсың дип уйлап йөрдем гомер буе.
И тансык яр, сизденме син минем уйны,
Укыганда күзләремнән серле кичне.

Әлфия СИТДЫЙКОВА – *шагыйрә; «Утлы җимеш», «Тансык бәхет», «Хәтер җебе» исемле китаплар авторы. С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. Чаллыда яши.*

Дулкын-дулкын хисләр ташый күңелемнән,
Үзем куркам чайпалыплар түгелүдән,
Тибрәттең дә сабый сыман кочагыңда.

Соң мәртәбә йөрәгемә ялкын капты,
Күкрәгемдә җырчы былбыл канат какты,
Янам дөрләп ялкынлы ут учагында.

**4**

Каршылыймын сөю тулы язларымны,
Китә күрмә каерыплар канатымны.
Әле яңа таныйм синең яратуны,
Төштәме соң, әллә өндә бу назларың...

Канатыңа тотынам да күккә ашам,
Гөлләр белән тулы синең күңел бакчаң,
Гарешләргә юл ачучы ул син икән.

Шәм түгел лә, кояш элеп куйдың күккә,
Җан түренә оя корды пар сандугач,
Өздерепләр сайрашалар, ал таң тугач...
Юкка чыкты язмышыма булган үпкә.

Хуш исләрдән исерәбез икебез дә,
Җәннәтләрдә пешкән алма икебезгә...
Алып менгәч, ега күрмә мине күктән.

**5**

Таһир-Зөһрә хәлен белә бары күкләр,
Галәм карый күзен кысып гашыйкларга,
Күк капусы ачыла тик ашкыннарга,
Мәхәббәтен җуйганнарга ябык чикләр.

Уйласак та, безнең башлар күккә тия...
Җир күчәрен күтәрерлек көчкә ия...
Адымнар да хәзер күпкә базымлырак.

Галәм кичтек, йолдызларның нурын эчтек
Һәм яшәрдек сөю диган затлы хистән.
Мең ел үтеп киткәндә дә чыкмас истән,
Чиксезлекнең серен ачып, җиргә төштек.

Җаныбызда, аңыбызда сихри балкыш,
Фал китабы битләрендә серле язмыш...
Безне кавыштырган йолдыз юлы ерак.

**6**

Йолдыз булып балкыр өчен Сөю кирәк.
«Син минеке, мин синеке» дигән сүзләр
Галәмнәрне кичеп мәңге безне эзләр,
Берсен-берсе тоеп тибәр ике йөрәк.

Мәхәббәтен беркөн җуйса гашыйк җаннар,
Безнең хәлне, әйтче, җирдә кемнәр аңлар,
Ишелмәсме күк капусы өстебезгә?

Кушылганда синең сулыш, минем сулыш,
Шаһит булды ай-йолдызлы җәйге кичләр.
Мәңгелекнең юлы булган галәм нишләр,
Аерылса кап икегә безнең язмыш?

Бертуктамый яңгыр койса, ташлар яуса,
Җимерелеп юлыбызга таулар ауса,
Каргыш булыр ул Сөюдән икебезгә.

**7**

Акыл белән хис табышкан көнне саклыйк.
Сизәсеңме, сөю хисе яши, тере!
Күзен ача агачларда яшел бөре.
Кышларга да җитәкләшеп бергә атлыйк.

Синсез дөнья булыр иде ямьсез, шыксыз,
Яшәр идем ятим булып, бер шатлыксыз.
Аңлаучылар булмас иде минем җанны.

Яшел үлән борын төртә. Сары чәчәк
Керфекләрен назлап искән җилләр тарый.
Җиргә килгәч очрашканбыз әле ярый,
Димәк, безгә насыйп икән бу күрәчәк.

Сөю тәмен татымаган бәхет тапмый,
Мәхәббәтен эзли, тәүге хисен саклый
Каршы алганчыга кадәр соңгы таңны.

**8**

Әле соңгы түгел, уртак таңны көтәм,
Төн пәрдәсен ерта якты йолдыз нуры...
Бергә атлап барган юллар безнең туры,
Җәйге якты иртә көмеш чыклар сипкән.

Энҗе бөртекләрен җыям учларыма.
Хисләремне тыям син янымда чакта.
Тарат шик-шөбһәне бер күземә бак та
Ялкын өстәп тор син күңел учагына.

Йөрәк дулап чаба, ул зарыккан назга,
Әйтмә миңа берүк, килдем, дип, бик азга.
Сөю әле яңа шаулап чәчәк ата.

Мин бит таптым сине чып-чын ихлас хистә,
Бәхетем син, дию ялган түгел һич тә.
Кал син яннарымда, янәшәмнән атла.

**9**

Таштан булса җаның, кит янымнан, әйдә,
Бәхет тәмен белдем синең белән бергә,
Тын тынлыкны бозып узган идең түргә...
Каршы алдың язда, калсаң әгәр җәйдә,

Рәнҗеп калмам сиңа, фал китабын ачтың.
Сөеп туймаганнар, дисә дисен язмыш,
Син бит гомеремдә иң зур татлы табыш,
Башка кидем якут серле сөю таҗын.

Яши алсак җирдә үкенмәслек итеп,
Яшәрерләр гөлләр, тансык назны көтеп,
Сөю күзе ачык, ак нур сибә юлга.

Ай күренгәч, кояш йөз яшерә, бакчы,
Кызарды да йөзе, ал офыкка качты...
Гашыйк булган ахры минем кебек ул да.

**10**

Төн тынлыгы – тылсым, ярда зифа буй-сын...
Ять-яшь кыз һәм егет су коена күлдә.
Безнең җаннар кабат дуңгәләкле чүлдә...
Шом өн ишетелә: «Язмышыңа буйсын!»

Югалттым мин ярны, өндә түгел, төштә,
Эзлим гасырлардан, таба алмыйм сине,
Вакыт саксыз өзде бергә язган көйне...
Җан ярылды шул чак, дүрткә әллә бишкә.

Тып-тын калды дөнья, йокы баскан сыман,
Ул тынлыкка сагыш, әрнү, үксү сыйган...
Тукталгандай вакыт, бар да калган катып.

Җиһан телсез, җансыз, ярымүле хәлдә,
Галәм төргән үзен бүген кара шәлгә.
Кояш чыкмас кире, безне кабат танып.

**11**

Саташулы йокы халәтеннән ардым.
Уянасым килә, уятасым килә.
Ишегемдә кинәт шылтырады келә,
Ишетелә төштә сүзе тансык ярның.

Дәшә ул да миңа: «Хисләреңне тыйма!..»
Сагынганын беләм, тоя ярсу йөрәк.
Шыбыр-шыбыр көлә тышта ялгыз тирәк,
Табигать тә сыен әзерлиме туйга.

Җете буяу белән буйый урманнарны,
Көзләр яба җиргә төсле юрганнарны...
Болытлардан тама шатлык яше, күрче!

Чык җемелди әнә дымсу яфракларда,
Бәхет кошын эзләп килдек таллы ярга...
Алтын яфраклардан бәйләм җыеп бирче!

**12**

Тезелешеп күктә кыр казлары оча,
Чит җирләргә сынап илтә язмышлары,
Каңгылдаша казлар, боек тавышлары,
Талган канатлары күк болытны коча.

Хушлашырга безгә иртә әле, иркәм,
Кыр казлары сыман китә күрмә очып,
Туйдым сагыш эчеп, ялгызлыкны кочып,
Күктә түгел, җанда кояш чыксын иртән.

Гомер үтеп бара ак бәхетне көтеп,
Һәрбер аткан таңны якты сагыш итеп
Каршы алыйк бергә, төреп татлы сергә.

Галиҗәнап Сөю җаныбызга керсен,
Мәңге китмәс булып аңыбызга сеңсен,
Узсын кыенсынмый тәвәккәлләп түргә.

**13**

Ап-ак кышлар алда, матур җырга ялга
Икәү бергә язган моңлы озын көйне.
Хәтерләрдә саклыйк күккә менгән көнне,
Өзеп биргән чакны язмыш алсу алма.

Колак салмый гына күңелдәге зарга,
Синең өчен яшим көч-дәрманым барда.
Кышны көткән чакта, яз китердең әл дә.

Сүлпәнәя күрмә, ялкын утта җылыт,
Ышыкланыйм синең көчле рухыңа.
Нокта куймый гына сөю тарихына,
Сагыш кочагыннан ал син мине йолып.

Оран салып дәшим, белсен бөтен галәм,
Өзлеп сөйгән ярга шигырь яза каләм,
Язмыш бураннары тынып калган мәлдә.

**14**

Язгы елга сыман ташый ярсу җаным,
Ташу судай хисләр били үзәннәрне.
Башта уйлар чаба, бал кортыдай гүли,
Таныйсыңмы кырда үскән үләннәрне?

Таулар булып таулар башын ия безгә,
Кыяларга басып дөньяга кул изә.
Тау башында бөркет оя корган икән.

Күреп белгәнче үк җанга якын кешем,
Юра күргән төшем, юра тик яхшыга.
Уртак таңны кояштай көлеп каршыла,
Җиһан йөзен дымга төрмәсен лә яшең.

Күкрәгеңдә тибә бөркет кебек йөрәк,
Яра тулы җанга аумас ныклы терәк,
Мәхәббәттән олы ни бар икән, иркәм?!

**15**

Бу сагыну җыры, соңгы җырым түгел,
Канат кына кага дәртле илһам кошы.
Чут-чут тавышыннан җуймам микән һушны?!
Сандугачтай сайрап тора моңлы күңел.

Йөз пәрдәсен тарткан күңел тәрәзәдә,
Колагымда алка, ташы фирүзә лә,
Тын тынлыкта саклый өрфиядәй җанны.

Кушыл син дә, ярым, бергә җырлыйк тагын,
Көе яңа, сүзе тик языла гына,
Күмеп дөньялыкны сихри назлы моңга,
Ал нурларга төреп уртак сөю таңын.

Язгы моңнар кага күңел ярларына,
Бер көчәя агым, бер карасаң тына,
Көтеп яшим җирдә синле якты таңны.

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

# КАЗАКЪЛАРНЫҢ ЙӨЗ АКЛЫГЫ

Казакъларның бөек шагыйре Мукагали Макатаев турында иң беренче булып Рәдиф Гаташтан ишеткәнем бар иде. Ул казакъ шагыйрьләре белән күптәннән кызыксына, Магҗан Җомабаевның татарча китабын да тәрҗемә итеп чыгарды. Кайчандыр, яшьрәк чагында Алматыга баргач, Мукагалине ерактанрак булса да күреп тә калганы булган икән. Аннары миңа Казакъстан Язучылар союзы рәисе, күренекле шагыйрь Нурлан Оразалинның шигырьләрен татарчага тәрҗемә итәргә туры килде. Яратып эшләдем, тәрҗемә иткән вакытта казакъ поэзиясенең үзенчәлекләрен, матурлыгын һәм зурлыгын тойдым. Алматыга шул китапны тәкъдир итәргә баргач, андагы каләмдәшләргә Мукагалинең язмышы һәм иҗаты белән кызыксынуымны әйткән идем. Нурлан Оразалинның урынбасары, шагыйрь Җанарбәк Ашимҗан аның авылдашы ук булып чыкты. Ул миңа Мукагали Макатаевның бик калын бер китабын бүләк итте. Китап Төркиядә берьюлы ике телдә – төрекчә һәм казакъча – басылып чыккан 600 битле «Сайланма шигырьләр» иде. Тәрҗемәгә тотынгач, китапның икетелле булуы бик тә ярап куйды. Казакъча аңламаган сүзләрне, төшенчәләрне төрек сүзлегеннән эзләп табарга була иде. Казакъ шигыренең төрекчәгә ни дәрәҗәдә төгәл тәрҗемә кылынганлыгын күзәтү дә үзем өчен кирәкле бер тәҗрибә мәктәбе шикеллерәк гамәл булды...

Кыскасы, тәрҗемә барышында мин үзем өчен өр-яңа бер шагыйрь, өр-яңа шигъри дөнья ачтым. Чыннан да, без моңа кадәр үз казаныбызда гына кайнап, рус теленә тәрҗемә ителгән кайбер шагыйрьләрне генә укып, үзебезнең төрки туганнарыбызның әдәбиятын бөтенләй диярлек белми яшәгәнбез икән. Ә инде русчага тәрҗемәләрнең ниндилеген, аларның күпчелегендә миллилекнең, милли үзенчәлекләрнең сакланмавы турында без инде хәзер яхшы беләбез...

Ә казакъ әдәбиятында Мукагали Макатаев дигән зур шагыйрь булган, ул искиткеч шәп шигырьләр иҗат иткән... Ни кызганыч, без аның иҗатын да, барлыгын да белмәгәнбез. Белгән булыр идек тә, казакълар белән кирәгенчә аралашмаганбыз. Аралашсак та, рәсми рәвештә генә, өзек-өзек кенә, җае чыкканда гына, ниндидер вакыйгалар уңаеннан гына. Ә бит Мукагали үзе исән чагында ук халык арасында шактый билгеле шагыйрь булган...

Ул – безнең бик күпләребез шикелле үк совет чоры шагыйре, бик күп шагыйрьләребез кебек үк әтисез үскән сугыш чоры баласы. 1931 елны Алматы өлкәсенең Карасаз исемле авылында дөньяга килгән. Димәк ки, быел аңа 86 яшь тулган булыр иде. Тик шагыйрь бик иртә – моннан 41 ел элек (1976 елны) вафат булып куя. Язмыш аңа бары тик 45 ел гомер биргән... Шулай да казакъның бөек шагыйре булыр өчен аңа шул кыска гына гомер дә җиткән. (Биредә үзебезнең Тукай, Бабич, Җәлил кебек гомерләре кыска, иҗат гомерләре озын булган шагыйрьләребез искә төшә.) Шул арада ул сигез шигырьләр китабы чыгарып өлгергән, поэмалар, повестьлар һәм хикәяләр, пьесалар язган, хәзерге казакъ шигърияте турында мәкаләләр иҗат иткән. В.Шекспирны, У.Уитменны, шәрекъ шагыйрьләрен, рус шагыйрьләрен тәрҗемә иткән, Дантеның «Илаһи комедия»сен тәрҗемә итә башлаган... Мукагали Макатаевның тормышы да, иҗаты да бик күп шагыйрьләребезнеке кебек үк төрле каршылыклардан, авырлыклардан, сынаулардан торган. Бик яшьли өйләнә, алты балалары була. Авылда рус теле укытучысы, район газетасында хәбәрче була, Алматыга күчкәч, газета-журналларда, Язучылар союзында эшли, Казакъстан радиосында диктор була. (Күптән түгел, интернеттан табып алып, мин аның үз тавышын, шигырь укыгандагы язмасын тыңладым. Аның тавышы, шигырь укуы мине, дөресен генә әйткәндә, тетрәндерде. Казакъ шигыре бөтенләй башка аһәң белән яңгырады. Мондый тавыш бездә Айрат Арслановта гына бар иде...) Популярлык аңа олы сынаулар аша килә. Олы кызы Майгөл унбер яшендә фаҗигале рәвештә һәлак була. Фатирсызлык, фатирдан фатирга күчеп, кеше өстендә яшәүләр, эшсез калулар,

кульъязмалары тулы портфелен югалту, үз-үзе белән, үзенең йомшак яклары белән, коточкыч дәвалап булмас авырулары белән көрәшүләр, каләмдәшләренең нахакка рәнҗетүләре, Язучылар союзыннан куылулары... Үзенең көндәлекләрендә ул мондый сүзләр язып калдырган: *«Каһәр суксын сине, шигъри язмышым! Өчләтә каһәр суксын мине чорнап алган мохитне! Мин ул тирәлеккә бөтен җаным-тәнемне бирдем, барысы да әйбәт булыр дип ышандым. Миңа кайгы-хәсрәттән башка берни дә китермәгән, мыскыл ителгән, кимсетелгән көннәремне тәгәлләп ятам. Хәзер менә аңладым инде, бу дөньяда миннән дә бәхетсезрәк кеше юк»*. Җан ачысы белән язылган, җанындагы бөтен авыртуларының, әрнүләренең кайтавазы булып яңгыраган бу сүзләрне шагыйрь болай гына язмас! Димәк, аны шул көнгә төшергәннәр, шушы халәткә җиткергәннәр.

Көндәлегендәге иң соңгы язмаларында ул болай дип яза: *«Хөрмәтле иптәшләрем! Әгәр дә сез биографиямне, иҗатымны, чыннан да, тикшерәсегез килсә, минем бөтен язганнарымны укып чыгарга онытмагыз. Мин шигырьләремдә үземнең «мин»ем аша үземнең тормышымның елъязмасын язып бардым»*. Чыннан да, Мукагалинең шигырьләре искиткеч ихлас, гади... Аларда бернинди ясалмалылык юк, акыл сату юк. Әйтәсе фикере ачык, әйтелгән сүзе – халыкчан, укучы күңеленә якын. Аның шигъри юлларына, образларына җете буяулар хас түгел. Ул күбрәк аклы-каралы төсләр белән эш итә, нечкә күңелле булудан кыенсынмый, газаплы уй-фикерләрен яшереп тормый.

Шуңа күрә дә аның шигърияте беркадәр бөек рус шагыйре Сергей Есенинныкы белән дә аваздаш. Ул үзенең бер шигырендә юкка гына болай дип язмагандыр: *«Мәхәббәт, дип яндым, көйдем һәм җан аттым, Гаделлек, дип борынымны күп канаттым. Чирткәнем дә булмады җан иясенә, Синең кебек, Сергей, мин дә эт яраттым»*. Мукагалинең иҗаты күпмедер дәрәҗәдә безнең бөек Такташ иҗатына тартым, Туфан белән Атнабайны да, Илдар Юзеев белән Зөлфәтне дә, Салават Рәхмәтулла белән Марат Кәбировны да хәтерләтеп куя. Тик безнең совет чоры шигъриятенә әйтергә теләгәнеңне дә әйтеп бетермәү, дөресрәге, әйтә алмау, хисләреңне белдерсәң дә, фикереңне яшереп калдыру, күп дигәндә, киная белән генә әйтү, әйтергә тырышу хас иде. Бу, билгеле, безнең зур-зур шагыйрьләребезгә дә кагылмый калмады. Ә менә Мукагалинең шигырьләре шәхси кичерешләргә бай булуы белән, ничек бар, шулай язуы белән башкалардан бик күпкә аерылып тора. Ул үзенең эчке дөньясын укучы алдында ачып салудан курыкмый. Совет чорында андый шигърият, йомшак кына итеп әйткәндә, хупланмый иде: үз хисләреңдә, үз күңелеңдә «казыну» буларак кабул ителә иде.

Мукагалинең күренекле казакъ шагыйрәсе Фариза Уңгарсыновага багышлап язылган бер шигыре бар. Ул анда үзенең бөтен әрнүләрен, кайгы-хәсрәтләрен, әйләнә-тирәсендәгеләргә булган хак мөнәсәбәтен һәм үзенең иҗатына булган үз бәясен дә сыйдырган. Үзенең каләмдәшенә ул болай ди: *«Күрсәтәләр икән монда күрәсеңне... Фаризаҗан! Син шуларны беләсеңме?»* Аннары дәвам итә: *«Шундый хәлем, нигә шагыйрь булганмындыр, Шагыйрь булып нигә генә туганмындыр?!.»* Мондый уфтанулар артында күпме фаҗига, күпме үкенечле көннәр булуын шагыйрь үзе генә белгәндер, әлбәттә... Шулай да шигырь ниндидер бер ышаныч, өмет белән тәмамлана: *«Том-том булып киштәләрдә тормасак та, Подвалдагы архивлардан табылырбыз...»*

Монысы инде Мукагалинең үз-үзенә бәясе, үз иҗатына ышанычы, үз бөеклеген аңлавы булып аңлашыла. Ә көндәлекләрендә ул үзенең XXI гасыр шагыйре дә булачагын язып калдырган. Үз-үзенә, үз иҗатына нык ышанган шагыйрь, чыннан да, хаклы булган!

Мукагали Макатаевка шагыйрь буларак танылу, чын популярлык үзенең вафатыннан соң килә. 1981 елны Алматының бер урамына аның исеме бирелә, ул яшәгән йортка истәлек тактасы куела. 1985 елны Казакъстан Язучылар союзы М.Макатаев исемендәге әдәби премия булдыра. 2000 елны шагыйрь «Әманәт» исемле шигырьләр җыентыгы өчен Казакъстанның Дәүләт премиясенә лаек була. 2002 елда шагыйрьгә Алматыдагы үз исемен йөрткән урамда бронза һәйкәл куела...

Бүгенге көндә Мукагали Макатаев – казакъ шигъриятенең классигы, казакъларның йөз аклыгы. Шәкертләренең берсе әйткәнчә: *«Шагыйрьнең икенче тормышы башланды. Мукагали бүген – легенда, Мукагали бүген – хакыйкать, Мукагали бүген – Коръән»*. Биредә бераз гына арттыру да бардыр, әмма кемдер шулай уйлый икән,

кемдер шагыйрьгә шундый илаһи бәя бирә икән, бу инде үзе үк хакыйкатькә тиң. Димәк, Мукагали Макатаев үз халкының күңеленә сандугач булып кунган, сандугач булып оялаган!..


Мукагалинең шигърияте минем күңелемне дә тулысы белән яулап алды, хисләремне, уйларымны биләп алды. Мин анда үз иҗатым белән якынлыкларны да таптым. Алар – авыл баласының уй-хыяллары, якыннарыңа булган җылы мөнәсәбәт, туган җиргә, туган илгә, халкыңа мәхәббәт хисләре... Халыкчанлык, укучы күңеленә, халык мәнфәгатьләренә якынлык, уй-хисләреңне укучының җанына үткәрерлек итеп әйтеп бирә белү осталыгы...

Мукагалинең шигъри теле урыны-урыны белән безнең татар сөйләменә дә якынаеп китә, татарча яңгыраган кебек хисләр калдыра. Чыннан да, телләребезнең уртак яклары бик күп икән шул...

Гомумән, минем тәрҗемәләрдә тәкъдим ителгән ошбу шигырьләргә укучыларыбыз һич кенә дә битараф калмаслардыр...

**Роберт МИҢНУЛЛИН,**
*Татарстанның халык шагыйре*

Мукагали
Макатаев



# ШИФА ЭЗЛИМ ҖАНЫМА, ТЕЛГӘ – ТЕРӘК

## Ни килеп, ни китмәгән бу галәмнән...

Ни килеп, ни китмәгән бу галәмнән,
Сулар аккан диңгезләргә әүвәлдән...
Күпме токым чапкан бәхет артыннан,
Бәхет кенә һәрчак качкан адәмнән...
Ни килеп, ни китмәгән бу галәмнән.

Вакытларны туктатыр чамаң бармы?
Дәверләрне туктатыр, заманнарны?..
Бар да үтә, әмма барлык кеше дә
Матур итеп гомерен тәмамлармы?..

Бар да үтә...
Аркаланып таңга,
Яңа бер көн туа акрын гына.
Минем җаным аша ахырына:
Таң нурына, кеше язмышына.

Минем җаным аша үткәннәргә,
Яңа гына гомер иткәннәргә.
Оран язып күккә элим микән
Сезгә – бүген гомер иткәннәргә?

Бар да үтә...
Төннәр елый, көннәр көлә,
Яңара да дөнья, искерә дә.
Урыныңны бушат, диеп, яшьләр килә...
Тик китәсе килми һич кенә дә.

## Ниләр күрдем?..

Ниләр күрмәдем, димимен,
Ниләр күрдем?
Миңа, гомер,
Күрсен, диеп, ниләр бирдең?
Бер әйбер дә күргәнем юк,
Белми, күрми,
Туры барырга тырышам,
Берни күрми...

Күргәнем юк куаныч та, кайгыны да,
Ризалык юк куанырга, кайгырырга.
Юкчыллык та оят миңа, байлыгың да.
Юл читендә туктар урын аерым гына...

Мәхәббәтне белмимен мин, сөюне дә,
Үткәргәнмен гомеремне сөйми генә.
Йөрәгемә гашыйк булган кайберәүләр
Сөйде микән янмый гына, көйми генә?

Кемнәрнеңдер яхшылыгын, мыскылын да
Күргәнем юк, белмимен мин барлыгын да.
Куанычым да билгесез, зар-моңым да,
Тәкъдиремне дә белмимен, таң нурын да.

Ниләр күрмәдем, димимен,
Ниләр күрдем?
Күрермен, диеп, барын да килер көннең,
Юл читендә тукталып, мин ут тергездем,
Пар өркәчле дөямне мин тезләндердем.

## Ни кыен бар?..

Мең үзгәргән куанычтан, кайгыдан,
Ни кыен бар, кеше җанын аңлаудан?
Мин киләмен үз җанымны аңламый,
Берчә салкын, берчә ялкын-ут гәүдәм.

Ни арзан бар, уйнау белән көлүдән,
Ни кыйбат бар, кеше серен белүдән?

Мин тырышам үз серемне белергә,
Искә алам бозылган елларымны:

Кичә бозып үкендем мин бүгеннән.
Кешеләрнең җаны белән йөрәген
Аңлар идем, белер идем теләген.
Аңласам, шат булыр идем, тик менә
Кояш төнне яктыртмады төнәген.

Иртәгә ни булыр, бүген әле мин
Үз-үземә яхшы ук күренәмен.
Кәлтә шикелле үзгәртә йөзләрен,
Төшенмимен кылыгына бәндәнең.

Бергә-бергә бер елаган, бер көлгән
Якыныңның ят булырын кем белгән.
Кешеләрне аңлый алмый йөрдем мин,
Аны аңлау мөмкин түгел, белдем мин...

## Китәрменме?..

Бер алайга, бер болайга йөгерәм,
Бер карарга килә алмый тилмерәм.
Тау һавасы кебегрәк, көн эчендә
Бер янарга, бер сүнәргә өлгерәм.

Салкын өтә, эссе чиллә яндыра,
Берсе – шатлык, берсе моңын калдыра.
Кем туасын белми йөргән хатындай,
Ни булырын белми йөрим, аңгыра.

Үзеннән-үзе үзәгем янганда,
Кайчакта үз-үземнән чирканганда,
Сары чире беләнме авырганда,
Өмет көтәм төненнән, таңыннан да...

Ни көтәм,
Ни кирәк соң миңа һаман?
Аяк-кулым, күзләрем, башым аман.
Түгел идемме хуҗаның баласы,
Үз көче белән тамак асыраган.

Гомер дигән мәйданнан үтәрменме?
Батыр йә куркак булып бетәрменме?
Гомер белән үлемнең уртасында
Бер карарга килалмый китәрменме?

* * *

Җырлар язам,
Тик алар кемгә кирәк?!
Шифа эзлим җаныма, телгә – терәк.
Мин Мәҗнүнгә эвереләм әкренләп,
Сау җаннардан читләшеп йөри йөрәк.

Җырлар язам,
Белмимен ни бирәсен,
Яшисен дә белмимен мин, үләсен...
Көенечен, сөенечен халкымның
Мин үземчә җырлый алмам, күрәсең.

Кемгә дару серләре кара башның?
Үзем белән мин күбрәк якалаштым,
Үз дөньямда хыялландым, уйландым,
Сәфәр чыктым, гәпләштем, аралаштым.

Сәфәрләрдә, әйе шул, аралаштым,
Инде артка әйләнеп карамасмын...
Үләрмен дип курыкмыйм, җырлар язам,
Каршысында торсам да дар-агачның.




Бөек рәссам Бакый Урманче остаханәсендә. Сулдан уңга: калмык халык шагыйре Давыт Көгелтинов, Лирон Хәмидуллин, Бакый Урманче. 1981 ел.



Бер төркем татар язучылары 1нче Май бәйрәме демонстрациясенә җыелганнар. Сулдан уңга: Илдар Юзеев, Марсель Галиев, Ринат Мөхәммәдиев (кызы белән), Мансур Вәлиев, Солтан Шәмси, Туфан Миңнуллин, Рөстәм Мингалим. Үткән гасырның 80нче еллары.



*Сәгыйть Сүнчәләй (1889-1937) –
шагыйрь, дәүләт һәм җәмәгать
эшлеклесе. Татар язучылары
арасында С.Сүнчәләй беренче сәяси
корбаннардан санала.*




*Татар әдәбияты классигы Галиәсгар Камалның
Татарстан халык рәссамы Ефим Симбирин иҗат
иткән рәсеме. 1970нче еллар.*




*«Казан утлары»ның актив авторлары – мәшһүр әдипләре редакциядә кунакта.
Утырганнар (уңнан сулга): шагыйрь, прозаик, публицист Айдар Хәлим,
Татарстанның халык шагыйре, «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры киңәшчесе
Равил Фәйзуллин, Татарстанның халык язучысы Гәрәй Рәхим;
басканнар: «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, ТРның Г.Тукай исемендәге
Дәүләт премиясе лауреаты Илфак Ибраһимов (шагыйрь Мөхәммәт Мирза),
Татарстанның халык язучысы Марсель Галиев, редакциянең бүлек мөхәррире,
шагыйрь, публицист Рәфикъ Юныс .*

# ФИДАКАРЬЛЕК

Тарихы 110 елдан арткан татар театр сәнгате – бүгенге көндә киң танылу алган, дөньякүләм масштаблы мәйданга чыккан абруйлы мәдәни институт. Аны хәзерге халәтенә җиткерүгә зур өлеш керткән данлыклы, бөек сәнгатькярләребез арасында драматург, артист, режиссёр, театраль педагог, ТАССРның атказанган артисты (1926) Кәрим Гали улы Тинчурин үзенең күпкырлы иҗаты белән аеруча мәртәбәле урыннарның берсен тота. Милли театр оешуның беренче елларыннан ук иҗатка килгән һәм аны аякка бастыру, ныгыту, үстерү өчен бөтен көчен, сәламәтлеген, хәтта гомерен биргән бу фидакяр шәхес шуңа күрә дә тирән хөрмәт, ихтирам белән искә алынуга лаек. Сентябрь аенда аның тууына 130 ел тула.

К.Тинчурин үзенең беренче сәхнә әсәрен – «Моназәрә» («Бәхәс») исемле комедиясен – 1906 елда, мәдрәсәдә укыган чорда яза. 1910 елдан башлап ул ел саен диярлек берәр-икешәр пьеса иҗат итә. Аның «Хәләл кәсеп» (1910), «Шомлы адым» (1910-1912), «Беренче чәчәкләр» (1913), «Назлы кияү» (1915), «Ач гашыйк» (1915), «Җилкуарлар» (1916), «Йосыф-Зөләйха» кебек сатирик комедияләре инкыйлаб алды чоры татар драматургиясенең үзенчәлекле һәм кыйммәтле бер сәхифәсен тәшкил итә.

Егерменче елларда К.Тинчуринның иҗат эшчәнлегендә төп урынны музыкаль драмалар били, һәм бу жанрда әдип аеруча зур уңышларга ирешә. Аның «Казан сөлгесе» (1923), «Сүнгән йолдызлар» (1923), «Зәңгәр шәл» (1926), «Ил» (1927), «Кандыр буе» (1930) исемле комедияләре, мелодрамалары шул чор татар театрының төп репертуарына әверелә, аннан соң да кабат-кабат уйналып, ничәмә-ничә буын тамашачыларның тирән мәхәббәтен казана. Салих Сәйдәшевнең гүзәл музыкаль номерлары белән баетылган бу әсәрләр татар сәнгатендә М.Фәйзинең «Галиябану»ыннан башланган музыкаль драма жанры традициясен үстерүдә зур роль уйный. Утызынчы елларда К.Тинчурин чор чынбарлыгын чагылдырган «Корыч орчык» (1930), «Ударниклар бәйрәме» (1933), «Алар өчәү иде» (1935) кебек пьесаларын иҗат итә. К.Тинчурин, талантлы драматург булу белән бергә, талантлы хикәяче дә. Аның юмористик һәм сатирик характердагы кыска хикәяләре әле революциягә кадәр дә, соңрак та газета-журналларда еш басыла.

К.Тинчурин үзенең күпчелек әсәрләрен сәхнәгә үзе куя һәм спектакльдә башкаручы артист буларак та катнаша. Дөрестән дә ул күпьяклы зур талант иясе була: язучы да, режиссёр да, театр җитәкчесе дә, сәнгать белгече дә, артист та…

Артист буларак сәхнәдә К.Тинчурин тудырган образлар татар театр тарихының якты сәхифәләрен тәшкил итә. Октябрьга кадәр, аеруча 1913-1917 елларда иҗат иткән образлары арасында Фердинанд, Вурм (Ф.Шиллер, «Мәкер һәм мәхәббәт»), Гата, Таһир («Кызганыч бала», Г.Камал тәрҗемәсе), Закир, Җамали (Г.Камал, «Бәхетсез егет», «Банкрот»), Газиз (Ф.Әмирхан, «Яшьләр»), Сөләйман (Ф.Әмирхан, «Тигезсезләр»), Таһир (Ф.Бурнаш, «Таһир-Зөһрә»), Гали (Г.Коләхмәтов, «Яшь гомер»), Хәмит (К.Тинчурин, «Беренче чәчәкләр»), Вахит (К.Тинчурин, «Соңгы сәлам»), Незнамов (А.Островский, «Гаепсездән гаеплеләр»), Хлестаков (Н.Гоголь, «Ревизор»), Пётр (М.Горький, «Мещаннар») һ.б. зур осталык белән башкарыла.

Революциядән соң, татар совет театры үзенең беренче адымнарын атлаганда һәм шулай ук 20нче елларда да К.Тинчурин артист буларак бик кирәкле эшен дәвам итә. Шулар арасында Сәфәргали («Йосыф белән Зөләйха»), Искәндәр («Американ»), Надир («Сүнгән йолдызлар»), Булат («Зәңгәр шәл»), Батырхан («Җилкәнсезләр») һ.б. күрсәтергә була.

К.Тинчурин – татар милли театр режиссурасына нигез салучыларның берсе. Бу өлкәдә ул революциягә кадәр үк Г.Кариев җитәкчелегендә эшли башлый. 1916 елның июленнән рәсми рәвештә «Сәйяр»нең режиссёры булып билгеләнә. Революциядән соң 1918 елның көзендә, акларны Казаннан куып чыгаргач, К.Тинчурин «Беренче татар совет драма труппасын», ә 1922 елда Татарстан хөкүмәте тапшыруы буенча Татар дәүләт театрын төзи һәм күп еллар буе аның сәнгать эшләренә җитәкчелек итә. Бу театрда ул бик күп әсәрләрне сәхнәгә куя, барлык әсәрләренең режиссёры да үзе була.

Татар театрына нигез салучы, Габдулла Кариев мәктәбенең реалистик традицияләре дәвамчысы, аларны яңа шартларда үстерүче, баетучы бу олуг талантның эшчәнлеген берничә өлкәгә бүлеп карарга була: практик режиссура, ягъни режиссёр-сәхнәгә куючы, режиссёр-оештыручы-җәмәгать эшлеклесе, режиссёр-педагог, режиссёр-теоретик.

Октябрь революциясенә кадәрге чорда К.Тинчурин – иң беренче чиратта, «Сәйяр» труппасы артисты, берничә әсәр язган драматург, аннан соң гына ул үз пьесаларын сәхнәгә куючы режиссёр. Режиссура сәнгатенә җаваплы рольләр башкарырлык дәрәҗәдә өлгереп җиткән актёр буларак килеп керә ул. 1915 елның көзендә Г.Кариев «Сәйяр»не үз антрепризасына күчерергә уйлый һәм шул вакытта труппаның режиссёры В.Мортазин-Иманский Оренбургка күчеп киткәнлектән, бу урынны К.Тинчуринга тәкъдим итә. Шулай итеп, булачак режиссёрның бербөтен сәхнә әсәре тудыру сәнгате өлкәсендә тәүге адымнары Кариев кул астында ясала. Театрның шул сезоны эшчәнлегенә йомгак ясаган тәнкыйтьче Г.Кәрам «Аң» журналында басылган күләмле мәкаләсендә труппаның җитәкчеләре турында «Мөдир мәсъүл Кариев, режиссёр Тинчурин» дигән белешмә биреп китә.

Алдагы ел К.Тинчуринга драматург буларак та, режиссёр буларак та танылу алып килә. 1916-1917 ел сезонында ул бер-бер артлы үзе язган «Шомлы адым», «Соңгы сәлам» драмаларын сәхнәләштерә. Театр дөньясындагы һәр яңалыкка үтә сизгер Г.Кәрам бу турыда: «Тинчурин бу ел «Шомлы адым», «Соңгы сәлам» исемле ике пьеса мәйданга куеп, милли сәхнәмезнең репертуарын киңәйтте вә үз тәэлифе булган «Соңгы сәлам» исемле әсәрен куеп җитди муафәкыять казанды», – дип яза.

Ил тарихындагы борылыш вакыйгалары сәнгать әһелләре алдына заманча яңгырашлы, чор проблемаларына аваздаш әсәрләр тудыру бурычы куя. Кәрим Тинчурин сәхнәләштергән «Ике фикер», «Яшь гомер» (Г.Коләхмәтов), «Беренче таң» (Г.Ниязбаев), «Революция» (В.Исхаков), «Беренче адым» (Ш.Усманов) кебек әсәрләр иң элек вакыт таләпләренә җавап бирүе, күпләрне дулкынландырган мәсьәләләр күтәрүе, көн геройларын сәхнәгә чыгаруы белән кыйммәтле. Бу пьесаларның күбесе Г.Кариев режиссура мәктәбенең реалистик традицияләре нигезендә куелган. Ләкин шушы ук чорда К.Тинчуринның режиссёрлык хезмәтендә традицион реализм кысаларының киңәюе, аның яңа стиль, жанр төсмерләренә баюы турында ассызыклап әйтергә кирәк. Бу яктан караганда, Г.Коләхмәтовның «Ике фикер», Ш.Усмановның «Беренче адым» әсәрләре буенча куелган спектакльләр аеруча игътибарга лаек. «Ике фикер» әле моңарчы татар театрында күрелмәгән үзенчәлекле стиле белән аерылып тора. Аның тукымасында көнкүреш конкретлылыгы – шартлылык, психологик тирәнлек – аерым образларның символ, аллегория алымнары ярдәмендә чишелеше белән кушыла. Шул ук вакытта бу сәхнә әсәрләрендә туып килгән кино сәнгатенең монтаж, вакыйгаларны катлау итеп, бер-берсе өстенә салу кебек алымнары да кулланыла. Ә «Беренче адым»да тормыш дөреслегенә агитацион театрга хас сурәтләү чаралары өстәлә. Биредә кичерешләргә, сыйнфый күрәлмаучылыктан башка хисләргә урын аз бирелә. Иң мөһиме – революцион тизлек, вакыйгаларның динамик агышы, төрле сыйныф вәкилләре арасындагы мөнәсәбәтләрнең соң дәрәҗәдә кискенләштерелүе.

Егерменче елларда К.Тинчурин – татар классик драматургиясенең алтын фондына кергән берничә пьеса биргән әдип, милли сәхнәбезнең үсеш юнәлешен билгеләгән режиссёр һәм театрның узганы, бүгенгесе, киләчәге турында төпле фикер йөртүче теоретик.

1922 елның җәендә әле яңарак кына Ташкенттан кайткан К.Тинчурин ачылу алдында торган һәм «Кызыл Октябрь» исемен йөртәчәк Татар дәүләт драма театрының баш режиссёры итеп билгеләнә. Режиссёр тиз арада 35 кешелек актёрлар коллективы туплый һәм сигез әсәрдән торган репертуар булдыра. Алар арасында Н.В.Гогольнең «Ревизор», Г.Дрегелиның «Яхшы тегелгән фрак», Ф.Бурнашның «Яшь йөрәкләр», «Җирсезләр», К.Тинчуринның «Беренче чәчәкләр», Ш.Усмановның «Бай кызы» һ.б. әсәрләр бар. Г.Камал исемендәге данлыклы Татар дәүләт академия театрының нигезе нәкъ менә шушы вакытта салына.

Сезон тәмамлангач, республика матбугатында татар театрының тоткан юлы, юнәлеше, спектакльләрнең формасы турында фикер алышу башлана. Беренче мәкаләне К.Тинчурин яза. «Татар театры нинди юл белән барырга тиеш?» дип атала ул. Шушы мәкаләсендә дә, соңрак басылган «Хәзерге театрның рәвешен – формасын үзгәртергә кирәк» дигән язмасында

да, вакытпы матбугаттагы күпсанлы теоретик чыгышларында да режиссёр эзлекле реализм позициясендә тора. Шул ук вакытта, аның аңлавынча, реализм катып калган догма түгел. Вакыт узган саен, ул яңарырга, баерга, күпмедер рәвештә үзгәрә барырга тиеш. Шуннан чыгып, спектакльләрнең форма, стиль, жанрлары да күп төрле булырга мөмкин.

«Вакытлы яңа татар театры караучының вакытын мөмкин кадәр аз алып, мөндәриҗәсе чын, күңелле һәм төрле-төрле булырга тиеш, – дип яза К.Тинчурин. – Декорация техникасы, персональ һәм уйнаучы артистлар аз булу белән бергә, сәхнәдә музыка, нәфис сүз, пластика, бию һәм башка төрле трюклар да кертелергә тиеш». Күренгәнчә, бу мәкаләсендә режиссёр милли сәхнә сәнгатен яңа сурәтләү чаралары белән тулыландыру проблемасын да күтәрә.

Егерменче елларда куелган спектакльләр Тинчуринның режиссёрлык өлкәсендәге уйлануларының, эзләнүләренең тормышка ашуы булып саналырга хаклы. Әлеге әсәрләр реализмның ныклы җирлегендә тора. Ләкин шуны да әйтергә кирәк: бу чорда К.Тинчурин реализмы Г.Кариев традицияләреннән шактый үзгә. Чор белән бәйле рәвештә, әсәрләргә яңа эчтәлек салынган. Шушы эчтәлек спектакльләрнең формасында да чагылыш таба. Хәзер инде сәхнә әсәрләрендә тормыш-көнкүреш билгеләре Октябрьгә кадәрге театрдагы шикелле үк куе түгел. Геройларның эчке кичерешләрен, психологиясен гәүдәләндерү дә беркадәр тизләтелгән. Сурәтләү чараларының күптөрлелеге, музыка, җыр, бию, юмор, сатирага бай булуы, вакыйгаларның кызулатылган агышы К.Тинчурин режиссурасының үзенчәлекле театральлеген тудыра. Үзе язган һәм куйган «Казан сөлгесе», «Сүнгән йолдызлар», «Американ», «Зәңгәр шәл», «Ил» кебек спектакльләре белән К.Тинчурин 20нче елларда режиссёрлык эшчәнлегенең иң югары баскычына күтәрелә. Аларда останың сәхнә кануннарын бөтен нечкәлекләренә кадәр аңлавы, драматургияне, артист иҗатын төптән белүе ярылып ята.

1922-1927 елларда К.Тинчурин берничә сезон Кызыл Октябрь исемендәге (1926 елдан академик театрлар исемлегенә кертелгән) коллективның баш режиссёры булып эшли, соңрак ике сезон Әстерхан Татар дәүләт драма театрына җитәкчелек итә. 1929 елда К.Тинчурин яңадан Татар дәүләт академия театрына чакырыла. Театрда әле яңарак кына кертелгән художество җитәкчесе урынында бер ел эшләгәннән соң, режиссёрлар коллегиясе әгъзасы итеп күчерелә. Унъеллык урталарына таба К.Тинчурин практик режиссура белән шөгыльләнүдән туктый.

Егерменче еллар – К.Тинчуринның театраль-педагогик эшчәнлеге чәчәк аткан чор. Самара студиясендә башланган бу хезмәт соңрак озак вакыт Татар театр техникумында дәвам иттерелә. Режиссёр-педагог буларак, Тинчурин – студентларга үтә сакчыл карашлы, эчке тактка ия, таләпчән, эрудицияле остаз. Шәкертләрендә ул татар халкының милли әдәбиятына, сәнгатенә, рухи һәм матди культурасына мәхәббәт тәрбияләргә тырыша, сәхнәдән яңгыраган телнең сафлыгы өчен көрәшә. Аның шушы ук сыйфатлары ул тәрбияләгән Р.Ишморат, Х.Сәлимҗанов, Г.Кайбицкая, Г.Нигъмәтуллина, Г.Булатова, К.Тумашева һ.б. кебек шәкертләренең эшендә чагылыш таба.

30нчы елларда К.Тинчурин практик режиссура белән аз шөгыльләнә. Чөнки, Мәскәү, Ленинградтагы зур-зур югары уку йортларын уңышлы тәмамлап, татар театр сәнгатендә Р.Ишморат, С.Булатов, Г.Ильясов, Г.Исмәгыйлов, соңрак Ш.Сарымсаков, К.Тумашева кебек яшь режиссёрлар килеп кушыла. К.Тинчурин исә көчен күбрәк драма әсәрләре язуга юнәлтә. Әдәбият-сәнгать өлкәсендә 25 ел тулу уңае белән үткәреләчәк юбилей көннәре алдыннан Кәрим Тинчурин, Язучылар союзы үтенүе буенча, барлык сәхнә әсәрләрен эченә алган исемлекне үз кулы белән төзеп бирә. Бу исемлек тантанага чакыру билетында басылып та чыга. Моннан күренгәнчә, К.Тинчурин 26 сәхнә әсәре иҗат иткән, шуның өчесе башка язучылар («Корыч орчык», Ф.Сәйфи-Казанлы, «Тургай», Р.Ишморат һәм «Булат бабай гаиләсе», К.Нәҗми) катнашында язылган. Шуның өстенә ул башка телләрдән дүрт пьеса үзгәртеп татарчалаштырган («Хан кызы Турандот», «Чит илләрдә», «Европа коралсызлана», «Зәңгәр палас» – соңгы варианты «Каракүз» исеме белән йөртелә). Исемлектә күрсәтелгән беренче әсәрләрдән «Моназара» белән «Хәләл кәсеп»нең әлегечә табылганы юк.

Соңгы елларда язылган пьесалар арасында драматург эволюциясе өчен бигрәк тә «Кандыр буе» музыкаль драмасы мөһим. Моңа кадәр «милли декоратизм» кысаларында гына иҗат итүдә гаепләнеп килгән К.Тинчурин, ниһаять, таләп ителгән заман проблематикасын

«Кандыр буе» әсәрендә сыйнфый рухта чагылдыра ала. Бүген бу борылышны төрлечә бәяләргә мөмкин. Әмма бер нәрсәне истә тотарга кирәк: бер иҗади шәхес тә үзе яшәгән җәмгыять шартларыннан азат түгел. Бу аксиома 30нчы елларда бигрәк тә актуаль.

К.Тинчурин өстендәге болытлар елдан-ел куера бара. Моңа кадәр үк яңгырап килгән «вак буржуаз язучысы», «милли демократизм» турындагы гаепләнүләр утызынчы еллар уртасына шактый куера, тискәре бер гәүдәләнеш ала. 1935 елда аны штат кыскарту сылтавы белән театрдан чыгарып ташлыйлар. Приказдагы формулировка игътибарга лаек: «Театрның иҗади йөзенә зарар китерми торган кыскартулар...» Әйтерсең лә 25 ел буена армый-талмый милли театрның төрле өлкәләрендә бердәй уңыш белән эшләп килгән фидакарь сәнгать эшлеклесе инде берни дә тормый! Театрда аның булу-булмавының бернинди дә әһәмияте юк!

Беренче һөҗүмне К.Тинчурин лаеклы кире кага. Алай гына да түгел, үзе дә һөҗүмгә әзерләнә 1936 елда республика күләмендә уздырылган иҗади эшчәнлегенә 25 ел тулу юбилее, илнең төрле төбәкләреннән килгән котлау хатлары, телеграммалар, Татарстан хөкүмәте бүләк иткән язу машинкасы, Казан хәрби гарнизоны бүләк иткән ау мылтыгы һ.б. – үз-үзенә нык ышанган, дәрәҗәсен, бәясен, сәнгатьтәге тоткан урынын белгән олы шәхеснең астыртын дошманнарына җавап сүзе булып тора.

Әмма үлем машинасы эш режимына куелган яңадан-яңа корбаннар сорый. Татар милләтенең каймагын тәшкил иткән, берсеннән-берсе талантлы, акыллы, гыйлемле шәхесләр әлеге машинаның туймас авызына кереп югала баралар. Фәтхи Бурнаш, Җамал Вәлиди, Мәхмүт Галәү, Галимҗан Ибраһимов, Галимҗан Нигъмәти, Мохтар Мутин, Шамил Усманов... һ.б.

Кәрим Тинчуринны алырга илле яшьлек юбилей көннәрендә, төгәлрәк әйтсәк, 1937 елның 17 сентябрендә киләләр. Асты-өскә китерелгән фатир. Арттан елап төрмә капкасы төбенә кадәр килгән тол калачак хатын. Гатин фамилияле тикшерүченең төн уртасында уятып сорау алулары, кыйнаулары. Җиде пункттан торган гаепләү акты.

7 гаепләүнең 4се Гаяз Исхакый исеме белән бәйләнгән: «Ил» газетасы редакциясендә эшләгән, коммунистлар партиясенә каршы көрәш җәелдергән, Казаннан ак чехларны куганда, Г.Исхакый, Җ.Вәлиди, Ф.Сәйфи-Казанлы белән Тәтешкә, Самарага чигенгән, буржуаз милләтче, ак эмигрант Г.Исхакый белән хат алышкан, «Милли юл» журналын алып торган, Япон шпионы Х.Исхаков белән бәйләнештә булган, аннан Г.Исхакый пьесаларын алган һ.б.

Әмма ел да ике айга сузылган сорау алулар нәтиҗәсез кала. К.Тинчурин үзенә тагылган нахак гаепләрне кире кага, үз-үзенә хыянәт итми.

Өч кешелек махсус комиссиянең 1938 елның 14 ноябрендә булган карары катгый: атарга! Карар шул ук төнне, таң алдыннан үтәлә. Кәрим Тинчуринның үлгән вакыты – 15 ноябрь, иртәнге ике туларга 10 минут...

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: К.Тинчурин иҗатының иң югары баскычында торган чорда тормыштан китәргә мәҗбүр ителә. Ни кызганыч, үзе белән зур иҗат планнарын, язылачак пьесалар, тудырасы образларын алып китә. Тик үкенүдән файда юк. Тарихи хаталар төзәтелми.

К.Тинчурин иҗаты, зур, кыйммәтле мирас сыйфатында, татар драматургиясенең алтын фондына керә, милли сәнгать тарихы сәхифәләрендә лаеклы урын ала. Ул – инкыйлабтан соң ике дистә ел буенча милли театр сәнгатенең алгы сафында атлаучы, аның юнәлешен билгеләүче, аны яңа стиль, жанр төсмерләре, сурәтләү чаралары белән баетучы олы шәхес.

К.Тинчурин – татар театрында Октябрьгә кадәр үк формалашкан Г.Кариев мәктәбенең реалистик традицияләрен бүгенге көн казанышлары белән тоташтырган сирәк иҗатчы да. Аның пьесалары милли театрларыбызның репертуарында әһәмиятле урын тота. Бүгенге көндә сәхнәләребездә Кәрим Тинчурин тәрбияләгән артистларның шәкертләре эшли. Театр әһелләренең һәр яңа буыны аның драматургиясендә чыныгу ала. Димәк, К.Тинчурин традицияләре исән, яши, үсә, ныгый. Халкыбыз күңелендә ул кабызган утлар, хәтәр җилләрдә дә сүнмичә, якты нурлар белән әле бүген дә балкып тора.

**Мөхәммәтгали АРСЛАНОВ,**
*сәнгать фәннәре докторы*

# РИФӘ РАХМАН ПРОЗАСЫНЫҢ ИҖАДИ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Талант – кешегә Ходай тарафыннан иңдерелгән бөек бүләк ул. Кемдер – оста аш пешерүче, пешергән ризыкларыннан телеңне йотардай буласың, кемгәдер техникага сәләтне кызганмаган, берәүләр – бер дигән ташчы, мичче... Җәмгыятьтә бөтенләй үк талантсыз кеше, мөгаен, юктыр да. Шул ук вакытта бигрәк тә иҗатта – гуманитар яисә төгәл фәннәрдә, сәнгатьтә – талант һәркемдә бер үк дәрәҗәдә түгел. Ходай Рифә Рахманга талантны кызганмаган, әмма Аллаһыдан бирелгән бүләк өчен маңгай тирен түгеп хезмәт итәргә дә кирәктер. Тырыш, эрудицияле Рифә ханым – әдәбиятта үзенең урынын, үз сүзен әйтә алган, шәхси стилен барлыкка китергән әдәбиятчы галимә, әдибә, журналист һәм педагогның берничә еллык иҗаты хакында нинди дә булса фикер белдерергә вакыт җиткәндер, мөгаен.

Рифә ханымның университет тәмамлаганнан соңгы гомеренең күп өлеше иҗат һәм гыйльми эшчәнлектән тора дип әйтерлек. Үзгәртеп кору җилләре, кемнең кем булуына карамастан, башыннан сыйпамаган туксанынчы елларда Рифә дә, Казан дәүләт университетында педагогик-гыйльми эшчәнлек янәшәсендә, журналистикага да хезмәт итәргә мәҗбүр иде. Ул яңа гына оешкан «Мәгърифәт» газетасында көн кадагына суккан кискен һәм актуаль темаларга мәкаләләр язды. Газетада эшләү дәверендә фәнни эшчәнлеккә вакыты азрак калса да, бу елларда иҗади потенциалы тагын да ныграк үсте, киңәйде – публицистик мәкаләләр белән беррәттән, әдәби иҗаты да югары дәрәҗәгә күтәрелде. Шигърият аша әдәбиятка килгән Рифә нәкъ менә шушы чордан чәчмә төрдә активлашты, бигрәк тә хикәя жанрын үз итте. Әдибәнең бу елларда иҗат ителгән прозасы тематик актуальлек, заман проблемаларын чагылдыру, юмористик һәм сатирик формаларга да урын бирү белән истә кала. Рифә Рахманның үзәк матбугатта дөнья күргән тәүге әсәрләре дә каләм сынавының уңышлы икәнлеген раслады. «Судан тапкан йөземнәр», «Сары шарф», «Бер микъдар былбыл» әсәрләре, әдәби конкурсларда җиңеп, авторга Ф.Хөсни, Г.Исхакый исемендәге әдәби премияләргә юл ярды. Әлеге әсәрләр Рифә Рахманның тәүге проза китабы – «Айлы күлдәвекләр»гә (2006) дә кертелгән. Әлеге җыентык бик бәрәкәтле туфрактан булып чыкты, соңрак аның янәшәсенә «Онытырмын, димә» (Казан, 2010), «Йолдызлар төстән язганда» (Казан, 2013) һәм «Таулар һаман ерак» (Казан, 2016) җыентыклары да өстәлде. Аларында да ярышларда җиңгән әсәрләр юк түгел. Араларында иң уңышлысы – берничә йөз хикәя эчендә лаеклы рәвештә беренче урынны яулаган «Сөннәтче әби»дер, мөгаен.

Рифә ханымның беренче проза җыентыгы – «Айлы күлдәвекләр» хакында әдәбият галиме Илһам Гомәревнең фикерләре кызыклы: «... күбесенчә мәхәббәт тарихларын яктырткан «Айлы күлдәвекләр» җыентыгы матур һәм якты мөнәсәбәтләргә омтылган яшьләре, сайлау-сайлануда абынулар, күңел төпләрендә яшәгән тирән үкенечләр һәм иң кадерле кешеләрне югалту сагышлары белән истә калган иде. Тупланмага кергән хикәяләрдә чынлап ярата белгән, эчке дөньясы бай кызга ихтыярсыздан бөтен тирә-як ир-егетнең карашы текәлгәндер кебек. Алар шигъри күңелле, бер үк вакытта уйчан да, шаян да гүзәлкәйгә тиңнәрне тапмыйлар, укучыга сөйләгән тарихлар тәмамлангач, калган гомерләрендә шул образ тудырган идеалга омтылып яшиләрдер шикелле».

Гомумән, Рифә ханым иҗатында тема-проблемалар, форма төрлелеге күзәтелә. Әдәби стиле үзенчә булуга һәм аерым бер алым-чараларга ияләккә карамастан, ул хәтта үзен дә кабатламаска тырыша. Бигрәк тә әсәрләрнең көтелмәгән рәвештә тудырылган башламы, әсәрне үтә бөтен итә торган бетемнәр, композицион төзелеш мөмкинлекләрен киң файдалану Рифә ханымның язу манерасын үз чоры әдип һәм әдибәләренекеннән, киң таралыш тапкан иҗади алымнар белән язучыларныкыннан кискен аерып куя, шунлыктан аның иҗаты да бөтенләй башка, тәэсирле, истә кала торган һәм укучыны уйга салучан.

Рифә Рахман прозасын уку массакүләм прозага бөтенләй башка караш ташлата. Әдибә кулланган тел-сурәтләү чаралары, көтелмәгән драматик вә интрига алымнары, аларның киң кулланылышы әсәрләрнең эчтәлеген баета, укучының күңелен үзенә тарта һәм игътибарын сюжетка теркәп куя, йотылып укырга мәҗбүр итә.

Р.Рахман иҗатында күпчелек әсәрләр татар авылының үткән тарихын, аның кешеләрен сурәтләүгә багышланган. Тарих – киң мәгънәле төшенчә. Күпләр, гадәттә, тарих дигәндә, борынгылык, җәмгыятьнең үсеше һәм бүгенге буынны тәрбияләгән дөньяны вә халыкларны яулап алу сугышлары булган чорларны күз алдына китерә, югыйсә тарихи пластта инде бүгенге вакыйга иртәгә тарихка әверелә. Узган гасыр азагыннан хәтердә нык кына уелып калган һәр иҗтимагый күренеш, җәмгыятьтә барган кискен борылышларга да инде тарих мөһере сугарга кирәктер дип беләм. Ә XX гасыр андый сәяси-иҗтимагый борылышларга, дәһшәтле вакыйгаларга хәтта ки кирәгеннән артык бай булды, һәм бу төр барыш Р.Рахман иҗатында да киң чагылыш тапты.

Әдибәнең повесть һәм хикәяләрендә тарихи тема зур тарихның бер өлешен – кечкенә авыл вә аның кешеләре язмышын тәшкил итә. Нигездә, бу тема 1917 елгы түнтәрелешкә кадәрге, 20-40нчы елларның кан-яшь түктергән сәяси һәм икътисади вакыйгалары, дәһшәтле вә гарасатлы сугыш еллары авылы, аннан соңгы авыл кешесенең канына тоз салган социаль үзгәрешләр, «Хрущёв җепшеклеге», тарихка «торгынлык чоры» дип кереп калган дәвердә кешеләрнең яшәү рәвешләре, XX гасырның 80нче еллар уртасында башланган «үзгәртеп кору» тәэсирендә совет идеологиясе корган икътисади нигезенең таркалуы нәтиҗәсендә, авылның яшәешен җитмеш-сиксән ел дәвамында саклап килгән системаның җимерелүе, 90нчы еллардан Россия сәясәтчеләренең милли сәясәтне җимерергә омтылган «Чечен сугышы» тасвирлануы («Таныды» хикәясе), иҗтимагый тормышта барган кискен үзгәрешләр белән янәшәдә, кешеләрнең психологиясе үзгәрү, милли һәм дини әхлакый тәрбия принципларының акрынлап юкка чыга баруы сурәтләнүе күзәтелә. Бүген тарих итеп каралырга тиешле әлеге темаларны чордаш әдибәләре арасында барлык нечкәлекләрен аңлап вә белеп яза алган шәхес ул Р.Рахман. Әдибә, теге яки бу вакыйга-күренешләргә үз мөнәсәбәтен белдереп, укучының тарихи вакыйгаларга карашын киңәйтә, конкрет персонажлар, аларның гыйбрәтле язмышлары аша нәтиҗә чыгарырга өнди кебек. Шуны да искәртим: Рифәнең хикәяләре, кыйсса-бәяннары динамик хәрәкәткә, тормыш вакыйгаларын бергә туплаган тематик төрлелеккә, әдәбият өчен өр-яңа сюжетлар аша проблемаларның отышлы куелышына, милләткә файдалы чишелешкә ия. Ул – типиклаштыру остасы. Образлары уңаймы, тискәреме – үзенчәлек холык сыйфатларына ия булу янәшәсендә, типиклык белән дә истә кала. Әдибәнең язмыш кочагына ташланган, тормыш сынаулары каршында сынмаган-сыгылмаган геройлары, ил тарихында барган вакыйгалар эчендә кайнап, заман, дәвер аның эчке һәм тышкы проблемалары белән яши. 1917 елгы Октябрь түнтәрелешенә кадәрге татар авылы, аның яшәеше, түнтәрелештән соң совет идеологиясе басымы астында колхозлашу, кулакларны сөрү, сугыш һәм сугыштан соңгы авылларның авыр хәлен чагылдырган «Алмашыну» (2010), «Батар күлең булмагач» (2012), «Дошман» (2011), «Чаршау кызы Дәмига», «Мөнәвәрә, балалар, бәрәңге» (2013), «Разведка» (2013), «Тоз» (2015) кебек хикәяләре, «Йолдызлар төстән язганда» (2012), «Таулар һаман ерак...» (2013), «Күтәрсең бит?!» (2014) повестьлары һәм «Сөннәтче әби» (2006) кыйссасы шул чорның тормышын, аның кешеләренең бөтен нечкәлеген, психологик кичерешләрен югары кимәлдә ачып бирә белүе, тарихи вакыйгаларны мөмкин кадәр төгәл тасвирлый алуы белән игътибарны җәлеп итә.

Р.Рахманның XX гасырның сәяси һәи иҗтимагый темасын яктырткан егермедән артык хикәя һәм повесть язуы мәгълүм. Әдибә әсәрләрендә тарихи тематика, язмышлар, кечкенә кеше образы проблемасы турында сүз алып барганда, иң беренче чиратта күләмле әсәрләреннән «Сөннәтче әби» кыйссасын, «Йолдызлар төстән язганда», «Таулар һаман ерак...», «Күтәрсең бит?!», «Атка печән кем сала яки Моңсу Күз сагышы» повестьларын искә алып үтү кирәктер. Бу әсәрләр XX гасырның мөһим вакыйгаларын эченә алу белән янәшәдә, алардагы кеше язмышларының тасвирланышын галим И.Гомәрев: «Р.Рахман әсәрләрендә кешене гомере буенча югалту арты югалту көтә, сынаулар сагалый, дип искәртә. Әлеге дә баягы югалтулар яшәешнең даими агышта икәнлеген сөйлиләр,

рухыбызга якын кыйммәтләрнең кадерен белергә чакыралар», – дип язды. Язмыш кочагына ташланган Кечкенә кеше образының типик әдәби персонажга әверелүенә игътибар итмичә булмый. Әдибәнең тарихи теманы яктырткан кайсы гына әсәрен алсаң да, аларда сурәтләнгән әдәби персонажлар һәркайсы типик образ буларак каралырга лаек. Р.Рахманның тарихи темаларны эченә алган әсәрләре турында әдәбият галиме Әлфия Мотыйгуллина, «Мәхәббәт шагыйрәсе данын йөрткән Рифә Рахманның иҗтимагый-сәяси проблемаларны тирәнтен ачуы һәм темаларны үтә дә гыйбрәтле язмышлар, башка прозаикларыбыз иҗатында чагылмаган сюжетлар ярдәмендә тасвирлавы язучы буларак осталыгын, талантының киңкырлылыгын күрсәтә», – дип белдерде һәм Р.Рахманның чордаш әдибәләргә караганда өстенлеге дә шул икәнлекне раслады.

Р.Рахманның хикәяләрендә аеруча 20-50нче еллар, сугыш чоры, сугыштан соңгы татар авылы, аның яшәеше, шул дәвернең вакыйгаларында үзенә бер җылылык сиземләнә. Әдәби геройларының җаннарына сеңеп калган дәһшәтле еллар авазы, авылның гади кешеләре язмышы һәр шәхеснең үзенә генә хас интонациясендә ишетелә сыман. «Мөнәвәрә, балалар, бәрәңге» хикәясендә шул заманның ачлыгы, яшәү һәм тамак өчен көрәше – Мөнәвәрә, «Чаршау кызы Дәмига»да – Дәмига, «Батар күлең булмагач»та – Нәвадир байның хатыннары Сара һәм Сафура, «Разведка»да Әсхадуллалар авазында укучыны тетрәндерерлек, гыйбрәт алырлык вакыйгалар тасвирланган. Мондый тормыш сынауларын, аның каршылыкларын җиңеп, сынмаган-сыгылмаган геройларга кем генә сокланмас икән?! Боларны укыганда, инде тарих тузанында югалып калган тарихи вакыйгалары эчендә шул дәвернең җан авазы да ишетелә, һәрбер детале күз алдына килеп баса, хәтер аша уза. Әдибәнең әсәрләрендә төп геройлар – хатын-кызга игътибар бирелсә дә, ул бары хатын-кызларны гәүдәләндереп кенә калмый, күрсәтеп үткән хикәяләре раслаганча, ул бер үк дәрәҗәдә ир-атларның эчке психологик кичерешләрен, характер үзенчәлекләрен аңлап, аларның дөньяга, кешеләргә карашлары аркылы яктыртуга ирешә. Ил һәм авыл тарихы, аның үткәне, бүгенгесе – хатын-кызмы, ир-атмы – һәр ике җенеснең уртак хәсрәте, уртак шатлыклары. Әдәби әсәрләрдә моны һич кенә аерып куеп булмый, Рифә ханым әлеге проблеманы дөрес күзаллаган, пропорциональ рәвештә сурәтләп барган.

Р.Рахманның тарихи темага язылган, XX гасырның дәһшәтле вә гарасатлы елларын тирәнрәк эченә алган повестьлары – «Йолдызлар төстән язганда» «Таулар һаман ерак...», «Күтәрсең бит?!» әсәрләренә кыскача гына булса да фикер белдерүне кирәк саныйм. Әсәрләр идея-эстетик яктан, сюжет-композиция эшләнеше ягыннан гына түгел, драматик вакыйгаларның югары кимәлдә гәүдәләнеше, интригаларның камил бирелеше, әсәрнең үзәген тәшкил иткән конфликтлы халәтнең кискенлеге белән дә үзенә тарта. Рифә ханымның башка әсәрләрендәге кебек мәхәббәт өчпочмагына корылган ике гаиләнең фаҗигале язмышлары тасвирлануы төп конфликтның нигезе салынуга бәйле рәвештә вакыйгалар эзлекле үсә, Кечкенә кешенең әсәр барышында эчке кичерешләре, дөньяга, якын-тирәгә, кешеләргә теге яки бу мөнәсәбәте төрле халәткә куела вә драматик төенләнеш зур сынаулар аша, җиңелү-җиңүләр белән туган туфрагына кайта алу бәхете, нәсел-нәсәп нигезенә тугрылык саклап яшәү үрнәге сыйфатында тәмамлана. Нигездә, әсәрләрнең төп геройлары – илаһи ана образында сурәтләнгән Җанбикә, Хөршидәләр һәм мәхәббәт символына әйләнгән Сания-Зәйнулла язмышына бәйле вакыйгалар нигезендә үстерелә.

«Йолдызлар төстән язганда» повестеның төп герое – авылның чибәр, уңган, булган кызы Җанбикәгә ярлылар комитеты рәисе Шәйдәүләт Тәкәрлекевнең гашыйк булуы, үзенеке итә алмау көнчелегеннән, хәләл көчләре белән ныклы тормыш кора алган, бервакытта да хезмәтче тотмаган Ходайбирдиевләр гаиләсен кулаклар рәтенә кертеп, контрреволюционер ясавы, Җанбикәнең ире Солтанморат һәм каенатасы Хәмидулланың төнлә авылдан качып китүләре, Шәйдәүләтнең моңа үч итеп Җанбикәне, алты яшьлек улы Хуҗиәхмәтне сөргенгә җибәрүе, әлеге үзгәрешләрдән соң Җанбикәнең ачы язмышы тасвирлана. Сюжет сызыгына Солтанморатның беренче мәхәббәте, ачы телле Нәфисә, аның улы Нурәхмәт, Солтанморатларның ерак кардәше Галиәхмәт тә килеп кушыла. Повестьның эчке мәгънәсе Җанбикә образы, аның психологик кичерешләре, ата-бабадан килгән традицияләргә нигезләнгән фәлсәфи уйлары аша тормышка ашырыла.

Укучының күңеле автордан Җанбикәнең төрмә һәм сөрген чорын, улы Хуҗиәхмәт белән күрештерүне дә сорый кебек. Әдибә, ачыктан-ачык сиздерми генә, укучының үзендә эзләнүләрне сораган интриганы оста оештыра белүе белән дә аерылып тора. Шунысы ачык: Рифә ханым XX гасырның 30-50нче еллар фаҗигале көннәрен әсәрнең икенче бүлегендә – Җанбикәне этап белән авыллары аша озатканда, биш айлык кызы Гөлхәбирәне соңгы тапкыр имезү күренеше, өченче бүлектә егерме биш елдан соң зур газаплар күреп, туган авылына кайтуы, Хуҗиәхмәтнең анасын кан-яшь түктереп сөргенгә сөргән Шәйдәүләтнең төпчек кызы Рәхилә белән тормыш корып яшәвен күргән укучы үз алдына куйган сорауларга җавап таба шикелле.

Әсәрнең кульминацион чишелеше – сөргеннән кайтып килгән, ризыгы киселмәгән, кырыс Себер туфрагында исән кала алган Җанбикәнең уйларында повестьның фәлсәфәсе ачык гәүдәләнгән. Авылы, туганнары, аның кешеләре хакында бер хәбәре булмаган Җанбикә үзенең үткәне, авылы, кешеләре турында фикерләре, хис-кичерешләрендә тасвирланып бара да инде. Үзен исән калдырган Себер хакында: «Себер ачлыкларын, Себер михнәтләрен Җанбикә белмиме соң?! Авылда калганнарга аннан да авыррак булды микән? Шулайдыр, шулайдыр... Үзенең дә монда калган гаиләсе тулысы белән еллар хәсрәтеннән искергән зират коймасы эчендә ята...» Улы анасы кайтасының алдагы кичтә күктәге йолдызларның төстән язганын күрә. Килене беренче тапкыр «әнкәй» сүзен әйтә. Повестьның исемен, эчке фәлсәфи мәгънәсен эченә сыйдырган әлеге сүзләр хакында Җанбикә: «Кара син аны, йолдызлар төстән язган, дигән була икән. Әтисе Солтанморат та вакыт-вакыт әллә йолдызлар төстән язган, әллә мин акылдан язганмын, дип уфтанып куя торган иде», – дип искә ала. Җанбикәнең яратуга да үз мөнәсәбәте бар: «Яраткандыр инде Хуҗиәхмәт, яраткандыр... Яратсаң, күзеңә бернәрсә дә чалынмый бит ул. Солтанморатның ничәнче күрүе булгандыр, ата-анасының да кемлеген белешмәстән, сиңа гына өйләнәм, дип әйтте дә салды. Шәйдәүләтнең күзе дә ерткычларча յратудан томаланган иде. Боларның яратулары башкача булсачы...» Рифә ханымның Җанбикәсе «ярату» төшенчәсен шулай аңлый, яратуны илаһи көч итеп таный һәм ул бары тик җан белән чын яратуга корылган булырга, ниндидер әшәке максатлар яшеренгән булырга тиеш түгеллеген искәртә. Әдибә әсәрендә «чибәрлек» һәм «исәнлек-саулыкның» тәңгәл килмәвен дә берничә урында ассызыклап уза. Җанбикәнең, чибәрлеге булып та, исәнлек-иминлек теләмәве ялгышлык итеп кабул ителә. Автор повестенның ахырында да бу төшенчәләрне искә төшерергә онытмый. Ул: «Сорар әле, сорар, кыз булса, әнкәм-балам кебек чибәрме, дип сорар. Тфү! Тагын шул чибәрлек! Башы исән-имин булсын, дип телә». Гомумән, чибәрлек әсәрнең үзәгендә бәхет төшенчәсенә туры килмәве, аның тормыш кору, гаилә тотрыклылыгын саклауда, көтелмәгән каршылыклар китереп чыгаруда сәбәп бирүе ассызыклана. «Йолдызлар төстән язганда» повестеның төп героинясы Җанбикә, чыннан да, олы җанлы мәрхәмәтле Бикә булуына ышанасың. XX гасырның 30-50нче еллар гарасатларын үз җилкәсендә татыган, Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән ачы язмыш сынауларын узып, сынмаган-сыгылмаган, кемнең кем булуына карамастан кичерә алырлык дәрәҗәгә күтәрелә алган, гомер бакый кешеләргә бары мәрхәмәтле, изгелек эшләгән Җанбикә шуның якты символы буларак кабул ителергә лаек сыман. Р.Рахман, күргән газапларны, мәрхәмәтсез дөньяны, үзенә һәм тирә-якка әшәкелек эшләүче, зарар китерүчеләрне җаны белән кичерә белгән Җанбикәгә мәдхия җырлап, әсәрен түбәндәгечә тәмамлый: «Инде исән-имин генә шушында яшәргә язсын. Нәзер үк итеп әйтмим, булдыра алсам, әткә-әнкәмне, иремне, баламны гына түгел, дошманнарымны да догамнан калдырмам. Исәннәренә, Себер җибәреп исән калдырганнары өчен, гомернең озынын теләрмен. Һич югы, мин чынлап торып кичерә алганчы яшәрлек гомер».Туган авылында яшәп тә, якын туганнары, чордашларының инде күбесе якты дөнья белән саубуллашуларына, үзенең исәнлегенә Ходай бүләге итеп каравын да ачык сиземләргә мөмкин.

Р.Рахманның «Таулар һаман ерак...», «Көтәрсең бит?!» повестьларында тарихилык темасы XX гасырның 30нчы еллар сәяси һәм иҗтимагый вакыйгалары белән генә чикләнми, гади авыл кешеләренең ачы язмышы берничә дистә елларны иңли, сюжет сызыгы һәм персонажларның язмышлары шул чордагы тормыш каршылыклары белән катлаулана, әсәр дәвамында буыннар алмашынуы белән үсеп, үзгәреп бара. Атап үткән

повестьлар үзләренең башламнары белән дә кызыклы. «Таулар һаман ерак...» әсәре Габәшир авылының бүгенге хәл-әхвәлләре, бабалары нигезенә Үзбәкстаннан күчеп кайткан һәм яңа тормыш кору нияте белән яшәгән Зиннурның вафаты һәм сюжет корылыш вә үстерелеше тумачие Әлфиянең нәсел тарихын яза башлауга бәйле рәвештә дәвам итә. «Күтәрсең бит?!» повесте исә гаиләнең бер гасырга якын узган тарихы Ярулла мулланың оныкчыгы Зөлфирәнең гаилә альбомындагы фотосурәтләр белән сөйләшүдән башлана. Ике әсәрдә дә милли һәм дини традицияләре, гореф-гадәтләре, ил тарихының барлык үсеш-үзгәрешләрен саклап яшәгән гади генә татар авылының үткән тарихында күргән вакыйгалар гәүдәләнеп, аларның уй-кичерешләрен, шул заманның яшәү рәвешләрен, аның идеяләре белән тәрбияләнгән персонажларның характер үзенчәлекләрен, аларның дөньяга карашларын, психологиясен күрергә мөмкин. Әлеге әсәрләр, нигездә, бүгенге татар авылы, аның проблемаларыннан башлана. «Таулар һаман ерак» әсәренең төп герое Хөршидәнең һәм аның ире Сары Салинең (чын исеме – Сәлигулла) оныкчыгы Зиннурның Габәширгә кайтуы, авылның бүгенге хәле бәян ителә. Нәсел башы Сары Сәлинең язмышы, баладан хатыны үлеп, алты бала белән тол калуы, аның карта уйнарга яратуы, күпмедер уңышларга ирешүе, суык куллылыгы да, бу гадәтен колхоз рәисе, Хөршидәнең беренче мәхәббәте Лотфулла «кеше үрдәген ашаганда, үз казыңны ныклап тот», – дип тешләп алуы, Кизләү авылының чибәр кызы Хөршидәне, шул авыл бае Миңлекәйнең хатыны булуга карамастан, очраклы гына карта уенында отып алуы, Хөршидәнең Сары Сәли белән тагы биш бала үстерүе һәм аларның балалары, оныкларына бәйле рәвештә вакыйгалар үсә, авыл, гаиләнең генә түгел, Ватан һәм Кече Ватанның тоташ бер гасырны иңләп, кырык битлек повестьта шуларны гәүдәләндерә алган. Әдибә Кече Ватанны, аның табигатен, кешеләрен яратырга өнди, горурлана. Алар – кечкенә кешеләр булсалар да, ил тарихы, аның язмышы белән яшәгән, дәһшәтле, гарасатлы елларны үз җилкәләрендә кичергән шәхесләр.

«Күтәрсең бит?!» белән «Таулар һаман ерак» повестьлары арасында охшашлыклар чагылып үтсә дә, икенчесе Сания-Зәйнулла мәхәббәте тарихы сурәтләнүгә, алар яшәгән заманны, кешеләрен тасвирлауга багышланган. Саф сөю, эчкерсез мәхәббәт үрнәге Сания-Зәйнулла мәхәббәтен җимергән сугыш китергән газаплар, каршылыклар Сания һәм Зәйнулланың кешелек һәм әхлак сыйфатларын, мәхәббәтләрен кат-кат сыный, әмма җимерә алмый. Ни чарадан – бичара дигәндәй, Фәһимгә кияүгә чыккан Саниянең бәргәләнүләре, кызның гаилә коруын ишеткән Зәйнулланың сугыш кырында ут яңгырына ташланып исән калуы һәм, исән-имин авылына кайтып, мәхәббәт газапларына дучар булуы, шул шартларда Фәһим һәм Саниянең гаиләне җимерелүдән саклап калырга тырышулары, Фәһимнең гаепсезгә төрмәгә җибәрелүе, Фәһимне төрмәгә утырткан Зариф белән Каюмның кулга алынулары һәм башка күп кенә бер-берсен алыштыра барган драматик вакыйгалар укучының игътибарын үзенә җәлеп итә, кызыксынуны арттыра.

Р.Рахман иҗаты темалар, проблемаларга бай. «Кем күтәреп караган» (2009), «Сан-зат тыйз-зи» (2012), «Юрась һәм Петруся» (2012), «Күкыжда – күк Алласы» (2012), «Раббың кем?» (2013), «Нигез туфрагы» (2006) һәм башка хикәяләрендә, «Сөннәтче әби» (2006) кыйссасында, «Йолдызлар төстән язганда» (2012), «Күтәрсең бит?!» (2014) кебек повестьларында язмыш һәм дин, милли әхлак тәрбиясе, әби-бабай, гореф-гадәтләргә ихтирам белән карауга игътибарны юнәлтә. Әдибәнең әби-бабалары руханилар нәселеннән булуы да, аның образлары үзе дөньяга килгән Кукмара төбәгенә һәм татар халкының шул тирәдә яшәгән мари-удмуртның милли-дини традицияләре белән уртаклашып яшәве эзсез калмаган, Рифә ханым аларны повесть вә хикәяләрендә чагылдыруга ирешкән. Галимә Ә.Мотыйгуллина искәрткәнчә, «Рифә Рахман хикәяләреннән аның башка халыкларның да традицияләрен, бигрәк тә мәҗүсилектән үк килгән йолаларны яхшы белгәнлеге күренә. «Күкыжда – Күк Алласы», «Юрась һәм Петруся» хикәяләре бу хакта ачык сөйли. Димәк, әдибә һәр халыкның мәдәни мирасына игътибар булуын тели». Аеруча, ул җитмеш-сиксән ел дәвамында милли һәм дини әхлак принципларын, гореф-гадәтләр, йолаларның җимерелүенә битараф түгел, повесть һәм хикәяләрендә бу темага кат-кат әйләнеп кайта, аларга ихтирам белән карарга өнди.

«Җиңелләрдән генә булсачы» (2012), «Сездә нинди хәлләр бар?» (2012), «Кәбестә шулпасы» (2014), «Кемнеке син, Хәмәтҗан» (2014), «Әйләнгеч юллар» (2005), «Нигез туфрагы» (2006), «Бәхет шарты» (2008) «Исемгә исең киткән» (2006), «Нәсиб-Нәсибә» (2006) хикәяләре, «Казан утлары» журналының 2017 елгы 4 нче санында басылган «Бәйрәм» хикәясе һәм «Таулар һаман ерак...» (2013) повестенда милли мәсьәләләр, туган якны сагыну, аңа кайту фикере өстен чыгарыла.

Казан – халыкара студентлар шәһәре. Әдибә – шул студентлар, яшь егетләр-кызлар белән аралашып яшәгән шәхесләрнең берсе. «Сездә нинди хәлләр бар?» хикәясенең үзәгенә татар кызы Алинә һәм кампучияле Прак Тьей алынып, бүгенге бәхетле яшьлек, студентлар тормышы сурәтләнә. Ләкин бу беренче карашка гына шулай. Һәр ике дәүләт һәм анда яшәгән халыкларның тарихи язмышлары бер үк төрле. Алинәнең анасы үзенең узган гомере, язмышы, ә Тьей Компучиядәге көрәшне сөйләгәндә, ике халыкның язмышында охшашлыклар шактый булуы ачыклана. Алинәнең бары Кампучияне «бананнар оҗмахы» дип уйлап йөрүе бу сөйләшү вакытында җимерелә, кешеләр язмышы кайда да бертөрле булуы ачыклана. Аның әсәрләрендә мөселман һәм христиан диненә мөнәсәбәт тә гәүдәләнеш алган. «Җиңелләрдән генә булсачы» хикәясендә ире Булатнур рус хатынына өйләнүе, хатыны Лилиянең чиркәүгә йөри башлавы, аның христанлык кабул итүе һәм каенанасы Алтынходаны христиан йоласы буенча җирләп, гаилә фаҗигасенә китерүе, Лилия һәм Булатнурның психологик кичерешләренең никадәр киеренке халәткә җиткерә алуын раслый. Бу күренешне «Таулар һаман ерак...» повестенда да күзәтергә мөмкин. Туган авылы Габәширгә төпләнеп калу уе белән кайткан Зиннурның хатыны да христиан, милләте билгесез Коровинаның татар авылы, мөселман традицияләре нигезендә гомер сөргән авылда яши дә, эшли дә алмый, Зиннурга хыянәт итеп, икенче кешегә кияү чыга. Гаилә таркала, үз-үзен кая куярга белмәгән Зиннур Мәскәүгә китеп вафат була. Гасырлар дәвамында дини идеология, аның фәлсәфи карашлары кешелекнең канына гына түгел, җанына, психологиясенә дә сеңгән. Кешенең яшәү рәвеше җәмгыять һәм аның әхлакый принципларына нигезләнеп корылган вә аның дөньяга карашы шул күзлек аша гына карый, адәми затның эчке психологик халәте, фәкать гуманлылыкка өстенлек биргән дини тәрбияне сикереп чыга алмавы, язмышларны катлауландыра, гаилә фаҗигаләренә китерә. Р.Рахман әсәрләрендә алар аеруча калку күрсәтелгән дә инде. Совет җәмгыяте, коммунистик идеологиянең милләтләрне таркатуга шактый көч куюы мәгълүм инде. Рифә ханымның бу фаҗигагә дә мөнәсәбәте ачык. Ул, мәсәлән, «Әйләнгеч юллар», «Кәбестә шулпасы», «Бәхет шарты», «Бәйрәм» кебек хикәяләре, шулай ук «Таулар һаман ерак...» повестенда татар баласының чит халыкларның милли гореф-гадәт, йолалар белән тәрбияләнгән Урта Азия вә Кавказ мәмләкәтләрендә яшәп, инде сагынуга түзә алмыйча, туган төбәкләренә кайткан геройларның эчке психологик халәтен, аларның шәхси фаҗигаләрен, мөселман булсалар да, милли гореф-гадәтләрнең татар халкыннан күпкә аерылуын ассызыклап, бәхет ул синең туган туфрагыңда, туганнарың, авылдашларың белән янәшәдә дип әйтергә тели.

Р.Рахманның һәрбер татар баласыныкы кебек яшьлек еллары, гомеренең күпчелек өлеше шәһәр белән бәйле. Университетта уку һәм эшләү, студентлар белән аралашу, аларның эчкерсез дуслары булган әдибә иҗатында шәһәр, яшьлек, студентлар тормышына караган хикәяләр белән очрашмасак, күңелдә ниндидер бушлык барлыкка килер иде. Ул хикәяләрнең нигезенә күбрәк юмор хисе салынган, әлбәттә. Бу аңлашыла да кебек. Яшьлек дәрте кайнап торган студенттан юмор, шаянлык көтмичә, тагын ни көтәсең инде. «Кеше булу» (2009), «Телефон» (2006), «Куык» (2007), «Төкергән мин сезгә...» (2005), «Әдәбиятта яңа күренешләр» (2008), «Көянтә» (2011), «Әҗер» (2013), «Яшибез икән» (1998), «Әйтер сүзем бар» (2013), «Таныш тавыш» (2006) «Депутат иптәш» (1999) кебек әсәрләрендә шәһәр тормышы, яшьлекнең матур яклары да, үкенечләре дә, дөньяга яшьлек күзе белән карау да бар. Рифә ханым бу темада бигрәк тә үзе яшәгән заманның геройларын типик образлар дәрәҗәсенә күтәрә. Аларны һич кенә әдәби персонажлар итеп карау мөмкин түгел, һәрдаим, һәр адымда алар белән очрашабыз, гәпләшәбез. Алар, нигездә, студентларның укулары, укытучыларның төрле ният, принциплар белән укытулары, шул ук вакытта педагогларның, кемнең

кем булуына карамастан, тәнкыйтьләп алудан гыйбарәт. Авылларыннан бәхет эзләп шәһәргә киткән яшьләргә дә Рифә ханым битараф түгел, авыл кызлары, егетләре дә аның әсәрләрендә типик образ дәрәҗәсенә күтәрелгәннәр. Моның мисалы «Төкерәм мин сезгә...» хикәясендә чыгылыш тапкан. «Куык» хикәясендә, ничәдер ел узганнан соң, инде элекке студентларның яшьлек еллары белән очрашулары, тормыш тәҗрибәсе туплаган, дөнья күргән сабакташларның «куык» темасына сөйләшер сүзләре шактый була. Аңа бәйле кызык хәлләр белән һәркем очрашкан, вакытында гаиләдә күңелсезлекләр тудыруга сәбәпче булса да, куык темасы яшьлекләре белән күрешкән кызларның күңелләрен күтәрә. Әдибә искәрткәнчә, ул заманда аның барлыгын да белмәгәннәр, сабакташ кызларның күпчелеге начальникка кияүгә чыккач кына актуаль мәсьәләгә әйләнгән. Гомумән, гомерләрен шәһәр, аның ыгы-зыгысы, мохитенә килеп капкан яшьлек, авыл, милли тәрбия күргән яшьләрнең дөньяга карашын, психологиясен, кешеләргә карата ышанычын җимерә. Шулар яшьлекнең үкенечләренә, газаплы кичерешләренә сәбәп бирә. Рифә ханым, бу күренешләрне «Әйтер сүзем бар!» хикәясендә ачык рәвештә сурәтләгән.

Яшьлек темасына кагылганбыз икән, әдибә авылда туган, балалык һәм яшүсмер чаклары авыл тормышы белән бәйләнгән, яшьлек дәрте кайнап торган, яшьлектәге мәхәббәт хисләре бөреләнә башлаган еллар хатирәсе аның әсәрләрендә чагылыш тапмаса, Р.Рахманның иҗатының бер өлеше китек чыгар иде. «Каеш кыены» (2006), «Көянтә» (2011), «Баланлы йортта бал яхшы» (2012), «Толым» (2013), «Дуңгыз исе» (2013), «Тиң түгел» (2013), «Кармак Шәфикъ» (2014), «Бәхетле йолдыз астында» (2015), «Фәхретдин карчыгы» (2013), «Тик сине алып кына» (2007), «Сары тавык дәвасы» (1998), «Исемгә исең киткән» (2006) кебек хикәяләрендә авылга, аның табигатенә, яшьлекнең шуклык, шаянлыкларына, мәхәббәткә дан җырлау, аны сагыну һәм үкенү хисләре урын алган.

Әдибәнең әсәрләре лирик хисләргә бай, тормышның төрле катламнарына, тормыш чынбарлыгы аша бәя биргәндә, ул еш кына көлеп, елмаеп та карый. Рифә ханымның иҗатында юмористик хикәяләрнең урын алуы очраклы түгел. Югарыда искә алынганча, Р.Рахман XX гасырның 90нчы елларында «Мәгърифәт» газетасында хезмәт куйганда, публицистик мәкаләләре белән бергә газета битләрендә укучының күңеленә һуш килердәй юморга бай хикәяләре дә дөнья күрә. Гомумән, ул – дөньяга юмор аша карый торган шәхес, яшәве дә елмаеп яшәүгә корылган. Бу деталь әдибә иҗатында урын алмаса, ул тудырган энҗе бөртекләренә нидер җитмәс иде шикелле. 90нчы елларда язылган «Төртелде» (1997), «Нәселле кәләш» (1997), «Милиция кызлар сөя» (1997), «Поп – пумала, мулла – чүмәлә» (1997), «Эт тормышы яки сәрхушнең эчке зары» (1997), «Хатын белән очрашсак» (1997), «Шашлык, шәраб һәм кызлар» (1999) кебек хикәяләрен искә алырга мөмкин. Дөрес, юмористик һәм сатирик әсәрләре XXI гасыр башында да шактый язылган. «Төкердем мин сезгә» (2005), «Фантанчик» (2000), «Телефон галәмәтләре» (2000) кебек хикәяләрен дә атап үтү җитәдер. Әдибәнең башка хикәяләрендә дә, мәсәлән, «Исемгә исең киткән» (2000) әсәрендә кайбер урыннарда шаян, юморга бай эпизодларның очрап куюы әдибә иҗатының күпкырлы булуын, төрле әдәби алымлардан оста файдалануын раслый шикелле.

Р.Рахман иҗатында ата-анадан килгән традицияләр дә роль уйнамыйча калмый. Ул бик теләп балалык чорларына әйләнеп кайта, мәктәп тормышын, яшь баланың эчке кичерешләрен, дөньяга, кешеләргә мөнәсәбәтен яратып, нечкәләп тасвирлый. Гомумән, ул теманы, иҗатының кайсы гына чорында булуга карамастан, кат-кат искә төшерә, көтелмәгән әдәби алымнар белән баета, камилләштерә. Балаларга махсус атап язылган вә үзенең балалык дәверен гәүдәләндергән «Кибән башы» (2006), «Кесәл» (1993), «Таң чыпчыгы» (1993), «Кызыл башмаклар» (1993), «Гает коймагы» (1993), кечкенә баланың кичерешләрен, мәктәп тормышы, балаларның шуклык вә шаянлыкларын мактаган «Әни, кайт» (1999), «Тылсымчы» (1993), «Сыбызгы» (1994), «Вафасыз» (2013), «Сары тавык дәвасы» (1998), «Зәңгәр алма димәскә» (2000), «Киндерче малай турында хикәят» (2013) – бала психологиясен барлык нечкәлекләре белән ача алган хикәяләр итеп каралырга лаек.

Авыл баласы, бигрәк тә иҗаты табигатьне, экологик мәсьәләләрне яктыртмаса,

кешеләрнең, җитәкчелекнең табигатьне мәсхәрәләүләре күңелен борчымаса, шуларны гәүдәләндермәсә, ул тудырган иҗатта нидер җитмәс кебек. Аның кайсы гына әсәрен алып карасаң да, экология, туган җирнең һәлакәтенә борчылу хисләрен белдергән мотивларны күрми үтеп булмый. Бу теманы чагылдырган әсәрнең тематик төре, куелган проблеманың, фикернең тирәнлеге ягыннан «Атка печән кем сала яки Моңсу Күз сагышы» повесте аерылып тора, минемчә. Әдибә заман, авыл, аның тормышы, традицияләре җимерелә баруны Моңсу Күзнең уйланулары, сагышы аша сурәтли, аларга үзенең мөнәсәбәтен белдерә. Гаять тә үзенчәлекле, хыялга бай әлеге әсәр Р.Рахман иҗатын яңа баскычка күтәрә. Гомумән, «Атка печән кем сала...» әсәрендә тасвирланган Ат образы әдибәнең башка әсәрләрендә дә очрый. Ат авылның яшәү өчен терәге генә түгел, ә, бәлки, табигать, адәми затның, күңел сызлауларын, халәтен сурәтләгән арадашчы да булуы раслана.

Р.Рахман хикәяләренең тематикасы болар белән генә чикләнми, әлбәттә. Безнең балалык елларында «к» хәрефенә башланган хикәяләр язу традициясе хәтергә кереп калган. Әдибә – бу теманы дәвам итеп, «б» хәрефен алып, «Бибисараның Бәдригә бәйрәм бүләге» хикәясен яза һәм ул шактый үзенчәлекле, кабатланмас әсәр буларак күз алдына килеп баса.

Р.Рахманның «Онытырмын, димә...», «Йолдызлар төстән язганда» һәм «Таулар һаман ерак...» тупланмаларында йөздән артык хикәя, дүрт повесть вә өч кыйсса урнаштырылган. Бу җыентыклардан күренгәчә, әдибә, нигездә, татар әдәбиятында хикәяләр остасы буларак күз алдына килеп баса. Мәгълүм ки, хикәя жанрында иҗат итү яисә итә алу җиңелләрдән саналмый. Хикәядә автор тоташ бер эпоханы, геройның язмышын, аның характер үзенчәлекләрен ачып бирергә тиеш. Рифә ханымның таланты, озынмы яки кыска хикәяме, нәсер, фельетонмы, бәлки, жанрның башка формасымы, хикәянең күп төрле алымнарыннан файдаланып, кешенең язмышын, психологиясен, характерын укучының күңеленә һуш килерлек югарылыкта тасвирлауга ирешә. Әдибә, бүгенге әдәбиятта хикәя жанрының традицияләрен саклаган хәлдә, төрле формаларга мөрәҗәгать итә, үзенә генә хас стиль, сюжет корылышларын яисә башламнарны эшкә җигеп, бертөрлелектән кача. Мондый иҗади эзләнүләр, беренчедән, татар прозасында кабатланмас жанр үзенчәлекләре тудыруга ярдәм итсә, икенчедән, үзенә кадәрге иҗат әһелләреннән аермалы буларак, хикәя жанрына яңалык, яңа алымнар алып килүе белән дә игътибарны үзенә тарта. Гомумән, Р.Рахман – бүгенге татар әдәбиятының проза жанрында тормыш таләбенә әйләнгән актуаль проблемаларны, проза жанрында үтемле чаралардан файдаланып, иң уңышлы һәм нәтиҗәле эшләүче прозаикларның берсе. Моны өч җыентыкка урнаштырылган проза әсәрләренең саннары да раслый шикелле.

Р.Рахманның иҗатына кыска гына күзәтү ясаган мәкаләдә, нигездә, проза әсәрләре турында гына сүз барды. Әдибә әдәбиятта, башлап, нечкә күңелле, лирик-фәлсәфи, мәхәббәт шагыйрәсе буларак танылды. Аның 1995 елда дөнья күргән «Шук алма, моңсу алма» һәм 2002 елда нәшер ителгән «Керфекле тәрәзәләр» исемле шигъри әсрләрен туплаган җыентыклары да бар. Болар хакында киләчәктә әле сүз булыр дип уйлыйм.

Кыскасы, татар прозасында хатын-кыз әдибәләр арасында үз стилен, сүзен әйтә алган Р. Рахманның дөнья күргән иҗади мирасына сәяхәт кылдык. Хезмәтебездә талантлы әдибә әсәрләренең кайберләрен, алардагы гомуми форма һәм алымнар, темалар, проблемаларга гына тукталып үттек. Авторның фикри тирәнлеге, катлаулы язмыш, характерлар бирелеше ягыннан әһәмиятле әсәрләре аерым анализ, күзәтүләрне, мәхәббәт шагыйрәсенең поэзиясе турында аналитик материал язуны сорый. Гомумән, аның бары кыйммәтле энҗе бөртекләреннән генә торган иҗат җимешләре – укучы ихтыяҗын канәгатьләндерерлек, үзенә генә хас җылылыкка төрелгән, авторның гына түгел, һәрбер персонажның җан авазы сеңдерелгән югары кимәлдәге чәчмә әсәрләр. Р.Рахман – бүгенге көндә әдәбиятның төрле жанрларында иркен эшләүче, бер үк дәрәҗәдә камил әсәрләр иҗат итүче, иҗади таланты ташып торган әдибә.

**Зөфәр МӨХӘММӘТШИН,**
*филология фәннәре кандидаты*

# МОҢ ШАГЫЙРЕ...

## РӘМИС АЙМӘТ ИҖАТЫ ТУРЫНДА УЙЛАНУЛАР

*Гомер буе шулай калсам иде,*
*Булып синең моңлы мишәрең.*
Р.Аймәт

2016 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән җыентыгына Р.Аймәт, гадәтенчә, сәер вә серле исем биргән: «Бозлы җилкәннәр». Бозга каткан җилкән көймәне сикертә-сикертә, дулкыннарны ярып, тиешле җиргә алып бара алырмы икән дигән «наив» сөальнең тууы да табигый. Әллә бу иртә үтә шартлы атаманың «мөгез чыгару» гына булмыйча, башка шигъри яисә иҗтимагый мәгънәсе бармы? Хәер, шагыйрьнең мәҗмугаларына башваткыч исемнәр бирергә яратуы яңалык түгел. Без «Шомырт салкыннары»на (2000) күнеккән генә идек, «Айның аръягына» (2005) «сәяхәт» кылырга насыйп булды. Халык иҗаты риваяте «сөйләгәнчә», җир йөзенә нур сибеп утырган ай рәнҗетелгән ятимә кызны көянтәсе-чиләге белән мәңгелеккә үзенә алган. Дөнья галимнәренең ошбу күк җисеменең безгә карап торган ягын да чын-чынлап өйрәнә алганнары юк. Ә шигырь сәнгатенең «чикләнмәгән» мөмкинлекләре укучыны айның «аръягына» чакыра. «Зөһрә кыз белән сөйләшү» шигырендә Р.Аймәт «һаман күкләрдә... һаман берьялгыз» моңсу кызны җиргә төшәргә үгетли, димче булырга «вәгъдәсен» дә бирә:

*Төш әйдә, йолдызлар*
*Сибелсен юлыңа.*
*Димләрбез без сине*
*Гади җир улына.*

*Туй итәр шаулатып*
*Җирләр дә, күкләр дә...*
(«Зөһрә кыз белән сөйләшү»)

Халык мифологиясенең гаделсезлекне, нахакка рәнҗетүне, ятимлекне кире каккан риваятенә таянып, Р.Аймәт житез иҗекле (6-6), миһербанлы (кызның «ризалыгына» ирешмәсә дә) әсәр иҗат иткән.

Шагыйрьнең әлеге җыентыгында урын алган «Ялгызлык», «Соңгы өмет», «Җирсү», «Сагыш», «Сыктау», «Моңлы яңгыр», «Соңгы яфрак»... парчалары кичерешне, хисси дөньяны эзлекле үстергән, камил эшләнгән. Традицион шигырь кысаларына фәлсәфи, этик яшәеш баклыкларын һәркайсы үзенчә, яңача күзаллаган, ихлас шигырьләр... Күзләрне чылатырлык сагыш, юксыну, ямансулау, нәүмизләнү... Дөньяңны онытып, шигырьләрне бер сулыш белән укыйсың! Әгәренки, мин Рәмис Аймәтнең ачык йөзле, итагатьле, аралашуда югары культурага ия, җиңел сөякле, хәрәкәтчән, шаян рухлы, Ш.Камал, Г.Тукай музейларында уңышлы эшләгән, күп еллар дәвамында Язучылар берлеге рәисенең иҗади гамәлләр буенча урынбасары вазифаларын башкаручы замана баласы икәнен белмәсәм, әлеге шигырьләр авторы яшен яшәгән, ашын ашаган өлкән бер кешенең үз эчке дөньясына бикләнеп, моңсуланып, сагышланып, яшь чагын искә төшереп, гомер азагын көтеп яткан карт дип фаразлар идем... Шул төр медитатив шигырьләрнең берсе – «Халәт» – Р.Аймәт иҗатында гына түгел, гомумән, хәзерге

татар поэзиясендә кеше җанының өзгәләнү-бәргәләнүләрен шигырь теле белән ачу юлларының чиксезлеген раслаган әсәрләрнең берсе. Лирик каһарман тормышының, рухи халәтенең иң авыр мизгелен кичерә. Ул киләчәктән җылылык көтми генә түгел, аңа берни, хәтта тәлинкәгә салып китергән бәхет тә кирәкми, тынлык эченнән дә ул тынлык эзли: *«Сүрелмәмен, сүнәм, югаламын, / Таралламын, эрим, онтылам. / Убыламын бәгыренә Җирнең / Кояш тотылгандай тотылам»* («Халәт»).

Югалып калуның, тормыштан бизүнең, түшенкелеккә бирелүнең чиге юк, ул фани дөньяны ташлап китү юлына да алып чыгарга мөмкин! Мәгәр үлем дә язмыштан котылуның бердәнбер ысулы түгел икән: *«Үлем генә саклап калыр микән / Иблис каһәрләгән язмыштан?»* («Кыямәт»).

Р.Аймәтнең әлеге әсәрләре тәэсирендә мәкаләнең исемен дә «Моң шагыйре...» (беренче атамасы – «Ялгыз сандугач») дип атадым. «Моң» – татар җырларының, көйләренең башка телләргә тәрҗемә ителми торган, халкыбызның рухи дөньясын, тарихын чагылдырган бер үзенчәлеге, шулай әйтергә яраса, «визит карточкасы».

Кыскасы, кешелекле моң – Р.Аймәт иҗатының буеннан-буена сузылган үзәк символ-образ. Шагыйрь үзен моңсулыкта, түшенкелектә битәрләүчеләр белән бәхәскә дә керә.

*«Моңсу», дисең, дускай, «Моңсу», дисең,*
*Бу бит инде иске яңалык.*
*Һәр яңалык туа иске булып,*
*Искеләре тора яңарып...*

*...Күзнең моңсу балкышыннан гына*
*Күчкән Моң түгел бу,*
*Моңсулык!!!*

(«Моңсу, дисең...»)

Лирик каһарманның моңсулыгы тирәлеккә, табигатькә дә «күчә».

*Наратлар – моңсу, моңсу...*
*Шаулыйлар таңга чаклы.*
*Шул наратлардай безнең дә*
*Моңланып торыр чакмы?*

(«Наратлар – моңсу...»)

«Вакыт монологы» шигырендә дә лирик каһарман хисләрен наратка «ышанып тапшыра»: *«Нарат ябалдашын айкый-чайкый / Моңсуланып искән җил мин»* («Вакыт монологы»).

Үз шәхси кичерешләрен үзәккә алган, эчке сөйләме – монологка корылган «Мин әле тумаган», «Мин китәсе көн», «Эзләмәгез мине» кебек мәгънәви юнәлешләре, ышанучан ихласлыклары, шигъри эшләнешләре белән камил әсәрләре лирик затны дөньяда яшәүдән туйган, югалып калган, пессимизм упкынында үзен югалткан шәхес дип күз алдына китерәләр. Шагыйрьне, төрле изм...нарда гаепләргә ашыкканчы, шундый халәтне тудырган сәбәпләрне эзләргә, ачыкларга кирәктер!

Лирик геройга авыр хис-тойгылар дөньяның гаделсезлегеннән килә икән:

*Бу дөнья – гарасат мәйданы,*
*Әллә соң яшәү дә бер җәза?!*
*...Мин әле тумаган, ә инде*
*Күкләрдә укыйлар җеназа.*

(«Мин әле тумаган»)

Лирик зат, «әле тумаган булса да», соңгы көннәре турында борчыла. «Мин китәсе көн» шигыре бер төркем яшь шагыйрьләрнең кумиры М.Цветаевадан алынган «знаю, умру на заре» юллама-эпиграфның мәгънәсен ачуга багышланган: үтә шартлылык

укучыны шулай ук гаҗәпкә калдырырга мөмкин: *«Мин китәсе көнме? / Тымык тынлык / Җирдә тынып яткан чакларда, / Әле уянмаган чәчәкләрнең / Таҗларында таңгы чыклар да* («Мин китәсе көн»).

Димәк, безнең лирик зат та, рус шагыйрәсе шикелле, фани дөньяны чәчәк таҗларында чык та кипмәгән вакытта ташлап китә һәм алдагы юлларда, сагынсагыз да мине, эзләмәгез, дигән «васыятен» калдыра.

«Эзләмәгез мине...» шигыре шул ук мәүзугъны – дөньяда яшәүнең мәгънәсезлеген тәкрарлап, гомернең кыскалыгы турында уйлануны дәвам итеп, тагын да кискенрәк нәтиҗәләр ясый. Үзәктә – лирик каһарманның Вакытка мөнәсәбәте, аны дөнья сурәте «ышыгында» кабул итүе: *«Беркайчан да эзләмәгез мине!!! / Минсез дөнья әллә үзгәме?! / Вакытларны тыю сезгәме соң? / – Өнсез калган Вакыт бизмәне».*

Постмодернизм рухы, поэтикасы кысаларында әйтелгән соңгы мисраг каян килә әле яшьлеге белән саубуллашып кына килгән ут егет Рәмис Аймәткә дөньядан тую, ямансулау, боегу төшенкелеге дигән сорау уята: *«Сагындыгызмы?.. Сагынырсыз! / Мин башка шул, башка оядан. / ...Эзләмәгез мине беркайдан да, / Кайтмаска (!) дип киттем Дөньядан!..* («Эзләмәгез мине»).

Р.Аймәт иҗатына хас бу лирик агым, мәрсия аңа гына хасмы соң? Дәүләтчелегебезне – Казан ханлыгын югалтканнан соң, кайсы мәшһүр татар язучысының милләтенең ачы язмышы, теленең, менталитетының киләчәге өчен борчылмыйча яшәгәне, иҗат иткәне бар! Һәрдаим тел очында торган мисалларны – Тукайның «Өзелгән өмид», «Көзге җилләр», Дәрдемәнднең «Өмидләр», «Куанды ил, канат какты мәләкләр» кебек шигырьләрен генә искә төшерик: *«И мөкаддәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз? / Син сынасың, мин сүнәмен, аерылабыз, ахырысы!»* («Өзелгән өмид»); *«Җиһан тормыш туен иткән чагында, / Синең урның – үлекләр аймагында»* («Куанды ил...»).

Хәтерем ялгышмаса, бер генә җитди галимнең дә XX гасыр башы даһиләрен төшенкелектә, көрәштән баш тартуда гаепләгәннәре юк. Киресенчә, бу шигырьләрне иҗтимагый-сәяси тормышта барлыкка килгән каһәрле үзгәрешләрне вакытында сурәтле телдә әйтеп калдырганнары өчен югары бәялиләр.

XX гасырның янә бер бөек шагыйре Такташның башлангыч чор иҗатында таң атуны, якты көннәр килүне көтеп яшәгән лирик герой белән «очрашабыз»: *«Таң атамы? Яктырамы? / Нишли дөнья, нишли ул? / Ник күренми якты көннәр? / Ник томанлы алгы юл?»* («Төркестан сахраларында»).

«Газраилләр», «Караңгы төннәрдә», «Юану», «Таң кызы» шигырьләрендә, бигрәк тә «Җир уллары трагедиясендә» Такташ тыйнак, салмак, сүзен уйлап әйтүчән татар шигъриятенә фәрештәләр, газраилләр, тәмуг гөлләре, таң кызлары кебек дини-мифологик символлар алып керә. Гайре табигый күренгән образлар таң атуны, якты көннәр килүне зарыгып, өмет, ышаныч белән көтү рухын чагылдыралар.

Такташның символизм белән мавыгып йөргән чорында кулланган сурәт-төшенчәләрнең күбесе, яңарак мәгънәви, эстетик юнәлешләр алып, Р.Аймәт эзләнүләрендә «ияналар». «Адашу», «Сөрелү» шигырьләрендә яшь Такташка хас сүз-образларны тануы кыен түгел. Әмма турыдан-туры кабатлау юк: *«Киләчәкнең канлы кыйбласында / Дөрләп янган чакта өметләр, / Төннәр буе тулган айга карап / Шыңшып өргән чакта ят этләр»* («Адашу»).

«Адашу»да Иблис, Шайтан туе (Ш.Бабичны искә төшерегез), Җәллад кебек «тарих тузаннарын» җилгә чәчеп йөрүче образларны, символларны төрлечә бәяләргә, юрарга мөмкин булса да (шигырьдә ачылып бетмәгән «сер» яшеренеп ятарга тиеш), әсәрнең асылында дастан булып калкаячак җыр эзләү, ирек таләп итү ята: *«Сүз – иркле! Тик сүз иреген / Аяк-кулы һаман богауда. / Эзоп теле – йозак теле. Сине / Тагын сынау көтә бу яуда»* («Адашу»).

Ошбу шигырьләрдә купшы сүзләр дә, декларатив шапырынулар да юк. Йөрәк әрнүе, чарасызлык, үкенү, корбанчылык идеясе генә үзәктә: *«Сөрелдем мин Күктән. Хуш, Чиксезлек! / Тугры калалмадым антларга»* («Сөрелү»).

Р.Аймәтнең лирик каһарманы үз эчке дөньясын, рухи халәтен, тирәлекне аңлау, бәяләү нияте белән «юлга чыга». Шаблон сүз-җөмләләрдән туйган укучы күңел нечкәлеген Тәңрегә табынып ачкан, тын, тыныч, моңлы-хисси шигырьләргә бик тә

мохтаҗ! Шул ук вакытта аны эчке һәм тышкы хис-кичерешләрне, үткәнне-хәзергене капма-каршы куюу тарафдары дип булмый. Тик ул олы дөнья мәшәкатьләренә, милләт, туган тел язмышы турында уйлану-хәсрәтләнүгә йөрәк серләрен ачу аша килә.Үз моңнарын түгеп, «елап-сыктап» ала да, милләтенең авыр язмышын исенә төшереп, явыз көчләрне каһәрләп, усалланып та ала. Ошбу медитатив, ягъни элитар, лириканы аңлау өчен, шигъриятне яратудан тыш, зыялылык һәм мәгълүм әзерлек булу да лазем.

*Көч бир, Тәңрем...*
*Өзелеп китәр сыман, –*
*Тегәр җептәй Төн һәм Көн арасы.*
(«Тормыш хастаханәсе»)

*Никтер моңсу үзе – татлы газап*
*Айкагандай иләс күңелне.*
(«Сиреньнәрнең соңгы бәйрәме»)

Рәмиснең ифрат нечкә, нәзакәтле үз дөньясы: аңа тупас бәяләр белән, аны тегеләй яз, болайрак уйла дип киңәш бирүе җитди булмас иде.

Сәер исемле «Сукыр тәкә» шигырендә (күргәнебезчә, Р.Аймәт хыялы өчен гадәти күренеш) үзәк каһарманны серле, чибәр кыз ирештерүен белә: күзләрен бәйли дә таңга таба йөгерә. Поэтикасы постмодернизм «таләпләренә» тулы җавап биреп, татар теленең сыгылмалы байлыгына, сурәтләү чаралары муллыгына мисал була ала: *«Ефәк шәлең – чуклы сихер / Күзләремне бәйләдең дә / Үртәдең син, үчекләдең. / Хур кызына әйләндең дә / И йөгердең таңга таба»* («Сукыр тәкә»).

Ирексездән күңелгә Такташның «Таң кызы» шигыре юллары килә: *«Пәри кызы! Ник чыктың да юлларыма, / Тәмуг гөле тотып нечкә кулларыңа»*.

Мин Р.Аймәтне яшь Такташның дәвамчысы, аның шигырь мәктәбеннән үсеп чыккан сүз остасы дип раслый алмыйм. Шул ук вакытта төрле чорларда иҗат иткән милләт балалары арасында телебезнең эчке җегәрен (энергетикасын) ачуда, лирик каһарманның ярсулы (сәбәпләре төрле) хис-кичерешләрен тасвирлауда типологик уртаклыкны, диалог-эчке сөйләм аһәңдәшлеген инкарь итеп булмый. Дөньяны сурәтләү, хис-кичерешләрне кискенләштерү җәһәтеннән бик күп шигырьләрен яратып, җөен-җөйгә китереп тәрҗемә иткән А.Ахматова фикерләве һәм өслүбе дә якын Р.Аймәткә. Нәселендә, димәк ки, үзендә төрки-татар каны акканнан сер ясамаган, киресенчә, Тукайдан башлап, татар шагыйрьләрен яратып тәрҗемә иткән А.Ахматова XX йөз башы модернизмының, соңрак калыккан юнәлеше – акмеизмның, иң талантлы тарафдарларының берсе иде. Үзләрен «акмеистлар» дип йөргән шагыйрьләр рухи дөнья, көнкүреш ваклыкларына, гадәт-зәвыкларга, шигырьнең шәпле төгәллегенә, эстетик яңгырашына зур әһәмият бирәләр. Сәясәттән читтәрәк торуны исәнлеккә файдалырак дип саныйлар, күрәсең. Акмеист шагыйрьләрнең дөньядан китү, үлем мотивларына «зур өлеш» чыгаруын, бер яктан, шул чорның иҗтимагый тормышын кабул итмәү, икенче тарафтан, олы тарих бизмәненә салып караганда, ифрат кыска гомердә бер-берсенә миһербанлырак булырга чакыру, дип тә аңларга мөмкин. Еш кына арадашчы вазифасы табигать сурәтенә йөкләнә. А.Ахматова «Туганнарым минем килмәделәр...» шигырендә, таяныч эзләп, җилгә сүз ката: *«Җирлә, әйдә, җирлә мине, җил! / Күрәсеңме, җилкәй, мәетем салкын, / Беркемем юк минем дәшәргә»* (Р.Аймәт тәрҗемәсе).

«Җеназа» шигырендә дә А.Ахматованың персонажы «Кабергә урын эзләп йөри», ә «җаны галәм учагында» талпына. Мәгәр аның кебек «Гөнаһлылар өчен» оҗмах ишеге дә йозакта икән.

Р.Аймәт Б.Пастернак, Р.Гамзатовларның дөнья картинасын үзләренчә сурәтләгән шигырьләрен татарча яңгыратып карый. Әмма аның рухына А.Ахматованың акмеизм чоры (1911-1915) шигырьләре иң якыны булып чыга[1]. Символист яшь Такташ,

[1] Тукай әсәрләрен яратып тәрҗемә иткән А.Ахматова шагыйрьнең рухи эзләнүләрен, бәргәләнүләрен чагылдырган шигырьләрен үзәккә ала: «В саду знаний», «Осень», «Слово к зиме», «Разбитая надежда», «Колебания сомнения» һ.б.

имажинист К.Нәҗми, футурист Г.Кутуй, Сириннәр янына «акмеист» Р.Аймәтне өстәргә ашыкмасам да, аның иҗатына хас милли ирекне, телне, матбугат үсешен чикләү, кысу тудырган чарасызлыктан ялгызлык, тынлык дәрьясына «чуму» кебек төшенчәләрнең акмеизм сәнгате аксессуарлары икәнлекне әйтми кала алмыйм.

Р.Аймәт төрле юнәлешләрдәге шигъри мәктәпләр белән «дустанә» яшәп, аларның ачыш-эзләнүләренә таянса да, аның остазы, таяныч ноктасы берәү – ул Тукай. «Казан утлары»нда (2016, №4) урын алган «Тукай карашы» шигыре беренче танышуда ук сурәтле фикерләү яңачалыгы, тыгыз, мәгънәле эчтәлеге белән күңелдә уелып калды. «Бозлы җилкәннәр» мәҗмугасындагы «Тукай карашы», «Ишетелә Тукай ютәле» шигырьләре Р.Аймәтне эзләнүчән, уйланучан һәм фикерле шагыйрь буларак танытала. Дөрес, XX гасыр башы татар шигъриятен дөнья сүз сәнгате югарылыгына күтәргән Тукайга багышламаларның исәбе-хисабы юк. Аның йолдыз атылган кебек кенә ялтырап алган кыска гомере, шәхесе, иҗаты турында яңа сүз әйтү мөмкин булмаган гамәл тоелса да, Р.Аймәт берәүне дә кабатламаган, үз сүзен әйтә алган дип саныйм. Шагыйрь «Тукай карашы»нда үз концепциясен, үз фәлсәфәсен тудыруга ирешкән. «Туры Тукай» исемен алган шагыйрьнең «Карашыннан яраланган дошман», алдакчы наширләр, Печән базары болагайлары аңардан куркып яшәгәннәр. Р.Аймәт Тукайның яшен кебек үткен карашын милләт азатлыгы өчен көрәшче символы дәрәҗәсенә күтәрә. Ул «караш» Тукай иҗатының төп юнәлешләрен аңлауда «ачкыч сүз» вазифасын да үти:

*Ул карашта... ил җанына сыенып,*
*Төннәр буе күзгә җилләр елый.*
*Ул карашта... зеңләп тартылган күк*
*Бер мөкатдәс моңлы сазның кылы.*
(«Тукай карашы»)

«Ишетелә Тукай ютәле»нә Тукайның С.Рәмиевкә язган хатыннан өзек, атаклы «Тотса мәскәүләр якаң» сүзләрен эпиграф-юллама итеп алып, эре сызыклар, төгәл гыйбарәләр белән бөек шагыйрь алдында «хисап» тотып *(«Син киткәннән бирле, бу татарым / Ничә тапкыр йоклап уянды»)*, халык кичергән коллык фаҗигасен күз алдына бастыра. Буйсыну, битарафлык, үз хокуклары өчен көрәшә белмәү милләтебезнең төп җитешсезлеге итеп күрсәтелә. Иң хәлиткеч мизгелләрдә беркемнең дә кар өстеннән яланаяк чыгып йөгермәвен (Тукай шундый вәгъдә бирә), «Тук елмаеп, бар да үз юрганын тартты үзенә», дип моң-зарын коя да, чаң сугып, кистереп, «моңсу шагыйрь» өчен шактый кыю нәтиҗәсен ясый.

*Татарыма ясин чыкмакчылар,*
*Газиз сөттән – телдән аерып,*
*Бу мәскәүләр якадан гынамы,*
*Бугазлардан алды каерып.*
(«Ишетелә Тукай ютәле»)

Дәрдемәнднең «сөт калыр» дигән тирән мәгънәле гыйбарәсен яңача, «сөт – туган тел» дип яңгыратып, «Рәсәй түмәрендә» «телем-телем»гә телгәләнеп, кара үлемен көтеп ятарга мәҗбүр Тукай телен яклап оран сала.

Күренә ки, шагыйрь айдагы Зөһрә кызга карап, моңсуланып, уфтанып, зарланып кына утырмый, публицистик, ялкынлы өслүбкә өстенлек биреп, усалланып та ала икән. Шуларның берсе – катлаулы символик эчтәлекле «Шарль Бодлерны уйлап» шигыре: *«Үлем бии кулларында / Кан төсендә ал гөлләр. / Күзләреннән мөлдерәп бага / Нурлы-гүзәл мизгелләр. / Кара тәмугтан бөркелә, / Җанны иркәләп аклык»* («Шарль Бодлерны уйлап»).

Шигырьнең каһарманы – фаҗига һәм оптимизм бердәмлеге – каршылыгы (үлеме – гүзәл мизгел, кара тәмуг – аклык) җимеше, төрле кичерешләр гаммасы эчендә югалып калган зат.

Р.Аймәт әдәби барыш мәсьәләләрен дә читләтеп үтә алмый. Монда да аның фикере анык, бәясе катгый: *«Шагыйрьләр үләләр, шагыйрьләр / Яралы шигырьгә капланып»* («Ритм»).

Шул ук шигырьләрендә ул ирекле шигырь алымнарын, «баскычларын» кулланса да, ак шигырьне кабул итмәвен әйтми кала алмый. Сәбәбе дә табыла: *«Дөньясы каралган чорларда / Ак шигырь үрчетер чакლармы?»* («Ритм»).

Икенче бер шигырендә ул «Ялгыз бүре кебек» уласа да, берәүне дә кабатламавын игътибар үзәгенә ала: *«Ятлар салган юлдан бармадым мин, / Юлсыз юлдан һәрчак атладым»* («Ятлар салган юлдан...»).

Мөстәкыйльлеген, үз шәхси өслүбен яклап чыгуын хуплаган хәлдә дә, укучы хозурына «Тукай карашы»ннан бер өзекне чыгарам: *«Шигырь утым сүнсә, ярты төндә / Тукай карашыннан ут аламын»* («Тукай карашы»).

Тукайдан алган ут шагыйрьне халык язмышы, киләчәге турында җитди уйлануларга корылган әсәрләр иҗат итү юлына чыгара. Мисалга, иң гади исемле «Тәрәзә» шигыренә күз салыйк.

Кояшка каратып уелган, елмаеп торган тәрәзәләр турында күп яздык. Р.Аймәт тәрәзәсе бөтенләй башка. Иң әүвәл ул яктылык күркенә тарихи-сәяси күзлектән бәя биреп, халкыбызның үткәнендәге бөеклеген *(«Сүрән карындыклар аша да бит / Еракларга карый алган халкым»)*, әмма «Европага тәрәз уя-уя...» милләт тәрәзәләргә тимер рәшәткәләр куелуын сизми дә калганын искәртә.

*Тәрәзәләр бар, ләкин ачылмыйлар,*
*Рәшәткәле безнең тәрәзәләр.*
("Тәрәзә")

Ошбу юлларны төрлечә карап була: каракლардан байлыкны саклау яисә башка максат белән куелганмы ул рәшәткәләр? Алдагы юлларда бу метафораның чын мәгънәсе ачыла: сүз үз илеңдә үз көеңә, җиреңә, үз байлыгыңа хуҗа була алмау, күп гасырларга сузылган халык фаҗигасе турында бара икән.

Олы бер катастрофаны – татар авылларының юкка чыгуын үзәккә алган, ачу һәм үпкә белән тулы, бәгырьгә агулы ук булып кадалган «Соңгы кан тамыры», «Йолдыз ташы», «Татар каены» шигырьләрен әйләнеп үтү һич мөмкин түгел. Авылларыбыз зур, көчле, дини, күп балалы булганда, патша хөкүмәте дә, совет империясе дә берни эшли алмады. Гаярь егетләребез, авылларны, үз хокукларын яклап, сәнәк, балталарга тотынырга чакыруга да күп сорамадылар. Авылларда татар мәктәпләре, медицина пунктлары юкка чыкса да, беркем бернишли алмый. Чөнки:

*Сүнеп бара авыл,*
*Тик каңгырып*
*Яр читендә калган ялгыз йорт.*
*Әйтерсең, ул өзелергә торган*
*Соңгы кан тамыры.*
*Сүрән ут*
*Тәрәзәдән бага, хуҗасының*
*Моңсу күзләредәй мөлдерәп.*
(«Соңгы кан тамыры»)

«Йолдыз ташы»нда җирдә мүкләнеп аунап яткан таш турындагы шигъри хикәят халык язмышы белән чагыштыру өчен табылган метафора-киная булып чыга: *«...И татарым! Син дә, шул таш кебек, / Ничә гасыр аунап ятасың?! / Алга юллар ябык булгангамы, / Син бармыйсың, һаман кайтасың* («Йолдыз ташы»).

Прокофьевның «Люблю берёзу русскую» эпиграфы илә башланып киткән «Татар каены» белән танышканчы, сүз каенның милләте юк дигән бәхәскә барып тоташыр дип уйлыйсың! Ә чынлыкта «Сулып барган туган телем кебек», сула, корый «татар каены» чагыштыруы халкыбызның авыр язмышы турында икән.

*Ә язмышлар?*
*Татар язмышлары?!*
*Бәхетсезлек кенә тоташтан.*

Һәм кинәт шундый нәтиҗә:

*Юк, аумассың, каеным, тамырларың*
*Халкым йөрәгенә тоташкан.*
(«Татар каены»)

Бу фаразның шартлылыгын аңлаган тәкъдирдә дә, үзе дә «тоташ бәхетсезлеккә тарган халыкның үз тамырлары да корып бара дигән сүз түгелме соң?

Шул рәвешле, шагыйрь медитатив лирика тарафдары – үз эчке хисләрендә казынган, үзен «чыбыркылаудан» тәм тапкан әсәрләрендә дә халык, туган тел язмышы хакында, ком барханнары астында калса да, күңелне җылытып торган тарихи бөеклегебез турында онытмый.

*Болгар, Казанымның мәгърур чоры,*
*Чулманымның якты җыры ул.*
(«Адашу»)

Р.Аймәт – метафора шагыйре. Ул шигырьләренең сәнгатьчә камил эшләнешенә ритм, вәзен, кафия кебек шәкли күренгән алымнарга кичереш гаммасын ачу бурычын йөкли, дигән идек... Кыска шигырьләрендә дә (фәлсәфи эчтәлекле «Күрешкәнгә кадәр», «Кырым дәфтәре»ннән шигъри цикллар иҗат итсә дә, лиро-эпик төрләрне әйләнеп уза) Р.Аймәт кешенең тарихи барыштагы урынын күзаллавында милли вазгыятьләргә килеп чыга.

Югарыда телгә алынган шигырьләрдән шундый нәтиҗә килеп туа: Р.Аймәт иҗатында үзара керешеп, берсен-берсе тулыландырып, хәтта үзара «бил алышып», ике мәгънәви катлам яши, үсә. Берсе – шагыйрьнең лирик зат артына «яшеренгән», үз шәхесен сурәтләгән, аның кичерешләрен, сагышларын, юксынуын, моңлануын, яшь, чибәр килеш үлемнән дә «курыкмавын» метафораларга, импрессионистик сынландыруларга «төреп» бирелгән гаҗәеп бай юнәлеше. Икенчесе – халык гаменә, тарихыбызга, телебезне яклауга, һәртөрле кысуларга нәфрәтен, ачуын, каһәрләвен ачыктан-ачык чагылдырган катлам («Татар каены», «Соңгы кан тамыры», «Туган телем», «Себер юлы», «Йолдыз ташы» һ.б.). «Бозлы җилкәннәр» мәҗмугасында ул ике – шәхси вә халык язмышы – юнәлешнең аерылгысызлыгына басым ясый.

*Дөнья базарында халкымның тик*
*Ялтырыйдыр алтын-көмешләре.*
*Ә мин йөрим милләт бакчасында*
*Татып аның ачы җимешләрен.*
(«Дөнья базарында»)

Тулаем алганда, Р.Аймәт шигырьләренә дөньяны, тормышны әхлакый-этик яктылыкта, эмоциональ хисләр аша кабул итү хас. Күңеленә сеңеп калган кичерешләре турында гына яза шагыйрь.

Аның өслүбе шигъри бизәкләргә, символик образларга бай булуы, вәзен, кафия, юлдагы иҗек саннары кебек шәкли алымнарны төгәл үти. Шуннан – шигърилек. Җырлап тору. Музыкальлек, шигырь техникасын яхшы белүе, ахыр чиктә, белемлелек – иҗатының асыл сыйфатлары.

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН**

# БЕРЕНЧЕ МӨФТИЛӘРНЕ БИРГӘН ТӨБӘК

## 1

Патша чоры Россиясе мөфтиләренең исемнәрен һәм алар кылган изге эшләрне хәзер сирәгрәк искә төшерәбез. Элегрәк аларны яманлабрак телгә алган чакларыбыз да булды. Яисә ул шәхесләрнең кем икәнлекләрен тәгаен белмәстән, хәзерге аерым төбәк, өлкә күләмендәге дин әһелләре белән тиңләү очраклары да күренгәләп тора. Күптән түгелрәк кенә әле бер яшь галимәбез, республика күләмендә таратылган газетабыз битләрендә, Россиядә мөселманнар мөфтияте оешуның 225 еллыгын искә алып, патша фәрманы белән расланган мөфти Мөхәммәтҗан Хөсәеневне «Татарстанның беренче мөфтие», дип язып чыккан иде. Әйе, патшалар хакимлек иткән заманда Россиянең үзәк өлешендә һәм Себер тарафында яшәүче барлык мөселманнарның беренче мөфтие булган шәйхелислам Мөхәммәтҗан Хөсәен улы әл-Җәбәли әл-Борындыкыйны «Татарстанның беренче мөфтие», дип язу зур хата. Кулларына богау салып, күкрәк өсләренә хач-тәре тагып, әби-бабаларыбызны чиксез җәберләп, диннәреннән яздырырга тырышып, мәчет-мәдрәсәләрне туздгытып йөргән Аксак Каратун, Гермогеннардан соң динебез сагына куелган иң беренче дин башлыкларын – беренче мөфтиләребезне онытырга ярыймы соң безгә?! Юк, әлбәттә. Без алар исемен Россиядә мөфтият оешуга фәлән ел тулган көннәрдә генә түгел, даими рәвештә искә төшергәләп торырга тиешбез!

Шул ук вакытта ул мөфтиләр җитәкләгән, императрица Екатерина Икенче рөхсәте белән оештырылган «Мөхәммәд дине җәмгыяте идарәсе»нең (русча: Оренбургское магометанское духовное собрание) барлыкка китерелү сәбәбен һәм вакытын да төгәлрәк итеп ачыкларга вакыт җиткәндер. Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре бу вакыйганы «1192 (1778) елның 22 сентябрендә Оренбург каласында бер мөфти һәм өч казыйдан торган «Мөхәммәт дине җәмгыяте идарәсе ачылган», дип хәбәр итә. Моннан йөз илле еллар элгәрерәк шушы оешма эшчәнлеге белән турыдан-туры бәйләнештә булган Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали...» китабында бу оешманың барлыкка китерелү сәбәпләрен түбәндәгечәрәк аңлата. «Бу идарәнең ачылуы, Коръән басылуга рөхсәт бирелү һәм мөселманнарны башкаларның җәберләвеннән тыю – Кече Кайнарҗа килешүе шартларының берседер», ди. «Госманлы дәүләте», ягъни Төркия белән Россия арасында 1768-1774 елларда барган сугыштан соң Дунай елгасы буендагы шушы торак мәйданында әлеге солых килешүе төзелгән. Һәм ерактагы дин кардәшләребез шул солых килешүенә әлеге теләкләрнең теркәлүен таләп иткән булганнар икән. Ә без яшәгән дәвер китапларында исә бу идарәнең барлыкка китерелү фактын фәкать «Пугачёв бунты» вакыйгаларына гына бәйләп аңлаталар иде. Дөрес, бу вакыйга да патша хөкүмәтенең әлеге карарны чыгаруына йогынты ясамый калмагандыр. Емельян Пугачёв җитәкләгән бу хәрәкәттә ирек даулап байтак кына мөселман өммәте вәкилләре – татар һәм башкортлар да бик актив катнашкан ич. Әмма шул ук вакытта Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре китергән фактларны да исәпкә алырга вакыттыр, мөгаен.

Алда искә алынган ике ил арасындагы әлеге килешүдән соң бу оешманың барлыкка китерелүен күренекле тарихчы галим Надир Дәүләт тә «Россия төркиләренең милли көрәш тарихы» китабында билгеләп үтә (Казан, 1998).

Шул ук хезмәтендә Шиһабетдин хәзрәт байтак документларда «Оренбург мөселман дине җәмгыяте идарәсе» дип теркәлгән оешманың барлыкка китерелү

вакытын да 1778 (мөселманча 1192) ел дип күрсәтә. Бу идарәнең турыдан-туры башкаладагы Эчке эшләр министрлыгына буйсынган булуын да әйтә. Безнең дәвердә нәшер ителгән хезмәтләрдә исә бу сан 1788 ел рәвешендә теркәлгән иде. Бу очракта кем хаклы? Шул оешма яшәгән заманда гомер иткән һәм шул дини идарәнең бер төбәк вәкиле булган Ш.Мәрҗаниме, әллә Совет хакимияте чоры белгечләреме? Бервакыт мин шундый сорауны хәзерге үзәк мөфтият оешмасында – Уфада хезмәт иткән, аның архив документлары белән берникадәр таныш булган чордашым Равил Үтәбай-Кәримигә дә биргән идем. Ул елларда Равил дустыбыз Уфадан Казанга бик еш сәфәр кыла иде. Татарстан китап нәшриятында аның бер-ике хезмәте дә басылып чыкты. Минем соравыма ул тулы мәгълүмат бирә алмады. «Уфадагы мөфтият архивында бу оешманың оешу чорына караган документлар сакланмаган бугай. Дөреслекне ачыклау өчен Петербург архивларына мөрәҗәгать итәргә кирәктер»,– дип җавап бирде ул.

Мөфтиятнең 1778 елда оешу датасы Ш.Мәрҗанинең беренче мөфти биографиясенә багышлы җөмләсендә дә раслана. «Тәрҗемәи хәле сөйләнә торган зат (Мөхәммәтҗан хәзрәт), озын гомер сөреп, якынча илле ел мөфти булып, 1239 елда вафат булды», дип яза ул (214 б.). 1239 дан 1192 не алсаң – 47 ел килеп чыга. Ягъни, нәсел башы хәзерге Татарстанның Тау ягы (әл-Җәбәли) Борындык авылыннан булган Мөхәммәтҗан Хөсәенев, кырык җиде ел мөфти вазифасын башкарганнан соң, хәзерге исәп белән 1823 елның декабрь – 1824нең гыйнвар аралыгында бакый дөньяга күчкән. Шиһабетдин хәзрәтнең атасы 1801 елда Оренбургка барып, шул мөфти кулыннан «указлы мулла» таныклыгын алып кайтучыларның берсе булган. «Мәрхүм атабыз мелла Баһаветдин, мелла Фәтхулла ахун Орывый, мелла Байморад әл-Мәңгәри һәм башкалар һәммәсе аның (Мөхәммәтҗан мөфтинең) фазыл[1] һәм камил булуын, зур белемгә ия икәнлеген бердәм рәвештә таныйлар. Халык телендә дә ул галим буларак танылган. Ул гасырларда «Бохарадан укып кайттым», дигән мулланы һәр кешедән өстен зат дип хисаплаганнар», дип язган Ш.Мәрҗани (213 б.).

Архив документлары белән эш итәргә яраткан, Эстәрлетамак өязе ахуны нәселеннән булган эзләнүчән шәхес Исмәгыйль Рәмиев тә бу оешманың барлыкка килү вакыты дип 1778 елны күрсәтә[2]. Ә башкалар аны ун елга кичектереп, «бу дини идарә 1788 елда оештырылган», дип язалар. Шул сан безнең энциклопедиянең 6нчы томында да теркәлгән. Ун ел яшәгәннән соң, ул идарә 1788 елда фәкать Оренбургтан Уфа шәһәренә генә күчерелә. Әмма аның Оренбургка бәйле исем-атамасы элеккечә саклана. XX йөз башында Уфа шәһәрендә мөфтият тарафыннан чыгарылган журнал исемендә дә «Оренбург» сүзе бар. Ул мәҗмуга болай дип аталган: «Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыяи Ырынбургия». 1788 елда мөфтиятнең Уфага күчерелүен, яңа губернатор килгәч, губерна башкаласының берникадәр вакытка шунда урнаштырылуы белән бәйләргә кирәктер, мөгаен.

## 2

Мөселманнар эшчәнлегенә бәйле бу оешма нишләп әле Россиянең ул вакыттагы көнчыгыш ил чиге буенда урнашкан Оренбург шәһәрендә оештырылган икән соң? Алда атап кителгән Пугачёв бунтының да шул төбәктә барганлыгын беләбез ич. Әллә чынлап та бу оешманың барлыкка килүенең ул вакыйгага турыдан-туры бәйләнеше бармы? Шиһабетдин хәзрәт тә әлеге китабында «Бу оешма нишләп Казанда оештырылмаган?» дигәнрәк сорау куя. Дөрес, ул Пугачёв хәрәкәтен искә алмый. Бу мәсьәләгә карата андый сорауны хәзрәт әлеге оешманың, ун ел яшәгәннән соң, Оренбургтан Уфа шәһәренә күчерелү уңае белән теркәп куйган. Ни өчен әле ул оешма «караңгы бер почмак булган», «ул мәхкәмәне урнаштырырдай бинасыз... Уфага күчерелгән? Казан шәһәренең бу оешма өчен иң кулай урын булуы һәркем өчен ачык ич», дип язган.

Бу мәсьәләгә карата җавапны, әлбәттә инде, Россия империясенең ул чордагы сәяси таләпләренә нигезләп кенә биреп буладыр. Урта Азия хан-солтанлыкларының

[1] Фазыл – намуслы, кешелекле.
[2] Рәми И., Даутов Р. Әдәби сүзлек. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2001. – 173 б.

чик буенда урнашкан Орск, Оренбург шәһәрләренең барлыкка килүе дә Россия империясе сәясәтенә бәйле фактларның берседер. XIX гасырның урталарына чаклы хәзерге Урал, элекке Җаек елгасының көнчыгыш өлеше рус әдәбиятында «Бохара ягы» яки «Төркестан ягы» дип аталып йөртелгән. Елганың аргы ягыннан ук Казакъ ханлыклары биләмәләре башланган була. (Рус әдәбиятында ул чорда аларны «Кыргыз-кайсак ханлыклары» дип йөрткәннәр. Бүгенге кыргызлар исә ул дәвер Россия тарихында еш кына «кара кыргыз»лар буларак теркәлгән.) Арал диңгезенең көньяк тарафларында исә Хива, Бохара ханлыклары яшәп килгән. Бохара ханлыгы чигеннән «Кабул патшалыгы» – хәзерге Әфганстан җирләре башланып киткән. Кабулдан соң инде ул заманда «мәңгелек җәннәт дөньясы» кебегрәк күзалланган Һиндстанга да ерак калмый... Бүген тасвирланган вакыйгаларга бәйле Россия империясе сәясәтенең төп максаты – әнә шул «чит-ят бай, иркен илләр» биләмәсенә якынаерга омтылудан гыйбарәт була. Бу гамәлләр чик буе артындагы төрки дәүләтләр башлыкларына һәм халкына уңай йогынты ясарга тырышу максатыннан чыгып эшләнгән. Шул максатка ирешү өчен, Оренбург губернасы карамагында махсус бер оешма – Чит ил комиссиясе дә барлыкка килерелә. Россиянең башка губерна идарәләрендә андый комиссияләр булмый. Монда исә ул комиссияне җитәкләү бурычы да губернаторның үзенә йөкләнә.

Яңа күрше мәмләкәтләргә үтеп керү, әүвәл алар белән дустанә мөнәсәбәтләр урнаштыру хыялын гамәлгә ашыру чараларына Пётр патша заманнарында ук керешергә ниятлиләр. Ул кинәт вафат булгач та, бу хыялдан ваз кичмиләр. Империя тәхетенә бер-бер артлы аның варислары – өч хатын-кыз утыра. Көнчыгыш илләргә бәйле сәясәткә аеруча игътибар итүләр аның кыз туганы Анна Ивановна белән үз кызы Елизавета идарә иткән чорларга туры килә. Анна патшабикә идарә иткән елларда әлеге ханлыклар белән чиктәш Урал елгасы ярларында Орск (1735), аннары Оренбург (1743) калалары торгызыла башлый. 1741 елда тәхеткә Елизавета утыргач та, яңа губернаның җитәкчесе итеп төрки илләр тормышын яхшы белгән И.И.Неплюев билгеләнә. Биредә ул унҗиде ел чамасы «хуҗа» булып утыра. Моңа чаклы ул унбиш ел Төркиядә илче вазифасын башкарган була. Кайбер язмаларга караганда, ул төркичә сөйләм телен аңлаган, шул телдә аралаша алган.

Күрше ханлыклар белән үзара мөнәсәбәтләрне җайга салу өчен, бу губернатор яңа шәһәрләр тирәсенә татар сәүдәгәрләрен җәлеп итү кирәклеген дәлилли. Чөнки күрше ханлыкларга мөселман өммәтеннән булмаган кешеләрнең кертелмәвен белә. Патшабикә Елизавета аның тәкъдимен хуплый һәм 1744 елда ике йөз сәүдәгәр гаиләсен Оренбург тирәсенә күчерү карарын имзалый. Ә бер ел үтмәстән, Оренбург янәшәсендәге хәзерге Каргалы авылын нигезләү карарына кул куя. Һәм аны, бу тирәләргә Неплюев белән бер вакыттарак күченеп килгән сәүдәгәр Сәгыйд Ает улы Хәялин исеменә тәңгәлләп, «Сәет бистәсе» дип атыйлар. Сәгыйдне исә монда зур хокукларга ия булган староста итеп куялар. Бер үк вакытта Оренбургның көньяк өлешендә – Урал елгасының аргы ягында «Бохара тарафыннан» килгән сәүдәгәрләр өчен «Меновый двор» дигән бистә дә барлыкка килерелә. Хәзер дә әле ул бистә Оренбургтан соң беренче тимер юл станциясе буларак яшәвен дәвам итә.

Шул ук патшабикәләр идарә иткән чорда үзәк өлештәге губерналардагы мөселман авылларында мәчетләр җимерелгән, яндырылган. Сенатның 1742 елның 17 ноябрендә кабул ителгән фәрманына гына күз төшерик. Анда Казан, Сембер, Әстерхан һәм Воронеж губерналарындагы авыллардагы мәчетләрнең юк ителергә тиешлеге ачык әйтелә. Һәм бер үк вакытта, Елизавета Петровнаның махсус әмере белән, яңа оешкан бу ике бистәдә мәчетләр ачыла. Патшабикә рөхсәте белән төзелгән ул мәчетләр 1749 елдан ук эшли дә башлаган. Дөрес, Меновый дворда төзелгән мәчет татар авылларындагылардан беркадәр аерылыбрак торган. Ул кечкенә манаралы зур тирмәне хәтерләткән. Димәк, Төркестан якларындагы мәчетләргә охшатыбрак эшләнгән була.

Төбәк тарихчысы С.Попов бәян итүенчә, 1749 елда ук Сәет бистәсендә йөз сиксәнләп татар гаиләсе яшәгән. Елизавета идарә иткән елларда ук Казан белән Оренбургны тоташтырган «Яңа Мәскәү юлын» тәртиптә тоту, ямчылык эшчәнлеген

башлап җибәрү өчен егерме мең чамасы татар, ун меңләп чуваш һ.б. милләтләрнең күчерелгән булуы да 1996 елда Оренбург каласында нәшер ителгән «История Оренбуржья» китабында теркәлгән. Хәзер дә Бөгелмә белән Оренбургны тоташтырган зур юл буйлап татар авыллары тезелешеп утыра.

Сәет бистәсенә күчерелгән сәүдәгәрләрнең һәм һөнәрчеләрнең күпчелеге Сәгыйд Хәялин туган төбәктән – Казан губернасының Мамадыш, Малмыж, Арча өязләреннән килгән. Сәгыйднең һәм аның бертуганының гаиләсе хәзерге Байлар Сабасыннан, Оренбург төбәгендә күпсанлы мәктәп-мәдрәсәләр ачкан һәм тоткан бертуган Хөсәенев байларның бабалары хәзерге Теләче районына кергән Югары Кибәхуҗадан була. Сәет бистәсенең беренче мулласы һәм беренче мәдрәсә ачучысы да – Арча төбәгеннән чыккан мәгълүм дин әһеле. Әйе, монда 1746 елда Ташкичү авылыннан күчеп килгән беренче мулла Габдессәлам Уразмөхәммәд имам улы була. Туган җире – Ташкичү янәшәсендәге Мәңгәр авылы, диелә. Ул Габдессәлам Урай буларак «Татар шигърияте антологиясе»нә дә кергән. Ә Ташкичү мәдрәсәсендә ирек даулаучы Батырша мулланы укыткан бик абруйлы шәхес. Аның оныгын, шагыйрь Әбелмәних Каргалыйны да әдәбият сөючеләр яхшы хәтерлиләр.

1747 елга караган теркәү кенәгәсендә[3] Мәңгәрдән чыккан «мулла Абдусалям Уразаевның» 28нче йортта төпләнгәнлеге күрсәтелә. Каргалының бер тирәсендәрәк яшәгән тагын алты гаиләнең дә шул ук Казан өязе Арча даругасының Үтәгән Шадыйров сотникка буйсынган авыллардан булганлыгы әйтелә. Бу исемлектән без Сәгыйд Хәялин гаиләсенең 3нче йортны биләгәнлеген, ике хатыннан аның биш улы булганлыгын да укып беләбез. Улларының исемнәре дә аталган. Аның авыл читендәге табигый тау ташыннан төзелгән йорт утары бүген дә сакланган – хәзер ул бистәнең нәкъ урта бер өлешендә урнашкан. Бу йортның иркен ишегалдында хәзер нәсел очы вәкиле, документаль кинолар режиссёры Рафаэль Хәялин үз өендә яшәп ята. Хәялиннәр тирәсендәге башка сәүдәгәр йортларының да күпчелеге шундый ук табигый таштан салынган булган. Бүгенге Каргалы урамнарында элекке сәүдәгәрләрдән калган, таштан яки затлы кызыл кирпечтән төзелгән өй һәм кибет-келәтләрне еш очратырга була.

Сәет бистәсенә нәүбәттәге муллалар булып килгән ике Вәлид хәзрәтне дә искә төшереп үтү кирәктер. Каргалы тарихында эз калдырган кешеләр буларак, алар икесе дә – Шиһабетдин хәзрәтнең алда күрсәтеп үтелгән китабына кергән шәхесләр. Ләкин алар монда беренче булып күчкән, 1747 елга караган йөз кырык өч гаилә исемлегендә әле теркәлмәгәннәр. Бу Вәлидләрнең берсе – Каргалыда икенче мәхәллә мәчетен ачучы һәм аның карамагындагы мәдрәсәне оештыручы кеше. Минем уйлавымча, әлеге вазифаны «Вәлид бине Сәгыйд әл-Каргалый» башкаргандыр. Элек «Бөгелмә өязенең Минзәлә башы авылында имам вә мөдәррис булган», дип яза аның хакында Ш.Мәрҗани. Сәет бистәсенә кагылышлы башка язмаларда бу мулланың элекке Бөгелмә өязе Тимәш авылында туганлыгы да теркәлгән. Ягъни ул хәзерге Лениногорск районына кергән Тимәш морзалар авылында туган. Шул ук елларда Оренбург шәһәрен төзүдә татар генералы Котлыгмөхәммәд Тәфкилевнең актив катнашканлыгы да билгеле. Ә аның кияве шул Тимәш морзалар нәселеннән була. Генералның хатыны Хәдичәнең һәм аларның «Тимашев атаманда» кияүдә булган кызларының каберләре бүген дә Каргалы авылы зиратының уртасында саклана. Хәтер ташы язуында Хәдичә бикәнең – 1751 елда, кызларының 1800дә бакыйлыкка күчкәнлеге теркәлгән. Тимашев фамилияле берәүнең 1773 елга караган документларда күренеп китүен дә әйтеп үтик. Пугачёв явы Оренбургны камаганда, губернатор А.И.Рейнсдроп уздырган зур киңәшмәләрдә катнашкан унлап түрә исемлегендә И.Л.Тимашев фамилиясе дә очрый. Коллежский советник дәрәҗәсендәге ул кеше шәһәрне саклау өчен Сәет бистәсеннән килгән төркем җитәкчесе буларак искә алына.

Димәк, Вәлид мулланың Каргалыга күченеп килү вакыйгасы шушы кешеләргә бәйле булырга да мөмкин. Вәлид әл-Каргалыйның монда беренче ахун дәрәҗәсенә ирешкәнлеге Ш.Мәрҗани хезмәтендә теркәлгән. Ул аны «бик укымышлы кеше булган.

[3] Переписная книга Оренбурга и уезда за 1747 г.

1802 елда фарсыча язган хаты саклана, фарсы телен ул камил белгән... Үзенең язган әйберләре дә булган», дип искә ала.

Шул ук елларда Сәет бистәсенә Тәтеш өязендәге Кайбыч авылында туган Вәлид Әмин улы әл-Кайбычи да килә. Анысын халык телендә «Вәлид ишан» дип йөрткәннәр. Ш.Мәрҗани аны: «Берничә мәртәбә Бохара белән Кабулга сәфәр кылган. Озак вакытлар Кабулда Фәезхан ишан тәрбиясендә булган», дип искә ала. Вәлид ишан моннан «1801 елда хаҗ сәфәренә дип чыгып китә» һәм, бер фетнә вакыйгасына юлыгып, 1802 елда шунда вафат була.

Ш.Мәрҗанинең бу хезмәтендә Идел белән Җаек елгалары аралагында милләттәшләребез яшәгән төбәкне еш кына «Болгар иле» дип тасвирлавын да билгеләп үтәргә кирәктер. «Болгар иленнән хаҗга дип чыгып киткән... Болгар иленнән Бохарага юл тоткан» рәвешендәге җөмләләр ул китапта еш очрый.

* * *

1754 елда шул ук Бөгелмә өязендәге Утыз Имән авылында туган күренекле шагыйрь Габдеррәхим Утыз Имәнине дә язмыш Каргалы бистәсенә алып килгән. Монда аның Вәлид мулла мәдрәсәсен тәмамлавы һәм берничә ел шунда укытырга калганлыгы бәян ителә. Ләкин аның кайсы Вәлид мәдрәсәсен тәмамлавын ачыклый төшү кирәктер, мөгаен. «Татар әдәбияты тарихы» китабына (I том, 1984 ел), әдәбият галиме Әнвәр Шәрипов мәкаләсенә күз салыйк. «Габдеррәхим башта үз авылында укырга-язарга өйрәнә, берничә ел күрше авылларга барып укый. Аннан Оренбург Каргалысына китә. Андагы икенче мәчет каршындагы мәдрәсәдә Вәлид бине Мөхәммәд әл-Әминнән белем ала. 1788 елда үзенең гаиләсен, балаларын алып», шушы авылда тупланган кәрван белән «Бохара тарафына чыгып китә». Беренче карашка монда яңа бистәдәге тагын бер Вәлид калкып чыга шикелле. Әйе, кайсыдыр Әмин төбәгеннән булган Мөхәммәд улымы ул? Әллә соң Мөхәммәдәмин исемле мулла баласымы?

Татар әдәбияты гыйлемендә бу ике Каргалы Вәлиденең берсен шагыйрь буларак та таныйлар. Әмма аларның кайсысын Утыз Имәнинең остазы итеп атарга соң? Шагыйрьнең якташын, әтисе белән бер авылдан – Тимәштән булганынмы? Әллә Кайбычтан чыкканынмы? Әдәбият фәнендә әлегә Вәлид ишанга өстенлек бирелә шикелле. Әмма бу очракта шагыйрь белән Вәлид ахунның бер тирәдән, бер авылдан ук булулары искә алынмый. Габдеррәхим бит Тимәш авылы баласы диярлек, атасы бик иртә вафат булгач кына, ул күрше Утыз Имән авылы кешесенә әверелә.

Шушы ук елларда тагын бер атаклы шәхеснең – Салават Юлаевның да Сәет бистәсе мәдрәсәләренең берсендә укыганлыгы, шул дәвердә шигырьләр иҗат иткәнлеге Уфада чыккан биографик хезмәтләрдә теркәлгән иде. Ул хезмәтләр белән күптән танышканлыктан, «Пугачёв бунты» батырының Каргалының кайсы мәдрәсәсендә укыганлыгын хәзер инде хәтерләмим.

Сәет бистәсе оешып килгән елларда мондагы мәдрәсәләрнең берсендә булачак мөфти Мөхәммәтҗан да укып йөргән. Аның остазы мулла, бу төбәкнең икенче ахуны Мөхәммәд Гали улы әд-Дагыстани булган, дип яза Ш.Мәрҗани. 1760 еллар ахырларында булса кирәк, Мөхәммәтҗан да, укуын дәвам иттерү өчен, моннан Бохарага чыгып киткән. Аның бабасы да шунда укып кайткан була. «Бабасы Мансур, әүвәлдә Мортаза әфәнде шәкертләреннән булып, соңыннан Бохарага сәфәр кыла. Ул – Идел буеннан барып Бохарада укыганнарның беренчесе. Фарсы телендәге «Тәракыйбе мансурия» китабы аңа нисбәтләнә», дип яза Ш.Мәрҗани. «Камил белемле» бу Мансур мулланың кайдан булуын, Бохарага киткәнче кай тирәдә укыганлыгын да ачыклыйк. Шул ук китапның 234-235 битләрендә бу сорауга төгәл җавап бирелә. «Ман-сур мелла Зөя өязе Борындык[4] авылында туган». Мәдрәсәдәге остазы – «Мортаза бине Котлыгыш әс-Симети хаҗи. Ахырында ул Мамадыш өязенең Симет авылында, 1723 еллар тирәсендә вафат булган». Шиһабетдин хәзрәт сүзләренә караганда, укымышлы Мансур мулла Бохарадан

[4] Зөя елгасы янәшәсендәге авыл хәзер Кайбыч районы биләмәсенә керә. «Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм», диелгән энциклопедиядә.

кайткач, алар үзара килешә алмаган. Мансур, «үзен остазыннан өстен күреп, Мортаза әфәнденең һәр эшенә һәм гамәленә каршы төшә башлаган». Шуннан соңдыр инде, Мортаза мулла үз Симетенә кайтып китә. «Хафиз буларак танылган Мансур мулла исә үз төбәгендә... күп шәкертләр җыеп, зур мәдрәсә тотып дәрес әйткән».

Мөхәммәтҗанның Каргалыга кайчан һәм кайдан килгәнлеге әлегә ачыкланмаган. Атасы «Хөсәен бине Мансур»ның кайда һәм ниләр эшләгәнлеге дә мәгълүм түгел. Каргалыга Мөхәммәтҗан үзе генә килгән булгандырмы, яисә аның атасы да Казан төбәгеннән күченгән сәүдәгәрләр төркеменә кергәндерме – Ш.Мәрҗани китабында андый мәгълүмат юк.

Кайберәүләр мөфтинең атасының берара Эстәрлебаш авылы мәдрәсәсендә укыткан булуы турында да язалар. Әмма Хөсәен бине Мансур әл-Җәбәли әл-Борындыкыйның исемен мин шул мәдрәсәне тоткан Тукаевларның соңгы вәкиле Шакир мулла 1899 елда нәшер иткән «Тарихи Эстәрлебаш» китабында очратмадым. Дөрес, кайчандыр ул авыл мәдрәсәсен нигезләгән бер Хөсәен телгә алына анда. Ул китапта шул кеше беренче мөфти атасы дип тә танытылган. Әмма ул Хөсәеннең атасы Габдерахман исемле булган. Мөфти бабасының исеме Мансур бит. Мөхәммәтшакир мулланың әлеге китабында башка төр төгәлсезлекләр дә очрый. Әйтик, Каргалы (Сәет бистәсе) авылының рәсми рәвештә нигезләнү вакыты тарихта 1744 елга нисбәтләнә. Бу китапта Эстәрлебашка нигез салыну тарихы болай тасвирлана: «Әүвәл заманнарда ошбу йергә Казан әтрафыннан вә Каргалы шәһәрендән бәгъзы кешеләр килеб, сәүдә вә кәсебләр илә шөгыльләнмәк өчен ошбу Эстәрлебаш урынында утар ясаб утырганнар... Йосыф купес дигән кемсәнең Каргалыдан килеп сәүдә кылганына варисларында язма кәгазь булган», дип яза да автор, үз авылының нигезләнү елы дип «1680 еллар чамасы»н терки. Сәет бистәсен башка авторлар да, шул исәптән Ризаэддин Фәхреддин дә, яшәүчеләре күп булганлыктан, «саф мөселман шәһәре», дип язганнар. Алдарак искә алынган китабында Исмәгыйль Рәмиев тә Эстәрлебаш мәдрәсәсенә багышлы аерым мәкалә урнаштырган. Бу авыл мәдрәсәсен ул, Шакир мулла китабына нигезләнеп булса кирәк, 1720 елларда ачылган, дип яза. Әмма «XX йөз башында элекке шәүкәтен югалта», ди.

Эстәрле төбәгеннән чыккан бүгенге заман кешесе, әлеге китапка нигезләнептерме, «Эстәрлебашта 40 мәдрәсә булган», дип тә күрсәтә. Шакир мулла Тукаев хәбәр итүенчә, 1897 елда ул авылда ике мең бер йөз кеше яшәгән. Икенче бер чыганакта исә анда кайчандыр өч мәчет булуы теркәлгән. Патша заманындагы тәртип буенча, мәктәп-мәдрәсәләр ачу фәкать мәчет белән чиркәүләр карамагында гына рөхсәт ителгән була. Мәсәлән, Ризаэддин Фәхреддиннең «Әхмәд бай» китабында, XX гасыр башында унөч мең кешесе, ун мәчете булган Каргалыда, шул мәчетләр карамагындагы хатын-кыз мәктәпләрен дә исәпкә алганда, мәктәп-мәдрәсәләр саны күпкә азрак күрсәтелә.

## 3

«Мөхәммәд дине җәмгыяте идарәсе»нең ни өчен Оренбург каласында оештырылуын ачыклый башлаган идек. Бу вакыйганың империя сәясәтенә бәйле икәнлегенә ишарәләр дә ясалды. «Мөхәммәд дине җәмгыяте...» туганчы ук, бу калада Россиянең бик үзенчәлекле «Чик буе комиссиясе» дип аталган оешмасы барлыкка килүен дә билгеләп үттек. Монда бу комиссиянең эшчәнлеге (кайбер язмаларда ул «коллегия», «миссия» буларак та теркәлгән) башкаладагы Чит илләр белән эш итүче министрлык (яисә, ул чордагычарак әйтсәк – департамент) вазифасын кабатлауга тиң була. Шушы чик буе комиссиясе кешеләре Төркестан ягы ил-мәмләкәтләренә илчеләр озату белән дә, шул тарафтан килүче илчеләр төркемен каршы алып, аларны Петербургка алып бару эшләрен дә башкарганнар. Бу комиссия штатында тылмач вазифасын үтәүче, ара-тирә чит мәмләкәтләргә илче сыйфатында баргалап та кайтучы милләттәшләребезнең ишле генә булуы да мәгълүм. Көнчыгыш тарафка озатылучы сәүдә кәрваннары да шушы комиссия кешеләре белән эш йөрткән. Алар монда хәзерге таможня оешмасы башкарган эшләрне дә башкарганнар.

Димәк, «Мөхәммәд дине җәмгыяте идарәсе»нең шушында оештырылуының төп сәбәбе дә, әлбәттә инде, Россия мәмләкәтенең көнчыгыш тарафта урнашкан төрки илләргә «айдай балкыган милли йөз» күрсәтергә тырышуыннан булгандыр. Бу сәясәтнең күзгә күренердәй беренче эше – ил чигенең аргы ягында урнашкан Кече Җөз[5] казакъ ханлыгы белән «дуслык килешүе» төзү чарасыннан башланып китә. Ә ул килешү Әбелхәер ханның Россия дәүләтенә ярдәм сорап мөрәҗәгать итү тарихыннан соң төзелгән, дип яза тарихчылар. Милләттәшебез Котлыгмөхәммәд Тәфкилев, 1731 елда казакъ илендә берничә ай яшәгәннән соң, бу эшне бик уңышлы башкарып чыга. Кайберәүләр әлеге вазифаны үтәгәндә, аның уңышка ирешүенең бер сәбәбе итеп казакъ дәүләте башлыгы Әбелхәер хан белән бер нәселдән чыгуларын да искә алалар. Аларның икесенең дә алтынчы буын бабалары бер кеше – Алтын Урда дәүләтенең дәвамчысы саналган Зур Урда ханы Шигай булган икән. Зур Урда таркалгач, Тәфкилевләр буыны Касыйм ханлыгында бүленеп калган. Һәрхәлдә, казакъ кардәшләрдән кайберәүләр шулай дип уйлый һәм яза. Ш.Мәрҗани китабында да Тәфкилев морзаларның бер бабасы буларак шул хан күрсәтелгән.

Шушы килешү нигезендә, иң элек безнең сәүдәгәрләргә бу илдә иркен сәүдә итү хокукы бирелә. Соңрак аларга, Урта Җөз ханлыгы биләмәләрен дә кичеп, Ташкент, Бохара, Үргәнеч (Гүргәнеч буларак та билгеле) тарафларына үтеп керү мөмкинлекләре дә тудырыла. Рәсми рәвештә теркәлгән хәбәргә караганда, зур бер тәүге сәүдә кәрваны 1741 елда Орск каласыннан[6] Ташкент тарафына юл алган. Һәм бу сәфәрдә ул кәрван ияләре зур уңышка ирешкәннәр. Бер пот чамасы көмеш тә сатып алганнар. Соңрак та кайбер кәрванчылар, үз әйберләрен зур бәягә сатып, ул яклардан бик арзанга көмеш тә алып кайткалаган. Урта Азия илләренә йөргән кәрваннардагы йөкнең бер өлеше рус сәүдәгәрләренеке дә булган. Каргалы кешеләренә, шулай итеп, арадаш сәүдәгәр вазифасын да үтәргә туры килгән. Байтак еллар дәвамында Каргалы кешеләре белән үзара килешеп эшләүче сәүдәгәрләр исемлегендә Мәскәүдән рус кешесе Г.Журавлёв, грек И.Мавродин, әрмәннәр динен тотучы В.Макаров, Ростовтан А.Кекиннар булуы теркәлгән[7].

Беренче уңышлардан соң инде татар сәүдәгәрләре Бохара, Хива ханлыклары җирләрен дә үзләштерә башлыйлар. Бохара белән Үргәнеч калаларына Орскидан да, Сәет бистәсеннән дә берничә кәрван озатыла. Ә 1751 елда Сәет бистәсендә тупланган бер кәрванга Һиндстанга барып кайту бурычы да йөкләнә. Ул кәрванның җитәкчесе, шул авыл сәүдәгәре Исмәгыйль Бикмөхәммәтов белән бергә аның сәфәрдәшләре Надир, Якуб, Габдерахман исемле кешеләр дә юлга чыккан. Әлбәттә инде, аларның һәрберсенең үз ялчы-хезмәткәрләре дә булган. Әйтик, Надир Сәфәровның мал куучысының Бохарадан кузгалуга ук һәлак булуы турындагы хәбәр тиздән авылга да кайтып җитә.

Бу чорда Һиндстанда Аксак Тимернең оныгы, төрки солтан Бабур нәселе вәкилләре идарә иткән. Бабур һәм аның оныгы Әкбар, бу илдәге аерым бәк-солтанлыкларны җиңеп, «Бөек Моголлар империясе» дип аталачак дәүләтне оештыралар. Аларның династиясе әлеге империя белән 1520 еллардан алып 1858 елгача идарә итә. Бу төркиләр идарә иткән дәвердә илнең башкаласы Дәһлидән көньяктарак булган Агра шәһәрендә урнаша. Шул шәһәр янәшәсендәге атаклы Таҗ Махал мавзолей-төрбәсен төзүчеләр дә алар. Җиһан шаһ, сөекле хатыны Мөмтаз Махал вафат булганнан соң, сөеклесенә аталган таҗ буларак төзетә ул мавзолейны. Төзелеш эшләрен башкарыр өчен дә күпсанлы осталарны алар Урта Азия төбәкләреннән китертә торган булган.

Сәет бистәсеннән чыккан кәрванның Дәһли шәһәренә барып җиткәнлеге мәгълүм. Әмма бару һәм кайту юлында югалтулар да күп була. Шул сәфәрдә исән калган кәрван башы Исмәгыйль туган иленә фәкать утыз елдан артык вакыт үткәч кенә әйләнеп кайту бәхетенә ирешкән. Аның илгә кайткач язган истәлек язмасы әүвәл «Ике хаҗиның рихләтнамәләре» дигән исем-атама белән 1862 елда Казанда аерым

[5] Ул дәвердә казакълар өч ханлыкка – Кече, Урта, Олы җөзгә бүленә.

[6] Җаек елгасына казакълар ягыннан килеп кушылган Ор елгасы тамагындагы шәһәр. 1735-1741 елларда Оренбург буларак төзелә.

[7] Искандаров Р., Искандаров А. Сеитов посад. – Казань: Татар.кн.изд-во, 2005.

китап рәвешендә чыга. Тагын кырык елдан соң исә ул истәлекле язманы Ризаэддин хәзрәт Фәхреддин дә 1903 елда «Исмәгыйль сәяхәте» исеме белән Казанда бастыра. Исмәгыйль каһарман кулында Һиндстан бәк-солтаннарына атап язылган хат-фәлән булгандырмы – әйтә алмыйм. Шул хакта, бәлки, аның сәяхәтнамәсендә берәр төрле хәбәр бардыр.

Шул ук Һиндстанга сәяхәт кылган икенче бер милләттәшебезне дә искә төшереп үтик. Сәүдәгәр һәм дипломат Мөхәммәдйосыф Касыймов Бабур нәселе идарә иткән озын дәвердә Һиндстанга – Агра шәһәренә 1675 елда Россия илчесе буларак та сәяхәт кыла. Аның кулында Бөек Моголлар мәмләкәте шаһы Әүренгазиб исеменә татар телендә язылган хат була. Рус патшасы Алексей Михайлович исеменнән язылган хат. Әмма шаһ Мөхәммәднең үзен кабул итми, кире кайтарып җибәрергә боера. Мөхәммәдйосыф, сәүдә малын тиз арада сатып, Урта Азия ханлыклары аша янә Мәскәү тарафына юлга чыга. Шул вакыйганы тирәнрәк белүчеләр хәбәр итүенчә, бу сәүдәгәр алдына куелган бурычларның иң җитдие – Һиндстанга бару юлларын хәтергә сеңдереп кайтудан гыйбарәт була. Урта Азия илләре буйлап сәяхәт иткәндә, ул байтак кына шымчылык мәгълүматын туплауга ирешә. Хәер, ул якларга юлга чыккан башка кәрванчыларга да махсус шымчылык бурычларының тапшырылган булуы көн кебек ачык. Гомер-гомергә бу шулай булган инде.

Оренбург Чик буе комиссиясе эшчәнлегенең бер юнәлешен чагылдырган тагын бер-ике генә мисалга тукталып үтик. Бу комиссия Төркестан, Һиндстан якларына махсус шымчыларны да даими рәвештә җибәргәләп торган. Орск каласыннан Бохара тарафына озатылган кәрваннарның берсе белән булачак шәкерт рәвешендә Ян Виткевич исемле егет тә бара. Әлбәттә инде, ул татар исемен алган була. Үзе ул Польшада туган. Мөгаен, мөселман динен тотучы чын татар кешесе булгандыр. Россия идарәчелегенә каршы чыккан фетнәдә катнашканлыгы өчен, аны Орскига сөргенгә җибәрәләр. (Бераз соңрак, Польшадагы чираттагы баш күтәрүдән соң, Уральск каласына озатылган берничә мөселман кешесен фабрикант Акчуриннарның үз фабрикаларына соратып алу очрагы да мәгълүм.) Мөселманча дога кыла, намаз укый белгән Ян Виткевич, җирле төрки телне бераз үзләштергәч тә, кәрван белән Ташкент аша Бохара тарафына озатыла. Иленә тизрәк кайтасың килсә – безгә хезмәт ит, дип яллаганнардыр инде аны. Шушы батыр разведчикка багышланган бер китапта аның гүзәл Сәмәрканд шәһәрендә булу вакыйгалары да, Кабул каласына барып җитеп, анда тупланган инглиз армиясе тәртипләре белән танышканлыгы да бәян ителә. Берәр ел чамасы шулай сәяхәт кыл-ганнан соң, ул икенче бер татар кәрваны белән илгә әйләнеп кайта.

Казакъстанда яшәүче тарихчы галим Вил Галиев, «Казан утлары»нда дөнья күргән «Тылмачлар, сәяхәтчеләр, дипломатлар» дип аталган очеркында Һиндстанга сәяхәт кылган тагын берәүне – Гобәйдулла Әмировны да искә ала. Ләкин журналда басылган вариантта ул телгә генә алына, аның кайчан чит илдә булганлыгы тасвирланмый.

Журналда басылган ул хезмәтнең миндә 23 битле кулъязмасы да саклана. Аны мин тәрҗемә итәргә тиеш идем. Әмма эшләп өлгертә алмавымны чамалагач, очеркны башка кешегә тапшырдылар. Ә ул аны бик кыскартып бастырып чыгарды. Кулъязмада исә Г.Әмировның 1805 елдан Чик буе комиссиясендә эшли башлаганлыгы, Һиндстанда шуннан алдагырак елларда булганлыгы әйтелә. Ул байтак еллар элек кайсыдыр төркем белән шул тарафка җибәрелгән дә, шунда кулга алынып, дистә ел чамасы Һиндстанда әсирлек газабын кичергән икән. Аның шул фаҗигале сәяхәткә багышлы истәлек язмасы да сакланган. Нишләптер бездә андый язмалар белән кызыксынучылар юк. Ә рус галимнәре әнә Афанасий Никитинның төркичә-татарча сүзләр дә кушып язган шундый сәяхәтнамәсен, төрлечә төзәткәләп, берничә мәртәбә бастырып чыгардылар инде. Әмировның истәлек язмасын сәяхәтче галим Г.Ф.Генс, берникадәр эшкәртеп, 1825 елда «Азиатский вестник» мәҗмугасының 1нче санында бастырган икән. Ә утыз елдан соң бу кызыклы истәлекне П.Небольсин дигән кеше кабат нәшер иткән. Гобәйдулла Әмиров белән Миндияр Бикчуринның шундый зур сәяхәтләргә багышлы истәлек

язмалары «бүгенге көндә Оренбург архивында Г.Ф.Генс фондында саклана», дип яза Вил Галиев.

Менә тагын бер сәяхәтче һәм, әйтергә кирәк, шул дәвер Россия хөкүмәтенең сәясәтен уздыруга үз өлешен керткән шәхес – Миндияр. Әйе, миндәге кульязмада аның да Чик буе комиссиясендә тылмач сыйфатында эшләгәнлеге, соңрак, бик җаваплы вазифаларны үтәр өчен, Бохара, Үргәнеч тарафларында булганлыгы бәян ителә. Миндияр Бикчуринның шул сәфәрләре, анда ниндирәк йомышларны үтәгәнлеге турындагы үз истәлекләре 1819 елда язылган, ди В.Галиев. Гомер чигендә ул Россиянең шәүкәтле гражданы булып танылa, аңа дворян дәрәҗәсе бирелә. Бер гасырдан соң, 1916 елда Петербургта нәшер ителгән «Восточный сборник» тупламасының 2нче томында аның сәяхәтнамәсе – хисап язмасы басылып чыга. Безнең журнал вариантындагы язмада бу хәбәр дә никтер теркәлмәгән иде. Шушы Миндиярның улы булган «тылмач морза» Мирсалих Бикчуринны да искә алып китик. Ул Оренбургта хәрби мәктәп – кадет корпусын тәмамлаган һәм байтак еллар шунда укыткан «мишәр генерал»ларның берсе санала. Гарәп, фарсы, төрки телләр кулланышына багышланган берничә гыйльми хезмәт язганлыгы да мәгълүм. Аны да төрле вакытта Урта Азия ханлыкларына җитди йомышлар үтәр өчен җибәргәләгәннәр. Генерал дәрәҗәсе аңа шул хезмәтләрен дә истә тотып бирелгән була.

Аның бай китапханәсе белән танышу өчендерме, башка сәбәп беләнме, Галимҗан Ибраһимовның шул морза өенә килеп йөргәнлеге үз истәлекләрендә теркәлгән. Дөрес, Совет хакимияте чорында язылган биографиясендә ул: «Вәлия»дә укыганда, генералның кучеры булдым», дип кенә теркәгән. Иртә яздан кара көзгәчә үз авылында барлык хуҗалык эшләрен башкарышуда катнашкан шәкертнең кай арада Бикчурин морзада кучер вазифасын үтәгәнлеген ачыклаучы юк әлегә.

Вил Галиев хезмәтендә ике татар кешесенең (берсе Казаннан ук икән) бик тә серле Тибет иленә сәяхәт кылганлыгы да искә алынган.Тылмач Мөхәррәм Габдерәшитов белән Сәефсаттар Сәйфелмөлеков 1814 елда башкаладан килгән Рафаилов фамилияле галим белән Кашгар каласына дип юлга чыгалар. Озатып баручылар рәвешендә. Җитәкчеләре сәяхәт барышында авырып вафат була. Мәгәр юлдашларына билгеләнгән җиргә барып җитү, йөкләнгән бурычны үтәп кайту кирәклеген аңлатып үлә ул. Бу татарлар ул кушканны үтиләр. Тибеттан кайткач та, күргән-белгәннәрен язып калдыралар. Соңрак ул язманы сәяхәтче казакъ галиме Чокан Вәлиханов үз хезмәтләре белән бергә нәшер итә, дип яза В.Галиев. (Ул язма Ч.Вәлихановның сайланма хезмәтләренең 1964 елгы 3нче томына кергән.) Үземнән шуны да өстәп куясым килә: язучы Сабит Моканов Ч.Вәлихановка багышланган ике томлык романында, Омск шәһәренең атаклы татар мулласы һәм мәдрәсә башлыгы рәвешендә, әлеге Сәйфелмөлековны тасвирлый. Мәдрәсәдә укыганда, Чокан шул мулла гаиләсендә торган, дип хәбәр итә. Ханнар нәселеннән чыккан бу шәкерт белән яшүсмер кызының күз сирпеп алышуларын күргәләгән мулланың Чоканны кияү рәвешендә кабул итәргә әзер булганлыгын да яза бу әдип.

**4**

Сәяхәтләрдә күп йөрдек. Инде мөфтиләребез белән якыннанрак танышыйк. Кемнәр булган соң алар, зур бер империя башлыклары фәрманы белән Россиядәге мөселман өммәте вәкилләре язмышын хәл итәргә алынган зур дәрәҗәле түрәләр? Шуларны ачыкларга тырышып карыйк. Дөрес, аларның барысының да диярлек тумышы, укымышлылыгы, эш-гамәлләре турында Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләренең «Мөстәфадел-әхбар...» китабында берникадәр язылган инде, диючеләр дә булыр. Әммә патшалар чоры мөфтиләрен бик күпләребезнең ишетмәгәнлеге, белмәгәнлеге турында көндәлек матбугат битләрендә чыккан язмалардан күреп торабыз ич. Шиһабетдин хәзрәт китабына кермәгән кызыклы гына мәгълүматлар да ул мөфтиләр биографиясендә бар. Әйтик, ул чор мөфтиләренең патша җәнапларын тәхеткә раслау (инаугурация) вакыйгаларында катнашу-катнашмавы анда теркәлмәгән.

«Алар рус патшасы яраннары булган погонлы офицерлар», дигән рәвешле

язмаларга да тап булгаларга туры килгәли. Дөрес, элек погон йөрткән дәүләт вәкилләре дә булган алар арасында. Әмма мөфти вазифасын үтәргә билгеләгәндә, инде аларның элекке чор хезмәтләренә басым ясамаска кирәктер. Элек ниндирәк вазифалар үтәгән булуларына карамастан, алар барысы да дини кардәшләре алдында үзләренә йөкләнгән бурычларын җиренә җиткереп үтәргә тырышкан чын дин әһелләре булганнар. Шиһабетдин хәзрәт билгеләп үткәнчә, иң әүвәл алар чын мөселман өммәте кешеләре булып калганнар. Хәтта мөселманлык, милли җанлылык мәсьәләсендә күпләрдән өстен торган, полковник дәрәҗәсендәге морза Шаһимәрдән Ибраһимовны, мөфтилеккә тәкъдим ителү нияте барлыгын белгәч, Ильминский ише кара фикерле кешеләрнең, «ул бигрәк милли җанлы», дип, башкала түрәләренә әләк хатлары язганлыгы да мәгълүм.

Патша чоры генералы Котлыгмөхәммәд Тәфкилев тә, кайбер галимнәребез аны «чукынган Тәфкилев» буларак сыйфатларга тырышсалар да, эш-гамәлләре белән эшлекле татар буларак күзаллана. Күп кенә рәсми документларда аның исем-атамасын русчалап теркәүләренә карамастан, ул беркайчан да үз диненнән ваз кичмәгән. Әйе, Россия тарихының аерым вакыйгаларын тасвирлаган кайбер чыганакларда аның «Алексей Иванович Мамышев» (атасы бит Мәмәш морза) буларак теркәлгән очраклары билгеле. Ләкин ул – рәсми рәвештә үз диненә хыянәт итмәгән олуг затларың берседер. Шиһабетдин хәзрәт тә бит әнә: «Котлыгмөхәммәд морзаның имамы, Оренбург имамнарының иң элеккегесе Ибраһим бине Түләк мулла иде», дип яза. Аның «Бохара казый вә мөфтиләренеке кебек зур мөһеренә «Ибраһим бине Мөхәммәд Түләк әл-мөфти», дип язылган була», ди.

Котлыгмөхәммәд генералның соңгы гомер иткән җире – хәзерге Әгерҗе районындагы Тирсә белән Мордыбай исемле татар авыллары. Аларның утары шушы ике авыл арасындарак була бугай. Шуннан ерак түгел бер Барҗы авылы янында аларның бакыр кою заводы тотканлыклары да тарихта теркәлгән. Тирсә зиратында аның кабере өстенә куелган затлы хәтер ташының 1920 еллар ахырынача саклангапнлыгы да мәгълүм. Бер әңгәмә вакытында шул хакта Равил Үтәбай-Кәрими дә искә алган иде. «Аның төрбәсе һәм кабер ташы үз авылларының берсендә төзелгән бер бина нигезенә салынган икән дип сөйләүчеләр бар», дигән иде ул. Ә 2008 елда нәшер ителгән «Әгерҗе төбәгенең ташъязма истәлекләре» китабының 112 битендә әлеге генерал кабере өстенә куелган истәлек ташы һәм андагы мөселманча язма тексты тасвирламасы китерелә. Бу китапны туплап чыгаручы галимнәр – Раиф Мәрданов белән Ирек Һадиев. Генерал кабере өстендәге истәлек ташындагы язманы алар «Шура» журналының 1915 елгы бер саныннан күчереп алганлыкларын хәбәр итәләр. Риза Фәхреддиновка ул истәлек ташы сурәтен һәм язмасын Мордыбай авылы мулласы күчереп язып җибәргән була.

Бу Тәфкилевләр нәселенең үз халкына карата кылган уңай гамәлләренең барланмавы сәбәпле генә, кайберәүләр аны шулай «чукындырып» күзалларга тырышадыр, мөгаен. Шул «усал» генерал оныгы Сәлимгәрәйнең Бөтенроссия күләмендәге дүртенче мөфти булганлыгын исә күпләребез белмидер дә әле. Соңгы Бөек Ватан сугышы дәверендә язылган байтак кына рәсми документларда да бит әнә бик күп милләттәшләребезнең исем-атамасы русчалатып теркәлгән. Шул язуларга нигезләнеп кенә без ул кешеләрне – үз ата-бабаларыбызны чукынганнар рәтенә кертә алмыйбыз ич.

Дөрес, бу генералның патшалар дәүләтенә җаны-тәне белән бирелеп хезмәт иткәнлеген һич тә инкяр итәргә җыенмыйм. Хәрби кеше буларак, ул кайвакытларда артыграк та тырышлык кылгалагандыр. Мәсәлән, Ор елгасы Уралга койган урында булачак губернаның башкаласын – Оренбург шәһәрен төзүгә керешкән чорда, ул шул төзелешне сакларга тиешле атлы гаскәр башлыгы итеп билгеләнә. Ә рус хәрбие җитәкчелегендәге унбиш ротадан торган җәяүле сугышчылар исә төзелеш эшләрен башкарганнар. Полковник Тәфкилев җитәкчелегендәге өч йөз илле кешеле һәм бер туплы атлы гаскәр сагындагы бу отряд Уфадан кузгалуга ук, аңа төрле яклап һөҗүм итүләр башлана. Соңрак Орск исеме белән аталачак Ор елгасы тамагындагы каланы төзи башлагач та, аңа төрле тарафтан һөҗүм итеп торулар тукталмый.


*Мөфти Сәлимгәрәй Тәфкилев*

Чөнки ул кала бу тирәләрдә ирекле күчеп йөрүче башкортлар өчен дә, елга аръягында урнашкан казакъ күчмәннәре өчен дә кирәкмәс киртә буларак кабул ителгән. Тәфкилев отрядына исә әнә шул күчмәннәр һөҗүменнән саклану бурычы йөкләнгән була. Ул отряд һөҗүм итүчеләрне даими рәвештә эзәрлекләп торырга мәҗбүр итеӘ. Кала төзелешенә бәйле истәлекләрдә бу полковникның булачак кала уртасындагы үр башына биек каланча төзеп, бер тупны шул каланча башына менгертеп куюы да телгә алына. Әле ХХ йөз урталарында да кайчандыр әлеге каланча урнаштырылган үр Орск халкы телендә «Полковник тавы» дип аталып йөртелә иде. Бу ике күрше халыклар телендә булачак шәһәргә тагылган «Җаман кала» исеме дә ХХ йөз башларынача сакланган була. Орскида туган күренекле артист Хәким ага Сәлимҗанов та истәлек китапларында үзен шул «Җаман кала» кешесе буларак таный.

* * *

Яңа губерна белән җитәкчелек итәргә 1740 елда билгеләнгән булачак тарихчы В.Н.Татищевка губерна башкаласының Ор елгасы тамагындагы урынга сайлануы ошамый. Россия үзәгеннән бик еракта һәм дошмани көчләр уралышында урнашкан дип, шәһәр төзелешен ул өч йөз чакрымга көнбатышкарак күчертә. Шулай итеп, урыннан-урынга күчерелә-күчерелә, хәзерге Оренбург каласына нигез салына. Полковник Тәфкилев тә үз атлы казаклары белән яңа, тынычрак урынга күчә. Һәм монда аны яңа губернатор И.И.Неплюев үз ярдәмчеләренең берсе итеп билгели. Россия чигенең аргы ягында яшәүче төрки кавемнәр телләрен белүче кеше буларак, аны тиздән әлеге Чик буе комиссиясе эшенә дә җәлеп итәләр.

Оренбург губернасын оештыру чорындагы эшчәнлеген истә тотып, генерал Тәфкилевкә монда байтак җир биләмәләре бүлеп бирелә. Шуларга Әгерҗе, Малмыж кебек уңдырышсыз җирле, ярлы төбәкләрдән байтак кына ярлы крәстияннар күчереп утыртыла. Тәфкилевләрнең бер биләмәсе, ике мең дисәтинәдән артыграк чәчү җирлеге, Оренбург белән хәзерге Каргалы аралыгында урнашкан була. Бу морзалар шул җир биләмәсеннән килгән табышның бер өлешен даими рәвештә Каргалы авылы мәчетләрен һәм мәктәп-мәдрәсәләрен яшәтү өчен тотканнар. ХХ гасыр башында әлеге иркен җир биләмәсен сәүдәгәр Мәхмүт бай Хөсәеневкә сатканда да, шул тәртипнең саклануын төп шарт итеп куйганнар. 1910 елда Мәхмүт бай вафат булганнан соң, аның варислары тарафыннан ул шарт төгәл үтәлми башлый. Шул хакта бер Каргалы мәчете имамының «Вакыт» газетасы редакциясенә юлланган хаты булуы мәгълүм. Ул хат 1913 елда Оренбургта нәшер ителгән «Гани бай» китабына да кергән. Ә ул китапны төзеп, туплап чыгаручы кеше – «Вакыт» мөхәрриренең беренче урынбасары Борһан Шәрәф була.

**Лирон ХӘМИДУЛЛИН,**
*Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты*

*(Ахыры киләсе санда)*

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ КОРЫЛТАЕ

Казанда, Бөтендөнья татар конгрессының чираттагы VI корылтае булып узды. Анда 1000нән артык кеше, шул исәптән 41 чит илдән, Россиянең 73 төбәгеннән сайланган 800дән артык делегат, 200ләп кунак һәм шушы вакыйганы яктыртырга алынган 100ләп журналист катнашты.

Беренче көнне «Татар рухы: тел һәм мирас», «Татар эшмәкәрлеге һәм иганәчелек», «Гаилә: демография, милли тәрбия», «Татар мөһаҗирлеге музее һәм татар халкының портрет галереясе» дигән темаларга секция утырышлары, бәхәс клублары, «түгәрәк өстәл»ләр оештырылды. Корылтайның пленар утырышы М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында узды. Шушында ук рәссамнар һәм дизайнерлар тарафыннан эшләнгән милли татар киемнәре күргәзмәсен дә карарга була иде. Әүвәл залда Россия Федерациясе Президенты Владимир Путинның корылтай делегатларына котлавы яңгырады. РФ Тышкы эшләр министрлыгының Ватандашлар департаменты директоры О.Мальгинов РФ тышкы эшләр министры Сергей Лавров котлавын укыды. Делегатларга чит төбәкләрдән килгән котлаулар да ирештерелде.

Корылтайда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясады. Ул бүгенге вазгыятьтә Бөтендөнья татар конгрессы эшчәнлегенең әһәмиятен ассызыклады, телне, милләтне саклап калу максатында халкыбыз алдында торган бурычларга тукталды. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров соңгы биш елда башкарылган эшләр турында хисап доклады белән чыкты. Конгресс тарафыннан тотылган чыгымнар турында докладны контроль-ревизия комитеты рәисе, Әстерхан өлкәсе татарларының милли-мәдәни мохтәрияте башлыгы Ә.Алмаев ясады. Аннары сүз ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевкә бирелде. Ул Конгрессның татарларны берләштерү максатында 25 ел буена алып барган эшчәнлеген югары бәяләде, ТР белән РФ арасындагы вәкаләтләрне бүлешү турындагы Шартнамәнең әһәмияте һәм үзенчәлеге турында сөйләде. Корылтайда Кырым Республикасының Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Рәмзи Ильясов, РФ Дәүләт Думасының милләтләр эшләре комитеты рәисе, Федераль милли-мәдәни мохтәриятләр советы рәисе Илдар Гыйльметдинов, ТР мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов, академиклар Рәшит Сүнәев, Роберт Нигъмәтуллин, Казандагы 2нче татар гимназиясе директоры Камәрия Хәмидуллина, корылтай делегатлары Фәрит Гыйбатдинов, (Чувашстан), Венера Вагыйзова белән Ильяс Ямбаев (Германия), Ирек Сабиров (Чиләбе), Туран Апакай (АКШ), Марат Шәрипов (Башкортстан), Мөнир Ерзин (Казакъстан), Регина Вәлиева (Бельгия) h.б. чыгыш ясады. Корылтайның беренче көнендә эшләгән секцияләр белән җитәкчелек иткән Дания Заһидуллина, Искәндәр Гыйләҗев, Камил Әбләзов, Разил Вәлиевләр дә делегатлар алдында хисап тотты.

Пленар утырышта Бөтендөнья татар конгрессының VI съезды резолюциясе, корылтай делегатларының татар халкына мөрәҗәгате кабул ителде, Бөтендөнья татар конгрессының Уставына үзгәрешләр кертелде. Милли шура сайланды. ТР Премьер-министры урынбасары Васил Шәйхразиев – Шураның рәисе, Ринат Закиров – аның беренче урынбасары, Илдар Гыйльметдинов, Камил Әбләзов, Тәүфыйк Кәримов, Дания Заһидуллина урынбасарлары итеп тәгаенләнде.

Пленар утырышны ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин алып барды.

## ТАНТАНА

Казанда Зөя утрау-шәһәрчегенең Успение соборы һәм монастырен ЮНЕСКО Бөтендөнья мирас исемлегенә кертү турында сертификат тапшыру тантанасы узды. Чарада ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, ЮНЕСКО генераль директоры Ирина Бокова, ТР Дәүләт Киңәшчесе, тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызу буенча «Яңарыш» республика фонды попечительләр советы рәисе Минтимер Шәймиев, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин h.б. рәсми затлар катнашты.

Тантанада И.Бокова Р.Миңнехановка махсус сертификат тапшырды. Татарстан хөкүмәте исеменнән рәхмәт сүзләре җиткереп, Президент Ирина Бокованы «Дуслык» ордены белән бүләкләде.

И.Бокова тәкъдиме белән, Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев ЮНЕСКОның мәдәниятләр арасында диалог буенча махсус киңәшчесе итеп билгеләнде.

## АВГУСТ КИҢӘШМӘСЕ

Республика мәгариф һәм фән хезмәткәрләренең август киңәшмәсе булып узды. Укытучылар Алабуга, Яшел Үзән һәм Иннополиста үткәрелгән җыелышларда фикер алышты. Пленар утырыш Мөслимдә узды. Анда ТР мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов доклад белән чыкты. Министр төп игътибарны милли мәгарифне үстерүгә юнәлдерде, шәһәрләрдә туган телне саклап калу һәм үстерү максатында җитәкчеләрнең җаваплылыгын арттыру, милли мәктәпләр, туган телдә белем бирүче балалар бакчаларының эшчәнлеген даими тикшереп тору мәсьәләләрен күтәрде. Пленар утырышта Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясады. Ул мәгарифнең республика үсешендә өстенлекле тармак булуын әйтте, милли белем һәм тәрбия бирүдә республикабыз мәгариф хезмәткәрләре алдында яңа бурычлар куйды, республикабызның фәнни потенциалын үстерүдә кайбер мөмкинлекләрнең кулдан ычкындырылуын, аерым алганда югары уку йортлары ректорларының имтиханнарда югары нәтиҗәләр күрсәткән абитуриентларның язмышы белән якыннан кызыксынмауларын тәнкыйтьләде.

Киңәшмә алдыннан ТР Президенты республика мәктәпләренә 54 «Ларгус» автомобиле, 14 автобус тапшырды.

## ЯҢА ТАТАР МӘДӘНИ ҮЗӘГЕ

Мәскәүдә Татарстан мәдәнияте көннәре булып узды. Бу чарада ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты. Ул Россия башкаласында яңа Татар мәдәни үзәге урнашачак бинаны карады, аны реконструкцияләү планы белән танышты. Бу – Мәскәүнең Көнчыгыш административ округындагы Вешняки районында урнашкан, 1977 елда төзелгән «Энтузиаст» кинотеатры.

## РӨСТӘМ ЯХИНГА – ҺӘЙКӘЛ

Татарстан башкаласының Зур Кызыл урамында, Казан дәүләт консерваториясе каршында СССРның халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан Республикасы гимны авторы Рөстәм Яхинга һәйкәл (авторлары – Асия Миңнуллина, Андрей Балашов) ачылды. Аны ачу тантанасында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Казан мэры Илсур Метшин, Россия һәм Татарстан Композиторлар берлекләре рәисе Рәшит Кәлимуллин катнашты.

## ИСКӘ АЛУ МӘРӘСИМЕ

Казандагы 1 Май мәйданында моннан 73 ел элек фашист төрмәсендә җәзалап үтерелгән Муса Җәлил һәм җәлилчеләрне искә алу мәрәсиме булды. Анда ТР мәдәният министры урынбасары Гүзәл Шәрәпова, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов чыгыш ясады.

Муса Җәлил, Гайнан Кормаш, Абдулла Алиш, Фуат Сәйфелмөлеков, Фуат Булатов, Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Абдулла Батталов, Зиннәт Хәсәнов, Әхәт Атнашев, Сәлим Бохаров – менә алар татарның бөек уллары. Митингта һәркайсының исеме мәйданда батырлык символы булып яңгырады. Һәркайсы турында мәгълүмат-белешмә бирелде. Искә алу мәрәсимендә Татарстанның халык шагыйрьләре Ренат Харис, Разил Вәлиев, шагыйрь Газинур Морат үзләренең шигырьләрен укыдылар. Митингта нәфис сүз Татарстанның халык артисты Римма Ибраһимова, Татарстанның атказанган артисты Айдар Нургаянов башкаруында патриотик җырлар белән үрелеп барды. Искә алу мәрәсимендә М.Җәлилнең кызы Чулпан ханым катнашты һәм чыгыш ясады.

## БҮЛӘККӘ – ТЕЛЕВИЗОР

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятендә газета-журналларга язылуда активлык күрсәткән әбунәчеләр арасында бүләкләр уйнатылды. Әлеге акциядә 161 кеше катнашты, 605 квитанция кабул ителде. Иң күп укыла торган газета-журналлар исемлегендә «Казан утлары» да бар. Бүләкләрнең иң зурысы – телевизорга Башкортстаннан Илдус Фазлетдинов ия булды. Өч фотоаппаратның икесе Әгерҗе һәм Әлки районнарына китте, берсе Казанда калды. Бүләкләнүчеләр арасында Минзәлә, Нурлат, Балык Бистәсе, Арча һ.б. районнар әбунәчеләре дә бар.

## ФӘЙЗУЛЛИН ЙӨЗҮЛӘРЕ

Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин тарафыннан 40 елга якын оештырыла, дистәләрчә язучылар, журналистлар, сәнгатькәрләр катнашында уза, әһле каләм ияләре арасында «Фәйзуллин йөзүләре» дип йөртелә торган традицион бәйге булды. Быел ярышлар Яшел Үзән районының Олы Чишмә (Большие Ключи) авылы янындагы күлдә кыска һәм озын дистанцияләрдә оештырылды. Йөзүдә 30лап, гомумән, әлеге мәдәният һәм спорт бәйрәмендә 100гә якын  кеше катнашты. Бәйге Бөтендөнья татар конгрессының VI корылтае алдыннан үткәрелгәнгә күрә, алар арасында делегатларны, шул исәптән Казакъстанның һәм Татарстанның халык рәссамы, академик Камил Муллашев, сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, тугызынчы дистәсен ваклаучы Фәндәс Сафиуллин кебек шәхесләрне дә күрергә була иде. Быел да Равил Фәйзуллин улы Газиз белән финишка беренче килде. Икенче урында – шагыйрә Илсөяр Иксанова.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: повести Н.ГИМАТДИНОВОЙ «Ульмес»; А.ХАМЗИНА «Можно сказать, что...», Р.ЗАКИРОВА «Моряк без парусов»; стихи Р.РАХМАН, Д.ХАЙРУЛЛИНА, А.ЮНУСОВОЙ, А.СИТДИКОВОЙ.*
*«Лучший рассказ»: С.ЯКУПОВА. «Уран».*
*«100-я страница»: Р.ЛАТЫПОВА. «Родной язык начинается с «Азбуки».*
*«Из литературы родственных народов»: стихи М.МАКАТАЕВА, с предисловием Р.МИННУЛЛИНА.*
*«130 лет со дня рождения Карима Тинчурина»: М.АРСЛАНОВ. «Самоотверженность».*
*«Наши юбиляры»: З.МУХАМЕТШИН. «Творческие особенности прозы Рифы Рахман».*
*«Литературная критика»: статья Т.ГАЛИУЛЛИНА о творчестве поэта Р.АЙМЕТА.*
*«История»: Л.ХАМИДУЛЛИН. «Родина первых муфтиев».*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: «Осень». Картина Айрата Гайфуллина;*
*Чистополь. Литературный причал.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novels by N.GIMATDINOVA «Ulmes»; A.KHAMZIN «We could say that...», R.ZAKIROV «Sailor without sails»; poems by R.RAHMAN, D.KHAIRULLIN, A.YUNUSOVA, A.SITDIKOVA.*
*«The best story»: S.YAKUPOV. «Uranus».*
*«100th page»: R.LATYPOVA. «Mother tongue begins with «ABC».*
*«From the literature of kindred peoples»: poems by M.MAKATAEV with a foreword by R.MINNULLIN.*
*«130th anniversary of Karim Tinchurin»: M.ARSLANOV. «Dedication».*
*«Our jubilees»: Z.MUKHAMETSHIN. «The creative features of the prose by Rifa Rahman».*
*«Literary criticism»: article by T.GALIULLIN about the work of the poet R.AMETA.*
*«History»: L.KHAMIDULLIN. «Homeland of the first muftis».*
*From the photo archive of the magazine.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: «Autumn». Painting by Ayrat Gayfullin;*
*Chistopol. Literary pier.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Көз». *Айрат Гайфуллин картинасы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Чистай. Әдәби причал.